# Казан утлары

11.1989



# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫННАН ФОТОРЕПОРТАЖ

(Дәвамы 190—191 битләрдә)




*КПСС Үзәк Комитеты секретаре Г. Усманов һәм РСФСР Язучылар Союзы председателе С. Михалков.*



*Съезд залында.*



*Т. Миңнуллин һәм М. Маликова.*



*Ә. Еники һәм Н. Арсланов.*



*Ш. Бикчурин һәм Х. Камалов.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

11

(805)

КПСС-ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ


Ә. ГАФФАР. **Олы юлның тузаны.** *Роман* . . . 3
Р. ФӘИЗУЛЛИН. **Яңа шигырьләр** . . . . . 39
З. ФӘТХЕТДИНОВ. **Үлем элмәге.** *Роман* . . . 47
Р. НИЗАМИЕВ. **Кем баласы?** *Шигырьләр* . . . 110
К. БУЛАТОВА. **Бер җәйге көн миңа бирегез сез.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . 115
Ф. ЛАТЫЙФ. **Аяклы Каза.** *Хикәя* . . . . . . 117


М. СЕСПЕЛЬНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ


Ю. СЕМЕНДЕР. **Яңа чор җырчысы** . . . . . 125
М. СЕСПЕЛЬ. **Шигырьләр** . . . . . . . . 125


ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫ


Ә. ЕНИКИ. **Хәерле сәгатьтә** . . . . . . . . 127
Т. МИҢНУЛЛИН. **Каләмебез, сүзебезне эшкә җигик!** . . . . . . . . . . . . . . 128
Р. ХАРИС. **Әйтәсе сүзебез соңгармасын** . . . 133
Ф. МИҢНУЛЛИН. **Кичермәсләр безне, кичермәсләр** . . . . . . . . . . . . . . 135
Т. ГАЛИУЛЛИН. **Шигърияттә — халык язмышы** . . . . . . . . . . . . . . 143
Ә. ӘХМӘДУЛЛИН. **Дөреслеккә ирешү юлында** 149
Г. КАШАПОВ. **Тешебез үтәме?** . . . . . . 153
Р. МИҢНУЛЛИН. **Балалар әдәбияты ни хәлдә?** 155
Н. ФӘТТАХ. **Гаделлек — нигез булсын** . . . 160
М. СКОРОХОДОВ. **Рус язучыларының иҗаты** 162
С. ШӘМСИ. **Яшәү даирәбезне киңәйтик!** . . 163
**Татарстан язучыларының XI съезды резолюциясе** . . . . . . . . . . . . . . . . 166


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. **Дөреслек каян башлана?** 168


МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА


Ф. ИБРАҺИМОВ. **Әле дә күңел түрендә** . . . 170
И. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. **Ялкынлы ел авазы** . . 173


ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ


Р. ГЫЙЛӘҖЕВ. **Быргы** . . . . . . . . . . 178

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

**Өченче дәрес** . . . . . . . . . . . . . . . 181

**Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре** . . . . . . . . . . . . . . 184

КОТЛЫЙБЫЗ

**Ш. Рәкыйповка 60 яшь** . . . . . . . . . . 185
**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары** . . . . . . . . . . 185
**Мәдәният тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 187
**Татарстан язучыларының XI съездыннан фоторепортаж** . . . . . . . . . . . . . 190
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС
*Редколлегия*
ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа А. ГАФФАРА «Пыль большой дороги». Окончание романа З. ФАТКУДИНОВА «Петля смерти». Рассказ Ф. ЛАТЫФА «Обуза». Новые стихи Р. ФАИЗУЛЛИНА, Р. НИЗАМИЕВА, К. БУЛАТОВОЙ.
В номере отмечается 90-летие со дня рождения чувашского поэта М. СЕСПЕЛЯ.
Материалы XI съезда писателей Татарии: Вступительное слово А. ЕНИКИ, доклады Т. МИННУЛИНА, Р. ХАРИСА, Ф. МИННУЛЛИНА, Т. ГАЛИУЛЛИНА, А. АХМАДУЛЛИНА, Г. КАШАПОВА, Р. МИННУЛИНА, Н. ФАТТАХА, М. СКОРОХОДОВА, С. ШАМСИ. Резолюция съезда писателей Татарии.
Реплика Р. ТУХФАТУЛЛИНА «С чего начинается правда».
«К истории культуры»: статьи Ф. ИБРАГИМОВА «Память не стареет»; И. ГИЗЗАТУЛЛИНА «Голос пламенных лет».
«Татарские народные музыкальные инструменты»: Р. ГИЛЯЗОВ. Гори. Уроки татарского языка.
Навыки чтения на основе арабской графики.
В номере отмечается 60-летие Ш. РАКИПОВА, представлены новые члены Союза писателей СССР.
На наших обложках — современный татарский гобелен. Творчество М. КИЛЬДЕБЕКОВОЙ. Виды Казани. XIX век. Булак. Фоторепродукция старинной открытки.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова

Производствога бирелде 05.09.1989 ел. Басарга кул куелды 26.10.1989 ел. ПФ 05333. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 77049. Заказ Б-389. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

С «Казан утлары», 1989 ел.

**Әхәт Гаффар**

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ ТУЗАНЫ

РОМАН

*Perdidit antiguum litera prima sonum*
*Беренче хәреф үз мәгънәсен югалтты.*
Латинчадан

*Мне возмездие и аз воздам.*
Евангелие.

*Кылганнары өчен әҗере бирелер.*
Коръән (7:179).

*Үлемнән соң да яшәү бар бит әле.*
Муса Җәлил.

**Беренче кисәк**

## Җир астына

### 1

*Сандугач бишенче төн оча инде. Алдагы көнне ул үзенең юлдашлары белән диңгез буендагы кыялар ышыклаган эссе иңкүлектә ял итте. Һәр яктан куркыныч янады. Күк гөмбәзеннән лачыннар югалып тормады. Кошлар арасыннан берәр корбан эләктерсәләр, ярдан ерак булмаган текә кыялы ялангач утраучыкка кунып ашыйлар. Җирдә исә сандугачларны еланнар сагалый иде.*

*Алар айсыз, ләкин күкле төнне ярып, Крит дигән утрау юнәлешендә очалар. Анда кыска гына вакытка тукталыш ясыйсылары, тукланып та тормастан, яңадан юлга чыгасылары бар. Ул утрауга кадәр озак очасы. Төне буена һәм көннең байтак өлешен һавада үткәрергә туры киләчәк. Ара ерак, юл авыр. Кайбер кошлар барып та җитмәс. Тик алар моны белмиләр әле. Бар ышанычлары — канатларында. Юлга кузгалганчы, алар үз канатларын ныгыттылар.*

*Сандугачның үзе дөньяга килгән туган ягына беренче тапкыр*

---

Әхәт ГАФФАР *(1949) — татар һәм рус телләрендә чыккан унбер китап авторы. Республика театрларында дистәгә якын пьесасы сәхнәләштерелде. Казанда яши.*

*әйләнеп кайтышы. Ул анда очарга, үзе яшәгән тирәлекне танырга өйрәнгән, әмма бер тапкыр да сайрап карамаган иде әле. Юлдашлары да нәкъ шулай. Сандугачларның бу төркемендә яшь тә тулмаган бала кошлар гына. Һәммәсе дә ана кошлар. Алар юлга үзләренең булачак парларыннан соң җыйналып кузгалды. Булачак парлары юлга аларга караганда алданрак чыгып китте. Иң соңыннан аларны дөньяга китергән әлеккеге әти-әниләре очачак. Гомер-гомердән килгән гадәтләре шундый. Хәер, хәзер инде алар да юлдадыр. Туган җирләрендә аларны куныл сайрар таллары, туй җырлары, куаклар арасында бер-берсе белән кавышасы аулак урыннары, оя кору мәшәкатьләре һәм бала чыгару, аларны үстерү, очарга өйрәтү авырлыклары көтә.*

*Йолдызлы биек күк йөзе сандугачның күзенә ачыклык, җанына тынычлык, ә төнге киңлек канатларына ышаныч, көч бирә иде.*

*Ләкин төн урталары тирәсендә ул һәркайсы үз алдына тезелешеп очкан кошлар көтүеннән аерыла язды. Ачык диңгез өстендә каршы яктан килгән давылга очрадылар. Кошларны шундук калын болытлар һәм куе караңгылык чорнап алды. Аста диңгез чайкала, дулкыннар дулаша, шаулап ишелеп төшә. Йолдызларны тыгыз болытлар капладьы. Караңгылыкны күз чагылдыргыч яшеннәр телгәләде, озын-озак итеп күкләр күкрәде. Болытлар арасында сандугач кайчакны иптәшләрен шәйләп алгалады. Яшен балкышлары кошларны ал, зәңгәр, шәмәхә төсләргә манчый иде. Балкышлар сүнгән мәлдә алар үзләренең кулагәләре сыман каралып калалар да күздән югалалар. Ә кайберләре түбән төшеп китәләр, һәм аларны дулкыннар йота.*

*Көчле, дымсу һава агымнары сандугачны әледән-әле артка алып ташлады. Тик бу аның күңелен төшермәде, җанына курку иңдермәде. Ярсу җил арттан иссә, кушкә начаррак, хәвефлерәк булыр иде.*

*Йолдызлар күмелгән чакта кошлар тәннәре белән сизенгән магнит дулкыннарын тоеп очалар иде. Давылга исә ул дулкыннар соң чиккәчә тартылып киерелгән кебек була. Шуннан соң магнит дулкыннарын тою авырая, алар җәя бауларыдай кинәт ычкынып китәләр дә сандугачларның эчке ритмы тотып аламастай хәлдә калтыранып тора башлыйлар, таркалалар, чуалышалар. Менә шунда кошлар үзләренең очу юнәлешләрен югалта, буталыша, таркала. Чөнки аларның һәркайсы магнит дулкыннарын фәкать үз йөрәкләре тибеше белән яраклаштыра, шуның аркасында куркуга бирелмәскә, үзләрен алга әйдәгән чакыруга бирелмәскә, үзләрен алга әйдәгән чакыруны югалтмаска тырыша иде. Төннәрен ай белән йолдызлар күренмәгәндә, көндезләрен кояш хәрәкәте сизелмәгәндә кошларны әнә шул соңгы ышанычлары — магнит дулкыннары алга әйди дә инде.*

*Сандугач, соңгы маягыннан тайчынмас өчен, бер һава агымыннан икенчесенә күчә-күчә, төрле якка талпынып оча башлады: әле өскә күтәрелде, әле аска ташланды. Канат кагышлары белән йөрәк тибешләре чуалды, бер-берсен тыңлый алмас хәлгә килде. Йолдызлар юклыгы һәм әйдәүче магнит дулкыннарының бозылуы юнәлешне дөрес тотарга комачаулый иде. Күздән югалган иптәшләрен чакырып һәм аларның үзенә дәшүләренә җавап итеп, ул әледән-әле тавыш биргәләп барды. Болытлар эчендә кошлар бер-берсенең тавышын яхшы ишетә. Сандугачның адашып калудан куркуы шулкадәр дә көчле иде ки, бу тикле курку аңа төп юнәлештән бер чеметем дә читкә тайпылмаска ярдәм итте. Моңа өстәп, адашмас өчен аның тагын чарасы бар иде әле. Анасы һәм атасының сайрауларыннан аңа тагын бер сизгерлек иңеп калган: ул очышын үз тавышының аста ишелеп-ишелеп каккан дулкыннардан кире кайтарылган кайтавазына көйләп алып бара ала. Кайтаваз аңа юнәлешне дулкын түбәләренә карата тиешле якка җайларга булыша.*

*Киеренкелек сандугачның бөтен тәнен калтыратты. Ә күңелендә салават күпередәй төрледән-төрле төсләр белән балкыган чәчәкләр.*

*аларның хуш исләре һәм таныш тавышлар яңарды. Боларның һәммәсе аны үзен көткән тугайларга, су буйларына таба тыелгысыз төстә чакырып тора сыман иде.*

*Көтмәгәндә каршы якта колак тондыргыч гөрелте ишетелде. Сандугач юлдашларына тагын чакыру авазы салды. Әмма бу юлы үз тавышының дулкыннардан кайтарылган кайтавазын тоймады. Аны канатларын хәлсез иткән куркү хисе биләп алды. Каршы җил китереп бәргән ачы төтен сулышын кисте. Аңа бу гөрелтенең һәм төтеннең чыганагы яхшы билгеле. Озын һәм очлы томшыклы, хәрәкәтсез каткан канатлы һәм ут койрыклы тимер кошлар шулай саңгыраулатып гөрелди, күңел болгаткыч исе белән тынны буа. Гадәттә, сандугачлар, бу тимер кош күренүгә, лачыннан өреккән шикелле, төрлесе төрле якка качалар иде. Тимер кош — кыска муенлы, ерткыч кошларныкы кебек үк. Озын муенлы зарарсыз кошларныкыннан әллә каян аерылып тора.*

*Каршыдан килгән тимер кошның күзләреннән бәреп торган нур көлтәләре болытларны тишеп чыкты да сандугачны бераз вакытка сукырайтып калдырды. Иләмсез тимер кош туп-туры аңа таба очып килә иде. Сандугач нишләргә дә белми калды. канатлары хәлсезләнде. Әмма ул читенә, читкә тайпыла алмый иде инде, алда — туган җир. Алда — шулай ук дәһшәтле ерткыч дошман да. Ләкин ул ата-анасының «карурманга караганда сандугач көчлерәк» дигән җырларын онытмаган бит әле. Карурманда дошманнар күп. Хәзер исә сандугачның каршысында аларның берсе генә. Иң зурысымы, иң кечкенәсеме — барыбер. Ялгыз дошман — куркыныч көндәш кенә ул. Ялгыз көндәшне җиңеп була дигән якты ышаныч сандугач күңеленә ата-анасы җыры белән үзенә генә түгел, ә балаларына да җитәрлек булып, мәңгелеккә кереп калган.*

*Сандугач читкә тайпылмады. Кош белән самолет арасы әлегә шактый, ләкин һичнинди киртәсез, буш һәм якты иде.*

*Кичкырын, кошлар көтүе диңгез ярының тын кыялары турысыннан очып үткәч, сандугач тимер кошларның астагы диңгезне иңләп йөзгән шыксыз дәү оясын абайлап өлгергән иде. Тирә-якны бихисап утлары белән яктыртып, ул оя ярга янәшә йөзеп бара иде. Аның сыртларында эре йолдыз сурәтләре яна, шундый ук йолдызлар тимер кошларның янбызында да күренә. Оядагы кошлар менә-менә ут чәчеп күтәрелерләр дә арттан куа чыгарлар кебек.*

*Тик сандугач алардан курыкмады. Оясында йоклап яткан тук кошлардан өркәсе түгел. Дошман һавага күтәрелгәч кенә яный.*

*Тимер очкычлар оясының артында зәңгәрле-аклы киң буразна сузылып кала, аңа ыгы-зыгыга бирелгән акчарлаклар ияргән иде. Акчарлаклар куркытылган көмеш балыкларны чүпләп бардылар.*

*Әнә шул оядан, әйләнә-тирәне гөрелтесе белән дер калтыратып, ут койрыклы ике тимер кош күтәрелгән иде. Ләкин сандугачлар ул арада алардан шактый ераклаштылар, артка әйләнеп карамадылар, шуңа күрә аларның нишләгәннәрен күрмәделәр.*

*Континентның иң көньягында — сандугачлар кышлаган җылы урыннарда да боларга охшаган көмеш кошлар таш юллардан күтәреләләр дә, нindидер корбаннарын эзләгән кебек, ажгырып очалар иде. Соңгы вакытларда алар кара тәнле кешеләрнең тимер чыбык киртәләр белән уратылып алынган тәбәнәк йортлары турысыннан күп очтылар, ә кешеләр, алар пәйда булганчы, котыртылган кырмыскалар кебек йөгерештеләр, кулларын йодрыклап, нидер кычкырдылар. Ак тәнле кешеләр исә, аучылар сыман, аларга мылтыклардан атты. Кара тәнлеләрнең байтагы егылып калды.*

*Шулай итеп, сандугач үзенә таба ажгырып килгән самолеттан читкә тайпылмады. Яшенле болытларны ерып очкан тимер кош алдында үзен ком бөртегеннән дә кечкенәрәк итеп сизде. Тимер*

*кош аны черки урынына гына кабып йотар шикелле иде.*

*— Унсигезенче!*

*— Әйе, сэр!*

*— Курс турысында — эре кошлар. Курс — ике йөз уналты һәм җилгә төзәтмә — алты градус.*

*— Аңладым, сэр: ике йөз уналты һәм җилгә төзәтмә — алты градус. — Боерыкны үтәгәч, истребитель очучысы үзалдына: — Миграция вакыты, шайтан! Җитмәсә, бу яшенле давылы... — дип сукыранды.*

*Сандугач үз юнәлешендә оча бирде. Ә тимер кош, аңа төтен исе бөркеп, кинәт сулга янтайды. Юл ачык иде. Сандугач юлдашларына үзе хакында хәбәр биреп, чакыру авазы салды. Тиздән аларны киң почмак ясап очкан фламинголар узып китте. Очучыга самолетлар йөртүче корабтан шулар турында хәбәр иткәннәр иде.*

*Әлбәттә, сандугач моны белмәде.*

*Кояш күтәрелеп, шактый югарыга үрмәләгәндә, сандугачлар көтүе диңгез эчендәге утрауга якынлашты. Төнге яшенле янгыр һәм давыл артта калды. Планктон диңгезне шәмахә төскә керткән иде. Яр читендә үк көмеш медузалар күренде. Сандугачның шатлыктан кабат-кабат аваз саласы килде. Арган-талчыккан канатлары яңа, саф көч белән тулды. Үзе кунасы үлән сабагының ныклыгын чамалап, ул кыска гына вакытка һавада талпынып торды, төшеп кунды, ләкин, кызыл ташлар арасында посып шуышкан еланны шәйләп, чәнечкеле кыргый роза куагы арасына күчте, үзе хакында иптәшләренә белгертеп сызгырып куйды. Сайрап та җибәрәсе килде һәм ул тыелып калалмады: менә аның томшыгында үзеннән-үзе диярлек нечкә генә һава агымы хасил булды, ул аның тавыш әлпәсенә кагылды, ә анда, чишмәнең кара күзендә тибрәлгән якты ком бөртеген хәтерләтеп, тыйнак кына, сандугачның әле үзенә дә таныш булмаган беренче сайрау авазлары бөреләнде.*

*Әмма сандугач шундук тынды. Аның беренче сайравы туган җирендә генә яңгырарга тиеш. Туган җирен дәртле моңнар белән кумәрлек беренче җыры аны алда көтә иде әле.*

*Ана сандугач парлашкан ярыннан соң гына, фәкать балалары йомыркалардан борнап чыгар алдыннан гына сайрый.*

## II

Ярлары тал, камыш белән каймаланган инешнең елгага ухват шикелле киңәеп кушылган тамагы томанлы иде. Зифа таллар һәм яшь камышларның җете-яшел яфраклары нәфис, чиста, тик бүгенге иртәне алар чык төшмәгән килеш каршыладылар. Тын иртә күзен тутырып елгага, яр читеннән үк башланган иске, ташландык зиратка карап тора. Әллә нидә бер акчарлак кычкыруы шул күзнең керфек сирпеше шикелле тоела. Тынлык бу сак тавышка борчылып әйләнә дә тагын да җәйлабрак ята, тагын да тирәнәебрәк, киңәебрәк кала. Томан юрганы калынайганнан-калынаеп, күтәрелгәннән-күтәрелеп, зират ягына авыша, андагы ташларның, тәре, чардуганнар һәм карт каеннар арасында ерткалана, кискәләнә, аннан соң ул бөтерелеп, яңадан укмаша, агач ябалдашлары, үр кашыннан астарак торган чиркәүнең гөмбәзләре, аның кыегайган тәреләре тирәсендә кояшның беренче нурлары белән очраша, эри, югала.

Һәм шунда тирән тынлыкны, калын томанны мотор тавышы шытырдатып ерткан кебек булды. Текә, биек яр артыннан зур борылыш ясап, елганың якты култыгына ялгыз көймә килеп керде. Су өсте кабарып китте, аңа кыйгач дулкыннар таралды. Сөзәк ярдагы вак ташлар, ком кыштырдады, таллар, камышлар калтыранды.

Мотор тавышы тынды. Яссы төпле дюраль көймә салмак кына ярга килеп төртелде. Тынлык элеккегә караганда да сагаярак төште. Судагы вак балыклар көтүе, таллардагы кошлар тынычланды. Сулык-сулык килеп, фәкать дулкыннар гына какты. Елга суы бала кебек йокы аралаш көлә иде шикелле.

Көймәдә ике кеше утыра иде. Аларның берсе, килеп туктау белән, көймә борыныннан ярга төште. Кулында — тимер чыбыктан челтәрләп үрелгән савыт, анда — балыклар. Балыклар тере иде әле. Ул йөген су төбендәге яссы соры ташка куйды. Савыт җәелә төшеп, иркенәебрәк калды. Балыклар елдам боргаланып, бәргәләнеп алдылар да тындылар, имезлек капкан бала шикелле сулый башладылар.

Көймәдән төшкән кеше көрән сыртлы судакларга, кызыл канатлы бәртәсләргә кәефләнеп карап торды, тычкан тоткан мәче кебек, аларны капшап-капшап карады. Кыска чәчле, кабарынкы мыеклы, коңгырт күзле бу кеше өстенә зәңгәрле-кызыллы йөнтәс свитер кигән, джинсы чалбары көчле ботларына сыланып тора, аягында шулай ук зәңгәрле-кызыллы кроссовка. Сыгылмалы итеп, беркадәр биебрәк атлавы белән ул, чыннан да, сабыр холыклы, кирәк чакта бик елдам була белгән мәчене хәтерләтә. Аның аяк астындагы ташлар ул йөргәндә кузгалмады да бугай. Балыкларны суга куйганда ул чүгәләмәде, ә бәлки үкчәсе үкчәгә, тезе тезгә орынып торган озын аягын төз тоткан хәлдә биленнән генә бөгелеп иелде. Бөтен гәүдәсеннән ниндидер пөхтәлек, зифалык бөркелеп тора кебек. Әгәр дә балыкларның берәрсе савыттан сикереп чыгып, суда йөзеп китсә, ул аны йә һавада ук эләктереп алыр, йә аның белән уйный-уйный, ярыша-ярыша янәшә йөзеп китәр сыман. Әйтергә кирәк, ул (бөтен килеш-килбәтенә туры китереп сайлаган диярсең) — җәядән ук атуда танылган спортчы Солтан Наймушин иде.

Ул балыкларга сокланган арада, көймәдәге икенче кеше әйберләр саклагыч урыннан ике шешә аракы, ике стакан, бер бөтен ипи, тоз салынган пыяла банка алып, утыргычка тезә барды. Аннары, кисәтеп тә тормастан, аракы шешәләрен берәм-берәм ярдагы иптәшенә ыргытты. Солтан аларны үзенә каныккан чебенне учы белән тоткандай гына эләктереп алды да суга яткырып куйды. Көймәдәге кеше шулай ук стаканнарны, банканы чөйде. Үзе һаман нидер урнаштырып, актарынып маташты, гел баскан урынында таптанды, әйләнгәләнде, тулганды, ярга чыгарга ашыкмады. Аның өстендәге штормовкасы кояшта, яңгырда уңып, ә якасы, җиң очлары керләнеп, ялтырап беткән, култык асларындагы, бил турысындагы эчкә баткан сырлары гына саргаеп калган, — бу нәрсә киң җилкәле, авыр сөякле һәм таза гәүдәле әлеге кешене төсе җуелган иске самавырга тартым иткән. Әйтерсең лә ул самавырны ком белән ышкый-ышкый ялтыратканнар, ә яньчек урыннары элеккегә караганда да каралыбрак калган. Бу тәэсирне аеруча аның йөзе көчәйтә: гүя ул яньчелгән булган да хәзер аны тигезләгәннәр — аның бите җәрәхәт җөйләре һәм янган эзләр белән тулган иде. Көймәдәге кеше — Степан Масленников, бишел элек Әфганстан сугышыннан яраланып, т а н ы м а с л ы к булып кайткан егет.

Ул кечкенә балта да ыргытты. Түбәннән очканга күрә, Солтан анысын тотып алырга кыймады. Балта ташка килеп төште, зыңгылдавы, акчарлак кычкыруына кушылып, ишетелми калды.

Озак кайнаган самавыр ише, Степан һаман көймәдә булашты әле. Ниһаять, бер бөтен ипи һәм яшел суганлы полиэтилен капчык тотып, көймә сыртыннан атлап суга төште дә ярга чыкты. Озын кунычы кайтарып салынган резин итектән. Балык савытына төртеп, ул көр тавыш белән:

— Яхшы градусниклар бит, ә? — диде.

— Балыкка градусник дигәнне беренче тапкыр ишетүем.

— Газета укырга кирәк, яшьти. Хәзер безнең балыклар миендә

терекөмеш тәгәрәп йөри. Белмичә ашасаң, үзеңнең дә тәгәрәп китүең ихтимал. Шуннан соң градусник куюның кирәге дә чыкмавы бар.

Степан, һавадагы балык сыман авызын зур ачып, көлеп җибәрде.

— Әйтәм аптекаларда градусниклар табып булмый... Терекөмешне суга агызганга икән, — диде Солтан юеш кулын чалбарына ышкып. Ул бер кавым елгага карап торды.

Су чиста түгел иде. Шушы арада өч көн буена тоташлый яңгыр явып, ерганаклар, инешләр ташыган, елганың суы арткан булган. Ул үзе кичә генә бабалары янына кайтып төште. Аларга бәрәңге утыртышырга исәпләгән иде. Яңгыр аркасында авылда язгы чәчүдән туктап торганнар, ә колхозчыларның бакчалары сукаланмаган да икән әле. Кайткач бер ял булсын дип, Степан аны бүген иртүк балык тотарга, яр буенда сөйләшеп утырырга алып чыкты. Кичә көн аяз иде, җир кибәргә дә өлгерде, елга суы да кимегән, үз эзенә төшә язган. Бераз юанып утырырлар да, Степан эшенә китәр, ә ул бабалары янына умарталыкка барып, кулыннан килгәнчә ярдәм итәр. Колхоз умарталыгы моннан ерак түгел, ике чакрымлап өстәрәк, шушы елганың калкулык астындагы уйсу ярында, бәләкәй генә урман аланында. Солтанның шунда тукталасы килгән иде дә, Степан риза булмады. Әллә нидә бер күрешкән, бераз тамак чылатырбыз, ә картлар алдында хәмер чөмереп утыру килешмәс диде. Биредә дә начар түгел. Яр ышык, аяк астында вак ташлы ком, кеше-кара йөрми торган аулак урын. Яхшы!

— Тома-ан да соң! — диде Солтан.

— Көн эссе булырга ул. Кичәге шикелле үк, эштиеңне куырыр әле.

— Берәр кабер ташына шакырбыз. Бәлки ачып кертерләр. Анда салкынчадыр, ә, Степа?

— Анда шакып кермиләр шул, парин, — диде Степан һәм, кулындагы әйберләрне җиргә куеп, балтасын алды. — Әйдәле, ботак-сатак җыеп килик.

Алар инеш култыгының кызыл үзле балчыклы һәм җирән төстәге комлы ярына таба атлап киттеләр. Степанның аяк астында ташлар чыгырдады, ваграклары, зур балыктан курыккан маймычлар сыман, алга очкалады. Эзләре батып-батып калды. Солтан исә аның белән чагыштырганда юка боз буенча гына бара диярсең: аяк атлаулары җиңел, сыгылмалы иде.

Ике метрлап биеклектәге яр кисентесеннән үк сөзәк үр күтәрелә, ә анда — ташландык рус зираты. Солтан ул зиратның елгадан шактый читтә торганын хәтерли әле. Әлек бу үр астында болын җәйрәп ята иде. Су күтәрелгәч, аста калды. Хәзер язгы ташкыннар һәм бозлар кимерә, ашый, агыза торгач, яр зиратка ук килеп төртелгән. Кайбер каберләр, алар өстендәге агачлар агып ук киткәндер. Әнә, яр читендә үк үскән тагын бер нарат тамырлары тотмыйча авып төшкән. Тагын берсе тәмам кыйшайган, астына ташлар чыгып торган яр шулай елның-елында ишелә, чигенә, киңәя бара, күрәсең.

Солтан ярты юлда туктап калды. Степан ауган наратның алтын кайрылы ботакларын чапкалаган арада, үр кашыннан чак кына түбәндәрәк торган чиркәүне, кайсысы янтайган, кайсысы җиргә сузылып яткан агач һәм тимер тәреләрне, кыйшайган, таралган, бер ишләре тәмам таркалып, череп яткан чардуган калдыкларын, сирәк кабер ташларын күзеннән кичерде. Томанда өлешләп-өлешләп кенә күренгән кызыл чиркәү һавада авыр гына очып барган сыман. Ул биш гөмбәзле, чаң манарасы гөмбәзләрдән калкурак. Исән тәреләре чалшайган, ике гөмбәздә бөтенләй юк. Калайлары челтәрләнгән, сәләмәләнгән; кайбер урында кайтарылып, купкан ямаулык шикелле асылынып төшкән. Гөмбәзләрнең ачык урыннарыннан шикмә агачлары каралып күренә, алар ите сөяккәчә кырылган һәм Россия шәһәрләрендә халык-

ка сатар өчен кибетләргә чыгарылган мал кабыргаларын хәтерләтә. Уртадагы баш гөмбәз иске зонтик сыман убылып төшкән. Аны корыган үлән сабаклары, кәкре тал, кәрлә каен үсентеләре баскан. Манарадагы кара кыңгырауның яртысы гына эленеп калган, күгәрек тимер бәргечен кагарлык түгел инде: ул бушлыкта асылынып тора. Ә кыңгырауның калган яртысы, яшел куңык белән капланган итәген күккә ачып, кайчандыр җирдә ята иде, хәзер кайдадыр, яр астыннан күренми.

Кабер ташлары авыру кешенең аксылланган теле төсле: аларны көмеш мүк сарган. Ә кайберләрен вакыт кыеп-кыеп алган, ваткан, тараткан...

Солтанның күз карашы нәрсәгә генә төшмәсен, абына, сөрлегә, аерыла алмыйча интегә. Аңа монда барысы да таныш, аның бу зиратка кергәне, йөргәне бар. Хәзер исә ул биредә үзен ят, чит хис итә. Бу тирәләрдән әйләнеп, ераклардан әйләнеп узар иде дә бит, әмма соңгы елларның шушы көнендә аны бирегә нидер тарта. Ул ничек тә килеп чыккаларга җай таба, моны тиеш дип саный һәм, төрле сылтаулар табып, һич югында сәбәпсез-нисез килергә мәҗбүр дә була. Шуңа күрә бүген Степанга бик теләп иярде, бабасы Кадрәк, дәү бабасы Чаныш янына умарталыкка ашыкмады. Хәер, алар юлга яңа гына җыенып яталардыр әле, үзләре кебек үк картайган атлары Тимерне арбага җигәләрдер.

Сәбәпсез-нисез дигәч тә, Солтан үзенең бу зиратка ни өчен тартылганын яхшы белә. Сәбәбе бар, бар. Нинди генә сәбәп әле. Аңа бу анык билгеле. Аңа гынамы соң? Аңа үзен монда һәммә нәрсә таныйдыр кебек тоела. Бу иртәне Солтанның барча нәрсәне күзеннән кичергәне кебек, һәммә нәрсә аңа да сынап төбәлгәндер, аның нишлисен сагаеп көтәдер шикелле. Бу зират ташландык кына түгел, монда хәтта вакыт та тукталып калгандыр сыман. Шул ук вакытта, Солтан пәйда булу белән, ул тукталган вакыт, әйтерсең лә, җанлана, хәрәкәткә килә...

— Мәетләр йоклыймы? — диде Степан, аны уйларыннан һәм күзәтүеннән бүлдереп. Ул биш-алты ботакны чабып өлгергән дә икән инде.

— Андый йокы бездән дә калмас, — дип җавап бирде Солтан һәм, якын килеп, бер ботакны көймә тарафына сөйрәде.

Степан, зират ягына ияген кагып:

— Йоклыйм дисәң, монда баш куеп ятарга мендәр җитәрлек, — диде һәм үзе дә бер ботакны сөйрәп китте.

— Күзеңне генә йом — хәзер өч аршинлы юрган ябарлар!

— Әйтмә дә, яшьти. Мин үзем көчкә котылып калдым.

— Ишеттем. Тик тагын бер сөйләрсең әле.

— Ишеткәнең җитеп торыр, — диде Степан. — Калганын яңа зираттагы минем каберем янына барып кара.

— Исемеңне кыргансың бит инде.

— Мин аны мәңгегә калдырыр идем дә бит, хәрби комиссариаттан килеп кырып ташладылар аны.

Степан ботакларны тураклады, Солтан ул тураклаганны учак итеп өйде. Ләкин нарат ботаклары чи булып чыкты, тиз генә кабынып китәрлек түгел икән. Степан тәкъдиме белән зиратка күтәрелеп, ауган ике агач тәре сөйрәп төштеләр. Аларның берсен Солтан авыш наратка сөялеп торган җиреннән кубарып алды. Кадерсез яткырганчы, ягуы хәерлерәк, дип уйлады. Бер заманны дәү бабасы Чанышның авылдагы татар зиратына яңа койма корышканы, иске рәшәткәләрне җыеп якканы исенә төште. Билгеле, кемнеңдер кабере өстендәге тәре яраксыз койма түгел инде түгелен, әмма ни аермасы бар? Бу зират ташландык, һәммә нәрсә авып чери, юкка чыга. Ахыр чиктә ягуы һич тә кешелексезлек түгел. Чистарак булыр. Болай эшләүнең үзенә күрә савабы

да бардыр әле. Ул үзен пошыныры к нәрсә юк дип тынычландырды. Дөнья шулай инде ул: исәннәр оялмаса, үлгәннәр кулдан тотмый. Бу аның үе түгел, бабасы Кадрәк сүзләре. Солтан оялу хисе кичермәде. Димәк, ярый.

Әнә Степан үзе сөйрәп төшергән тәрене балта белән тураклап та ташлады. Солтан ул нык, коры имән утыннарны яңа урынга учак итеп тергезде, аларга нарат ботакларын өстәде, чыра телеп, ут элде. Һавага сыек төтен күтәрелде, чәер исе таралды.

— Балык апкил, — диде Степан.

Ул нечкә биш нарат ботагы чабып алды, аларны учак тирәли кадап чыкты. Солтан китергән ике бәртәсне һәм өч судакны тозлады да саңакларыннан шул ботак очларына элеп куйды. Тере балыклар, ялкын кайнарлыгыннан читкә очып китәргә җыенган сыман, канатларын җәеп җибәрделәр, саңакларын һәм авызларын ачып, утка таба көмеш дуга сурәтендә каерылып бөгелделәр, аннары калтырана-калтырана турайдылар, шиңделәр, асылынып калдылар.

— Үлгәннәрен көтәсе калган, — диде Солтан аларны кызганып.

— Аларның үлгәннәрен көтеп утырсаң, үзең яшәми калырсың. Сине ач тотып булмый инде, яшьти, — диде Степан. — Ылыс ташла. Төтен кирәк, — ыслансыннар.

Солтан учакка ылыслы ботаклар ташлады. Балыкларны аның сары төтене сарды. Шуннан соң һавага очкыннар чәчрәде, көл күтәрелде, ялкын бөркелде. Балыкларның күзләре борчак шикелле агарып, бүртеп чыкты.

Степан ипи кисте дә телемнәргә эре тоз сипте, аннары бер шешәне ачып, стаканнарга аракы койды.

— Әйдә, бер барып кайтыйк әле,— диде ул стаканын күтәреп. Алга иелебрәк эчкәч, суган кыягы төреп капты. — Чылат мыегыңны, чылат. Томан күшектерә.

— Томан шул, — диде Солтан сүз булсынга.

Читкәрәк борылып һәм йөзен җыерып, стакандагы эчемлекне, мыегы аша сөзгәндәй, озаклап эчә башлады.

— Нигә йөзеңне җыерып эчәсең аны? Елмаеп кирәк, елмаеп! — диде Степан балыкларны әйләндергәләп.

— Беләсең ич, моның белән дуслыгым юк.

— Аның белән микән? Юк, бәла белән дус түгел син. Үлем белән. Югыйсә, аракының кадерен белер идең. Әнә теге кабер ташлары артыннан синең маңгаеңны прицелга алсалар... Хәер, син бәхетле кеше, төшләреңә өрәкләрнең прицел аша төбәлгән кара күзләре керми. Күз дә түгел, ә кара кабер...

— Әйе, төшкә керми андый нәрсәләр. Бездә бер җыр бар: «Дуска түгел, дошманга да без кара коелмыйбыз...» Әйт әле, туган, әфган дошманнарының синең алда шәхсән гаепләре бар идеме?

Степан җавап бирмәде. Балта түтәсе белән төгәл кизәнеп, тураклаган тәренең уемыннан астагы борысны сугып чыгарды да учакка салды.

— Минем алдамы? — дип телгә килде ул. — Син тинтерәтмә инде, парин. Кунак булсаң, тыйнак бул... — Ул учак каршысына тезләнде. Т а н ы м а с л ы к булган битенә ялкын яктысы төште. Бите кызарса да, уйлары кара иде, ахрысы: ул ашыгып папирос капты, күмердән ут элде дә тирән итеп төтен суырды. — Без Россияне сакламадык саклавын. Без үз җаннарыбызны, иптәшләребезнең гомерләрен саклап сугыштык... «Духлар» безнең иптәшләрне дүрткә ботарлап үтергәннәр икән — гаепсезләрмени?! Ә без ул иптәшләребездән ата-аналарына җибәрерлек бер нәрсә дә калмаган очракта бер-ике мәртәбә табутларына туфрак тутырганбыз икән — моңа кем гаепле?

Солтан дустын бөтен күңеле белән кызганып куйды. Степан аннан фәкать яраланган йөзе белән генә аерылып тора, бүтән бер ягы

белән дә түгел. Ләкин хәзер, очрашканнан бирле беренче тапкыр ул аның күзенә төбәлеп, җанына тикле үтеп керергә тырышып бакты. Шунда аның үзе кебек түгел икәнен тойды һәм күрде. Ул, ни әйтсәң дә, кеше үтереп кайткан адәм. Үз теләге белән түгел, әлбәттә. Ул аннан иң әүвәл шуның белән аерылып тора һәм моны, шиксез, бик авыр кичерәдер, оныта алмыйдыр, төннәрен саташып ук чыгадыр. Шулай гынамы соң әле — ул кешеләрнең һәм менә бу мизгелдә Солтанның үзе хакында нәкъ шулай уйлаганын сизәдер. Шуңа күрә Солтан дусты хакында шушылай уйлавын яшерүне кирәк санамады. Киресенчә, аны үзе белән тигезләргә теләп, кырыс сорау бирде:

— Син үзең үтердеңме соң?

Юлдашы кинәт башын күтәрде, тураеп басты, кулындагы балтасын ташлады да аңа төбәлде. Аннары карашын учакка, учакның иң кайнар ноктасына — үзәгенә күчерде. Дустының карашында Солтан дәү бабасы Чаныш белән бабасы Кадрәкнең моңсу күзләрен күргәндәй булды. Солтан әллә кайчан — бала вакытында алардан: «Син кылычың белән күпме акларны кырдың, бабай?» яисә: «Син күпме фрицны үтердең, бабай?» — дип сораганын исенә төшерде. Алар беркайчан да аңа төгәл җавап бирмәделәр. Җавап урынына: «Санамадым, улым», — дип кенә әйтәләр иде. Бу сорауларны ул аларның һәркайсына бары тик бер генә тапкыр биргән иде. Сүз куешкан шикелле, җаваплары да бер генә төрле. Күз карашлары да аерылгысыз: әллә син алар каршысында түгел, әллә алар синең каршыңда түгел. Ул караштa әйтеп булмастай бер бушлык бар иде. Нәкъ Степанныкы кебек. Шуңа күрә ул аннан «Ничәне үтердең?» дип сорамады, ә кырыс төстә:

— Син үзең үтердеңме соң? — диде.

— Булды инде... — дип җавап бирде Степан аңа карамыйча.— Берне. Ә калганнарын кирәк чагында һәм булдыра алганда юкка чыгардым.

— Барыбер түгелмени?

— Юк, барыбер түгел.

— Ни өчен?

— Чөнки мин бер генә тапкыр үтердем һәм үзем дә бер генә тапкыр үтерелдем... Шушында вәссәлам — бетерик... Инде берне күтәреп искә алыйк.

— Кемне?

— Мине. Миңа өстәп, бөтенләй кайтмый калганнарны, кайтканнарның үз туфракларына кереп ятканнарын, чит табутларны кысан итмәгәннәрне.

Бу юлы чәкештермичә генә эчтеләр. Солтан дустының дәвам итүен көтте. Әмма ул дәшмәде.

— Степан, ә Степа... Теге беренчесен... син ничегрәк?..

— Җанны кырма инде, ул җитәрлек сөялләнгән. Ымлыкларны җенем сөйми. Турыдан яр — ничек үтердең диген.

— Ничек соң?

— Үз косыгыма батканчы. Махмыры гомергә төзәлмәслек булганчы.

— Шулай да?

— Без аларны бер кышлакка китереп кыстык. Без инде аларның эзләре суынганын белгән идек. Аларда кириз дигән нәрсәләр бар. Безнеңчә, җир асты юллары инде. Алар аны кайчандыр кырларын сугарыр өчен казыганнар. Унар чакрымга сузыла. Шуннан килеп чыгалар да тераплар аталар. Иң әшәке киризлар кышлаклар астындагысы. Акылдан шаштырырлык... Менә шул: кышлакларын урап алдык. Яңа гына шуннан безгә ут яудырганнар иде. Җир йоткан шикелле юкка да чыктылар. Без дә тындык. Аннары алга киттек. Ә бер дош-

ман посып калган, безне кургаш яңгыр белән коендыра башлады. Гранатаның балдагын тартып алдым да тәрәзәгә томырдым. Өйгә бәреп кердем — тузан, төтен. Күзгә төртсәң дә күренми. Автоматтан чытырдатып алдым да көтәм. Шунда күрәм: минем дошман саман стенага сөялеп утырган, өзелеп чыккан аягын кочаклаган. Калтырана, усак яфрагымыни... Чалмасына автомат көпшәсен терәп куйдым да көтәм инде. Күз бәбәге белән минем җанны бораулый бу. Мин дәшмим. Шунда взвод командиры бәреп керде. Мине беткән дип уйлаган, ахрысы. Хәлне күрде дә: «Добей!»— дип боерды. Ә мин кызганам. Яралы бит. Миңа төбәлгән дә каткан. Командир атасы-анасы белән сүгенә: «Эшен бетер!»— дип кычкыра. «Пушка»сын болгый. Мин, читкә карап, чакмага бастым да бар патронны чыгарып бетердем. Шундук косып та җибәрдем. Ашказаным тискәре ягы белән әйләнеп чыга дип торам...

Солтан кинәт үзләрен тере учында тоткан дөньяга Степанның күзе, аның җаны һәм вөҗданы белән караганын тойды.

Иртәнге суык әкренләп чигенде. Томан тарала башлады. Аның калдыклары елга борылышындагы кыя артыннан бәреп чыккан кояш нурларында эри иде инде. Су киңлеге яктырып китте. Җиргә төрле күләгәләр сузылып ятты. Вак балыклар уйнашырга кереште. Акчарлаклар үзләренең иртәнге ауларын тизләтебрәк җибәрде. Якты күн күзен тәмам ачты.

Күмерле агач алып, Солтан сигарет кабызды.

— Балыклар... яхшы,— диде ул, сөйләшүне үзгәртергә теләп. Степанга да ял кирәк бит.

Чыннан да, балыклар алтынланып пешеп килә, көйгән канатлары тәмле ис тарата.

— Шәпләре суда калды аның, парин. Бүгенге шикелле, кармакка тоту минем саруымны кайната. Синең хакка гына инде. Башка чакта мин җәтмә белән бер урыйм да, атна буена тамак тук.

— Ә миңа шушылай тансык. Тансык кынамы соң!.. Кармакка балык каптырып утыручылардан көнләшәм мин, Степан. Яратып көнләшәм. Ленин күперенең ике ягында — ике диңгез. Өсте тыныч, якты, күз камаша. Каршыда — кремль, Сөембикә манарасы кояшка таба авышкан, чиркәүләрнең алтын гөмбәзләре ялтырый. Ә балыкчыларның һичнидә гамьнәре юк. Резин көймәләренә сеңгәннәр. Карашлары калкавычта, күңелләре су төбендәге балыкларда, уйларын су агызып киткән... Хикмәт тамак туклыгындамыни, туган! Хикмәт — җанда ул.

— Сөйләмә! Тамак турында сүз чыкканда җан турында лыкылдаучыларны өнәмим.

— Булды, дәшмим.

— Син дәш, дәш! Балык кына дәшми. Без дә күп дәшмәдек. Дәшмәгәннәрне ашыйлар аны.

Степан бер судакның саңак төбендәге канатын умырып алды да чәйнәп карады. Канәгать төстә телен шартлаткач, аны яссы ташка алып куйды, япьле пәкесе белән буйдан-буйга ярып, эчәкләрен, куыгын кырып чистартты, тоз сипте.

Ысланган балык исе борынны кытыклый иде. Солтан ике ташны өсте-өстенә куеп утырды, ләкин өске таш селкенә, утырырга җайсыз: ике аяклы урындыкка утыргандай булды.

— Циркач мәллә син? — диде Степан.— Әйдә, ярдан бер-ике таш кубарып апкиләбез. Табын икән, табын булсын. Кунагың да киләсе бар. Камәриягә өстәл әзерли торыйк.

Әйе, Солтан бүген Камәрияне чакырган иде. Иртәрәк әле, килер. Килермен, диде.

Ярдан чыгып торган ташлар авыш нарат турысында күбрәк иде. Шуларны кубардылар. Һәркайсы икешәр яссы ташны үзенә утыргыч

итеп җайлады. Өстәл урынына зуррагын сайладылар. Көчәнә-көчәнә арлы-бирле кузгата торгач, ул җимерелеп төште, вак ташлар, ком коелды, ярда бушлык хасыйл булды, куыш ачылып калды. Солтан шунда үрелеп карады.

— Ни бар? — дип сорады Степан.

— Еланнар оясы, ахры.

— Еланнар? Еланнар буенча мин белгеч. Анда елан ите ашар чиккә җиткән чаклар булды, парин. Шулай бервакыт Гардез белән Хост арасындагы юлны сакларга туры килде. Берничә көн сусыз яттык. Сугыш... Ярты взвод кырылды. Шулай бер ташбака тотып алдык. Нишлисең — ашадык. Җирәнгеч анысы...

— Әллә миңа елан ите ашатырга уйладыңмы?

— Ашый торган еланнар башка ул. Ә болар — тузбашлар.

Еланнарның башлары кайда да, койрыклары кайда — буталышып беткәннәр. Яктылыкны бар дип тә белмиләр. Күзләре йомык, тәмам онытылганнар. Нindидер ләззәткә бирелгәндәй, бер-берсенең тәннәре буенча алга да артка шуышалар. Кайсылары бау шикелле урала, кайсылары чишелә. Кайсысы авызын шыплап япкан, кайсысы киереп ачкан. Авызлары ачылганнарының ике аермалы уклары йә хәлсез асылынып төшкән, йә киерелеп тора, йә калтырана. Башларындагы сары таплары светофор утлары шикелле әле кызара, әле яшелләнә кебек.

Ботак алып килеп, Степан аларны тузгытырга тотынды.

— Тимә, ятсыннар— диде Солтан.

— Ә юк инде, яшьти. Мин артта елан торганга күнекмәгән. Тыл чиста булырга тиеш.

Еланнарның ни белән мәшгуль икәнен Солтан төшенеп өлгергән иде инде. Яз бит. Табигатьтә яратышу мәхшәре хөкем сөргән вакыт. Күз алдында бала чагының онытылып беткән, ә хәзер кинәт искә төшкән бер күренеше җанланды. Майның кайсыдыр көннәрендә яр буендагы җылы ташларның дымсу асларыннан бер-берсен алгы һәм арткы аяклары белән кысып кочаклап, ак йомшак корсаклары белән сыланышып беткән гөберле бакаларны актарап чыгарганнарын, аларның серләренә төшенергә теләгәндәй, ике таяк очы белән бер-берсеннән аерырга тырышуларын хәтерләде. Ләкин бакалар тиз генә бирешмиләр иде. Солтанның һәм башка малайларның кызыксынудан, көчәнүдән борын очлары, маңгайлары тирләп бетә, ә бакаларның салкын, кытыршы тәннәрендәге шадра төртекләрдән тамчы-тамчы сөт саркып чыга. Малай-шалай бөтен дөньяларын оныта, аның саен үҗәтләнә. Түземнәре беткәч, ахырда һичнинди тартынусыз, җирәнүсез төстә алар бакаларны сыртларыннан куллары белән тартып, аякларын бармаклары белән каерып аералар иде. Бакаларның аяклары, көзән җыергандагы шикелле, киерелгән көйгә бөкерәешеп, тырпаешып кала, күзләрен ачмыйлар, тавыш-тын чыгармыйлар, җиргә ташлагач, үпкәләгән сыман, кыймылдамый яталар. Әгәр шул вакыт берәр кыз бала килеп чыкса, малайлар шул бакаларның берәрсен сиздермәстән аның аркасына салырга да күп сорамыйлар иде. Солтан үзе бака салырга ни өчендер Камәрияне сайлый, аны көтеп ала, посып сагалый иде. Камәрия аркасында йә күкрәгендә салкын ят нәрсәне тоеп алу белән, тәне буенча боз кисәге шугандай, башта киерелеп катып кала, аннары бөрешеп килә, куырылып китә, шуннан соң тыпырчына, чапалана башлый, ачыргаланып кычкырырга, еларга тотына, күлмәген күтәрә дә, зәңгәр трусигын күрсәтә-күрсәтә, баканы кагып төшерә. Ә үзе урынына Камәрияне башка малай куркытса, Солтан аның белән сугышмый калмый иде.

Сары көнбагыш чәчәге кебек ачылып киткән бу истәлек Солтанның күңелендә яңа уй кузгатты. Кайчандыр ул Камәриягә үз мөнәсәбәтен белдерер һәм аның игътибарын үзенә юнәлтер өчен арка-

сына ямьсез, чиркангыч гөберле бака салган. Ә бүген нәкъ шуның өчен нишләргә кирәк икән соң? Менә бу еланнарны яктыга сөйрәп чыгара, бакаларны бер-берсеннән куптарган шикелле, аерып ташлый һәм берәрсен аның куенына сала алмый бит инде! Киресенчә, Камәрия белән мөнәсәбәтен, куышта уралышкан еланнарга охшатып, һичкем тарката алмаслык рәвештә ныгытып үрер иде...

Аяк астына кубарып төшергән ташка басып, Степан кулын куышка тыкты да еланнарны төргәге белән тышка сөйрәп чыгарды. Аларның чуалчык бәйләме шапылдап комга тәгәрәп төште. Тузбашлар бер мәл тын тордылар, аннары, аерылыр алдыннан кочаклашкан кешеләр сыман, тагын да тыгызрак булып укмаштылар. Солтан ул төргәкне янган, корымланган, күмерләнгән агач төбенә охшатты.

Һәм шунда хәшәрәтләр кинәт йомшадылар, аралары бушады, алар бер-берсеннән читкә тартылдылар. Күмерле агач төбе күз алдында тамыр җибәрә, ул тамырлар җир дымын эчәр өчен таш араларына төртелеп, тишек эзлиләр сыман иде. Минут арасында еланнар төргәге чишелеп бетте. Алар арыган, талчыккан төсле төрле тарафка таралыштылар.

Степан берсенең койрыгыннан эләктереп, баш очында айкады да болганчык суга селтәп ыргытты.

— «Өрәкләр»[1] шундый иде,— диде Степан.— Безнең «вертушкалар»[2] килеп чыкканда алар да, еланнар шикелле, тау ярыкларына кереп кача иде.

— Кызганам мин аларны.

— Өрәкләрнеме? Бар, кочагыңа җыеп кил дә ояларына тутыр.

— Һәркемнең үз каланчасы инде.

— Әллә мине гаепләвеңме бу?

— Юк, үземне,— диде Солтан.

Ул учак янына барып басты да аракы салып эчте, яссы бер ташны елан йөзеп киткән якка чәпчетеп җибәрде. Таш суны үпкән урыннардан коймак-коймак нурлар сирпелде. Алар алтын күбәләк канатлары сыман җилпенделәр дә сүнделәр. Ә сүнгәч, әллә төпкә тондылар, әллә агып киттеләр.

Еланнар, муенга урап йөрерлек, зарар кылмас тузбаш еланнар. Солтан үз-үзеннән: «Нигә тик торганда рәнҗеттек соң әле без аларны?» — дип сорады. Күңеленә килгән җавап аның кәефен кырды. Еланнар булып еланнар арасында муенга урасаң да җирәндерми, тәнне чиркандырмый торганнары бар. Ә кайбер кешеләрнең кылган эшләре арасында муенга күтәралмаслык таш булып асылганнары һәм сине төпкә тартканнары күпме!

Шуышырга гына дучар булган баягы бичара тузбашларны туздырып ташлаган кебек, Солтан үзара гыйшык тотып йөргән ике кешене дә бер-берсеннән аерып атты, алар арасында кара яшен булып яшьнәде. Көйдерде, яндырды. Үзе дә көл сарган күмер сыман көйрәп кенә калды. Хәзергәчә ялкынланып китә алганы юк әле. Хәтер җиле искән саен, пыскый гына. Менә тагын шул исенә төште. Башыннан кичергән бер вакыйганы аның һич онытасы юк. Ул вакыт-вакыт аның җанына шуышып керә, өтә, куыра иде.

Өч ел элек, егерме яшен тутырган көнне, Солтан шушы зиратта Камәрияне яратуының авыр тойгыларын кичерде. Шуннан аралары суынды. Упкын. Хәзер шунда басма салып йөргән көннәре. Чайкалып торган асылмалы басма. Чын, нык күпер салынырмы — билгесез. Ышаныч бар-барын. Ләкин алга килми белеп булмый әле.

---

[1] Әфган мөҗәһитләренең совет солдатлары телендәге кушаматы (Автор).
[2] Совет вертолетлары аталышы (Автор).

Әйе, өч ел элек. Шушы зиратта. Нәкъ шушы көнне...

Ай күзе белән тыныч дөньяга караган зәңгәрсу май төне иде. Ул Казаннан кайтып, авылда бергә уйнап үскән иптәшләре, аларның йөргән кызлары белән үзенең туган көнен үткәрде. Камәрия килмәде. Кунаклар таралышып, бабалары өендә ялгызы гына калгач, Солтан урамга чыкты. Ул көнне Камәриянең элек йөргән егете Иштуган армиядән кайтып төште. Тау-ташлы, канлы, меңнәрчә аналарның, аталарның, сөйгән ярларның, балаларның котын алып торган, кешеләр шәһәр кухняларында, авыл өйләрендә сүккән, каһәрләгән, матбугат, телевидение, радио башта ләм-мим искә алмаган, аннары тоташлый, уздыра-уздыра мактарга, данларга керешкән Әфганстан сугышыннан әйләнеп кайтуның ул елларда да, соңрак та әллә ни абруе, даны юк иде. Ил дәшмәде, халык сагайды. «Интернациональ бурыч» дигән гыйбарә барлыкка килде. Кешеләрне сәер, зиһен кабул итәргә тартынган, хәвеф-хәтәр салкынлыгы бәреп торган каршылык тетрәндерде: шәһәр каберлекләрендә, авыл зиратларында кызыл яисә кара граниттан, төрле төстәге мәрмәрдән коелган кабер ташлары калкып чыкты һәм аларга «интернациональ бурыч үтәгәндә һәлак булды» дигән рәхимсез, аңлаешсыз сүзләр уеп куелды. Рәхимсез — чөнки илгә беркем, шулай ук ил дә һичкемгә сугыш игълан итмәгән. Аңлаешсыз — чөнки нинди бурыч ди ул? Кайсы ата-ана үз улын белмәгән-нитмәгән чит ил халкы һәм чит партия мәнфәгате өчен еллар буена сөешеп дөньяга яраткан? Аларны ата-аналары күкләр ишелеп төшкәндәй авыр газапта тапкан, күз карасыдай саклап үстергән, картлык көннәрендә терәк булыр дип ышанган! Бурыч икән — үлгән балаларны кем кайтарып бирер соң? Газиз балаңның фоторәсемен тотып, исемен, фамилиясен язып, кем каршына барып басарга? Җелек кебек тере, исән-сау ир-егетләрне үз властен үз халкыннан саклар өчен бурычка сораган партия икенче бер партия белән еллар буена сөешеп, дөньяга яңа кеше ярата алмый; аның аналар бала тапканда кичергән газапны үлчәрлек үлчәве юк; күз карасыдай кадерләү урынына ул егетләрне һәр куак артыннан үлем сагалады. Чит солдатлар чит илнең киләчәгенә терәк була алмый. Ярдәм кирәк икән, кеше каны сорама — нефть ал; халкыңны туендырырга хәлеңнән килми икән, җан кыйма — ашлык гозерлә; халкың белән идарә итәрлек иманың юк икән, чит солдатларның сукырайтылган күзләре, өзделгән кул-аяклары, Степан Масленниковныкы кебек т а н ы м а с л ы к булып яндырылган йөзләр бәрабәренә ихтирам казану мөмкин түгел. Ярдәмгә чакырылган дустыңны әйләнеп кайтырына анасы шатлыгы, атасы горурлыгы, сөйгән яры назы, баласы кочагы каршыламыйча, өч аршын җир көтеп ята икән, сине үз халкың хәтта кабердән дә мәхрүм итүе ихтимал.

Иштуган — Щукарь сыманрак табигатьле Шәмгун картның Мортаза атлы улының бердәнбер малае иде. Солтан аның белән бергә уйнап, атларда чабышып, сулар коенып, колхозның алма һәм яшелчә бакчаларын басып үсте. Үтә дә горур холыклы егет. Чаялыгы, тәвәккәллеге, әллә нинди бәлаләргә юлыгып та исән-имин кала белгәнлеге өчен аны Биш туган дип атый торганнар иде. Сөйли башласа, авызына каратып тота. Нинди генә төркемдә дә — беренче. Үзен һичкайчан арзанга куймас. Теле зәһәр. Кемгә дә булса бәя бирсә, үтерә дә куя инде. Чыда гына. Тик гөнаһсызга үпкәләтми. Гаделе. Егет икәнсең, килешәсең. Инде үпкәлисең икән, үзеңә кара — Иштуганның сүзе катгый, әйткәненнән кире кайтмый. Аны шуның өчен хөрмәт итәләр дә иде. Сүзенраслыйсы булса, кирәкмә-кирәкмиме, Платон, Монтен, Коръән, Ленин сүзләрен китерә. Гәүдәсе чандыр, башы кечкенә, борыны почык кына булса да, вакыт-вакыт һаваланырга да маһир. Әмма башкаларга гына түгел, үз-үзенә дә

уен-көлке белән карый, кирәк тапса, шәфкатьсез төстә камчылый да белә. Ә бу — үзенә кешедән артыгын таләп итмичә, акыл белән яши белү билгесе инде.

Иштуган менә шундый — күпмедер дәрәҗәдә беркатлы, шул ук вакытта катлаулы холык-табигатьле егет иде.

Солтан аның армиягә кадәр йөреп киткән кызы Камәрияне үзенә каратты. Иштуган белән Камәрия бер-берсен ярата идеме икән. Солтан бу хакта әллә ни баш ватмады. Шулай килеп чыкты инде. Үзе исә Камәрияне ошатты. Кыз да аны якын күрде. Мәсьәлә хәл ителгән, бәхәсләшергә, бигрәк тә бүлешергә урын калмаган иде бугай инде.

Ә Иштуганның Камәрия белән ачыклыйсы, хәл итеп бетерәсе соравы булган икән. Һәрхәлдә, кайтыр алдыннан салган соңгы хатында шуны искәрткән. Шушы нәрсә туган көн мәҗлесенең буеннан-буена Солтанның утырган урындыгындагы энә белән бер булды. Дөрес, Солтан белән Иштуганның уртаклыгы шактый ерак иде. Солтан — шәһәрдә, студент. Әнкәсе белән ару гына җитеш тормышта яшиләр, дус-ишләре күп, дошманнары җитди хәвеф-хәтәр китерерлек түгел.

Бу вакытта медицина техникумында укучы Камәрия белән ул көтмәгәндәрәк якынаеп, матур гына йөрешеп, бер-берсенә ияләшеп киттеләр. Бер заманны Чаныш бабасы Солтанга Камәрия артыннан бал җибәргән. Камәрияләр тулай торагына шул күчтәнәчне алырга барган иде дә, илле генә сөйләшеп киттеләр. Кызыл почмакта танцы көне икән, шунда төштеләр, биеделәр. Шәһәрдә яхшы кино күрсәтәләр иде, шунда барырга килештеләр. Атна-ун көннән соң комсомол активы җыелышында очраштылар, эш беткәч, Яшьләр үзәгендәге диско-барга киттеләр. Сүзләре байтак ара авыл хәбәрләреннән, тулай торак вакыйгаларыннан, таныш-белешләрне искә алудан узмады. Сәлам дә хәл-әхвәл, сәлам дә хәл-әхвәл...

Бер чакны Солтан аны бүлмәләрендә ялгызын гына туры китерде. Камәрия яңа гына мунчадан кайтып кергән, авыл әбиләре сыман, чынаяк тәлинкәсенә өрә-өрә лимонлы чәй эчеп утыра иде. Аны да кыстады. Баш тартмады, утырды. Сүзгә-сүз ялганды, уенкөлке китте. Күчтәнәчсез кергәне өчен Солтанга бераз уңайсыз булды-булуын. Ә базардан бер тәңкәгә сатып алынган лимонлы чәй тәмле иде. «Рәхмәт,— диде Солтан,— сый-хөрмәтең өчен икенче юлы әлү кагы алып килермен.» Камәрия: «Апкил, апкил, мунчадан соң бик тансык ул,— диде.— Тик кара аны, онытасы түгел, яме?»

Камәрия зәңгәр җирлеккә кызыл чәчәкләр сурәте төшкән гади генә тегелешле бумази халаттан иде. Чумып диярлек, челтәр аслы тимер караватка утырган. Шуңа күрә тезләре ачык, йомырыланып калкып торалар. Халатының аскы ике төймәсе әллә каптырылмаган, әллә ычкынган, шәрә ботлары үзеннән-үзе күз карашын тарта. Карасана, кыз төскә-биткә хәйран-тамаша икән. Йөзе әле генә эшләп кергәндәй алсуланган. Матурлыгы бүген генә кирәк булыр өчен кычкырып тормый, ә һәрвакыт теләрдәй. Бар шундыйлар. Сөйләшүе тыйнак, сабыр. Ясалмалылыкның, акыллы булып күренергә теләүнең эзе дә юк. Солтан бер пыяласы чатнаган кара күзлектән, Камәрия аның тутырып-тутырып каравын сизмәде дә бугай. Әмма кай арада итәген тартып, халат төймәләрен яшертен генә сәдәплэп тә өлгерде. Урынында кузгалгалап, итәген тартканда, аның гәүдәсе сылулыгын Солтан беренче тапкыр күрде шикелле. Ә шул көнгә кадәр ул боларның һичкайсына игътибар итмәгән икән. Бактың исә чәчен татарча шома итеп, уртада нечкә генә ак, туры эз калдырып тараган һәм ике толымлап үргән Камәрия чибәр икән лабаса!

Гореф-гадәт кушканча, Камәрия аны озата чыкты. Егетләр белән кызлар ягы уртасындагы урам якка караган тәрәзә каршысында

өйләргә ут алынганчы аны-моны сөйләшеп тордылар, нигәдер саубуллашырга ашыкмадылар. Солтан үзенең кичке күнегүгә соңлаганын да искәрмәде. Ул, назлы гына итеп, кызның бит алмасына иренен тидерде. Татар кызларына хас карышу-фәлән сизмәгәч, кыюланып иреннәннән дә үбеп алды...

Шуннан соң май ае кичләрендә урам буенча йолдызлар астында яисә ышыкланмый-нитмичә яңгырда йөрүләр дә булды. Камариянең тулай торагы янындагы чокыр төбеннән — Кызыл позиция урамына янәшә поезд юлы үтә иде. Шул чокырның яшел үлән баскан уйсу бер төшендә чынлап торып дигәндәй беренче үбешү назы кичерделәр. Бүтән юлы сәгатьне билгеләп, кем күпмегә түзә дип үбештеләр. Сәгать сылтау гына булган, күрәсең. Вакыт агышын узып киткән поезд утларыннан, аларның җирне калтыратуыннан гына тойдылар...

Солтан вәгъдә иткән әлү кагын алып килергә онытты, әлбәттә. Камәрия дә исенә төшермәде. Егет көлеп: «Йөзләремне сары лимоның белән генә саргайттың»,— дия иде. Камәриянең: «Ватык пыялалы күзлегеңне бел, яме?» — дигән җавабыннан Солтан кызның үзен тәмам үз иткәнлеген аңлады.

Шулай итеп, аларның кичләре генә түгел, хисләре дә уртакка әйләнде. Тора-бара Камәриянең Солтаннар фатирына килеп күренгәләве дә гадәтигә әверелде. Авылга да алдан килешеп, бергә кайткалый башладылар. Шәһәрдә култыклашып йөрсәләр дә, авылда алай күренергә кыймадылар-кыюын. Ләкин авыл кешеләренең сизгерлегеннән ничек яшеренмәк, качмак кирәк? Хәбәре солдат егет Иштуганга да көне-сәгате белән дигәндәй ирешелгән. Камәрия җавап бирмәсә дә, ара-тирә язгалый иде әле. Камәрия моны сер итеп тотмады.

Ә бер заманны, Солтанның әнкәсен ашыгыч төстә эшенә — больницага чакыртып алгач һәм ул аннан улына: «Бүген кайта алмыйм, борчылып торма»,— дип шылтыраткач, Камәрия беренче тапкыр куна калды...

Шуннан соң, гәрчә авыз ачып сүз катмасалар да, уртак киләчәк хакындагы җитди ният күңелләренә оя корган иде инде. Ләкин Камәриягә бер заманны бик кирәге чыгуы ихтимал булган әлү кагы салынган кайнар чәйне кара-каршы утырып һәм тыннары белән өреп суыта-суыта эчүләр хыялда гына калды.

Әйе, туган көне мәҗлесеннән соң Солтан төнге урамга чыгып китте. Бабалары Кадрәк белән Чанышның, төн ката йөрмә, дигәненә колак салмады. Аны тышка Камәрияне юксынуы чакырды. Алар ул көнне Казаннан авылга бергә кайтканнар, килешенгән булмаса да, очрашырга тиеш иделәр. Клубка барды — аннан таралышканнар. Камәрия өйләрендә дә юк икән. Һич таба алмады.

Бабаларының өйләре авылның түбән очында. Эч пошуын басарга теләп, Солтан инеш ярына барып басты. Аннары үз уйларына чумып, төнге тавышларны тыңлый-тыңлый, язгы исләрне исни-исни зур елгада төзелеп бетеп яткан су электр станциясе тарафындагы яктылыкка каршы китте. Ул якта кинәт балкыш уйнаклап алды, ниндидер тонык шартлау авазы ишетелде. «Яшенме соң?» — дип уйлады ул. Юк, күк йөзе чиста, йолдызлар ачык, төзелештә берәр нишләгәннәрдер, күрәсең. Чакрым ярымнар тирәсе атлый торгач, ташландык урыс зиратына күтәрелә башлады. Ә мондагы рус авылы, су күтәрелү сәбәпле, алты ел элек алар авылына күчкән иде.

Шулвакыт ул бер моң сызылуын ишетте. Үткер пәке кискән яңа яра шулай сулык-сулык килеп сызлана. Әлеге моң ай нурының үләннәрне, чәчәкләрне, агач яфракларын, каен тузын коендыруы идеме, әллә зиратны тутырып торган төнге шом булды микән — ул

моның белән кызыксынмады. Шул моңнан, шул шомнан котылырга теләгән шикелле, яр буенда тиз генә чишенде дә тын суга сузылып яткан ай юлы астыңа чумды. Балан чәчәк атса да һәм күке кычкырса да, су шактый салкын иде әле. Әмма зыянлы түгел, ул чыныккан кеше. Боз ватып һәм бәке ясап, кышкы суда да коенганы бар. Өскә калкып, башта агымга каршы, аннары агым уңаена йөзеп килде. Хәер, елганың агымы сизелми дә инде, хәзер монда киң сусаклагыч. Шуннан соң ярга чыкты, киенде. Ә теге моң сызлануы тирә-юньгә җыр булып тарала иде инде. Чәчен тарагач, ул сәерсенеп җыр ишетелгән якка — үр башындагы чиркәүнең кара шәүләсенә таба китте.

*Сандугачның баласы*
*Алты бөртек барысы.*
*Юынсам, суларга чыга*
*Йөзләремнең сарысы.*

Атлаган саен, җыр ачыграк, инде аяныч төсмере белән өртелеп ишетелде:

*Сандугачның балалары*
*Тезелә каеннарга.*
*Сөялсәм, каеннар авар*
*Миндәге кайгыларга.*

Ул, җыр иясен күрмәсә дә, таныды. Таныды да — шаккатты: аның туган көненә килергә тиеш булып та килми калган Камәрия җырлый иде!

Арыш дулкыннары бер ачып, бер каплап торган такыр юл борылмалары шикелле, җыр әле көчәеп, әле тоныгаеп ишетелде. Сагаеп тыңлады: Камәрия чиркәүнең аргы ягында икән. Чиркәү үр кашында ук түгел, түбәндәрәк, үрнең түшендәрәк. Кыз шунда моңаеп утыра иде, күрәсең. Кинәт арттан килеп чыгып аны өркетмәс өчен, Солтан караңгыда болай да шомарак атларга тырышкан адымнарын тагын да сагайтты, зираттагы күләгәләргә сыенып кына барды. Чиркәү яныннан узганда җыр аңа ишетелмәс булды һәм, күләгәдән чыгуга, җырның:

*Төштем кайгы дәрьясына,*
*Чыга алмам йөзеп тә,*

— дигән сүзләре аның йөзенә кара яулык булып ябылды сыман.

Шуннан соң Камәрия тынды, бераздан:

— Нишләдем мин, нишләдем?! — дип, әллә ничек — Солтан беркайчан да ишетмәгән сыктау белән еларга кереште. Ә юк, аның болай сыкрап елаганның шаһиты булганы бар. Шулай итеп, Солтанның очучы әтисе Рево Наймушин авиация һәлакәтендә вафат булгач, әнисе өзгәләнде бит, әнисе. Күптән булган хәл.

Мәҗлесендә тиеш кадәр генә хәмер заты эчкән булса да, ул тамчы да исерек түгел, су коенгач, тәмам айнып калган иде инде. Ләкин шул чакны күз алдында пәйда булган күренештән аңы тагын чуалды, зиһене томаланды, аяк астындагы җир тотрыклыгын югалтты. Күзенә туп-туры көчле яктылык нуры юнәлтеләр диярсең: уң кулы белән йөзен каплады. Ике кабер ташы арасында аңа аркан килеш Камәрия утыра иде. Талгын гына чайкала, бөрешкән, сулкылдап калтырана. Солтан дәшкәч, ул аңын югалтып ауды.

...Камәрия ике көннән соң гына — кара төн уртасында больницада ят, ямьсез тавыш белән көлеп уянды. Көндез үз янына килгән Солтан белән ул теләр-теләмәс кенә, танымыйчарак сөйләште. «Йөрмә инде, бетте, челпәрәмә килде...» — диде ул һәм, читкә борылып, башка ләм-мим сүз катмады. Терелеп чыккач, көндезге укуын ташлады, читтән торып укуга күчте. Авыл шифаханәсенә шәфкать

туташы булып эшкә керде, ә техникумын тәмамлагач, педиатр булып эшли башлады. Шул төннән аның башы вакыт-вакыт чыдамастай авырта торган булып калды...

Бөтенесен Иштуган китереп чыгарган. Шул төнне ул Камәрияне аңлашырга дип чакырып алган. Сөйләшә-сөйләшә инеш буенча шушы зиратка ук килеп җиткәннәр. Ул кызның күңеленә алай да, болай да басма салырга тырышып караган. Шаян төстә юмалап та, кырыс сүз белән дә, ялварып та Камәриянең күңелен яңадан үзенә карата алмаганына ышангач, аны кабер ташы артына төртеп еккан, ә үзе читкә йөгергән дә, җиргә ятып, күкрәге астында кул гранатасы шартлаткан...

Горур егет иде шул. Ул Әфганстан шаукымнары аша узу да егетнең җанында һәм зиһенендә төзәлмәс яра калдырган булса кирәк. Хәтәр сугыш, яман үлемнәр аша исән-имин калган егет, җан атып йөргән кызы баш тарткач, яшәү яме калмады дип санаган, күрәсең.

Солтан бу хакта күп уйланды. Ә бәлки бу фаҗигадә иң гаепле кеше ул үзедер? Камәрия белән Иштуган арасына ул кермәдемени? Ул. Әлбәттә, ул. Кем әйткәндәй, йөрәккә әмер бирә алмыйсың. Шулай да баштанаяк, бөтен гомергә җитәрлек гаепле. Кеше алдында акланырга да ярыйдыр, ә үз вөҗданың алдында?

Дөрес, ахыр килеп, Камәрия белән Иштуган арасы суынган иде ич инде. Укып бетергәчме, кайчан, бәлки Камәрия бөтенләй башка берәүне сайламас идеме? Әнә ич, Солтан белән йөреп китте. Матур итеп, ихластан. Инсафлы төстә, өметле, якты ният белән. Ә Солтан урынына аның бүтән берәүне очратуы мөмкин түгел идемени?

Юк шул. Сары лимонлы чәйне Камәрия эчертте, әлү кагын Солтан вәгъдә итте.

Тормышны дәвам итү белән мәшгуль булган тузбаш еланнарны да ул — Солтан аерып, туздырып ташлады. Әйтерсең лә алар моңарчы Камәрия белән аның арасында ятканнар.

Яшәр өчен аңа Камәрия кирәк иде. Башка һичкем. Ә хәзер, җылы учак янында тәмле балык ашап утырыр өчен аңа җайлы таш кирәк булды. Таш кубарды — еланнарга юлыкты. Ә бу кайтуында, кичә ул Камәрия белән килеште инде. Күрештеләр, озаклап сөйләштеләр. Аңлаштылар бугай. Камәрия аның күкрәгенә башын салып, иркенләп елады, сарылып-сарылып үпте һәм, сискәндереп атылган йолдыз шикелле, Солтанның кочагыннан кинәт читләшеп, капкаларыннан кереп китте.

Степанга таш алып килергә булышырга кирәк иде. Солтан әле генә еланнар бөгәрләнеп яткан яр куышына карады. Анда кояш нурлары бәреп кергән иде инде.

«Мне возмездие и аз воздам»...

Солтан бу сүзләрнең күңеленә каян, нигә килгәнен ачыклап өлгермәде. Игътибарын бая гына еланнар яткан куышның эче җәлеп итте.

— Степа, кара әле! — дип кычкырды ул.— Монда кирпеч өелгән. Әллә стена калдыгы инде? Әллә берәр төрле нигез микән?

Ишеп төшергән ташны бер күтәреп, бер аударып, Степан мышный-мышный учакка таба авыштыра иде, тураеп куышка карады. Аннан тигез, пөхтә итеп салынган кирпечләр күренеп тора иде.

— Нигез түгел бу, парин,— диде Степан.

— Җир астында түбә булмас инде тагын!

— Нигә булмасын ди? Нәкъ үзе — түбә. Гөмбәз. Күрмисеңмени — түгәрәкләнеп килгән.

— Бәлки баздыр?

— Зираттамы? Кабер бу... Ә бәлкем хәзинә базыдыр, ә?!

— Ә еланнар шуны саклап ятканмы?

Степан кулын куышка тыгып, кирпечләргә чирткәләп алды, бармак битен аксыл-соры измә буенча йөртеп карады.

— Кабер бу,— диде ул.— Ахирәт йортына караганда, андыймондый гына мәет күмелмәгән монда.

— Да, күмгәннәр дә соң! Иренмәгәннәр.

— Чи усак тактадан ясалган стандарт табут түгел инде,— дип, Степан ярның комын, ташларын ишәргә керешге.

— Әллә кулың кычытамы? — дип сорады Солтан.— Кабер ачу — аракы шешәсе ачу түгел ул сиңа. Моңа статья бар.

— Статьядан минем әни дә курыкмаган. Минем каберне ачып караган.

— Минем йөрәк җитмәс иде, Степ.

— Ул бит синеке! Ана йөрәгендә баласына кабер була димени? Биш ярты биреп, ир-атларны яллаган да ачтырган. Төнлә инде бу. Качып. Таныдым, минем улым, дигән. Мин түгел икәнне әтигә дә әйтмәгән. Ә мин ул чакта Киевтә аңсыз ятам. Кайтып төштем — танымадылар. Чырайны үзең күрәсең бит. Кайвакытны мин дип күмелгән шул кабергә төшеп ятасыларым килгән чаклар була, яшьти... Тик анда күмелгән егетне, бу минем кабер, дип куып чыгарып булмый бит инде... Ә аның урынына кем күмелгән? Анасы кем каберенә яшь коя? Алла белсен.

— Син ул ананы эзләмисеңме соң?

— Хайван мәллә мин?! Минем өчен җирдә яткан ул егетне ничек тагын бер тапкыр үтерәсең ди? Анасы да бар бит әле. Аның бәхетенә кем кул салыр икән?

Солтан, юлдашының соңгы сүзенә сәерсенеп, тетрәп китте.

— Бәхетенә?! — дип сорады ул.

— Баласының һич югы кабере булган ана бәхетле ул, яшьти... Син бар, балыкларны кара. Ә мин бу кирпечне тишәм әле.

— Үзеңә кара алайса,— дип килеште Солтан.— Мине теге дөнья кызыксындырмый әле. Бусында да эш муеннан.

Кулын югач, инде тәмам пешкән, тәмле ис бөркеп торган балыкларны казыклардан алып, ташка куйганда Солтан: «Татар зиратында булсак, мин аңа юл куймас идем,— дип уйлады. Шундук үзүзеннән: — Ә ни өчен? — дип сорады. Һәм җавап та бирде: — Татар зираты — ул минем дә үткәнем. Анда минем кандашларым — хурлауга юл куймас идем. Шул ук вакытта татар зираты — минем киләчәгем дә. Миңа шунда барасы, шунда күмеләсе...» Тагын бер нәрсә бар: шикләндерә. Зираттан курку, түмгәк кенә булып калган билгесез каберләргә басудан тайчыну аның канына сеңгән. Куркыта. Кеше исәннәр хөкеменә дучар булудан кача, ә үлгәннәр хөкеме аны куркыта ук. Исәннәр фәкать җәза гына бирә, ә үлгәннәр үч ала...

Степан ашыкмады. Кулын юып, табынга килеп утырды. Стакан төбендә калган аракыга чак кына өстәп, эчеп куйды, тәмләп балык ашады.

— Бер нәрсә искә төште әле,— диде ул.

— Соң?

— А! — диде Степан кулын селтәп. Аннары, йөзен җыерырга теләп, кашларын кушырды. Әмма ул үз кичерешләрен йөз сызыклары белән белгертүдән мәхрүм. Бит тиресе киергегә тартырылган тукыма сыман. Ул кул сырты белән иренен сөртте дә аягына басты.

— Аннары сөйләрмен әле,— диде ул. Әвеш-тәвеш килеп, көймәгә керде һәм лом алып чыкты.

— Кара аны, сак кылан. Нарат басмасын. Таш та хәтәр,— диде Солтан.

Син утырып тор алайса.

— Яхшы.

— Ярый, мин тиз.

Степан өстенә аварлык нарат һәм ишелергә торган зур таш астына кереп, тукылдатырга да керешге. Чиркәү гөмбәзеннән кара каргалар күтәрелеп, читкә очып киттеләр. Кайдадыр тукран тукылдатырга тотынды. Ул аваз, Степанның лом белән кирпечкә бәрүенә кушылып, икәүнең тимерчелектә тимер чүкүен хәтерләтте. Тук-тук-тук... бусы — тукран. Тук-тук... бусы — Степан. Алар, шул рәвешчә, тирә-юньне баскан тынлыкны ваталар кебек иде. Берсе корыган агач аша тере кортка таба чокый, икенчесе кызыл кирпечләр аша — черек (мөгаен, шулайдыр) табутка таба. Моны ап-ачык рәвештә күз алдына китергән Солтан баш тиресенең, чәч төпләренең кымыржып-кычытып куйганын тойды.

Учак ялкыннары басылды инде. Көйрәп торган күмер араларыннан тымызык кына итеп, зәңгәр ут канатлары җилферди. Алар карашны җәлеп итәләр, күңелне тынычлык белән өретәләр, изрәтәләр. Учакка карап утыруы рәхәт иде. Ләкин тукран белән Степанның өзлексез тукылдавы уйларны тарата. Хәзер Солтанның барыннан да бигрәк Камәрия турында уйлыйсы килде. Ә ул нигәдер юк, кире уйлады микәнни? Солтан ялгызлыгыннан котылыр һәм эч пошуын басар өчен көймәдәге магнитофонын алып чыкты, әйләндереп җибәрде. Музыканы исәпләмәгәндә, елга буе тын иде. Ни теплоход, ни баржа узмый. Әллә ничә кат тыңлаганга күрә төссезләнгән көй бу тынлыкка, бу киңлеккә туры килми, ятышсыз. Ул магнитофонны сүндерде, свитерын, күлмәген салып, аркасын кояшка куеп утырды. Кояш җылысы тәнен изрәтте, эчелгән аракы зиһенен таратты. Вакыт агышы туктаган кебек булды.

Солтан туралган тәре-утыннарны учакка салды. Каралы-сарылы утыннар башта көйде, аннары алар арасындагы бушлыкны ялкын телләре биләде. Бу тәрене кемдер ясаган, ә ул яга...

Тук-тук-тук...

Бу аваз кинәт Солтанга кайчандыр дәү бабасы Чаныш сөйләп биргән бер вакыйганы исенә төшерде. Үзенең Наймушин дигән фамилиясенең каян чыкканы, кемнән башланганы белән кызыксынып, бабасыннан сораштырган иде. Чаныш карт аңа гыйбрәтле тарих сөйләде. Хәзер гүя Солтан каршында тәре калдыкларыннан тергезелгән учак янмый, әнә шул тарихның хәтергә иңеп калган сары сәхифәләре ялкынлана иде.

...Бер очы бөкәнгә куеп күтәртелгән коры имән агачы дүртенче ягыннан да борыслап уелып, агарып килә иде инде. Агач нык. Кан тамырлары бүртеп чыккан кул мөһерле үткер балтаны җәйлы гына итеп ару-талчыгусыз селти дә селти. Кабергә бастырып куяр өчен үз гомерендә беренче тапкыр тәре юнучы кеше — татар агае Наймуш. Ул имән агачының аскы өлешен биш сөям кадәрле юнмый калдырды — җиргә күмәсе төше. Агачны дүрт яклап юнганнан соң, ул борысның кырларын алып чыкты һәм, ян кесәсеннән чиккән янчык чыгарып, эре итеп чабылган тәмәкене гарәп хәрефләре чуарланган гәҗит кисәгенә төреп кабызды. Тәре ясау гөнаһмы, савапмы, дип уйлады. Әлегә кадәр аның мөселман өммәтеннән булган мәет рухына багышлатып, Корьән чыгарткан урыс кешесе хакында ишеткәне юк. Ә менә ул тәре ясый. Шәригать җәһәтеннән караганда тәгаен гөнаһ гамәл инде. Мулла белән киңәштабыш корырга вакыты калмады. Аның каруы ул үз-үзе белән киңәште. Мәетне кичә төнгә каршы затлы кара табутка салып, сугыштан алып кайттылар. Аның каберенә бастырып куяр өчен тәре ясауның савап саналырга хаклы ягы да бардыр...

Чаныш бабасы Наймуш картның кемгә атап тәре ясаганын да әйткән иде. Хәзер онытылган инде. Ниндидер ни татар, ни рус

фамилияле иде ахрысы. Бу җирләрнең алпавыты булган. Каты куллы, коры сүзле дигәне истә. Наймуш әнә шуларның утарында управляющий сыманрак бер эштә торган. Моның өчен аңа утызынчы елларда бераз эләккән дә булган. Колхозга кермәгән. Сөрә язганнар. Тик монысы бүтән вакыйга...

Тук-тук-тук...

Утар сугыш аркасында шактый бөлгән, таркалган, калдыкпостык җирләр сатылып беткән, арендага таратылган, мал-мөлкәт җилгә очкан тузан кебек генә калган. Керем-төшем юк диярлек. Хәзер ул җирләрнең күбесендә ачы әрем, алабута котырып үсә. Кешеләрнең җир эшкәртергә, иген игәргә көч-әхвәле, чарасы калмады. Гуҗ сугыш кешеләрне дә, атларны да йотып кына тора. Татарда да, урыста да, чуваш һәм удмуртта да бердәй хәлсез карткоры да хатын-кыз гына. Сугыш кешеләрнең кайсысын кул-аяксыз, кайсысын дөм-сукыр итте, кайсысының үпкәсен газ белән көйдереп кайтарды. Гарип тә горәбә. Алынып бетмәгән атларның кабыргалары гына тырпаеп калды. Адәмнәр арасында хәл алып, көчәеп, байтак җиргә хуҗа булып киткәннәре дә бар. Тик синең кайгың, тамагың ачлыгы аларны борчымый. Үлем-китем күп. Мулла аларга багышлап бер чыккан Коръәнен дистәләп мәрхүм рухына бер очтан, уптым илаһи гына укый.

Инде менә байларга да чират җиткән. Хатыны Мария хәрәкәттәге армиядән ире Кулунчаковны алып кайтты. Полковникның мәетенә ияреп кайткан акча күмү чыгымнарына чак җитә язды, поминканы анасы Марфа Петровнаның чыбык очы туганы кибетче Савелий үз өстенә алды.

Наймушның тәре ясавын бу мәхшәр эчендә аллаһе тәгалә ничек тә кичерер. Заманы шундый: кешеләр чиста, чын күңелдән кылган гамәлләргә мохтаҗ чак. Шулай икән, урысның Христосы да, мөселманнарның Мөхәммәт пәйгамбәре дә бичара адәм балаларының бер-берсе хакына кылган яхшылыкларын үзара килешеп кабул кылырга тиешләр. Йөз чөерәләр икән, күмәк бәла-каза алдында адәм балалары ул хәтле дә горур түгелләр: аллалар кешеләрнең гөнаһсын ярлыкамаса да, кешеләр аллаларның горурлыгын кичерергә разый-бәхилләр.

Тәмәке төпчеген баш бармагы бите белән үзе утырган бүкәнгә басып сүндергәч, Наймуш карт тагын балтасына тотынды.

Аның моңарчы тәре ясаганы юк. Шулай да ничек тиеш икәнлеге аңа мәгълүм. Иртән иртүк урыс зиратына барып, буй баганасын да, аркылы зур һәм бәләкәй агачларын да, һәр өлешенең арасын сөямләп үлчәде.

Наймуш имән борысны җиренә җиткереп ышкылады, шулай ук сөямләп үлчәгәч, пычкы белән өлешләп кисте: озыны баганага, икесе аркылы кагарга. Шуннан соң аларны тоташтырасы урыннарны билгеләп, пычкы һәм өтерге белән тигез, пөхтә итеп ырмаулады, балта түтәсе белән борысларны бер-берсенә кагып кертте. Аның агач эшенә кулы яхшы ята иде. Өч борыс та нык беректе, хәзер аларны кирегә бәреп чыгаруы каккандагыдан күбрәк көч алыр иде.

Ул тәрене бастырып карады. Биеклеккә сажиннан артыграк, ә җиргә төшкән күләгәсе күпкә озынрак. Тәре кайсы ягы беләндер кеше сынын хәтерләтте.

Наймуш тәрене җиргә сузып салды, ул үз күләгәсен каплап ятты, һәр сигез очы үз күләгәсенең сигез очы белән кушылды.

Тук-тук-тук, тук-тук...

Солтан учак янындагы тәрегә карады. «Тәренең сигез очы алты континентка, шуларга өстәп, җиргә һәм күккә омтылышны белгертми микән? — дип уйлады ул.— Тәре бөтен дөньяга хуҗа булу-

ны дәгъва итмиме?» Аның мондый фараз хакында һичкайдан укыганы юк. Бу фаразын кем беләндер уртаклашырга теләде. Ләкин Степанны шөгыленнән бүлдермәде. Гомумән, Степан үз ниятенә ирешә алмастыр. Бар, хикмәтле измәгә катырылган кирпечләрне кәкре лом һәм балта белән генә алдырып кара! Динамит кирәк. Әнә чиркәү. Шундый ук куе кызыл төстәге кирпечтән, измәсе дә бер үк — аксыл-соры. Ә стенасында ник бер ярык заты булсын! Степан туяр да туктар...



## III

Ә Степан тынган икән инде. Солтан карашын учактан ярга күчерде. Дусты эшен ташлаган, аңа таба килә. Бил тиңентен шәрә. Итләч күкрәге, корсагы лычма тир. Бер сүз дә катмыйча, елга ярына килеп басты да йөзенә, күкрәгенә, корсагына учлап-учлап су сипте, кулбашын, беләкләрен юды.

— Окопка кереп посканмыни! — диде ул учак янына килеп утыргач. Итекләрен салды, аяк чолгавын җәеп, таратып куйды.

— Ул склепны күмелгән кеше салмаган бит, нигә аны сүгәсең? — диде Солтан.— Бәйләндең син бу кабергә, туган!

— Беләсеңме, анда бер хайван ятмый микән дигән уй килде әле. Патша полковнигы. Ялгышмасам, Кулунчаков булса кирәк. Шушы җирләрнең алпавытлары токымыннан. Егерменче гасырның соңгы чиреген күрсәтәм мин аңа хәзер! — дип, Степан коры һәм хиссез төстә көлеп куйды.— Череп таркалган сөякләрен көл итеп җилгә очырмасаммы?!

Солтан әллә нишләп китте. Сискәнеп. Юк, куркып ук бугай. Куркып кына да түгелдер. Степанның сүзләреннән соң нинди хис кичергәнен ул аңлап өлгермичә калды. Нинди дер салкын җил кагылып уздымыни! Әле генә учакка карап, күз алдына китергән күренеш кайчандыр чыннан да булган микәнни? Степан да ишеткәч һәм хәтерләп калгач, Чаныш бабасы сөйләгән хәл заманында күпләргә билгеле булган инде алайса.

— Син ул полковник турында каян беләсең, Степа? — дип сорады ул.

— Әби мәрхүм сөйләгән иде. Әллә кайчан инде. Бабай үлгән елны. Минем әби шул полковник утарында йорт хезмәтчесе булган. Син аны белмисең. Безне сезнең авылыгызга күчергәнче үк үлде... Мин бу каберне бик табасым килгән иде.

— Хәтәр хәтерле син.

— Без бит авыл малае. Хәтер чүп-чарсыз. Кыш үтә — яз килә, җәй җитә — көз башлана. Һәммә нәрсә әз-мәзләп кенә тия. Әби сөйләгәннәрне башка нәрсә күммәгән. Шул гына,— дип Степан кулмәген йомарлап битен сөртте, зират ягына борылып: — Нәкъ шуның кабере бу, парин,— диде.— Наратына кара, җитмеш еллар чамасында.

— Ярар, юк белән баш катырма.

— Син бәйләнмичәрәк кенә утыр әле, яшьти. Ул монда унҗиденче елдан бирле ята.

— Сиксән бишенче елда син килеп чыгасыны көтепме?

— Бер заманны аңа барыбер кубарылып чыгасы. Ахырзаман җиткәч...

— Ә син азапланып кирпеч дөмбәслисең! Үзе чыкканын көт. Сөйләшеп утырырсыз... Килер ахырзаман. Син дә, ул да каберләрегез өстенә чыгып утырырсыз. Күрешерсез. Син: «Нихәл, иптәш полковник, исән-сау гынамы?» — диярсең. «Ничава, парин, бер көе.

Үзең ни хәлдә соң? Быел гектардан ничә центнер суктырдың?» дип сорар бәлки... Аннары житәкләшеп Алла каршысына барып басарсыз. «Ну-с,— дияр Алла,— ни кырдыгыз?» Полковник сугышта ничә кеше кырганын сөйләр, ә син гектардан күпме уңыш алганыңны. Шуннан соң Алла өстәл тартмасыннан путевкалар бланкасы чыгарып, сезгә тиешенчә тутырырга кушар. Аннары тамгасын салып да сезне мәңгелек ялга озатыр. Полковникны — җәннәткә, сине — җәһәннәмгә.

— Кулунчаковны — җәннәткә, ә сержант Степан Масленниковны — җәһәннәмгә!.. Гаделсезлек ич бу! — дип, Степан тәмләп кимереп утырган балык башын киң селтәнеп елгага томырды да, арлыбирле йөренеп алгач, кырт борылып, Солтанга карады. Кулы биләндә, теш казналарын кыскан, күзендә үпкә чаткысы. Әйтерсең Солтан — Алланың үзе, ә бу аннан чынлап торып җавап таләп итә. Ул эре тешләре арасыннан черт иттереп читкә төкерде.— Шыттырасың да инде, ә?!

— Син кызма, Степан, кызма. Ходай тәгалә сабыр булырга кушкан. Болай кызсаң, ул сине кабат Газраил кулына ук тапшырмагае. Ул сиңа колхоз председателе түгел, каршы дәшкәнне өнәмәве ихтимал. Тыңлап бетер... Алла каршысына корсагыңны болай ук терәп басма — тир исең килер. Түбәнчелек белән башыңны и, күзеңне яшер. Аннары басынкы гына: «Ул кадәр үк шыттырма инде, Раббым, мин сала малае инде, культура житеп бетми, дорфарак сөйләшеп ташлыйм. Ну шулай да чәйнәбрәк каптыр: ни өчен полковник Кулунчаковны җәннәткә җибәрәсең дә, мине җәһәннәмгә олактырасың?» — дип сора. Телеңне җалләмә.

Степанның кулы салынып төште, ул ташка утырды.

— Менә шулай... Тынычландыңмы? Алланың сиңа болайрак җавап бирүе ихтимал: «Мин сине, Степан җаным, шуның өчен тәмугка олактырам ки, чөнки оҗмахка эләксәң, син бетәсең. Беләсеңме нигә бетәсең? Чөнки син анда яшәргә күнекмәгәнсең». Шулай булгач, Аллага үпкәләмә инде, туган. Бүтән аллаларга үпкәлә.

— Мин күзгегә генә үпкәлим, яшьти. Өч ел инде рәтләп көзгегә караганым юк. Кырынганда да күзне йомып кына кырынам...

Степан, кулы белән каты басып, битен сыпырды. Гүя йөзенә ябышкан ч и т б и т л е к н е кубарып ташларга теләве иде аның.

— Син мине кызганма, яшьти,— диде ул.— Миңа Настюшаның кызгануы да җиткән... Көткән. Курыкмады, баш тартмады. Торабыз. Торабыз да бит... Мин шул ук Настюша белән. Ә ул кем белән тора? Мин бит үземне үзем дә танымыйм, Солтан...

Степан авыр атлап, алпан-тилпән чайкала-чайкала яланаяк көенчә ярга таба китте. Ул тарафта тагын лом белән кирпеч төйгән тавыш ишетелде: тук-тук-тук... Әйтерсең лә офыккача түгәрәкләнеп торган бу җирнең йөрәге шулай тибә иде.

Солтан аның артыннан моңсу гына карап калды, беравык уйсыз утырды.

Башта өзек-өзек, аннары тоташлый чикерткәләр зыңларга кереште. Елга буенча үзйөрешле баржа узып бара, аның артыннан киң дулкыннар таралды. Дулкын каккан саен, савыттагы балыклар шыбырдашты.

Ә Степан дөмбәсли дә дөмбәсли.

— Монда кил әле! — дип кычкырды ул. Солтанны ломына таянган килеш көтеп алды.— Күпме дөмбәслим, йодрык кадәр тишек уелды. Хет егылып үл — бармый.

— Армиядә кем идең син?

— Сапер.

— Сапер!— диде Солтан үчекләп.— Ә фортификацияне шайтаным да белмисең. Син склепның гөмбәзен чукыйсың бит, ә монда

кирпечләр яңы белән салынган. Астанрак — стенасыннан тиш.

Степан комны ишеп төшерде. Ком, шулай ук, убылып төшәргә торган зур таш астыннан да купты. Таш урыныннан кузгалды, өске ягы кара туфрактан аерылды, үсемлекләрнең ак, наратның көрән тамырлары күренде.

— Саклан!— дип кычкырды Степан һәм Солтанны таш астыннан читкә этеп җибәрде.

Нарат төбендәге куе зелпе куагы арасыннан ике сандугач пырхылдап чыкты. Таш убылмый калды. Аны агачның ниндидер тамыры бәйләгәндәй тота иде, күрәсең.

Маңгаена бәреп чыккан салкын тирне сөртеп, Солтан:

— Башта ташны ишәргә кирәк,— диде.

Баскан урыннан бер карыш та тайпылмыйча, Степан алдан ташка, аннары авыш наратка сынап карады.

— Ярамый. Стенаны каплый ич. Нарат та аумагае.

— Маташма дим ич!

— Юк инде, парин. Минем, бәлки, полковник яткан җәннәтне күрәсем киләдер.

Шуннан, юри генә дәгәндәй, ломга Солтан ябышты. Сулышы иркен иде, көч-куәте үзе белән. Лом тавышы кайтаваз булып яңгырамый иде инде: һава кызган, һәр тавышны йота гына бара. Кирпеч нык, коры. Шикәр шакмагы хәтле генә кителә, ком, тузан булып коела. Бер кирпечне ваклап бетергәч, күршедәгеләре тоташлый кубар дип уйлаган иде. Кая ул! Измәсе тагын да катырак сыман. Кирпечләр чатнап ябышкан. Алай да икенчесе яртылаш диярлек кителеп чыкты. Шул рәвешчә ул ян-яктагы кирпечләрне дә кыеп алды. Алар артында тагын бер рәт тезелгән ич әле. Тышкы катны җитәрлек сүтмичә торып, анысына керешү файдасыз.

— Дәвам ит,— диде ул ломны иптәшенә биреп.

Аннан күрмәкче, Степан да тәртип белән генә чокыды, хасыйл булган тишекне шактый киңәйтте. Эчке катны җимерсәләр, кеше башы сыярлык тишек ачылачак иде.

Ломга тагын Солтан тотынды. Ялыктыргыч эштән туеп, ломны гайрәт белән орган иде, кирпечләрнең берьюлы икесе кубып, эчкә җимерелде. Ломы эчкә кереп, кулыннан ычкына язды. Селтәнгән шәпкә ул күкрәге белән тишеккә капланды. Йөзенә коры, салкынча саф һава өретелде. Һавадан җир дымы, бигрәк тә кабер исе килмәде. Хәтта гадәттә зиратта гына булучан ис тә тоелмады. Ул ломны тартып алып, караңгылыкка карады. Кабер эче шулкадәр дә караңгы булып күренде ки, Солтан үз битенә аның салкын күләгәсе төшүен дә сизде шикелле.

Эчтәге караңгылыкка күзе ияләшкәч, Солтан т е г е н н ә н үзенә текәлгән караш белән очрашты. Анда икона сөялеп тора иде. Аңа йөзе сагышлы, карашы моңсу һәм кырыс хатын сурәте төшерелгән. Ул сурәт нидер бирергә дә тели сыман, нидер таләп тә итә иде шикелле. Кирпеч тузаны аша Солтанга соры баш сөягенең буш күзе дә текәлгән иде.

Солтан читкә янтайды.

— Ни бар анда?— дип сорады Степан.

— Үзең кара. Син ашкындың ич.

Зелпе куагы арасына бая очып киткән кош әйләнеп кайтты. Йомыркаларын суытасы килмәгән инде. Пырылдап, икенчесе дә килеп җитте.

Кабер һавасын күкрәгеннән кысып чыгарырга теләгәндәй, Солтан тирән итеп сулыш алды.

— Йә?— диде ул.— Күңелең булдымы инде?

— Казанская Богоматерь!— дип пышылдады Степан.

— Ә полковнигың кайда соң, полковнигың?!

— Полковник... Энә ич. баш сөяге ята. Анныкыдыр.

Кызыксыну алдырды. Яктылыкны капламас өчен муенын җәйсыз сузып. Солтан эчкә карады. Бая күргәннең көтелмәгән тәэсиреннән арынган иде инде. Бу юлы әсәрләнмичә, салкын акыл белән күзәтте. Баягыча ук, игътибарын иң әүвәл икона сурәте җәлеп итте. Рәсем күңелгә иңеп керә кебек иде. Инде гаҗәпләндерми. куркытмый. шаккатырмый, бәлки гади, саран исәп белән аңны били.

Сурәт тактага төшерелгән. Буявы җете. ачык. Ходай анасының сурәте бил тиңентен төшерелгән. Сул кулында имчәк баласы. Уң кулын хәер-фатиха биреп сузган. Рәсем кызгылт кирпеч тузаны аша чәчелеп, тоныгаеп чагыла.

Эчтә икона белән баш сөягеннән гайре бүтән нәрсә күренми — караңгы. Ә юк, әнә, таш идәнгә елышкан кием калдыклары. Тагын — шул кием өстенә сузып салынган чәч толымы. Калын, сары чәч толымы.

— Полковник өйдә юк, иптәш Масленников,— диде Солтан.— Өйдә — полковникша гына. Дөрес, әле торып җитмәгән. Синең кайнар кофе ясап кертәнеңне көтеп ята булса кирәк.— Бармакларын бөгеп, Солтан кирпечкә каккалады:— Рөхсәтме, ханым?

Степан, йөзе белән тагын тишеккә капланып, кабер эчен күзләде.

— Полковник өйдә,— диде ул бераздан.

Кабер эчендә тонык кайтаваз:

— Өйдә-ә, —дип кабатлады.

Степан кулын артка сузды. Солтан аңа ломны тоттырды.

Шуннан соң тишек зурайганнан-зурайды. Кирпеч вагы тышка да, эчкә дә коелды. Лом белән бәргән саен, кабер буш мичкә шикелле гүләп җавап бирде.

## IV

*Елга еракларга сузылган Урсал үзәнен чикләүче Зур суга таба җиде көн, җиде төн буена ага да ага, ага да ага. Зур суга барып кушылгач та җиңелми әле ул: үз тәмен, үз җылысын тагын бер көн, бер төн буена саклый, әмма шуннан соң үз ярларын хәтерләми башлый инде. Су эзе ярда калса да, яр эзе суда калмый бит ул.*

*Елга белән бер үк юнәлештә, ярты чакрым чамасы читтәрәк, кояш батышы ягыннан кояш чыгышы тарафына торган саен биегәя барып, сирәк имәннәр, юкә белән каеннар һәм төрле куаклыклар белән капланган яисә бөтенләй шәрә, итәкләренә зур-зур ташлар ишелгән таулар сузылып китә. Тауларның текә урыннарындагы туфрак коры һәм ком-ташлы, ә ялпылыкларында — кара, уңдырышлы. Шуңа күрә бу җирләрдә бик борынгы заманнардан бирле күп итеп мал-туар асраган, иген иккән, сунарчылык кылган, балык тоткан көчле, зирәк, бай болгар ырулары, аларның токымнары, алар идарәсендәге башка кабиләләр яшәгән. Елга Зур су кочагында таралып, үз-үзен тәмам оныткканга кадәр үзеннән күтәрелгән иртәнге яки кичке томаннарда, кышкы кар-бураннарда шул халыкларның өзелмәс тере сулышын һәр тамчысында аларның сүнмәс рухларын, агымында сүрелмәс гайрәтен тоеп ага әле.*

*Ә тау итәкләреннән бәреп чыккан салкын чишмәләр, яшел үзәннәрдән килеп кушылган инешләр елганың суын гына тулыландырып калмыйча, хәтерен дә уяу тота. Шуңа күрә ул үз ярларының текә борылышларын урaганда да, тирән чоңгылларында хәл ала-ала черем иткәндә дә, Кояш һәм Ай тартымы, Айның фасыллары тәэсиренә карамастан, төп юнәлешен югалтмый иде. Ул гына да түгел: әнә шул чишмәләр, инешләр аңа язмышының үз ярларында яшәгән кешеләр тормышы белән бәйле икәнен искәртәләр. Ул кешеләрнең чит бас-*

*кыннарга каршы яшен яшьнәве кебек кыска бәрелешләре вакытында булсын, су өстенә боз катуыдай дәвамлы салкын сугышлар чорында булсын, елгада балык мул үрчи торган иде. Бигрәк тә җәен, чуртан, кырпы, осетр кебекләре. Алар елгаларны ташытырдай итеп аккан мәетләр белән туеналар, симерәләр, ләкин кешеләр ул балыкларны барыбер тоталар, ашыйлар иде. Мондый чакларда вак балыклар тынсыз кала һәм, ак корсакларын ялтыратып, вак дулкыннарда чайкала. Киек кошлар, балаларын ташлап, ерак күлләргә очып китә. Җәнлекләр су эчәргә төшми. Елганың суы таңнарда калка, шәфәкьләрдә бата торган Кояш белән бер төстә була. Аның хәтта төптәге йомшак ләмнәре дә кызыл канга манчыла, ә Зур судагы юлы күпкә озыная иде. Соңгы дәверләрдә кешеләрнең кан коешуы бетте, елганың күптәннән инде кан белән тозланганы, мәетләр белән бозылганы юк. Аның каравы, язмышына башка хәвеф яный башлады. Елгага шул ук тау итәкләреннән, киң үзәннәрдән кара май чишмәләре, кырлардан әче һәм сасы сыекчалар агып төшә башлады. Кайбер вакытларда елганың соры, тирән күзле чишмәләре генә капланмыйча, Кояш һәм Ай яктырткан зиһене дә карала торган булды.*

*Бер заманны, елганың нык ярларын дер селкетеп, корыч атларга утырган кешеләр килде. Алар Олы борылыш турысында җирне актарып, яңа яр уйдылар, елганы бүтән юлдан агызып тордылар да, иске ярны киңәйтеп, тоташ таштан буа будылар. Аннары елганы кире үз ярына кайтардылар. Шул урында аның су агышы гына түгел, ә сулышы да байтак тукталып торды, өстенә май җәелде, чуп-чар тулды. Ниһаять, ул урында зур гына с у с а к л а г ы ч барлыкка килде. Елга күтәрелде. Һәм, тар гына ярыкларга бәреп кергәннән соң, таш буадан түбән томырылды. Ярсыды, шаулады, тирләгән ат сыман күбекләнде. Күбекләре сәламәт ак төстә түгел, ә тимер күгәреге төсендә иде. Ул күбекләргә елга үз суында эрегән чит, шакшы матдәләрне ягарга тырышты. Һәм елга ярына кагып чыгарырга теләде. Әмма буа артындагы ярлары текә иде. Шуннан тегеләр күбек бүрекләре комлыкларга утырып калды. Ул урыннардан кошлар да, җәнлекләр дә читләшеп бетте.*

*Елганың агымы көчәйде. Камышлыкларны, комлыкларны, ташлыкларны су туктаусыз юды, айкады, урыннан-урынга таратты. Вак балыклар да, эреләре дә, уылдык чәчәр урын тапмыйча, таш буа астына тыгылышты. Юлларын югарыга таба ары дәвам итә алмагач, алар шул болганышта чәчәргә мәҗбүр булган уылдык, сөт боткасына тончыгып үләләр иде.*

*Бу да түгел, елга шул борылыштан читтәрәк ниндидер һава дулкыннары кайнарлыгын сизде. Ул моңарчы көтүчеләр яккан бер генә учакка да охшамаган иде. Кешеләр аның суын әнә шул кайнарлыкны йөгәндә тотар өчен куллана башладылар. Елга хәзер Олы борылышны тутырган бөтен суы белән кайнар көчәнешле электр тогы ясый башлады. Елганың буеннан-буена җиде көн, җиде төн, ә Зур суга кушылганнан соң тагын бер көн, бер төн аккан агымы озынайды, сузылды. Ул уза торган юл җыенысы уникe көн һәм уникe төнгә тигезләнде. Суының табигате үзгәрде. Елга Чулпан йолдызының да, хәтта Сатурн кыршауларының да йогынтысын тоя башлады. Аның үз суын таш буадагы шарламадан аска түгел, бәлки Кояшка коясы килә иде шикелле.*

*Антициклон уртасында кайнар көннәр һәм бөркү төннәр башланып, Кояшка таба омтылган койрыклы йолдыз Җиргә иң якын ноктага якынлашкан бер мәлне елга үзенең калтырана башлавын тойды. Бер генә мизгелгә аның агымы хәрәкәтсез калды, аннары туктады ук. Балыклар чәбәләнеп ярларга томырылды, аулак урыннарга*

*качты. Елганың горурлыгы, куанычы, сердәше булган Зур балык Олы борылышка җитәрлек яссы яр буена урнашкан умарталыкның бу араларда өч көн тоташлый яуган яңгыр аркасында суга күмелеп калган ташландык базына кереп посты. Комлы, текә ярларга оялаган кәрәшәләр үзләренең җылы ояларыннан алдан ук очып чыккан, хәзер, һичнинди өн-тавыш салмыйча, тәртипсез төстә югарыда тузына иде. Камышлар тирбәлеп кыштырдадылар, агач яфраклары җилсез калтырап җилфердәштеләр. Тере үлән һәм чәчәк тамырларын шытырдатып өзә-өзә суга текә ярлардан кантар-кантар җир кисәкләре убылып төште, туфрак, ком, таш коелды.*

*Таң атып килә иде. Елга су астындагы тирән катламнарның хәрәкәткә килүен һәм сыгылуын, аннан соң тураюын, тартылуын сизде. Туфрак, таш токымнары йә кысылды, йә бушады.*

*Һәм кинәт җир тетрәп куйды. Ераклыкларга һәм тирәнлекләргә дулкын-дулкын гүләү таралды. Елга суы буеннан-буена чайкалып торды, ышыкланыр урын эзләгәндәй, ярларга, бөгелеп төшкән тал ботаклары астына ташланды.*

*Ниһаять, Җир тынычланды. Елганың ярсуы басылды, агымы үз юнәлешен тапты. Балыклар тынычландылар, җим эзләргә чыктылар.*

*Шулвакыт елга иркен Олы борылышы артындагы иң киң урынында үзенең болганчык җылымса суына астан салкын чишмә килеп кушылуын тойды. Яңа чишмәнең күзе бик бәләкәй, әургымы хәнҗәр кебек үткер, тыелгысыз иде. Елганың үзен чиксез кысып, энә күзеннән үткәрсәләр, ургымы ул тиклем гайрәткә ия булыр иде микән? Тирән, эңгер-меңгер баскан чоңгыл төбеннән бәреп чыккан чишмә ургымы су өстеннән хәтта камыш биеклеге чамасында күтәрелде. Ә юк, чишмә мондый булмый: чишмә суы, җир астыннан чыгу белән, рәхәтләнеп җәелеп китә дә шундук елга иркенә бирелә. Бусы андый түгел. Монысында әллә нинди буйсынмас куәт бар. Ул елганың әнә нинди тирән чоңгылын тишеп үтте һәм, нининдер көчнең хәбәрчесеdәй, югарыга ыргылды. Әйтерсең лә максаты — күкләргә ашу, йолдызларга җиту.*

*Яңа чишмә пәйда булган турыда елганың суы сафлана, тона башлады. Озакламый чоңгыл суы чистарды, тынычланды, әмма барыбер әүвәлге рәвештә түгел иде инде. Гәрчә чишмәнең су өстеннән көмеш камышка охшап күтәрелгән ургымы тиздән басылса, юкка чыкса һәм елга агымы юнәлешенә авышып ятса да, салкынлыгы, дәрте үзгәрмәде. Ул елгага чит, ләкин янәшәлеге хуш иде инде. Аны тоюы, кабул кылуы һәм ярлар буенча, борылышлар, чоңгыллар аша ияртеп китүе рәхәт иде.*

*Елга Олы борылышта чишмәнең әнә шундый саф сулышын, тансык тәмен татыды. Һәм шунда, сабыр гына бөтерелеп әйләнеш ясаганда, ул яңа чишмәнең үзе кебек үк, әмма шактый тирәндә ятып аккан билгесез бер елганың үзенә эндәшү сүзе икәнен аңлады.*

*Койрыклы йолдыз, боларның һәммәсенә битараф төстә карап, чиксез һәм мәңгелек сәфәрен дәвам итте. Тауларның түбәләрен, калкулык битләрен, агач очларын алтын нурларына коендырып, кояш чыкты. Ояларындагы йомыркалары, әле төксез яисә канатларын сынар чак җиткән балалары янына кире кунган кошлар, үзәндәге сирәк киекләр, таш араларында шуышкан кәлтәләр, еланнар, әлегә ояларына керергә кыймаган йомраннар, тычканнар үлән кыякларының, чәчәк таҗларының һәм агач яфракларының бу таңда чыксыз икәнен күрде — чык бөртекләре җир кузгалып алган мизгелдә коелышкан, туфракка, комга сеңгән иде. Аның каруы караш җитәрдәй җирне томан сарды.*

*Ә кешеләр җирнең иртәнге салкынча һавадан чирканчык алган-*

*дай чак кына тетрәп куюын сизмичә дә калдылар.*

*Боларның һәммәсенең сәбәбе гади, әмма гадәти булмаган эш белән бәйле иде. Хәрбиләр, мелиораторлар белән бергәләшеп, эш системаларының ышанычлы булуын сынар өчен җир асты шартлавы үткәрделәр. Ул системалар ярдәмендә җир астындагы елганы буарга, икенче урында катламнарны тишәргә һәм ул елганы югарыга бәреп чыгарырга уйладылар. Бу су яңа өстәмә турбиналарны эшләтер, бер очтан сугарыр өчен мөмкин кадәр күбрәк су җыйнар өчен кирәк иде.*

*Төп бурыч — җир астында тыныч, халык хуҗалыгы максатларында дип аталган кечкенә куәтле атом-төш шартлавы үткәрү алда тора иде әле. Моңысын тормышка ашыру көннең уртасына билгеләнде.*



## V

Май ахырында Кушкаен авылында өч көн тоташлый яңгыр яуды. Ерганакларга су төште. Ярыннан инеш ташып чыкты. Ул барып кушылган елга суы да хәйран күтәрелде. Чәчүдән туктап тордылар. Мал-туар абзарлардан чыкмады. Кошлар тынды.

Халыкның кәефе тәмам кырылды, тәкате бетте дигәндә генә кургаш болытларга җан керде. Җил чыкты. Күк йөзе ярты көн эчендә аязды. Инеш белән елга үз ярларына кайтты. Кояш чамасыз кыздыра башлады. Ике көн дигәндә җир кибеп бетте. Кошлар тернәкләнде. Үләннәр, агач яфраклары үрләп китте, чәчәкләр ачылды.

Колхозның елга буена урнашкан умарталыгындагы ташландык озынча таш подвалга бер балык кереп калган булып чыкты. Иң алдан аны умартачы Чаныш күрде. Балык болганчык суда ята иде. Койрыгы өстә, ә башы белән подвалның авыш юлыннан эчкә кереп киткән. Чаныш аны шундук таныды: кырпы балыгы икән.

Чанышның умарталыкка килмәгәненә дүрт көн узган иде инде. Шул арада, көтелмәгән кунакны тозакка калдырып, су чигенгән. Чаныш, гадәттә, килгән һәрбер кунакка шат. Бу юлы да куанды.

Ул яңгыр чистарткан сукмактан төшкәндә үк балык койрыгын абайлаган һәм аны ярга килеп төртелгән көймә җилкәненә охшаткан иде. Бервакытны елгада җилкәнле ике көймә йөзеп барганы хәтерендә. Көймәләр ярга килеп туктадылар. Кешеләре мондагы табигатьнең матурлыгына кызыккандыр, күрәсең. Умарталык урнашкан тау итәген камыр агачы, кыргый алмагачлар, куләгәле имәннәр һәм төрле куаклар уратып алган. Теге көймәләр өченче елны, Петрау көнендә, бал аерткан вакытта килеп чыктылар. Әлеге көймәләрдән кызлар белән егетләр төште. Җыенысы дүртәү. Тәннәре кояшта каралган, көчлеләр, шуклар, шатлар. Чаныш аларны яңа бал белән сыйлады. Ә алар аңа алтынсу төстәге чех сырасы эчерделәр. «Алтын фазан» дигән сыра, ул моны яхшы хәтерли әле. Тегеләр сыра артыннан киптерелгән балык чәйнәмәделәр, ә кылыч шикелле кәкре кабыргасы белән какланган ат ите ашадылар. Казылык та алтынсу төстә, хуш исле һәм бик тәмле иде. Чаныш ике чокыр чамасы сыра эчте, бер стакан тутырып, улы Кадрәккә дә бирде. Аңа шуннан артыгы ярамый. Сыра кәефне ярыйсы гына күтәреп җибәрде. Аннары ул егетләргә кызыл чөгендер салып әчетелгән бал авыз иттерде. Күп түгел, берәр чокыр чамасы гына. Тегеләр төрле ымнар белән өстәтергә яскандылар. Тик ул аларны узындырмады. Әчегән умарта балы эч нигъмәте генә түгел. Ул аны тән даруы, җан азыгы урынына гына тота...

Әйе, балыкның койрыгы шул җилкәннәрне исенә төшерде. Төсләре белән генә аерылалар. Җилкәннәр ак, аларга кызыл хәреф-

ләр, зәңгәр саннар төшерелгән иде. Ә балыкның койрыгы көл төсендәрәк. Зәңгәрсу-көрән элпә сызыклары, сөякләре беленеп тора. Чанышның кулындагы кан тамырлары яисә туфрактан калкып чыккан имән тамырлары шикеллерәк. Хикмәт андамыни? Балык койрыгы да матурлыгы белән теге җилкәннәрдән һич кайтыш түгел. Өске сөяге җилкәннең мачтасына тартымрак.

Арырак, подвалның авыш авызына зур балыкның гәүдәсе кереп киткән. Аның тәңкәләре чәй тәлинкәсе хәтле бардыр, әй! Араларына көрән кабырчыклар ябышкан. Алар урыны-урыны белән бәйләм-бәйләм асылынып торалар.

Быелгы җылы көннәр башлануга, Кадрәк белән бергәләшеп умарталарны аланга чыгарып утырткач, Чаныш подвал ишеген ачык калдырган иде. Җилләтер өчен инде. Кортлар хәзер яңа сарайда кышлый, ә бу подвалда түгел. Сарай нарат бүрәнәләрдән буралган, түбәсе шифер. Түбәне мүк сарып өлгерде инде. Шифер кабыргалары арасына күгәрек яфраклар ябышкан. Шуңа күрә сарай түбәсе ала-кола күренә. Ябагасын койган ат тиресе диярсең. Ә базда тузган, тик әлегә исәптән төшерелмәгән умарталар, кайбер кирәк-ярак, көя ашаган балавыз сакланып килде. Бомба базы сыман нык булса да, подвал эшкә ярарлык түгел инде. Искерде. Стеналары яссы ташлардан өелгән, түшәменә урталай ярылган имән бүрәнәләр түшәлгән. Ишеге тимер, әүвәлге осталар аны ахырзаман җиткәнче чыдарлык итеп койган.

Балыкның кайбер җиреннән болганчык суга кадәр җиткән озын су үсемлекләре асылынып тора. Тамырларын тәңкә араларына җибәреп, алар шундук үскәндер дә әле дип уйлады Чаныш. Су чак кына дулкынлана. Мөгаен, балыкның тын алуы шулай итәдер.

Баз кырыена баскан урыннан Чаныш балыкның зурлыгына хәйран калып торды. Тирләп чыкты. Кадрәккә дәшәргә ашыкмады әле. Аның улы Кадрәк күптән пенсиядә инде. Алтмыш сигез яшендә генә булса да, тәне сырхаудан арынмый. Тик ул Чанышка кулыннан килгәнчә булышкалый әле. Чанышка калса, ул яшьтә кеше картлыкның бусагасында гына. Ни хәл итмәк кирәк, Кадрәкнең бер дә бирешергә исәбе юк. Һәр эштә аңа беренче таяныч, беренче киңәшче, фикердәш. Калган өч улын Чаныш соңгы сугышта югалтты. Икесенең вафат булган, берсенең хәбәрсез югалганы хакында кара кәгазь алдылар. Кадрәкне ул бу гаҗәп зур балык белән искәрмәстән куркытмас өчен чакырмый торды. Гомерендә моның ише могҗизаларны байтак күргән Чаныш үзе дә балыкның зурлыгына хәйран калды. Аеруча ул аның тәңкәләре арасыннан төртеп чыккан яисә асылынып торган, күгәрек белән капланган тимерчыбык шикелле, пычрак куныклы чал төкләренә шаккатты. Балык аңа яшьтәш ахрысы. Ихтимал, картрактыр да. Бу колак ишетмәгән, күз күрмәгән төкләренә караганда, бәлки аңа йөз яшь үктер инде. Тәгаен, аның сакалы да бардыр әле, дип фараз кылды Чаныш. Кешеләрнең бөтен тереклеккә салган җәбереннән, һәр адымда сагалаган куркынычлардан, бәлаләрдән исән-имин чыккан бу балыкның акылы ниндидер, ә? Үзе йөзеп килгән һәм үз-үзенә подвалда кабер эзләп тапкан икән, ул яшәүдән туйган булса кирәк инде. Үз-үзенә кабер эзләп табарлык хәлгә җиткәч, ялгызлыкның, гаҗизлекнең чигенә килеп терәлгәндер. Киереп тартылган, аннары кинәт атып җибәрелгән ук шикелле зыңлаган бу уй һәм бу күренеш Чанышны әллә нишләтеп куйды. Хәтта үзенең үлеменнән соң да үз-үзенә кабер казырлык ялгызлыкка дучар булган кешене күрдемени! Бу хакта уйлау гына да әллә нишләтерлек шул. Әнә шундый ялгызлыкта калдырудан курыкканга күрә үзе дә Кадрәкне бөтен белгән ысуллары белән саклап килде түгелме соң? Чаныш үзе дә ялгыз калуны һич тә

теләмИ. Аны — Чанышны — кимендә бер генә улы булса да җайлы һәм коры ләхеткә салып күмәргә тиештер бит инде? Шул ук вакытта ул моңа җаны-тәне белән каршы да. Ул үзе үк Кадрәкнең соңгы туганы диярлек ләбаса. Кадрәкнең бердәнбер улы Рево, хәрби очучы, авиация һәлакәтендә харап булды. Аны шунда вафат булганнар белән уртак кабергә җирләделәр. Күмәргә Кадрәкне дөнья читенә — Сахалинга чакыртып алганнар иде. Зурлап каршылаганнар, олылап озатканнар. Кадрәк килене Мөрсәлимәне, оныклары Солтан белән Сөембикәне дә үзе белән алып кайтты. Алары яхшы гына фатирлары белән Казанда торалар. Чанышның хәтта үз-үзеннән яшереп йөртәсе килгән теләге бар: аның улын югалткан Кадрәкне үзе җирлисе, каберенә бер уч туфракны үзе саласы килә. Ә инде соңынтын, үзе дөнья куяр алдыннан, иң соңгы уч туфракны учына үзе кысып калса, бик таман.

Дөрес, Кадрәк Чаныш уйлаганча ук ялгыз түгел анысы. Аның, әнә, егет булып җиткән оныгы бар — Солтан. Чаныш оныгының улы. Бу яктан хәл яхшы, нәсел чылбыры өзелмәгән, өмет бар. Әлбәттә, төрле хәвеф-хәтәр Чанышларның нәсел агачына шәфкатьсез зыяннар салды. Шөкер, токымның тамыры корымаган. Шулай да хәзер вакыт башка, кешеләр бүтән. Аерата — яшьләр. Дөнья, анысы, аларны да җаена салыр. Сабакка утырырлар, игә килерләр. Кая китсеннәр. Утырган арбалары алга тәгәрәр. Ахыр килеп, Чанышлар җырын җырларлар. Күпмедер баргач, үткән юлга әйләнеп карыйсың ич аны. Болар да шулай карарлар әле — каерылып-каерылып карарлар. Менә шунда тартып барган атлары нинди дә, утырган арбалары кемнеке икәнен күрерләр. Яшереп-нитеп торасы юк: соңгы вакытта олы юл маякларыннан читләште алар. Солтанны гына ал. Чаныш аның, әйтик, милләт җырларын көйләгәнен ишеткәне юк бугай. Җырлап азапланмый, тыңлый гына. Йөгән күзелдерегенә[1] тартым бер нәрсә кия дә кесәсендәге тартма сихеренә бирелә. Тыңламаган да шикелле ул аны, хәерсез. Эндәшсәң, саңгырау кеше сыман, кулын колагына куя да теге нәрсәне сала, кайтарып сорый. Миңгерәүләнгән ише, билләһи. Әллә ниткән чит, моңсыз җырлар шунда. Дөрес, үзләре дәртле, дәрманлы, бирелеп китсәң, биетерлек көйләр. Тик инде, җәмәгать, ул көйләргә көрәк белән җир казырлык, балта тотып утын ярырлык, себерке белән ишегалды себерерлек, чалгы айкап, печән чабарлык түгел. Берзаманны Солтан шул җырларны умарталыкка алып килгән магнитофоныннан кычкыртты. Бал кортлары тузгып та күрсәтте соң, әй! Солтанга ябырылдылар. Кая качар тишек тапмады, бичара. Суга чумып кына котылды. Солтан гынамы соң — кич җитте исә, клуб ягында гел шул музыканы акырталар. Әйе, ул җырлар җир казытмас инде. Дошманга каршы атакага күтәрүе дә шикле. Җырын алыштырган кеше иманын да үзгәртә ул. Чаныш алданрак дөньядан китәрме, Кадрәк аңарчы ук мәңгегә күзен йомармы, Солтанга саф мөселманча күмү йоласын ышанып тапшыру файдасыз. Җирләүчеләргә ияреп йөрсә, хәтеренә салып куйса да бик әйбәт булыр әле.

Әйе, соңгы мыскыл туфрак Кадрәк, йә Чаныш учында булыр.

Чит кеше өенә кергәндәге сыман, Чаныш резин итегенең олтанын үләнгә ышкып сөртте дә, балыкның кытыршы койрыгына тотынып, югары үрмәләде. Бер тәңкәнең кипши башлаган үткер чите чалбар балагының, эчке ыштанының тез турысын ертты, аягы шуып китте. Ул тезенең әрнүен тойды һәм, балыкка менгәч, тез капкачы тиресенең суелганын күрде. Ул урынга бөрчек-бөрчек кан тамчылары саркып чыккан иде. Чаныш аягына басты. Балыкның тәне йомшак икән. Итек табаннары аңа батып тора, сазлык түмгәгендәге шикелле, ти-

[1] Ат күзен ян-яктан томалар өчен йөгәнгә тегелгән каеш каплавыч.

гезлек саклавы читен. Ул сак кына тирбәлеп алды, әйтерсең лә аяк астының ныклыгын чамалады. Җавап итеп, балык койрыгын селкетте. Койрыгы белән бөгәлчәннәр куган атмыни! Бүрәнә буенча барган кебек, Чаныш балык сыртыннан алга атлады. Гүя, ул, яшьлегендәгеише, атка аягүрә менеп баскан. Балыкның сырт канатына кадәр барып җитте. Канат шиңгән әрекмән яфрагын хәтерләтеп янтайган иде. Юка булганга күрә, читтән йомшактыр кебек тоелса да, бактың исә, юкә кабыгыдай каты икән. Кытыршы зәңгәрсу элпә белән капланган канат сөягенә уң кулы белән тотынып, ул ишек өслеге астыннан подвал эченә карады. Анда әңгер-меңгер. Салкынча һава бәреп тора. Юеш таш һәм черек исе аңкый. Ул ят тавыш ишетеп сагайды: балык, тозакка эләккән җанвардай, тын гына сулкылдый сыман иде. Күзе караңгылыкка ияләшкәч, Чаныш балык саңакларының киң капкачларын шәйләде. Тимерчелек күрегенә охшап, алар бер көйгә ачылып-ябылалар, суны эчкә суырып алалар да кысып чыгаралар, дулкын итеп тараталар. Балык, аны күрергә теләгәндәй, башын судан чыгарып алды. Шунда Чаныш аның сул күзен күрде. Шул рәвешчә, кайчакны атлар яшенгә караучан. Балык көтмәгәндә очраткан дустына карагандай тоелды. Карт үзенең балык белән бер үк ешлыкта сулаганын искәрде. Алай гына да түгел, алар икесе дә охшаш уй уйлыйлардыр, бер-берсен инде сүзсез дә аңлаганга гына сөйләшмиләрдер кебек. Бар нәрсә инде сөйләшенеп кенә бетмәгән, ә яшәлеп үк беткән диярсең. Бу тойгы Чанышның кәефен һич тә бозмады, авырыксындырмады, үз-үзен кызганырга сәбәп бирмәде. Ә киресенчә, шундый яхшы, шундый иркен булып китте ки, әйтерсең лә алар — балык белән Чаныш — бер-берсенең тормышы хакына үзләренең җаннарын фида кылганнар һәм соңгы мәлдә берсе икенчесенең тәгаен исән калганнарын уйлап өлгергәннәр кебек.

Кеше дөньяга килгәннән соң һәм үлгәнгә кадәр эшли алган иң яхшы гамәл шундый — бер-берең өчен җан ату була инде. Шуннан да зуррагы юк. Кешегә башкалар гомере хакына, хәтта ул башкалар үзләре теләмәгән очракта, да көрәшергә кирәк. Моны Чаныш бик яхшы белә иде.

Саграк атларга, балык тәнен авырттырмаска тырышып, Чаныш кире китте. Балыктан, әле тәпи йөри алмаган бала сыман, арты белән шуып төште. Карашы белән Кадрәкне эзләде. Ул исә аланда күренмәде. Тынлыкта елга дулкыннары кагуы, атның умарталар арасында керт-керт яшь үлән утлавы ишетелә иде. Чаныш елга суы белән баз арасына күз ташлады. Балык бирегә төнлә кереп калган, ахрысы. Шул арада су ярты метр чамасы кимеп өлгергән. Тәгаен, ташудан шикләнә калганнардыр, һәм, сусаклагычның шлюзын ачып, суын киметкәннәрдер. Өч көн тоташлый яуган яңгыр инеш суын да, елга суын да шактый арттырган иде шул. Аннары, суында шундый зур балык йөзгән елга ничек артмасын да, ничек җәелмәсен инде ул, дип уйлады Чаныш.

Кадрәкне ул чокырдан эзләп тапты. Шешәдәге сөтне, әчемәсен дип, чокырдагы чишмәгә куяр өчен төшкән. Андагы чишмә катлам-катлам ташлар арасыннан бик көчле бәреп чыга, ике күзле. Күзләре шундый тирән, бервакыт кызык өчен Чаныш анда тал чыбыгы тыгып караган иде, бөтенләй кереп бетте. Чишмә күзеннән дә тирәнрәге Чанышның күптән вафат булган Асылъяры күзләре генә булгандыр кебек. Асылъярның зәңгәр күзләре, чыннан да, шундый тирән иде. Чаныш шушыңа кадәр, хәтта иксез-чиксез хәтерендә һәм сагышында да аларның төбенәчә төшеп җиткәне юк әле.

Көчәнә-көчәнә һәм тешләрен кыса-кыса, тезенә таяна-таяна чокырның ташлы ярына уелган баскычтан сулы чиләк күтәреп менгән Кадрәккә ул әкрен генә:

— Әйдәле,— дип эндәште.
— Нәрсә бар?— дип сорады Кадрәк.
— Могҗиза.
— Һе, могҗиза! Тапкан куандырыр нәрсә.
— Җәһәтрәк атла инде. Бигрәк сөйрәләсең.
— Кая ашыгасың?
— Ашыга дип... Качмый анысы.
— Җук. Син гел ашыгасың. Чәчәкләрне дә ничек иснәгәнеңне күрми дип беләсеңме әллә?
— Иснәсәм суң. Шуннан ни булган?
— Иснә, миңа жәл түгел.
— Ә ник сукранасың?
— Сукранмыйм. Тик алай иснәмә.
— Алай дигәнең ничек була инде ул?
— Шулай инде... соңгы тапкыр иснәгән шикелле. Ашыгуың шуннан күренә.
Улының тел төбен аңласа да, Чаныш:
— Кая ашыгам?— дип сорады.
Кадрәк аяк астына карап:
— Шунда инде... Ашыкма әле, эти,— диде.
«Һаман шул — ялгызы калудан курка»,— дип уйлады Чаныш.
— Яхшы, улым,— диде ул нык итеп.— Чәчәкләрне бүтән соң мәртәбә иснәгән шикелле иснәмәм.
— Шулай булгач, мине әллә ниткән могҗизалар белән котыртма. Без аларны күп күргән инде. Шаккатыра алмассың.
— Күреп бетермәгәнбез икән шул әле.
Чаныш улының үзенә төбәп караганын сизде.
— Өйгә керик, эти. Ятып тор. Самавыр куеп җибәрермен. Чәй эчәрбез.
— Аннарырак эчәрбез. Башта могҗизаны күрсәтим әле. Әйдәле, әйдә.

Агачлыктан чыккач, ул түбәнгә, су читенә ишарәләде:
— Күрәсеңме? — дип сорады.
Кадрәк, кулын каш өстенә куеп, аска — су яктылыгына карады.
— Ни бар суң анда, эти? — диде ул сузып кына.
Чаныш чиләкне үзенә алып, өйалды баскычына куйды да подвалга таба төшеп китте. Артка әйләнеп карамаса да, улының үз артыннан ияргәнен сизде.
— Менә,— диде ул Кадрәкне алга уздырып.— Балык булыр бу.
— Әстәгъфирулла! Балык түгел бу! Бу — чыннан да могҗиза лабаса.
Чанышның бая ләмдә калган эзләренә баса-баса, Кадрәк балыкның койрыгы янына үтте. Аны сөякчел бармак очлары белән генә капшагач, Чаныш кузгаткан тәңкәне җайлап куйды.
— Әйе, балык икән шул,— диде ул тын гына.— Күпме су, ә барыбер үзенә урын тапмаган.
— Әйе,— дип килеште Чаныш.— Зур юл, шулай, тар сукмак белән очлана инде. Зур өйдә озак торганнан соң җан бәләкәй бүлмәне тансык итә. Ахыр килеп, озак бара торгач, аяк табаннары җир салкынын сагына. Әх-әх-әй!.. Кеше генәме соң, олы юллар да тузанга әйләнә. Бер нишләр хәлең юк.
— Шулай уйлаган идем аны.
— Ничек?
— Бу балык бит карт, ахрысы. Ул безнең янга килгән. Яхшыга түгел бу. Ихтимал, ул синең чәчәкләрне җиргә иелеп иснәгәнеңне күргәндер... Балык үзенең могҗиза икәнен белгән. Шуңа үзен күрсә-

тергә килгән дә. Ул безнең соңгы могҗизабыз булмагае. Белдеңме?
— Булса суң! Алайса яхшылап карап калыйк... Каяле, Кадрәк, син аңа атлан әле.
Кадрәк:
— Нигә? — дип сорады.— Ат түгел ич ул!
— Ат булмаганга күрә атлан да. Мин сине гомергә бер мәртәбә балыкка атландырып йөртергә тиештер бит инде?
Чаныш сирәк чал сакаллы, ябык, җиңел гәүдәле, кыюсыз гына карышкан улын култык астыннан тотып күтәрде дә балык сыртына атландырды. Кадрәкнең күнитекле аякларын салындырып, учлары белән балыкка тотынып утырудан гайре чарасы калмады. Чыннан да, хәзер җилгә каршы җилдереп китәргә әзерләнгән сыман, ул соры киез эшләпәсен маңгаена батырып киде. Һәм менә ул Чанышның күз алдында үзенең алтмыш еллык гомерен чигереп, артка ташлап калдырды да, сигез яшьлек малай булып, үзенең шул ук алтмыш еллык гомеренә каршы җилдереп китте кебек. Алтмыш ел әүвәлгечә көчле, шук җанлы, ләкин карап торышка кырыс күренгән, егылган шәттә Кадрәкне тотып калырга, күтәреп аягына бастырырга, көлә-көлә, юата-юата, атта нык утырырга өйрәтә-өйрәтә, бәрелгән җирен угаларга әзер ир сурәтендә Чаныш улының артында басып торды.
Кадрәк, бик күп еллар элек булганча ук:
— Бәреп төшермәс микән суң? — дип сорады.
— Нык тотынсаң, төшерә алмас,— двп җавап бирде аңа атасы.
Кадрәк үз-үзен читтән күргән кебек булды, оялды. Хәл көнләшерлек түгел, дип уйлады ул. Бер караганда ахмаклык инде: ул, ак сакаллы карт башы белән, балыкка атланган! Ике тере кәҗә мөгезенә куеп, пычкы белән бүрәнә киссәң дә, мондый ук ахмаклык булып тоелмастыр. Андый хәлгә калмас анысы, ә менә тере балыкка атланып утыра лабаса әле! Дөрес, әллә ниткән биеклеккә ашкан да шикелле. Юк шул инде, юк. Тормыш дулкыннары ярга кагып чыгарган йомычка шикеллерәк. Әйе, Кадрәк үз-үзеннән оялды. Ләкин атасының аның балыкка атланганын бик күрәсе килгән икән, моны ничек кире какмак кирәк? Әзрәк шулай утырды да:
— Җитәр инде. Яхшы җилдердем бугай,— диде.
— Утыр әле, улым, утыр. Ашыкма. Җиргә төшәргә өлгерерсең,— дип үтенде Чаныш. Аның т е г е н д ә, үткәннәрдә, хәзер шундый якын, фәкать күз яшьләре генә томанлатып күрсәткән үткәнендә озаграк тукталып торасы килә иде. Ул үзенең: — Ашыкма әле,— диган үтенечен тагын кабатлады.
— Иярсез җайсызрак шул,— дигән булды Кадрәк.— Катырак.
— Мендәр кирәкмиме суң?
— Мендәргә күнегәсе түгел анысы. Тик минем мендәрләргә ис китмәгәнне беләсең ич инде. Миңа күбрәк нарларда аунарга туры килде. Беләсең ич инде, эти.
— Беләм, улым, беләм. Яхшы беләм. Андый нәрсәне ничек оныт-мак кирәк?

## VI

Белә Чаныш, ник белмәсен. Бик яхшы белә. Аның улы Кадрәкнең күргәннәре адәм балалары башына төшә язмасын инде. Ул сәламәтлеген сугыш алдындагы мәхшәрдә, сугышның үз кырларында байтак какшатса да, госпитальләрдә аунап ятмады. Кадрәкнең нарларда аунарга туры килде дигәне бүтән аның. Ул саулыгын Кола дигән ярымутрауда урманнар кисеп какшатты. Себер карлары астындагы шахталарда күмер чабып югалтты. Югыйсә, сугыш булып сугыштан тәненә

ядрә тию түгел, шырпы да кертмәгән килеш кайтты. Аның улы Кадрәк җәфаны алданрак күрде. Госпитальнең йомшак мендәрләре, чиста җәймәләре бәхетлерәкләргә эләккәндер ул. Аның улы Кадрәк өлешенә төрмә сәндерәләре, лагерь нарлары, ачлык тиде. Кеше өчен нахакка рәнҗетелүдән дә катырак җәзалар да бардыр-барын. Нәсел-ыру намусы бар бит әле. Әнә шул нахак гаепнең бөтен нәсел-нәсәпкә ягылуын күтәрү сират күперенең кыл уртасында чайкалып торудан да яманрак булды. Алай да нахак гаеп — таш түгел. Аны муенга асып, суга сикерәсеңмени? Үлүе җиңел ул, яшәве авыр. Исән чагында өнәмәгәннең, үлгәч, сөякләрен яратырлар. Менә ничек бит ул, агайне!

Әйе, белә Чаныш, ник белмәсен. Аның улы Кадрәкне сугыш чыгарга дүрт ел ярым калганда алып киттеләр. Ник икәнлегенә хәзер, гомер узып барганда, хәтсез вакыт юшкыны кунган инде. Хәер, истә. Ничек алып киткәннәре аерата. Ут сүндереп йокларга яткач, ишекне төеп уяттылар, килеп керделәр. Авыл советы рәисе Зәйнәпбикә, ике милиционер, тагын каратут йөзле, әйбәт киенгән бер кеше. Җыенысы дүртәү болар. Шушыңынчы МТСта плугарь, аннары комбайнчы булып эшләгән, ә язын, Кызыл байрак ордены алгач, авыл советы рәисе итеп сайланган Зәйнәпбикәнең бу вазифасына яңа гына керешкән вакыты. Сары каш-керфекле, бөдрә җирән чәчле, эре сипкел баскан йөзле булса да, сөйкемле, күңелгә хуш килердәй зифа буйлы хатын. Кияүгә чыкмыйча, ир бала тапты. Авыл халкы арасында, орденын шул малай өчен алды, дигән сүз йөрде-йөрүен. Анысы караңгы инде. Тырнак астыннан кер эзләргә маһирлар кызыксынсын.

Милиционерларның берсе — ач яңаклысы, куе кара кашлы, югары бөтерелгән очлы мыеклысы — каккан казык булып, ишек катына басты. Бүтәне — кызыл түгәрәк битле, почык борынлысы — өстәл башына утырды да алдына кара савыты чыгарып куйды, дәфтәр ачып салды, каләм алды, эш башланганны көтеп, иягендәге бетчәләрне капшап сыткалады.

Ул чагында Кадрәк өйләнгән, ләкин әлегә башка чыкмаган иде. Ә көзен өмә белән мүкләп өясе шәп юкә бурасы хәстәрләнгән, капка төбендә.

Чанышның бер улы, Кадрәктән яшь ярымга гына өлкәне Тәлгать, район үзәгендә балыкчылар артелендә эшли. Өченчесе — Сибгат — Казанда танк училищесында укый. Ә төпчекләре Сәйдәш кызлар исен тоя башлады ахрысы инде, кичке уеннан кайтмаган иде әле. Ике гаиләгә дүрт почмаклы өй кысанлыкка кысан иде анысы. Бигрәк тә язгы айлы төннәрдә кыенга килде. Чанышның үзенең дә хәтәр генә гайрәтле чагы. Эшкә яраксыз тәртә ише, куйган җирдә сөялеп торуга гына риза түгел. Асылъяры да үзенә иш: терекөмеш сымак, учта тәгәрәтерлек әле. Шула-ай... Зарланмый-нитми, тиешле итәгать саклап дигәндәй, әйбәт тордылар. Аның каравы мунча шәп иде, мунча. Кышкы озын кичләр, язгы ташулар, бигрәк тә шомырт чәчәк аткан вакытларда шул мунчаны бик еш яккаладылар. Хәзер дә өй борынча мунча бар анысы. Мәгәр хәзер инде фәкать юынырга, кунак-төшем кадерен күрергә, тагын кияү белән кәләш, кода белән кодагыйлар хөрмәтенәрәк ягыла. Теге чакларда мунчаның хикмәте бүтәндәрәк иде шул... Өйләнгәненә ел ярым дигәндә Кадрәкнең хатыны Рәхиләнең икенче балага йөкле икәнен яшеребрәк йөргәнен Чаныш сизенә иде инде. Тик ул балага яшәү генә насыйп булмады. Имчәк баласы вакытында ук дөнья куйды, бичара. Монысы соңыннанрак булган хәл.

Менә шул: ут сүндереп, йокларга яткач, т е г е л ә р — чакырылмаган кунаклар килеп керде. Тышта пычрак, яңгыр, күнитекләрен ышкып-нитеп тормадылар, эчкә, түргә уздылар. Ут эләргә өлгергәннәр иде инде. Бөтенесе уянышты. Сәерсенделәр, шикләнделәр. Хатыннар, әдәп саклап, башта чаршау артына кереп киттеләр. Каенанасы белән чышын-пышын килеп, Рәхилә самавыр капкачын шылтыратты. Аның

бу якка чыгып, мич калагына үрелүен теге каратут йөзле кеше мыек очын ирен почмагы белән чәйнәп карап торды да почмактагы китап шкафы каршына барып басты, урысчалатып, үзе өчен генә әйткәндәй: «Ну-ка, поглядим».— диде. Китапларның иң калынын — күн кырыйлысын кулына алды: «Что за книга?» — дип сорады. Үзе үк ватаҗимерә укып та бирде: «Әл-мәсхәфү эш-шәрифу»[1].

Каратут йөзлене күреп белмәсә дә, кем икәнен Чаныш чамалады — Абалак фамилияле кеше. Тирә-күрше авылларда аның Шапалак дигән кушаматы таралган иде инде. Чебен үтергеч була инде. Өстәвенә, бу сүзнең яңакка сугу дигән мәгънәсе дә бар. Ай-яй да соң бу ирләр: уйлап чыгарырга һәм чәпәргә кирәк бит, йә! Кешесенә, шөгыленә шул хәтле дә туры килер икән. Шәп тә соң, ә — Шапалак!

Әйе, кешеләр язмышы өстендә чебен үтерә торган шапалак шикелле селтәнде ул. Шап! — бер авылдан мәктәп директорын. Шап! — күрше авылдан агрономны. Шап! — чираттагы авылдан комсомоллар башлыгын... Кемне генә алмады. Тик кешеләр чебен түгел иде бит, чебен түгел иде. Кешеләр — кемнеңдер атасы, ире, анасы, хатыны, баласы, туганы иде!

Шапалак ияген күтәрде дә эчке күлмәкчән һәм яланаяк басып торган Кадрәккә төбәлде. Чанышның өенә үтә хәтәр мәлләрдә генә кузгалучан курку йөгерде. Ул полк комиссары сыйфатында йөргән чагында полкларын батька Махно армиясе тар-тар иткән, шуның өчен партиядән чыгарылган, ревтрибунал хөкеменнән могҗиза белән генә исән калган, үз-үзенә кул салудан көчкә генә тыелып, шуннан соң гади кызылармияче булып, байтак сугышлар кичкәч, туган авылына кайтып төпләнгән һәм колхозда тегермәнче хезмәтендәге кеше иде. Ыгызыгыланмады, кабаланмады, юк-барга кысылмады. Калган гомеренә башыннан кичкәннәре бик җиткән дигән карарга килде. Шуңа күрә башта тегеләрне үзен алмага килмәделәрме икән дип уйлаган иде. Кем белә, кайдадыр, кемнәрдер үткәннәрне актарып чыгаргандыр да, моңа да вакыт дигәндер.

Теге чакны Чаныш ревтрибуналга да әйтте, хәзер дә кабатларга әзер: полк тар-мар ителмәде. Аның өчтән икесе крестьяннар иде — менә шулар Махно ягына күчте. Һәм моның өчен полк комиссары Чаныш Украинадагы Совет власте органнарын гаепләде. Уен эшмени: көрәшнең иң кызган мәлендә сугышчылар арасында Украина Җир Халык Комиссариаты әүвәлге алпавыт җирләренең өчтән ике өлешен совхозларга бүлеп бирә икән, дигән сүз таралды. Нинди «Коммуния» ди әле ул?! Ә Совет властеның «Җир турындагы декреты» нишли? Буш куык булып каламы? Крестьяннарны алдаумы? Ниемә дип революция ясадык соң әле, җир даулап түгелмени? Бирделәр дә шундук тартып та алалармы? Тапканнар шыр тиле мужик! Мә, җанны ал, ә җиребезгә тимә! Бирмисез икән — «Долой Народный Комиссариат Земли Украины! Киттек, туганнар, батька Махнога».

Менә хикмәт кайда иде. Полкның революцион аң ягыннан таркалуына комиссар Чаныш Наймушинның юл куюында түгел.

Киштәдә ничектер Чаныш кулына килеп эләккән бер китап та бар: «Махно» дип атала. Артык та түгел, ким дә түгел. Менә хәзер Шапалак шуны актарып чыгарыр да — шап! — бетте-китте.

Әмма Шапалакны китапларның калыннары кызыксындырды. Китаплар микән әле? Әйе, юк икән, аңа Кадрәк җаны кирәк икән.

Шапалак: «Коран, значит»,— диде дә һәр буынын диярлек төк баскан озын бармаклары белән китап битләрен җилфердәтеп актарды, әйтерсең лә аннан нидер эзли иде. «А ты комсомолец, если я не ошибаюсь?» — диде ул бу юлы Кадрәккә карамыйча гына. «Камса-

---

[1] «Изге кәгазьләр». Коръән (гарәпчә).

мул».— дип җавап бирде Кадрәк. Шапалак, үз-үзенә әйткәндәй: «Едва ли.— диде.— Тогда как понимать в твоем доме наличие Корана? А?» Кадрәк эндәшмәде, җавап эзләгәндер инде. «Я спрашиваю: как понимать Коран?» Күрәсең, каратут йөзлеләнең Шапалак икәнен Кадрәк тә искәреп өлгергән иде инде. Ул татарча: «Коръәнне язылганча аңларга кирәктер. Кабул итүе кешенең иманына карап инде».— диде. Шапалакның татарча яхшы аңлаганы, ипи-тозлык сөйләшә алганы мәгълүм иде. «Что такое иман?» — дип сорады ул Зәйнәпбикәдән. Зәйнәпбикә аңлатып бирергә авырыксынды. Ул телен әйләндерә башлаганчы, Чаныш: «Рух».— диде. Шапалак, бусын тагын да аңлавы авыр икәнен белгертеп, Зәйнәпбикәгә янтайткан муенын сузарак төште. Зәйнәпбикәнең җавабында нәкъ шул иман булмаслыгын белгәч Чаныш тагын үзе телгә килде: «Рух — это человек». «Но Коран — не иман, а каждый человек не комсомолец?» — диде Шапалак игътибарын Кадрәккә юнәлтеп. Ул Коръәнне милиционерларның нидер язып барганы алдына куйды да тагын шүрлеккә үрелде, бу юлы китапларның куе көрән төстәге лидерин тышлысын алып, тышлыгына күз салды: «Изрядно потрепана. Читаете, стало быть?» — диде. «Читаем».— диде Чаныш нигәдер ашыкканын һәм ни өчендер русча җавап кайтарганын аңышмастан. Шунда Шапалакның йөзе кара коелып килде. «Литература-то запрещенная? — дип, ул китапны Зәйнәпбикәгә якынайтты.— Книга Галимджана Ибрагимова. Как Ленин терпел его возле себя — уму непостижимо! Догадался бы, что окажется врагом народа...— Ул, хәзерге хәлләрне күз алдына китергән булса, Ленинның нишләү ихтималын әйтеп бетермәде.— Теперь не допросишь...— диде ул һәм күзен кысып, Зәйнәпбикәгә кырын карады. Авыл советы председателе кулын киң аерылган тезләренә куеп, ак керфекле күзен челт тә пелт йомгалый иде, йөзе бурлаттай кызарган, сипкелләренә хәтле юкка чыккан.— Вы же отчитывались о том, что полностью ликвидировали в вашей деревне произведения этого врага народа!»

Зәйнәпбикә орденын таккан бүз пинжәктән иде, шуның җиңе белән маңгай тирен сөртте. «Гөнаһ шомлыгына каршы, күреп җиткермәгәнбез шул, пәрәми,— диде ул елак тавыш белән. Иренен бүлтәйтеп, әле Чанышка, әле Кадрәккә карап, әле чәчәкле чаршау артыннан ишетелгән чыш-пышка колак салып: — Бу күптән бәдрәфкә чыгарып куясы китапны үз башыгызга дип тоттыгызмыни соң инде, амавызлар?» — дип сорады. Кызганды Чаныш Зәйнәпбикәне, ярдәмгә килеп: «Мы этой книгой намеревались яйца заворачивать,— диде, инде бала итәкле күлмәген киеп, почмакка барып баскан һәм өйгә килгән хәвефне сизүен, тик ничек тә ярдәм итә алмаганын, шулай да үзенең кыяфәте белән тегеләрне кызгандырырга тырышканын белдереп, чакырылмаган кунакларны күзәткән Рәхиләгә ишарәләп: — Вот она яйца заворачивает, когда на продажу несет в Казань».

Ул арада Асылъяр, капкачындагы көлләрен пуф-пуф итеп өрә-өрә, өстәлгә шаулап торган җиз самавыр чыгарып утыртты. Чакырылмаган кунаклар санынча чынаяк-тәлинкәләр тезде, әле утырырга өлгермәгән юкә балы белән касә, телемләп киселгән ипиле тәлинкә куйды. Ул ап-ак йон оекбаштан, төнге күлмәген алыштырган инде, башында юка батист яулык. Почмактагы агач кисмәктән җиз чүмечтә салкын су алып килде. Ул аяк атлаулары, идәндәге суккан чуар паластан тын гына, тик ышанычлы йөрешләре килешле иде. Лампалары җиделе генә, ә кайнар самавырның бите белән морҗасы арасында җайлы гына кырын яткан бер дистә йомырканың, чүмечтәге суда коенып чыккач, өстәлдә тәгәрәшеп ятулары ачык күренә. Әйтерсең лә өйдәгеләр җыенысы хәерле сәфәрдән бик отышлы йомыш үтәп кайтканнар, хәзер Асылъяр шуларны сыйларга әзерләнә. «Ешьте, дорогие гости. Видать, приутомились с дороги».— диде ул. Шапалак аның чиста сөйләшүенә гаҗәпсенеп, кашларын күтәрде. «Не удивляйтесь,— диде

Асылъяр,— я — баба русская». Бу сый-хөрмәтнең үзләренә икәнен аңлагач, Шапалак кырыс кына: «Спасибо. Но уберите это!» — диде. Асылъяр, ничарадан бичара калып, тын гына, ләкин инде ачык йөзендәге борчылуны, бармаклары калтыравын, кулы тотмавын яшерә алмыйча, шул ук вакытта үзенең буйсынмас калганын да белгертеп, өстәлне җыештырырга мәҗбүр булды. «Пиши,— диде Шапалак аның сүзен җәпләп язарга әзер торган милиционерга,— распространение запрещенной литературы идет путем заворачивания отдельными листками куриных яиц, якобы для продажи на...— Ул бүленеп, инде папирос кыстырылган ике бармагы белән Кадрәккә төртеп: — На каком базаре?» — дип сорады. «Гадәттә, Суконныйга төшәбез»,— диде Кадрәк. Шапалак: «...на Суконном базаре города Казани,— дип милиционерга әйтеп яздыруын дәвам итте,— где, по всей видимости, действуют против власти лица.— Папиросын кабызып суыргач, китапны ачып карады.— Шрифт латинский, готического образца. Г о т и ч е с к о г о — подчеркните. Нет ли в том скрытный умысел. Возникает вопрос: не в угоду ли немцам? — Бусы арттырып җибәрү түгелме дигән сыман, каләме төртелеп калган милиционерга: — Пишите, пишите! — дип боергач, ул бу китапны да Коръән янына куйды, янә шкаф ягына борылды.— Ленин,— дип укыды ул күзе төшкән кызыл тышлы китап сыртыннан.— Это хорошо.— Однако, где ж товарищ Сталин? Ясное дело: нет. Почему?» Кадрәк эндәшмәде, ә Чаныш: «Што ясно?» — дип сорады. «Ясно, как день». «Тышта — төн»,— диде Кадрәк. «Ночь в вашем сознании, комсомолец Наймушин. На улице заря наступает. Идти же навстречу заре вам рано, если не сказать вообще нельзя. Так, собирайтесь».

Рәхилә, җил ургымы китереп бәргән каен кебек, калтыранып куйды, бар күкрәге белән югарыга талпынды, бер адым алга атлады да шул килеш катып, куырылып калды, бите агарып килде. Кадрәк аңа сабыр, әмма тынгысыз караш ташлады, тирән итеп сулыш алды да шундук йомшарды, кулы көчсез асылынып төште. Чаныш зәңгәр һәм тирән төннәрдә ялгызы калачак киленен күз алдына китерде; ә Асылъяр аркасы белән салкын мичкә терәлде дә, үз каршында ачылып киткән төпсез бушлыкта кинәт яклаучысыз калган Кадрәкне мәңгегә югалыр алдыннан соңгы тапкыр күреп калырга теләгән шикелле, күз керфекләренең һәр бөртеген талдырып, әллә кая — мондагыдан чынрак тоелган ераклыкка төбәлде.

Зәйнәпбикә, кулын тезләреннән алмыйча, юеш күлмәк итәге ябышкан ботларын кушырды, пычрак галуш кигән аягын утырган урындыгы астына яшерде.

Шуннан соң Кадрәк, кабаланмаска, каушамаска тырышып, аягына күнитек, костюм өстеннән арттан башлыгы асылынып торган брезент кожанын киде. Рәхилә яшь ярымлык Ревоны күтәреп чыкты. Кадрәк, улын үчтекиләп сөйгәч, барысына да: «Хушлашмыйк. Көтегез»,— диде.

Шапалак чыгышлый Чанышка әйләнеп карады: «Вас, как отца народа врага, тоже вызовем. Ждите!» Сул күзе кысык, кара сөлек диярсең; уңы шар ачык — бер көпшәле мылтык тишегемени. Алай итеп, Чанышка берәү генә карады: т е г е чакны, таш карьерында... Тик Шапалакның карашы хәтәррәк кебек иде: т е г е чакны Чанышка винтовка гына төбәделәр, тәнenә пуля гына аттылар, ә Шапалак кешеләрне яратмый торган карашы белән җанга кадалды.

*Ахыры бар.*

**Равил Фәйзуллин**

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Сальвадор Дали үлеменә

«Мине үлем ала алмый!»
дигән Дали да,—
газеталар хәбәр итте,—
киткән дөньядан...

Лоркалар белән исемең
калса да кереп,
тик үзеңне исәнлектә
булмады күреп.

Үзеңнең дә безгә килү
булган теләгең.
Ни дисәң дә, син бит әле
Казан кияве![1]

Без сөйләндек: — Дали — сәнгать
хатасы! — диеп,—
сюрреалист каһәрләрнең
атасы! — диеп.

Кемдер йөргәндә останың
«тетмәсен» тетеп,
Замана күптән таныган
даһие итеп.

Без фәкыйрь дә Мадридта
күргәзмәң күргәч,
шедеврларың тезелгән
залларда йөргәч,

Рәдиф белән шаклар катып
тордык бер икәү:
менә Рухның ниндие дә
була ала икән!

Хезмәте әйтә: Сальвадор —
титан эш аты!
Димәк, экспериментларга да
булган чын хакы!

Талант җанын аңлый алмас
тәнкыйтьче гыйбат.
Даһи теләсә ни кылсын —
нәтиҗә кыйбат!

Иҗатчы заман үзәген
ачык сиземләр.
Ничек чагылмасын анда
катаклизмнар?

Сүз чыкса испан Пикассо,
Дали хакында,
шул кавемнән искә төшә
безнең Бакый[2] да.

Күпме булды сәер хәлләр
шушы гасырда!
Эверест күк торып кара,
тоеп барсын да...

...Инде гүр иясе булган
Сальвадор Дали.
...Аның замандашы булдык,
ансы да ярый.

---

[1] Галина Дьяконова — Далиның хатыны, Казанда туган.
[2] Бакый — Бакый Урманче.

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН *(1943) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән утызга якын шигырь китабы авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт, М. Җәлил исемендәге комсомол премияләре лауреаты, РСФСРның атказанган культура работнигы. Казанда яши.*

## Әлмәттә җир тетрәү

*Әлмәттә җир тетрәгән...*
*Дүрт-биш баллга җиткән, ди!*
*«Татнефть»тәге графиннар*
*чайкалышып киткән, ди.*

Җирне җансыз дисезме сез? —
күрсәтер «җансызлыгын»!
Килер буыннар каргаячак
бүгенгеләр аңсызлыгын.

«Таланылып, кечләнелеп,
чирле булып кал да син,
бәгырь каның — нефтең биреп,
алмашка су ал да син,
үзеңнән чыккан алтының
үзеңә ятмасын да,
шешә ватыклары белән
өслегең капланусын да,
чишмәләрең тозда эреп,
дегетләнеп бетсен дә,
тәнеңә күп меңәрләгән

скважиналар үтсен дә,
өстеңдә үскән игенең
ярымагу булсын да,
буыннар вагая барып,
зәгыйфь алмаш тусын да,
бакый гомер туган җырлар
капылт онытылсын да,
шушы мәхшәрләрне данлап
кемдер язып торсын да...
Бер тетрәп куярсың шул!»

Әлмәттә җир тетрәде.
Бик күптән түгел әле...
Кемнәрнеңдер, кардәшләрем,
тетрәдеме күңелләре?
Тетрәдеме күңелләре?..

## Топономик мозаика

(ТУГАН ЯК)

Биектаулар кичмәсәк тә,
Күгәрчен очырмасак та,
Күкиләргә күктән төшеп,
Зәңгәр Күлгә чуммасак та,—

Балтачларда туып, балачакның
алтын тәхетендә утырдык!

Яңа Салалары кала булган,
Ямашлары күзне камаштырган,
Түләкләре бүләк тоелган,
Кадрәкләр дә кадерле чакта —

Котлы Бүкәшләрдә бәхет юрап,
хыялыйлар булып укыдык.

Уракчыда урак урылмады,
Тегермәнлекләрдә тартылмады,
Көлдә көлчә пешереп ашап,
Кызыл Ярда ятылмады...

Ә шулай да Шомыртбашта
миләш җыйдык бер яр белән!

Бөрсетләрдә бурсык тотар чорда,
Солтаннарда солтан,
Чаллыларда шанлы,
Үрнәкләрдә үрнәк булыр чакта —

Балык Бистәсенең балыгыдай
Казаннарга киттек кайнарга!

Гомер үткән саен газиз —
Корноухы, Ыргасы да,
Әшнәге дә, Елгасы да,
Анатышы, Арышы[1] да —
барысы да,
барысы да...

Кая барсам да каерылып
карар җирем — Туган як!

## Язмыш торса да өстән...

*Хыял өнди, хыял өстери...*
Сөйләшүләрдән.

Ун яшь чакта кем ышанмый
хәзинә табасына?
Унбиштә мәхәббәт-гөлнең
алдына тамасына?
Утызда аның һич шиге юк
мәйданнар тотасына.
Кырыкта хис итәр үзен
дөнья уртасында.
Илледә — акыл иясе,
алтмышта хаким сизеп,
Кеше һаман куяр үзен
гел биеккә менгезеп.
Яше ашып, нәсел үрчеп,
уллар-оныклар җиткәч,
нәфси адәм хыял тотар
хәтта Үлемсезлеккә!

...Ишеттем гүя Язмышның
каһкаһәле көлүен:
бар хыялың юк итәргә
җитә бер төчкерүем!

## Кара син ташларга!..

*Тауларның да җаннары бар,*
*кыяларның — йөрәге...*

Кырым күчкән кулдан-кулга
кәнизәк кыз кебек.
Барсы да: «Син гүзәл!» дигәннәр.
Кочкан җирдән — кара янып эз,
үпкән җирдән —
саркып кан калган...

[1] Баш хәреф белән язылган исемнәр авторның туган ягындагы, нигездә, Балык Бистәсе районына кергән авыл исемнәре.

## Көньяктагы рәсемең

*Л...гә*

Утырасың диңгез буенда
тезләреңне кочаклап.
Дулкыннар көенә, яраткан
шигъри юллар кабатлап.
Чәчләреңне кояш ягына
иркәләп җил тараткан...

...Бәлки, шушы күренеш өчен
тәңре сине яраткан?

## Читкә китүчеләргә

*Аерылганны аю ашар...*

Мәкаль.

Аю башы җитәме соң
һәрбер аерылганга!
«Еракtагы кояш шәп!» дип
читкә каерылганга!

Туган җирне ташлауларның
юлы ник бетми икән?
Китү чире ил канына
бер керсә — китми икән!

Тудыра, суын эчерә,
тел бирә, кеше итә...
Тагын нишләсен Туган җир?
Ә кемдер... ташлап китә.

Китә кайчак язмыш кушкач,
кайчак — үзе теләп тә.
Ялгышып та, язылып та,
китә бәхет эзләп тә.
(Уйласаң, һәр кылган эшкә
табып була сәбәп тә.)

Аерыла илдән — теленнән,
җиреннән — нигезеннән...

Кайчак үзен дә югалта
яшәеш диңгезендә...

һәр чакрым киткән саен
үз җырыңнан язасың.
Соңрак... балаларың татый
ялгышларның җәзасын.

Кошлар да әйләнеп кайта,
ташламый Туган җирен.
Кеше кадәр кеше булып,
ничек оныта илен?

...Аерылган да чәчелгән,
сибелгән дә таралган.
(Мисаллар бар: кай халыклар
тупланалар яңадан).
Җил бер чәчкән орлыкларны
җыеп кара яңадан!

...Аерылганны аю ашар,
бүленгәнне — бүредер.
Аю-бүре «эзләп» читтә
күпме җаннар йөридер!

❦

*Шигырьнең кирәклеге турында кайчак кирәкмәгән бәхәсләр дә булгалый.*

«Шигырьне укымыйлар...» дип
«сөенү» җиңелрәк.
Бездә әдәбият әнкәсе
гомердән Шигърият!

Әнкәләрне санламаучы
сантыйлар да җитәрлек.
Бездә шигырь — аңлаганга —
башың Себер китәрлек!

## Җәйге төннең бер бәләкәй вакыйгасы

*Юк, ирексез мөмкин түгел бу дөньяда!*
*Юк, ирексез мөмкин түгел бу яшәү!*

Бүлмәмә — ачык балконнан
бер кош очып кергән төнлә.

Ят тавыштан уяндым да,
ярым аңсыз торып бастым.

Мескен кошчык
бүлмә бетереп бәргәләнә караңгыда,
тыпырчына, чыгу юлын табалмыйча.

Матур төшем шундук эреп юкка чыкты.
Герле сәгать йөрүеннән туктап калды.
Сабый улым, уянып, елап җибәрде.
Стенага элгән карта шуып төште.
«Ни булды?» дип әнисе сикереп торды.
Ут яндыргач, кош җилпенеп,
лампочканы бәреп ватты.
Өстәлдәге ваза авып, кульязмама су түгелде.
Кош куганда пианинога ялгыш басып,
яман әче аккорд чыкты.
«Нишлисез?» дип күршеләр ишек какты.

Ә югыйсә,
бер кош ялгыш бүлмәгә очып,
вакытлыча
(бер биш-алты минут кына)
иреген җуеп алган иде.

...һәм, ниһаять, юлын табып,
кош тәрәздән очып китте.
Балконга чыксам, йолдызлар атыла —
(әйтерсең лә)
күкне бизгәк тотып тартыша...

## «Шайтан кала»сыннан КамАЗларга карап

Чал Чулманның яшел ярына
җәелеп ятты зур Кара Сыер.
Корчаңгылы килмешәк Сыер!..
Тояклары тимер — җирне изә,
мөгезләре — күккә терәлгән!

Тургайлар куркынып сибелде
Агыйдел, Нократ ягына...

...Өстәвенә Хайван бикәч икән!
Җыелды янына исле Үгезләр...

Болганды дөнья. Җыелды халык.
Артты зиналык. Басты төтен...

Чишмәләрнең якты күзенә
...де Вәхшәт,
чапырдатып.

## Очраштык кеше туенда...

Гомер эзе — маңгаеңда...
Еллар эзе — муеныңда...
Сискәнеп киттең шикелле —
ишеткәч кеше туенда
икебез белгән бер җырны:
«...Синең белән даным чыкты,
җаным чыксын куеныңда!»

Борылып миңа карадың,—
мин идем үз уемда.
...Уеным да, чыным да,
әкиятем дә, җырым да!

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘРДӘН

## Шундый чак...

Ияремне җиргә куеп,
өстенә утырган чак.

Алдымда — күмере төшеп,
ялкыны кайткан учак.

...Ә үземә нибарысы —
өч тапкыр унсигез чак!

## Ау сезоны ачылгач

Җанлы күләгәләр кими көннән көн
елга-күлләр, болын-үзән өсләрендә...

Кискен шарт-шорт шартлаулардан
йолдызлар
күбрәк
коела
күкләрдән.

❋

Әйтәләр: котыплар җылына,
ихтимал туфаннар кузгалу!
Ә юкса — отыры гел арта
кешеләр күңелендә бозлану...

## Берлек

Йолдызлар күктән сикереп
диңгез төбенә чумган.

Ә болытлар — дәрьяларның
күләгәләре сыман.

❁

Тамчыда да,
күлдә, диңгездә дә,
чагыла икән йолдыз,—
ни гаеп — димәк, якты!

Яшьлектә дә,
хәтта картлыкта да
яндыра икән сөю,—
ни чара — димәк, татлы!

## Тәрәзәдән бер күренеш

Телеантеннада — кара карга.

Экраннарда — кайный халыклар!
Оча президентлар!
Яшь ботлардан шуыша СПИД!..

Ә карганың исе дә китми —
тора шунда һаман каркылдап
шул борынгы белгән үз көен!

❁

Кош булалмады. Сызланды
очканнарны күреп, тоеп.
...Хәзер йөри, көнләшүдән,
еланнарга канат куеп.

## Үземне юатам...

Зәмһәрир кыш көнне чәчкәгә кунам дип, исәр кош
бәрелде тәрәзгә, имгәтте канатын.
Мин дә шул кош кебек, кулҗитмәс матурга
җан атып, күпме кат җанымны канаттым...
Шулай да үземне юатам: гүзәл хис — ярату!

## Төнге учак янында

Офыктагы кара болыт —
толымнарың күләгәсе.
Ялкын теле —
күз нурыңның бер очкыны.

Каршыңда — мин.
Матриархатның
үзе теләп әсир төшкән
бер тоткыны.

❋

КҮҢЕЛЕҢНЕҢ —
Изгелек китапларын һәммәсен укыдым.
Явызлык тулганнарына көчем юк...

## Теннис кортында

Мин — яшеннәр уртасында!

Синең яктан килгән һәрбер ак шар —
күңелеңнән килгән йолдыз күк!

## Урын

Түрдәме йә ишек катындамы,
урыным минем —
вөҗданы булганнар янында.

❋

Рәшәләнеп торган күңелдә
оча Хәтер күбәләге.

❋

Ил мантырга теләмәсә —
халкыннан дошман эзләр.

## Тегермәндә

Дөньяны яктыртып, агартып
мөшкәдән җылымса он ага.

## Бу заманда

Хакыйкатьнең күзенә карап,
күңелдән яшь чыга.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Зөфәр Фәтхетдинов

# ҮЛЕМ ЭЛМӘГЕ

РОМАН



Милиция» алып киткәннән соң, Михаил Тряпкин суга төшкән кебек юкка чыкты. Бу сәер хәлне Талип Әкрәмовичка да сөйләргә, аңардан киңәш сорарга туры килде.

Контрразведка «төлкесе», Шамилнең хикәятен тыңлап та бетермәстән, үз сүзен әйтергә ашыкты:

— Аңлашылды, агайне, аңлашылды. Доктор Тряпкин белән күн заводы эшчесе Семен Перинов — икесе бер үк кеше, дип әйтергә җыенасыз.

— Ничек инде бер үк кеше булсын?..

Мулюков, учы белән аның авызын капларга теләгәндәй ишарә ясап, ярты сүздә туктатты:

— Ак таштан, кара таштан... сөйлимме яңабаштан? — дип шаярткан булды.— Игътибар итегез әле: Перинов Семен Семенович карачкысы кай чакларда калкып чыга? Казанда — дары заводын шартлатырга җыенганда; Чистайда — полковник Кузнецовны шпионлыкка дүндергәндә... Кыскасы, билгеле бер эш-хәрәкәт вакытында гына. Йөзен танытмаска юлбасарлар кия торган оек-маска белән бер ул исем. Операция тәгәлләнә яисә барып чыкмый икән, әлеге оек-исемне сала да куя — вәссәлам. Теге чакта тикшердек, ачыкладык: күн заводында чынлап та Перинов Семен Семенович дигән кеше бар булып чыкты. Шактый олы яшьтәге эшче иде ул. Әмма немец агенты түгел. Карачкы аның исемен генә файдаланган.

— Ә Карачкы үзе...

Шамил ниндидер сорау белән бүлдермәкче иде, Мулюков аны тагын кул ишарәсе белән туктатты: сабыр ит, янәсе, ашыкма.

— Узган ел, полковник Кузнецов үлемен тикшереп кайту белән, күн заводына йөгердем. Кәгазьләрне караштыра башлагач, Перинов Семенның март аенда ук эштән китүе мәгълүм булды. Тик бу хәлнең Карачкы белән бәйле икәнлеген исбатлау берничек тә мөмкин түгел иде. Кем белә, бәлки, эз яшерү өчен, Периновны да үтереп ташлагандыр ул...

Мулюков авыр көрсенеп дәвам итте:

— Чистайда чакта ук шигем бар иде... Сезгә хәтле кузлада

Ахыры. Башы 9, 10 саннарда.

утырып дилбегә тоткан арада иң аегы... Полковникның башына шул Тряпкин гына җиткәндер дип уйладым. Полковник янына Перинов булып та нәкъ менә ул барганын сизендем. Казанга кайткач Тряпкин хакында мәгълүмат та җыя башлаган идем. Ләкин беренче адымны атлауга ук туктап калдым: аның хәрби госпитальдә врач булып эшләве ачыкланды. Шул хәл кулдан коралны сукты да төшерде.

— Үтерүченең табиб булуы бер дә гаҗәп түгел югыйсә...

— Аны хәзер генә әйтүе җиңел, агайне. Кичә син шалтыраткач та, күкрәгемдә яңадан контрразведчик йөрәге тибә башлады. Теге чактан калган канәгатьсезлек хисе дөп-дөп бәрә. Тряпкинның госпитальдә әле бер елдан артыграк кына эшләвен, бик уртакул врач булуын ишеткәч, шигем тәмам бугаздан алды. Дары заводындагы диверсант үткән елның март башында тотылган иде бит. Озак та үтми — март ахырында — госпитальдә Тряпкин пәйда була. Язулары барысы да тәртиптә. Бөтен кешегә ялагайлана, юхалана, мин сиңайтим. Шуңа күрә эшендәге хаталарын да күрмәмешкә салышалар. Госпитальгә ул бик яхшы чамалап керә: яралыларны сөйләндереп, азмы-күпме мәгълүмат җыярга да җайлы; врач буларак «әлләкем» түгел икәнеңне дә сиздермәскә була: кызыл гаскәри егетләр — түземле халык — ничек дәваласаң да төзәләр...

— Ә нәкъ менә күн заводы эшчесе ник кирәк булды икән аңа? — дип куйды Шамил.

— Мин үзем дә шул сорауга җавап эзләдем. Перинов фамилияле адәмнең күн заводында эшләвен ул, мөгаен, кешеләр аша белгәндер. Аны йөзгә таныган булуы да бик мөмкин. Чөнки ул Периновны «карачкы», дөресрәге «яшен үткәргеч» итеп файдаланган булырга тиеш.

— Алайса ул аны һәрвакыт күзәтеп торган...

— Син беләсең инде: диверсант белән Карачкының даими очрашу урыны — күн заводы каршында. Ә менә ашыгыч элемтәгә кирәсе булса? Якшәмбе көннәрендә завод эшләми бит. Ул чакта нишләргә?

— Димәк... Карачкы шул тирәдә генә яшәгән булып чыга?! Йә, зарыктырмагыз инде, Талип Әкрәмович. Әзенә төштегезме, юкмы?

Мулюков аның соравын ишетмәгән дә кебек кыланды:

— Кызыл Чәгендер урамына ул соңыннан күчкән. Диверсия барып чыкмагач... Ә теге чакта аның фатирыннан завод каршысындагы мәйдан күренергә тиеш булган. Периновның иртән эшкә килүен күзәтеп күңелен тынычландыру өчен дә. Диверсантка «койрык» ияреп килмәгәнме дип тикшерү өчен дә. Шуңа күрә һәр очрашуга ул чирек сәгатькә соңгарып килгән...

«Юри суза,— дип нәтиҗә ясады Шамил.— Күрәсең, исәпләп чыгара алмагандыр».

— Мин кичә шул тирәгә барып килдем,— диде Мулюков, егетнең сабыры төкәнүен чамалап.— Чаттагы йорт, икенче каттагы бүлмә — бөтен урам уч төбендәгедәй күренеп тора. Хуҗасы — шактый бетәшкән, колакка да бик сак корткa. Карачкы аңа күн заводында эшлим дигән, исемен Семен дип таныткан. Ятимә карчыктан куркып тормаган, әлбәттә. Әмма әбинең әле күзе яхшы күрә, хәтере шәп. Ул үзенең квартирантын шундый нечкәләп тасвирлады — Тряпкинның төп-төгәл сурәте килә дә чыга. Семен аның түбә-канаты астында бер елдан артык яшәгән. Карчыкның әйтүенчә, имештер, үткән елның язында Тверьгә, эти-әниләре янына кайтып киткән. Байгыш кебек үзалдына гына карап яшәгән. Хатын-кыз алып кайтмаган. Киенеп-ясанып йөрмәгән. Дөрес, кайчакта командировкаларга, яисә каядыр кунакка бара иде, ди. Шундый чакта гына көязләнеп алган.

— Сез ул карчыкка үзегезне кем дип әйттегез инде?

— Әйе, алай-болай мине эзләп гомер уздыруыгыз бар бит әле. Фәлән кеше килгән иде, дисә... Мин аңа фатир сорап кергән булдым да шунда сөйләштереп утырдым. Бик сүзчән әби, сорау биреп аптырыйсы юк...

Шамил, рәхмәт әйтеп саубуллашканда, Мулюковның кәефе күтәренке булуына игътибар итте: «Чынлап та, яңадан контрразведчик дәрте уянган Талип Әкрәмовичта. Нинди канәгать ул бүген үз-үзеннән!..» — дип уйлады.

— Сез миңа үпкәләмәгез, Шамил, якын күреп кенә кисәтәсем килә,— диде Мулюков, яшь чекистның кулын җибәрмичә.— Карачкы — бик житез, бик хәйләкәр дошман. Үзенең эзенә басканны бер чакрымнан сизеп тора. Куркытмаска тырышыгыз аны...— Кинәт кулын тартып алды. Авыр сулап куйды.— Йөзегездән күреп торам: сез дә ычкындыргансыз ул еланны... Их!..

...Икенче көнне Шамилне Брауде үзенә чакырды.

— Кузьмин йортында булган атышны хәтерлисеңдер...— дип сүз башлады.— Хәзер сүз аның хатыны турында...— Вера Петровна алдында яткан кәгазьгә кызыл карандаш белән нindидер билге ясады.— Шактый каты чикләвек булып чыкты ул ханым. Баштарак авызына су капкан кебек, берни дә сөйлисе килмәде...— Брауде, бик мөһим сер әйтергә җыенгандай, Шамилгә туп-туры, сынап карады.— Кузьмин соңгы вакытларда астыртын, йомыкый бәндәгә әйләнгән, хатынына да ачылып бетмәгән, имеш. Моның шулай булуы бик ихтимал: алар әле күптән түгел, март аенда гына өйләнешкәннәр. Үзенең караңгы эшләренә яшь хатынын җәлеп итәргә өлгермәгәндер, ә бәлки теләмәгәндер дә. Шулай да, тел яздыра торгач, боларга Серадов...— алдындагы кәгазьгә карап алды Брауде.— ...Алтынбай Тархнович дигән берәүнең килеп йөрүе ачыкланды.

«Дөнья нинди тыгыз! — дип уйлап алды Шамил.— «Килә ява бер болыт» дигәндәй, шул ук Чистай төрмәсе «каһарманнары» әллә нинди юллар белән, бер төенгә төйнәлә бара, төйнәлә бара...» Кайчандыр аны үлемгә хөкем иткән Серадов ич бу! Юл өстенә тагын шуның шәүләсе төшә!»

Серадов турында белгәннәрен сөйләп биргәч, үз-үзеннән сорагандай, әйтеп куйды Шамил:

— Ничек табыштылар икән алар? Полковник Кузнецовның соңгы хаты буенча эзләп килгән дисәң... Кузьмин белән Серадов арасында нинди уртаклык булырга мөмкин?..

— Серадовның кайсы шайтанга ялланганы әлегә мәгълүм түгел,— диде Вера Петровна.— Бер генә нәрсә ачык: Кузьмин йорты Совет властена каршы көчләрнең яшерен очрашу урыны булган. Атышканда һәлак ителгән есаулның кесәсеннән чыккан кәгазьләр дә әллә ни бирмәде.

Тәрәзә төбеннән салынып төшкән френчлы зур гәүдә әле дә булса күз алдында тора Шамилнең. Маузеры белән бер егетне харап итәргә өлгерде бит, каһәр.

Вера Петровна өстәл тартмасыннан папирос алды, бармак очлары белән генә баскалап аны йомшарткан булды. Авызына капты, кабызды, тирән итеп бер суырды.

— Ул есаул дигәнебез Кузьминны Дон буйларына китәргә димләгән. Атаман Краснов контрразведкасында синдәйләргә эш тә, дәрәҗә дә, акча да табылыр, дигән. Кузьминның хатыны шул сүзләрне ачык ишетеп калган.

Брауде, урыныннан торып, тәрәзә буена китте. Пәрдәләрне як-якка тибәреп, тәрәзәнең бер канатын ачты. Бүлмәгә иртәнге йомшак җил, саф һава ургылып керде.

Шамил әле һаман Алтынбай Серадов турында уйлый иде.

— Димәк, теге атыш вакытында Серадов әфәндене кулдан ычкындырганмын инде мин?

— Юк, ул әле килеп җитмәгән булган. Син өйгә керергә ашыккансың. Әмма качкан кешенең дә кем икәнлеге билгеле...

Измайлов урыныннан талпынып куйды. Ә Вера Петровна, сүзен шунда юри өзеп, урынына кире килеп утыргач кына дәвам итте:

— Дардиев булган ул. Хәтереңдәдер, Миргазиянов Самат исеменнән безгә хат язучы...

— Ә-ә-ә. Элеккеге прапорщик... Кузьминның ахирәт дусты, шешәдәше...

— Күрәсең, без уйлаганга караганда, сәеррәк фигура ул Дардиев та. Хатны, әлбәттә, үз белдеге белән сырламаган — юк: бусы мәнди анасына да билгеле. Кемдер аңа ни язасын әйтеп торган, юнәлеш биргән. Аңлыйсыңмы, нинди көтелмәгән бәйләнешләр ачыла! Серадовтан Дардиевка, Мусин белән аның «кунак егете»нә һәм Константин Балабанов бандитларына ук барып тоташа. Кайдадыр, шул пәрәвез җепләрен үрмәкүч сыман бергә учка җыеп, немец агенты Карачкы утыра... Аларның тегеләйме, болаймы үзара баглы булуына минем бер шигем дә юк. Җепнең бер очыннан эләктереп аласы да сүтәсе иде, туздырасы иде шул көфер почмагын...

Вера Петровна тәмәке төпчеген утлы башы белән көллеккә басты.

— Әле генә сөйләгәннәрем — белеп тору, мыегыңа урап кую өчен... Ә менә бусы...— Брауде ачык сейфка үрелеп, аннан саргаеп какланган кәгазь бите алды: — ...сиңа, буш вакытыңда бераз баш ватсын әле дип, әзерләп куелган табышмак.— Сейфтан тагын бер бит кәгазь алып сузды: — Шул башваткычны табып кайткан милиция хезмәткәрләре рапортын да карап чык. Бу план-картаны аларга бандит «бүләк иткән». Нindидер шайканы куа барганда... Һәм шул шайкага — беләсеңме, кем? — әлеге дә баягы Мусин эзләре барып тоташа. Аңламассың ул Мусинны: әле уголовниклар арасында йөри, әле анархистлар белән бәйләнешкә керә...

Телефон чылтырады. Брауде, сүзеннән бүленеп, трубканы алды, бер сүз дә дәшмичә тыңлады, иң азактан гына:

— Аңлашылды. Ике егетне җибәрәм,— диде.

Телефонны ташлап, бөтен гәүдәсе белән Шамилгә таба борылды, ашыгып әйтте:

— Хәйретдиновны ал да, хәзер үк — «Цивильское подворье» кунакханәсенә!.. Анда сезне Мурашкинцев көтә.— Вера Петровнаның җитдиләнеп киткән йөзендә елмаю чаткысы кабынып сүнде.— Уголовный розыск хезмәткәрләре Мусинның эзенә басып баралар. Искә төшереп кенә тора идек үзен,— гомере кыска булыр, күрәсең...

...«Алла йорты»нда чекистларны Мурашкинцев каршы алды. Эшнең асылын тиз генә аңлатып, ул Измайловка «Воскресный день» журналын сузды:

— Мусин торган бүлмәдән таптык,— диде.

Журналга бер күз салу белән, сагаеп калды Шамил: Сөембикә манарасының түбәсеннән төрле якка сузылган җеп-сызыклар...— болар әле генә Вера Петровна биргән борынгы план-картадагы сызыкларга бик тә, бик тә охшаган ич!

Мурашкинцев, әлбәттә, аның уйларын сизмәде, ашыктыруын гына белде:

— Әйдә, калганын юлда карарсың, тизрәк Әрхәрәй дачаларына юл тотыйк! — диде.

Шулай да башта Кремльгә, консисториягә сугылып чыгарга булдылар. Анда бердәнбер яңалык: владыка Иаковның ни өчендер Питерга ук юл тотуы мәгълүм булды.

— Турыдан — Георгий урамы аша! — дип кычкырды Мурашкинцев шофер егеткә.

Бөтен көчкә чапкан машинада рәхәт җылы җил агымына йөзләрне куеп барганда, болыт артыннан ялтырап кояш күренде. Тиздән Әрхәрәй резиденциясенең матур манзарасы да ачылды.

— Ух син, малай! — Бүтән вакытта ни басынкы Мурашкинцев сызгырып куйды.— Җәннәт бакчаларың бер якта торсын!

Барысы да, авыз ачып дигәндәй, өскә карадылар. Таш суы белән агартылган кирпеч дивар эчендә, талгын рәшә дулкынында тирбәлеп ап-ак ташпулат балкый. Аның сул ягында алтын очлымнары, зәңгәр гөмбәзләре белән бәләкәй генә чиркәү күз явын ала.

Шушы кирмәнчекне иңенә утырткан тау ямь-яшел чирәм белән капланган. Ә аның итәгендә, юлдан ерак та түгел, нык торыклы, дәү ябалдашлы карт тирәкләр тезелешеп баскан.

Юлның сул ягында тауның ярты кашлактан ук текә убылган төше күренә: ул текә яр, шәт, берничә катлы йорт биеклегендә булыр.

Уң кулда исә көмеш тәңкәләр сибелгән кебек зур күл ялтырый. Митрополит йортының тәрәзәләре дә шул Кабан ягына карый. Икенче каттагы ике тәрәзәдән сөт төсле ак пәрдәләр, әнә, тышка ук суырылып чыккан да җилдә салмак кына тирбәлеп тора. «Гаҗәп,— дип уйлап алды Измайлов,— икенче каттагы бүтән тәрәзәләр дә шар ачык, ә алардагы пәрдәләр тарттырып кадакланган шикелле — кымшанырга да уйламыйлар».

Ул арада машина сулга — тигез, такыр юлга борылды, аннары, көчәнеп үкерә-үкерә, өскә — капкага таба үрмәләде. Әмма тимер капкага эт башы хәтле йозак эленгән булып чыкты.

— Да-а...— дип сузды Мурашкинцев, кинәт боега төшеп.— Мондый йозакны бомба белән дә ача алмассың. Владыка үз йортына берәүне дә аяк бастырмаска кушкан, күрәсең... Гаеп итештән булмасын, туганнар, балактагы тузанны бераз кагып алырга туры килә инде.

Өсте яшел калай белән тышланган дивар әллә ни биек тоелмый иде. Мурашкинцев, кул ишарәсе белән башкаларны да үз артыннан әйдәп, таш коймага үрмәләде.

Күземә шулай күренәме әллә, дип аптырап калды Измайлов, ишегалдына килеп төшкәч. Гади ишегалды гына түгел, тигез-матур аллеялары, аллы-гөлле чәчәк түтәлләре, бөдрә юкәләре һәм кояш нурында салават күпере булып балкыган көмеш фонтаны белән ис-акылны алырлык гаҗәеп парк-бакча иде бу. Сул кулда — митрополит өе: зәп-зәңгәр күк гөмбәзе астында аның ак сыны күзне чагылдыра. Ә уң тарафта, бәләкәй чиркәүдән ерак та түгел, юкәләр рәте буйлап мәһабәт кенә атлап тавис кошлары йөренә.

— Кара син боларны, ә! — Мурашкинцев та бу күренешкә хәйран калган иде.— Ахирәт гүзәллекләренә барып ирешкәнче үк үзләренә нинди оҗмах төзеп куйганнар. Бу дөньяда да, тегесендә дә бал-майда йөзәргә исәпләре бөтен. Безгә исә, юләрләргә: «Ачлыкка да, ялангачлыкка да түзегез, түз, ходай каршысына баргач, рәхәт күрерсез»,— дигән булалар...

Мурашкинцев, егетләренә тиешле боерыкларны биреп, архиерей йортына таба атлады. Ә Измайлов, ишек төбендә үк туктап, юан кирпеч баганаларга утырган, пыяла белән тышланган матур галереяны карап тора иде.

— Шәп эшләнгән,— диде Мурашкинцев, аның янәшәсенә басып.— Кар-яңгырларда чыланмыйча, ташпулатның икенче катыннан туп-туры чиркәүгә уза ала владыка. Таш яуса да берни түгел...

Әмма Измайловның чыраенда сокланунын эзе дә юк, киресенчә, күзләре сагаеп кысылган иде. Мурашкинцев чекистның шөбһәле

уйларын йөзеннән укыган кебек булды, шунда ук бер милиционерны чакырып, чиркәү ишеге төбенә бастырды.

— Аң бул... Йомраннар, асларына су кергәнен сизеп, берәмберәм өскә калыксалар, йоклап калма,— дип өстәде.

Бөтен бүлмәләрне, подвал һәм чардакны айкап-капшап чыктылар. Чиркәү эчләре, монах хөҗрәләре калмады, хәтта мунча белән ат сараен да җентекләп тикшерделәр. Әмма бернинди нәтиҗәгә ирешеп булмады: Мусин да, аның белән йөрүче «кунак егете» дә табылмады.

Мурашкинцев, яңадан архиерей йортына әйләнеп кайткач, Шамилнең ике монах белән сөйләшеп торуын күрде.

Караңгы чырайлы монахлар власть вәкилләренең кемнедер эзләп килүен инде аңлап алганнар иде. «Монда бер генә чит-ят кеше дә юк, ә Варсанофий атакай чирләп тора; хәзер Казанда ул, бертуган сеңелесе янында.»— диештеләр.

Арудан да түгел, уңышсызлыктан кәефе кырылып, тәрәзә янагына сөялмәкче иде Мурашкинцев, әллә ничек кенә, маңгае белән дөп итеп рамга бәрелде. Һәм шулчак кемнеңдер үзенә үтәли тишәрлек итеп каравын тойды. Як-ягына тиз генә күз йөртеп алды, утызкырык адымда гына, тәрәзә аша күренеп торган чиркәүне капшады. Аны бораулап торган караш шунда — тимер челтәр-рәшәткә тартылган кечкенә тәрәзә уемында иде. Мурашкинцев яхшырак күрү өчен, кашын җыерды, күзләрен кыса төште: түгәрәк тук чырай, зур купшы кара сакал...— кем булыр бу?! «Тасвирлаулары буенча Варсанофийга да туры килә, ләкин аны Казанда диделәр бит. Монда булса, нигә качып ятыр икән?»— Бер мизгел эчендә шундый уйлар үтте Мурашкинцевның башыннан. Ни генә булса да, кемнеңдер усал күзләре аның йөзенә кадак каккан кебек бага иде.

Мурашкинцев әкрен генә чекистка эндәште.

— Кил әле, Шамил, чиркәүнең уңдагы тәрәзәсенә кара әле,— дип пышылдады.— Әнә шуннан иблис үзе күзләрен тасрайтып торадыр шикелле.

— Мин анда беркемне дә күрмим,— диде тегесе, җилкәсен җыерып.

Мурашкинцев та игътибар беләнрәк карады.

— Чынлап та юкка чыккан... Ах, шайтан! — Аның тавышында аптырау сизелде. Ул шундук ике милиционерны алып, чиркәүгә ташланды.

Чиркәү буш, анда Кара сакал да, бүтән адәми зат та юк иде. Ишек төбендә калган милиционер шулай ук: «Моннан берәү дә үтмәде»,— дип тора.

— Менә сиңа кирәк булса! — диде Мурашкинцев, архиерей йортына кире кайтып.— Тәрәзәдә карачкы кебек берәү чагылып китте дә юкка чыкты. Күземә генә күренмәде ич инде ул Кара сакал!..

Измайлов, бер сүз белән дә җавап кайтармыйча, янә җилкәсен сикертеп кенә куйды. Ул икенче каттагы бүлмәләрне тагын бер йөреп чыгасы итте. Болар «Цивильское подворье» хөҗрәләре генә түгел шул. Биек түшәмнәр, затлы җиһаз! Ачык тәрәзәдән бер күз салсаң, үзеңне зур ак пароходның өске палубасында итеп тоясың. Әйтерсең лә вакытлыча гына бер пристаньга туктаган да бу пароход, менә хәзер, менә хәзер кузгалып китәргә җыена. Шул тәэсирне көчәйтеп, аста, вак таллы, камышлы ярлар кысасында зур көзге сыман күл җәелеп ята, нәкъ Идел өстендәге төсле моңсу тавышлы акчарлаклар канат кага.

Шулай йөри торгач, иң кырый бүлмәгә дә барып җитте Шамил. Монда инде урамга чыгу, дөресрәге — ябык коридор буйлап чиркәүгә бару юлы ачыла. Бая да ул галерея ишегендәге шул зур йозакка килеп төртелгән иде. Бу юлы хәтта: «Сәер бит: өй эчен-

дәге ишеккә амбар йозагы элгәннәр»,— дигән уй килсә дә, бик тиз онытылды.

Шамил гадәтенчә тәрәзәдән аска карады, тагын бер мәртәбә «палуба» рәхәтлеген кичерде. Кузгалып киткәндә генә игътибар итте: тышта җил әле тынмаган — җиләс, йомшак җил, ә тәрәзә пәрдәләре нигәдер тирбәлүдән бөтенләй туктаган иде.

— Нишләп алай, ә? — чекист үзен озатып, һәр адымын күзәтеп йөрүче монахка таба борылды.— Бая гына менә бу пәрдә бәргәләнә-бәргәләнә җилдә чайкала иде. Ә хәзер... Нигә ул селкенеп тә карамый?

Тегесе аптыраган-йөдәгән төс белән чекистка текәлде. «Үзем дә белмим»,— ди иде бу караш.

— Ярый. Хәзер, эт сизгәнче беләбез аны.— Измайлов башы белән галерея ягына ишарә ясады.— Яле, алла хезмәтчесе, йозакны келт итеп кенә ач әле.

— Ач... ач... Минем ачкычым юк... Әһә...— Монахның куркуы иреннәренә чыкты.

Шамил, әлбәттә, моны сизеп алды, уенын-чынын кушып, кырыс төскә керде:

— Кемдә ул ачкыч, ә?

— Владыка кулында. Әһә...

— Ә тышкы ишек ачкычы нишләп аңарда түгел? Ничек инде ул бер ачкычын сезгә ышандыра, икенчесен бөтенләй бирми?

Монах каушап, бармакларын уды, аягын авыштырды, әмма ләм-мим сүз кайтармады.

— Сезнең монда кайсыгыз баш? — диде чекист, аның чарасызлыгын күреп.

— Кем баш?..— дип кабатлады монах көтелмәгән хәбәрдән югалып калган, әле дә булса зиһенен җыя алмаган кеше кебек.

«Башын җүләргә сала! Вакытны суза дисәң... Нинди максат белән?»— дип уйлап алды Измайлов.

— Кайсыгыз баш, дим!.. Ачкыч кемдә? Йә, тизрәк бул! — дип ашыктырды ул монахны.

— Варфоломей баш... Варфоломей, әһә...

— Кайда соң ул? Варфоломей кайда?

Монах, моннан кире чыгу юлын күрсәтеп, теләр-теләмәс кенә баш какты.

— Балык ашатырга киткән ие... Әһә...

— Ниткән балык ул тагын? Нәрсә, сез монда балык тотып ятасызмыни?

Монах ашыгып аңлата башлады (Шамилгә ул кинәт кенә хафага калган кебек тоелды). Чиркәүнең теге ягында саф сулы кечкенә генә буа бар, аның чит-читләрендә ак төнбоек үсә, шунда балык үрчетелә, имеш.

Измайлов белән Мурашкинцев бер милиционерны тиз генә Варфоломейны алып килергә җибәрделәр.

Ул арада Шамил «балыкчы» турында кайбер мәгълүматларны белешеп өлгерде. Варфоломей монда әле күптән түгел, апрель аеннан гына «штатта» икән. Шуңа кадәр Раифа монастыренда яшәгән...

Милиционер китте дә юкка чыкты, көтеп-көтеп тә кайтмады. Измайлов белән Мурашкинцев, ул күренмәсме дип, ишегалдына караган тәрәзә каршында торалар иде.

— Әнә! Әнә... Тагын теге Сакал... тәрәзәдә! — дип кычкырды кинәт Мурашкинцев.— Күземә генә күренәме соң әллә? — Кая таба карыйсын ым-ишарә белән Шамилгә дә аңлатып маташты. Ләкин Шамил бу юлы да чиркәү тәрәзәсендәге сәер «Сакал»ны күрмәде.

— Берәү дә юк шикелле анда... Нишләптер мин күрмим...— дип, уңайсызланып, гаепле төскә керде ул.

Федор Лукич, тәрәзә уемындагы иблис күзләре ничек тәэсир итәр икән дип, Шамилне күзәтеп-сынап тора иде. Карашын тиз генә чиркәүгә күчерде. Түзмәде, сызгырып җибәрде:

— Ю-у-ук! Өрәктер лә бу, адәм түгелдер. Яисә албастыга әйләнеп йөри торган берәр рухани бардыр монда, валлаһи! — Мурашкинцев бу юлы бер егетен чакырып алып, аны гына чиркәүгә кертеп җибәрде. Сакаллы албастыны тапмыйча чыкма, дип колагына киртләде. Аннары: — Ходай юлында йөрүче изге-әүлиялар арасында да әллә нинди тәмуг кисәүләре булган ич, чын-чынлап албасты сурәтенә кереп йөргәннәр! — диде.

Шамил аның төрле тарихлар сөйләргә яратуын белә иде, шуңа күрә астыртын гына ут үрләтте:

— Китче?! Гөнаһтан, халыктан курыкмаганнармы? — дигән булды.

— Нишләп курыксыннар? Тәүбә итсәң, ходай барысын да ярлыкый, ә халык алар каршында — кара сарык бит ул...— Федор Лукич, чекистның хәйләсен сизеп, бераз үртәлә, ихтыярсыздан кузгалып килүче сүз-сөйләү өянәген басарга тырышып та, баягы «өрәк»не тагын бер күрергә теләп тә, күзен чиркәүдән алмый иде әле. Ләкин тимер рәшәткәле тәрәзә уемы утсыз мич авызы кебек караеп торуында булды. Ә Мурашкинцевның «сүз казаны»на менәменә кайнау кирәргә тора.— Бүтәннәргә ни сан,— дип дәвам итте ул, теленә салынудан бераз уңайсызлану да кичереп, чиксез рәхәт-тәм дә табып.— Рим папасы Иоанн XXIII, әнә, әүлия чикмәне кигәнче, яшьлегендә диңгез пираты булган. Өч йөз монахиняны көчләгән. Үзе алдыннан тәхеттә утырган папаны агулаган. Әле аның белән генә дә бетми Иоанн хикмәтләре.

— Булмас ла... Шундый дегет чиләге ничек папа булып утыра алган?

— Ышанмыйсыңмы? — Мурашкинцев, әле сүнеп бетмәгән өмет белән, янә чиркәү тәрәзәсенә күз төшереп алды.— Мин үзем укыдым ул хакта. Билләһи! Себер трактында духовный академия булганын беләсеңме? Менә шунда безгә кардәш тиешле бер агай укыта иде. Ул миңа китаплар биреп тора, үзе дә бик күп кызыклы нәрсәләр сөйли иде. Белмәгәне бер дә юк иде ул агайның...

Мурашкинцевның бер күзе Шамилгә, икенчесе чиркәү ягына карый иде: көрәк сакаллы теге пумала башны ничек тә күрсәтәсе килә кебек иде. Аның борчылуы Измайловка да күчте. Үзе белән килгән яшь чекист Хәйретдиновка кычкырды:

— Эскәр, бар әле, егетләрне кузгат, йокыга киткәннәр бугай.— диде.

— Беләсең килсә, Шамил, баштүбән йөргән әүлиялар, папалар бер Иоанн белән генә бетми,— дип дәвам итте Мурашкинцев.— Мәсәлән, Александр VI дигән папа белән аның тәти кызы Лукреция теләсә нинди шайтанны юлдан яздырырга сәләтле булган. Кызының һәр туенда... Ә, оныта язганмын: Лукреция, ширбәтле ай үтү белән чираттагы ирен агулап үтерә дә, байлыгын үзенә ала икән; шуңа күрә аның зөфаф кичләре шактый еш булып торган... Менә шул туйларны Александр VI ачыктан-ачык уйнаш кылу, Рим кызларын йөгертү мәҗлесенә әйләндерә. Әйтик, алтынчы туйга изге папа иң сылу илле куртизанканы чакыра. Өсләренә ятьмә кебек үтә күренмәле тукыма ябындырып кына утырта. Туйның иң кызган вакытында, папаның ишарәсе белән, чибәркәйләр шул оят япмаларын да салып ташлыйлар. Әлегә кадәр сакал сыпырып утырган тәкъва агай-эне, ачыккан ата эт ярсуы белән, шәрә куртизанкаларга ябыша. Кем кая утырса шунда үз кәсебенә керешә, мин сиңәйтим: идән дә, хәтта ризык-хәмер тулы өстәл дә зөфаф түшәгенә әйләнә.

Измайлов «өстенә басарга» тырышты:

— Дин тарихчылары, билгеле, бу вакыйганы ишеткәч, төкерә-төкерә чукыналар инде, ә... Сафсата, бөһтан яла, диләрдер...

— Юк-юк, алар да нәкъ шуны раслап тора!

— Алайса, иблис-мәлгунь вәсвәсәсе, диләрме?.. Сабый кеби саф күңелле папа белән аның гыйффәтле кызын шул мәлгунь саташтырган түгелмени?

— Юк шул! — Мурашкинцев тагын башын чайкады.— Папаның гайбәтен сату да, димиләр, шайтанга да сылтамыйлар. Болай дип аңлаталар: Александр VI бу тамашаны бүтәннәргә гыйбрәт өчен оештырган, имеш: гөнаһка батуның ничек җиңел икәнлеген ачык мисал белән күрсәтеп биргән. Яшь куртизанкалар өстендә, ягъни мәсәлән. Вәт шул.

— Шәп... Акылга сыймаслык, әмма барча чиркәү әһеленә сабак булырлык...

Мурашкинцев мыек астыннан көлемсерәде:

— Әйе, ул сабакны безнекеләр дә бик һәйбәтләп үзләштергәннәр. Кәҗә чикләвеге кебек, шулхәтле бер-берсенә охшарлар икән! Конашевичны гына алсаң да... Рим папаларының төшенә кермәгән нәрсәләрне эшләгән...

— Елизавета патша заманында йөзеп калган Казан әрхәрәен әйтәсеңме? Лука Конашевич — Аксак Каратунны?

— Шул үзе. Чиркәүдәге җылы урыннарны сатып, христианның, керәшеннең канын эчеп симергәч, ул комсыз епископ бөтен губерна татарларын таларга керешә. Кул-аягын тәмам чишү өчен, императрицаның үзеннән фатиха ала.

— Ничек, махсус указмы? — дип куйды Шамил. Ул бу хакта ишетмеш буенча гына белә; Федор Лукич сөйләгәннәрнең күбесе аның өчен, чыннан да, яңалык иде.

— Мең җиде йөз кырык икенче елда Казанның януы турында ишеткәнең бардыр.— Мурашкинцев, яңа дәрес аңлатырга керешкән мөгаллим кебек, тәфсилләп, тәмләп сөйли башлады.— Шәһәр кисәүләр өеме булып тәтәп ята, ә Лука Конашевич инде көне-сәгате белән императрица янына ашыга. Эчә-эчә шешенгән шул надан хатынга: Казандагы янгын — мөселманнар эше генә, дип сөйли, аларның тораклары, җирләрен тартып алырга өнди. Татар бистәсенең дә нигезенә хәтле янып бетүен әйтү кая! — киресенчә, аларның йорт-куралары исән калды, руснык гына харап булды, дип бара. Имештер, ут төртүче татарлар инде тотылган да икән. Кайда соң ул имансызлар, китерегез монда, хөкем итик үзләрен, дигәч, Конашевич күзен дә йоммый: «Агу эчеп үлделәр алар»,— дип ялганлый...

«Укытучы» сын бүлдереп булса да, Шамил бу урында үз белгәнен кыстырды:

— Минем дә ишеткәнем бар иде: ул чорда Казанның янулары — Аксак Каратун этлеге генә, дип. Имеш, кара максатына ирешү өчен, әз генә ут-күз белән уйнап алырга җыенган да, үз кешеләреннән иске агач чиркәүгә ут төрттергән. Ә агач урынына зур таш чиркәү салу уе булган...

— Петр һәм Павел чиркәве ул,— диде Мурашкинцев.

— Менә шул чиркәүгә ут кабу белән, һич көтмәгәндә җил күтәрелгән дә, «кызыл әтәч» бөтен шәһәр буйлап йөгерә башлаган, имеш...

— Ә ул нәкъ шулай килеп чыккан да. Өеңә карак керсә, бер әйбереңне ала, нигезеңә ут төшсә — бөтен малыңны ялмый, дип, белми әйтмәгәннәр. Әмма Конашевич заманына кадәр дә, аннан соң да Казанның шулай илереп янганын тарих хәтерләми. Чөнки ул оятсыз епископ һәр «кызыл әтәч»тән үзенә алтын күкәй салдыртып калган. Өстәвенә меңләгән кешеләрне кан-яшь елаткан, дүрт йөздән артык мәчетне җимерттергән...

Үзенең хикәяте белән мавыгып киткән икән Мурашкинцев, бая чиркәүгә кертеп җибәргән егетенең кай арададыр ишегалды аша үткәнен күрми калган. Менә инде ул, тынына кабып, икенче кат ка йөгереп менгән, каршысында ук басып тора.

— Анда берәү дә юк! — диде милиционер еш-еш сулап.— Әмма кемдер булган. Сез әйткән тәрәзә төбенә терсәге белән таянган да, тузанны сөртеп алган.

— Күзгә генә күренмәгән инде алайса,— дип куйды Мурашкинцев.— Димәк, Варсанофий атакай монда: кайсыдыр ярыкка кереп поскан. Әле Мусин да аның итәге астына елышкандыр.— Нәрсәдер исенә төшкән кебек, Шамилгә таба борылды.— Беләсеңме, ул Мусинның кулы хәтта Мәскәү мулласының канына да буялган. Ике мулла хәер акчаларын бүлешә алмаганнар. Берсе икенчесен үтертү өчен Мусинны яллаган.

Яшь милиционер Мурашкинцевның боерыгын көтеп тора иде.

— Варфоломийны табып кайтканчы көтәргә туры килә. Хәзергә керфек тә какмыйча чиркәүнең тәрәзәләрен, керү-чыгу юлын күзәтегез.— Әмер шул булды, егет кушылганны үтәргә китте.

«Варфоломий озаклады. Әллә инде анысы да качканмы?» — дип уйлап алды Шамил. Вакытның бик әкрен узуын онытып торыр өчен, Федор Лукич хикәясен дәвам иттерергә кирәк иде. Шуны искә төшереп:

— Рим папалары түшәк яңартканда, Конашевич кисәү башы белән генә селтәнеп йөргәнмени? — диде Шамил. Мурашкинцев, бөтен дикъкатен янә чиркәү тәрәзәсенә баглаган булса да, белгәнен сөйләү ләззәтеннән баш тарта алмый иде. Өзелеп калган сүзен җай белән генә ялгап китте:

— Һәй, аның маҗараларын сөйләсәң... Иеромонах Досифей дигән берәүнең Изге Синодка язган шикаяте генә дә ни тора. Епископ Конашевич христиан таңрәсен мөселман чәчбиләренә алыштырды, дип борчылып хәбәр иткән ул Досифей. Кайнар канлы, сылу тәнле яшь мөселман кызлары белән дәртен баса, аларның суырып үбүләре, кысып кочаклаулары Луканы тәмам акылдан шаштыра, дип язган. Шәрә килеш аның белән кич утыралар, имиләрен аның корсагына ышкыйлар, имеш. Билен бирсә дә буен бирмәгән кыз кебек чыелдый-чиный, манара башына менгән мәзин төсле сузып-сузып мөгри икән азгын Лука, мөселман кызлары белән йоклаганда. Бу хәл, ди Досифей, чын христиан хатын-кызларын да аздыра, аларның күңеленә, тәненә гыйшык-мыйшык вәсвәсәсе сала...

— Бик җитди шикаять булган ич бу. Изге Синод бер чара да күрми калганмы?

— Конашевичка бераз тирләргә, Синод түрәләренә үзенең хәзинәсеннән өлеш чыгарырга туры килгән. Ниһаять, болай шаярырга ярамавын аңлаган. Чибәр кызларга сусавын «законлы юл» белән генә баса башлаган. Императрица рөхсәте белән мөселманнарны көчләп иманга китерә бару, берочтан, мөселман кызларын көчләү юлы белән дә ныгытылган. Чиркәү йоласыннан хәбәрсез чибәр, яшь кызларга ни? Епископ үз түшәгендә тотып өшкерсә — христиан диненең изге кочагына эләгү өчен иң туры юл шул дип белгәннәр. Елантау монастыренең бер хөҗрәсендә яшь киленнәрне, яшь кызларны шулай җайлап кына «денгә кертеп» җибәрә торган Конашевич... Тәнлә — кызларын өшкерсә, көндез халыкны кан-яшь белән чукындырган...

Федор Лукич сүзеннән бүленеп калды. Тәрәзәдән күрде: әрхәрәй йортына таба зур гәүдәле, киң җилкәле яшь монах якынлашып килә иде. Салмак-сабыр гына, картларча олысымак кыяфәт белән атлый. Әрхәрәй дачаларының өлкән монахы — Варфоломей шул булырга тиеш.

Монахны икенче катка алып менделәр. Ул владыка каршысына килеп баскан кебек, җиңелчә генә башын иде, йөзе буйсынучан-юаш төс алды:

— Ни боерасыз?.. Мин сезнең ихтыярда...

— Хәзер үк галерея ишекләрен ачыгыз,— диде Мурашкинцев катгый-кырыс тавыш белән.

Бер мизгелгә Варфоломей тынып-катып калган кебек булды, аннары тыныч кына җавап бирде:

— Владыка Иаков ул ишекне үзе ачадыр иде: гыйбадәткә барганда...

— Әбиеңә сәлам әйт.— Мурашкинцевның йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты.— Әкиятеңә әле ул да ышанмас. Яраннарын ияртеп чиркәүгә баручы архиепископ, ачкычларын шалтыр-шолтыр китереп, амбар йозагын ачып ята, имеш. Кайсы әбинең күргәне бар мондый хәлне?!

Шундый сүзләр белән Мурашкинцев монахка якынрак килде, күзләре белән аны капшап, әйтте:

— Яле, Варфоломей-җан, кара кабыгыңны сал әле. Балахоныңны әйтәм. Карыйк. Эчең ниндирәк икән синең — кызылмы, әллә акмы?

— Гөнаһтан куркыгыз, алла коллары...— Олы яшьтәге монах арага керде.— Ходай йортында изге җан ияләрен мыскыл итү — кайчан булганы бар мондый хәлнең? Бу бит имансызлык, дәһрилек кенә дә түгел,— ачыктан-ачык көчләү.

— Ярый, дөньяны әшәкелекләрдән чистартып бетерик әле. Аннары чиркәүгә барып, бөтен гөнаһны берьюлы ярлыкатырбыз.— Мурашкинцевның йөзендә елмаюның әсәре дә юк иде.— Ә хәзергә, монах әфәнде, мин кушканны эшлә. Сузма.

Шуннан соң булган вакыйгалар, куркыныч төш күргәндәге кебек, зур тизлек һәм һич көтелмәгән юнәлеш алды. Варфоломей, әз генә кырын басып, өстендәге монах чапанын сала башлаган иде... Капылт кына бөтен гәүдәсе белән суырылып килде дә, кизәнеп торып, Мурашкинцевның борын биленә китереп орды. Икенче омтылышта ул яшен тизлеге белән сикереп, янәшәсенә үк баскан яшь милиционерның тез капкачына типте. Шул ук мизгелдә кулында кечкенә браунинг пәйда булды.

Юк, Варфоломей атарга өлгермәде: Әскәр Хәйретдинов аның кулыннан пистолетын сугып төшерде, үзен җиргә егып салырга маташты.

Измайлов көтелмәгән хәлләргә әзер торса да, бераз гына кичекте: кесәсеннән наганын тартып алганда, Варфоломей инде ике кешене бәреп егарга өлгергән иде... Наганын алды Шамил, әмма аңа да атарга бирмәделәр: олырак яшьтәге монах мәче җитезлеге белән чекистның кулына килеп ябышты.

Измайлов, дүрт кешегә каршы ике монах һөҗүм итәр дип, бер дә уйламаган иде. Баштан ук һичнинди каршылык күрмәгәч, уголовный розыск хезмәткәрләренең дә, чекистларның да уяулыгы шактый кимеде шул, дип уйлап алды ул.

Болар җирдә әүмәкләшкән арада, кинәт галерея ишеге ачылып китте. Зур йозак аңа юри генә элеп куелган икән: теге яктан этүләре булды, авыр бик бөтен оясы белән шап итеп идәнгә төште. Ишек уемын тутырып, мәгъриб диюе кебек кап-кара әзмәвер пәйда булды. Кара чәч, кара сакал, өстендәге кара кием, кулындагы зур кара маузер аны шулай дәһшәтле итеп күрсәтә, кара акай күзләре ялт-йолт килеп бөтен тирә-юньне айкый иде. Кара монахның артында да кораллы ике адәм күренде.

Исенә килеп барган Мурашкинцев ишекнең ачылуын да, аннан килеп кергән кешеләрне дә күрде. Арадан берсен шундук таныды:

Мусин! Аның янындагысы, мөгаен, «кунак егете» булырга тиеш. Бөтен билгеләре шуңа туры килә... Мурашкинцев, кабыннан револьверын алып, яткан җирдән генә кара монахка төбәп атты. Ишекне иңләп торган әзмәвернең күзләре атылып чыгардай булып акайды, кулыннан маузеры төшеп китте, тезенә кемдер китереп типкәндәй, алга таба сөрлекте, аннары әкрен генә бусагага чүгәли башлады.

Кара монах ышыгындагы Мусин белән аның янындагы адәм, йөзләренә кайнар су эләккән кебек, бер атып калырга да өлгермичә, кирегә сикерделәр.

Мурашкинцев торып басты. Борыныннан сиптереп кан ага иде. Шулай да ул тешен кысып алга таба атлады, Әскәр Хәйретдиновка ярдәм итәрлек көч тапты. Муен тамырына наган терәгәннәрен тоеп, Варфоломей яшь чекистның бугазыннан кулын ычкындырды. Шул чакны, ишек яңагына ышыкланып, револьверлы кул сузылганын берсе дә күрми калды. Кул, барысын да рәттән, терәп диярлек ата да башлады. Беренче булып Мурашкинцев егылды, аннары тагын бер милиционер...

Беләгенә ябышкан монахны селтәп, Измайлов әлеге кулга төзәде. Ә монах шул арада идәннән сикереп торды да, галерея ишегенә ташланды. Револьверлы кул аны шунда ук атып екты. Шамилнең чакмага басуы да бик вакытлы булды: бандит, коралын ташлап, юкка чыкты. «Кулына тидердем ахрысы», — дип уйлады Шамил.

Үгез кебек таза Варфоломей инде Әскәр Хәйретдиновны стенага китереп кыскан, менә-менә бөтереп салырга җыена иде. Измайлов пистолет сабы белән монахның башына берне бирде.

— Әскәр! Бар, тиз генә ишегалды ягыннан каршы төш, — дип кычкырды Шамил. Чиркәү каршында калган яшь милиционерның ялгызына гына авыр буласы билгеле иде.

Измайлов канау кебек тар, озын коридор-галерея буйлап чиркәүгә таба йөгерде. Әмма аргы баштагы ишекне теге яктан бикләпме, терәтепме куйганнар — аны ачу мөмкин түгел иде. Чекист кире борылды... Ишегалды аша чиркәүгә таба йөгергәндә, мунча тарафында атышкан тавышлар ишетте. Чиркәү ишек төбендә калган милиционер исә, арып йокыга киткән кебек, стенага сөялеп утырган, гимнастеркасының күкрәк турысына кызыл-кучкыл тап җәелгән иде. Димәк, бандитлар чиркәү аша чыгып ычкынганнар, Әскәр аларны куа киткән.

Шамил яшь чекистка ярдәмгә ташланды. Тик шул вакыт ату тавышлары тынды, кемнең кайда икәнлеген чамалап булмый башлады. Үзен куркыныч астына куеп булса да, Шамил калын кирпеч дивар өстенә үрмәләп менде. Аның өсте шактый киң икән, сукмактан барган кебек күпмедер араны йөгереп үтте. Як-ягына каранды. Кытай стенасыдай озын дивар алга таба биек, куе тирәкләр арасына кереп югала. Сул кулдагы юкә аллеясында кеше заты күренми, ә таш коймага ук сыенып утырган кабер калкулыклары артына качарга мөмкин түгел. Бандитлар паркның агачлар куерак үскән аргы башына йөгергәннәрдер, күрәсең, ә аннан, койма аша сикереп, Әрхәрәй дачаларыннан әллә ни ерак булмаган авылга элдерткәннәрдер.

Тиздән аллея сукмагы буйлап кайтып килүче Әскәр дә күренде.

— Булмады, — диде ул, гаепле кеше сыман, башын түбән иеп. — Канлы эзләрен калдырып ычкындылар, шайтаннар.

— Иптәшләр кызганыч... Федор Лукич... — дип кушылды аңа Шамил.

Икенче көнне Измайлов берничә егет белән яңадан Әрхәрәй дачаларына килде. Митрополит Иаковның Питерга юл тотуы бик ихтимал иде: аны беркайдан да эзләп таба алмадылар. Әмма бу аның эш белән китүеме, әллә чека күзеннән качуымы — хәзергә

әйтүе кыен иде. Һәрхәлдә, Иаков турында: «Епархиясендәге попларның Советка каршы вәгазьләрен хуплый, ул гына да түгел, үзе шундый эшләр белән мавыга»,— дигән сүзләр хак булырга охшый. Аның кара канаты астында Мусин кебек бандитларның гына түгел, монах чапаны ябынган офицерларның да яшеренеп ятуы да тикмәгә мени. (Кичә моның нәкъ шулай булуы ачыкланды). Ул коздгын-башкисәрләрдән шәхси гвардиясен тупларга җыенмыйдыр ич инде Иаков атакай? Бу эштә Варсанофийны үзенә булышчы иткәнме әллә ул?

Варсанофий дигәч тә, тагын әллә нинди сораулар калка — әлегә берсенең дә җавабы табылмаган. Кайсы ярыкка кереп кысылды ул алла хезмәтчесе? Мурашкинцев-мескен: чиркәү тәрәзәсендә тәгаен аның башын күрдем, дип тәкрарлады бит... Чын-чынлап күзбуар булып чыкты ул Варсанофий.

Измайлов митрополит чиркәвен бик җентекләп тикшерде югыйсә. Әмма ачыклый алган кадәресе күңел юатырлык түгел иде. Варсанофий карачкысының күзгә күренеп тә, якынлаша башлау белән юкка чыгуы, әлбәттә, бу чиркәүнең хикмәтле булуы турында сөйли... Йә мондагы төп биналарны тоташтыручы җир асты юлы бар, йә ике катлы стена шулай фокус күрсәтергә, күз буарга, албастылар асрап ятырга мөмкинлек бирә. Ни генә булмасын, митрополит Иаковның иң ышанычлы кешеләре генә беләдер бу серне, һәм алар аны, үзләре белән каберга алып китсәләр дә, чит кешегә чишмәячәкләр. Галереягә чиркәү ягыннан керү ишеге дә «табышмаклы» икән: ул ифрат зур иконастасның бер кисәге булып чыкты. Аның ничек бикләнгәнен белмәгән кеше, әлбәттә, ача да алмый интегергә тиеш иде.

Байтак еллардан соң, әлеге чиркәүне үзгәртеп корганда, Шамилнең бу фаразлары расланасы бар әле: стенаның ике катлы булуы, ягъни Варсанофий атакайның стена эченә кереп китә торган яшерен юлдан файдалануы да, алтын суы йөгертелгән иконастасларның бер үк вакытта әкияттәгедәй «сихерләнгән» ишек хезмәтен үтәүләре дә... «Николай-угодник» иконасының өстәге сул почмагына баскач кына ачыла торган ишектән подвалга төшәргә була икән. Ә аннан чиркәү белән әрхәрәй йортын тоташтыра торган юл башлана — җир асты юлы... Протоирей Варсанофийның, йомран шикелле, җир астынан йөгерүен ул чакта күрә дә, белә дә алмыйлар иде чекистлар. Андый хикмәтләрне чиркәү әһеле, оят җирен кешегә күрсәтмәгән кебек үк, чит-ят күзгә чыгарып салырга ашыкмый иде, әлбәттә. Шул рәвешле, куркыныч килә калса, тиз үк җир тишегенә кереп югалу мөмкинлеге сакланды. Кашка төштә булганлыктан, «йомран юлы»нда язын-көзен дым-су әсәре күренми, ә инде суларга һава дисәң... Пыяла коридор-галереяны митрополит йортының икенче катына җиткәнче күтәреп торган кирпеч баганалар бар бит әле. Аларның эче куыш! Салам белән сөт эчкән төсле, җир асты дөньясы шул баганалар аша һәрдаим саф һава суырып тора иде.

Унсигезенче елның июнь көннәрендә әрхәрәй йортының бу хәйләсе ачылмаса да, Шамил Измайлов белән аның иптәшләре зур кара пәрдәнең бер читен күтәреп карый алдылар: ул пәрдә артында митрополит Иаковның яшь Совет властена каршы көрәштәге чын йөзе чагылып калды. Чиркәү әһелләренең кара чапан астына монархист-офицерларны сыендыруы да фаш булды. Әмма вакыйгаларның катлаулы агышы, үрмәкүч челтәре төсле үрелеп-чуалып беткән заговор җепләре бу эшне ахыргача тикшереп бетерергә мөмкинлек бирмәде. Тәреле очлымнар астына оялаган шөпшәләрнең зәһәр угы соңыннан коточкыч бәлаләр китерде.

## VI. Яңа танышлар арасында

Әрхәрәй дачасыннан исән-имин котылса да, Сабадырев бер мәлгә дөм-ятим калган сабый сыйфатында иде. Соң, шулай булмый ни: әле генә аларны үз канаты астына алган Варсанофий атакай, өрәк кебек, күз алдында эреп юкка чыкты. Мусин Фаикъ белән исә янәшә басып тору гына да бик хәтәр була башлады: аның эзенә басып уголовный розыск шымчылары килә... Бу шәһәрдә каккан казыгың да булмаган көе ничек җан асрамак кирәк?! Әле бит тереклек итү генә түгел, Казан алтынына ачкыч табу бурычы да тора алда. Хәзер кая инде ул иркен сарайлар, йомшак түшәкләр турында уйлау — ас корыда булсын да, баш җылыда булсын!

«Әллә «Болгар» номерларына сугылып карыйсыңмы? — дип котырта иде аны эчендәге шайтан — хыял белән фараз.— Чекист халкы һәрвакыттагыча артык уяулык күрсәтер: чүплек башларыннан, фәхешханәләрдән эзләр, әмма шәһәр уртасында Махно эмиссары ачыктан-ачык яшәп ятыр дип башына да китерә алмас».

«Анысы шулай,— дип җөпләгән була аны тыштагы шайтан — шактый нужа күреп кыйналган салкын акыл.— Ярый ла чека абзарына ниндидер аңгыра маэмай килеп эләкмәгән булса. Бөтен бәла шундыйлардан бит: белер-белмәс килеп ябыша да, үзе дә аңламастан, койрыгыңнан сөйрәп чыгара, нәгъләт».

Шулай да бу юлы аны азау теше ярган адәм әзәрлекләп килә, ахрысы. Атакай фатихасы белән юлга чыгып та атлаган саен уңышсызлыкка юлыгып торыр идемени югыйсә. Ә тәҗрибәле чекист... Сабадыревның күз алдына бик ачык һәм бик куркыныч булып килә ул: шәһәрне уч төбенә куйган да, имеш, һәр төрле монархист-анархист ишеләрнең кайсы тишеккә барып кергәнен карап-күзәтеп кенә утыра.

Шуларны уйлап-уйлап та, уйларының очына чыга алмагач, баштагы бер-ике көнгә булса да, Мусинның иске квартирасында туктарга карар итте Митька. Сыртына таяк төшкән эт шикелле боегып, әмма саклык чараларын онытмыйча кайтып керделәр.

Агач йортның икенче катындагы бер бүлмә иде бу. Сабадырев өзелгән бармагын сүтеп бәйләде, тәрәзә-ишекләрне капшый-капшый бүлмә буйлап йөренде. Басмалары чершенгән агач баскычка чыгып, кое төсле тар, аркылысы-буе тигез ишегалдына карап торды. Йортның беренче каты яртылаш җиргә чумган. Озынрак кеше булса, икенче катның тәрәзәсенә үрелеп буе җитәрлек.

— Моннан сикерергә әйбәт икән...— дип куйды Митька. Өйгә борылып керде, картларча авыр сулап, эскәмиягә утырды:— Көн буе сука сукалаган ат кебек арыдым...— дип уфырды.

Кулындагы яраны йод белән көйдереп маташкан Мусин:

— Наганны бәреп төшерде, анавы! Кызган шомпол белән китереп ордымыни...— дип мыгырданды.— Һаман шул ут борчасы бит, каһәр. Чистайдан бирле өченче тапкыр килеп кысылды! Үзем дә инде... Егерме адымнан атып тидерә алмадым! «Франция» номерларында тагын да якынрак иде. Җен малаедыр, валлаһи: аңа аткан пуля читкә борылып оча. Абзаңның әле кайчан гына «Мәргән» дигән кушаматы бар иде...

— Алай... Ул ут борчасы синең башыңа җитәчәк инде бер,— дип иренеп кенә әйтеп куйды Митька.

— Тфү, тфү, тфү...— дип төкеренде Мусин; иреннәре юешләнеп чыкты.— Каргышың кара башыңа, тинтәк!

— Каргавым түгел. Күңел сизенә. Ишеткәнең бардыр ич: өч тапкыр сугып та үтерә алмасаң, елан тәгаен чага, диләр...

Мусин авыртуын да онытып, кулларын бутады, бармаклары белән колак тишеген томалады.

Шулчакны ишек шакыган тавыш ишетелде. Митька белән Фаикъ, сулыш алырга да куркып, бер-берсенә караштылар. Тагын шакыдылар,— бу юлы катырак, таләпчәнрәк итеп.

Сабадырев иренено бармагын куеп, Фаикъны кисәтте. Шунда ук куенынпан пистолетын чыгарды, тәрәзә янагына ышыкланып ишегалдына күз салды. Юк, ишегалдында берәү дә күренмәде.

— Федя... Фаикъ! — ишек артыннан шактый олы яшьтәге хатын эндәшә иде.

— Хуҗабикә,— дип пышылдады Мусин, маңгаена тибеп чыккан тир тамчыларын сөрткәләп. Күзе Митькада: ул ни әйтер, нинди әмер бирер, дип көтә иде.

— Йокларга яткан идем, диген, хәзер үзем синең янына керәм, дип әйт.— Сабадырев тубыгыннан икенче пистолет алып, йөзе агарынып киткән Мусинның учына төртте.

Фаикътан шундый җавап ишеткәч, хуҗа хатын башмакларын кыштырдатып кире китте.

Сабадырев ишеккә колагы белән сыланды, аннары ачкыч тишегеннән тышка караган булды. Усал гына сорап куйды:

— Нәрсә син, Азман, шул корткa белән яшисеңмени? Әллә фатир хакын түләмәдеңме?

— Өч ай алдан биреп куйдым, валлаһи! — дип пышылдады Мусин. Ул үзе дә куркып-аптырап калган кебек иде.— Нәрсә иснәнеп йөрүе икән, анавы?!

Беравык, колакларын торгызып, коридордагы тынлыкны тыңлап тордылар. Шылт иткән тавыш та юк иде.

— Тәвәккәллим,— диде Фаикъ һаман пыш-пыш килеп. Чылбырын да ычкындырмыйча, ишекне сызык кына ачып карады. Коридорда кеше заты күренмәде.

Мусин хуҗабикә янынпан бик тиз әйләнеп килде.

— Йә, нәрсә кирәк булган аңа? — диде Сабадырев, түземсезләнеп.

— Үзенең бер хаҗәте дә юк. Браты эзләп килгән мине.

— Аның агасы бармыни?! Чынлап әйтәме? Дөресме?

— Барын бар анысы, үзем беләм; Серадов Алтынбай...— Мусин сәкегә кырын төшеп, җиңел сулыш алды.— Элеккеге тикшерүче, төрмә следователе... Мин аны Чистайдан ук бераз хәтерлим. Әллә ни зарарлы мужик түгел. Монда Октябрь фетнәсе алдыннан гына килеп чыкты.

Митька тагын наганына ябышты:

— Андый эт хуҗасыз тора алмый. Хәзер Советка ялланганды. Өстебезгә бәла алып килер!

— Килмәс. Үзенең асты юеш.— Мусин өстәлдән сохари үрелеп алды, шытыр-шытыр кимерә башлады.— Ә болай, адәм затыннанмы, җен затыннанмы икәнен аңларлык түгел.

— Алайса «күз-колак» инде! — Сабадырев, урынынпан кубып, бүлмә буйлап йөренеп килде.

— Патша хәзрәтләренә хезмәт иткән. Аннары — Вакытлы хөкүмәткә. Әле дә хуҗасыз калмас, билгеле...— Ач эт сөяк кимергәндәй, таза тешләре арасында сохарины көл итә иде Мусин.— «Дөнья малы — дуңгыз каны» дип сөйләнә үзе, әмма шул дуңгыз канына бик хирес күренә ул Алтынбай. Кем күбрәк түләсә, шуңа сатылуы бик мөмкин.

— Әйтәм ич! «Арты юеш... Килмәс...», имеш! — Митька, мыскыллап, авызын чалышайтты.— Кайчандыр үзенә күрә хөкемдар булып та эшләгән... Димәк, ул инде кешеләр язмышы белән уйнауның тәмен белеп алган. Акчалы үгезгә үз тәнен бирүдән фахишә нинди рәхәтлек кичерсә, кешеләрне сатудан андый бәндә шундый ук ләззәт ала. Әлеге Серадов та кайсы аллага табынуның бер аермасын да күрми: анар-

хистларныкы яисә большевикларныкы булса да барыбер, ат каракларыныкы булса да зарары юк. Мин ышанмыйм андыйларга. Анасын саткан адәмнәр алар.

— Белсәң иде, Митенька: аның хәзер, минемчә, үз кайгысы кайгы. Әгәр Совет ягына чыга калса, хәзерге хуҗалары аны җир тишеге ннән эзләп табып булса да, сөякләрен җыеп ала алмаслык итәчәкләр.

— Ярый, анысы хәерле булсын... Ә сине нинди максат белән эзли инде ул?

— Әҗәл фәрештәсе кирәк булган. Бер генә юлга, ди, тик тиз кирәк, имеш.

— Кемне йомдырасы, ди инде? — Сабадырев, ата каз кебек, муенын алга сузды.

— Ризалык бирсәм, иртәгә әйтәчәк, өйлә вакытында.

— Ничек бәхилләтергә уйлый? Ходай ризалыгы өчен генә түгелдер бит?

— Ике яңа паспорт вәгъдә итте. Шуңа өстәп — илле алтын гривенник.

— Алтын эчне тишмәс, анысы. Документның да кирәге чыгар.— Митька алтын тәңкәләрне чәйнәп карарга теләгәндәй, яңак сөякләрен уйнатып алды.— Риза бул, Фаикъ. Мин дә сиңа булышырмын. Алай-болай, көтелмәгән хәл килеп чыкса, утны үземә алырмын.

«Алырсың, пычагым»,— дип әйтәсе килде Мусинның, авызын чалышайтып көлемсерәгәндәй итте, әмма уендагын теленә чыгармады. Алаша хәзер «булышырмын» дип сөйләнә икән, моның чынлыкта сукыр бер тиенгә дә тормавын ул инде яхшы белә. Куркыныч туды исә, Митенька ике дә уйламыйча тәпи ялтырату ягын караячак. Хәвеф-хәтәрсез генә барып чыкса — капчыгын тотып мәгәрич бүлешергә киләсен көт тә тор.

— Утны үзеңә алу ук кирәкмәс, Митенька.— Мусин, теше сызлагандай кыяфәткә кереп, чыраен сытты.— Ничек тә ерып чыгармын, боерган булса. Күрмәгән-белмәгән эш түгел. Ә инде сиңа да үз авызымнан өзеп өлеш чыгарган өчен... Бераз тир түгәргә туры килер шул, ахири, әйе.

— Син инде, ни, Фаикъ...— Сабадырев, шунда ук аның шартына күнгән кебек, килешүчән тавыш белән сүзне читкәрәк бора башлады.— Ул Серадовтан берәр алачык сорап кал, дим. Тагын бер түбә кирәк булыр бит кара көнгә. Алай-болай үзебез эзләргә керешсәк, безне һәр чатта чека сагалап торачак хәзер. «Һап» итеп эләктереп кенә алырлар.

Мусин дәшми-тынмый гына тыңлап торды да ияк какты:

— Сөйләшеп карармын әле ул хакта да,— диде.

Икенче көнне Фаикъ үзләренә тапшырылган эшне төгәлрәк белеп кайтты. Шактый четерекле бурыч булып чыкты ул. Башы бетәсе ирнең исеме Газыйм, фамилиясе Дардиев булып, аның кайда яшәве ачык кына билгеле түгел иде. Шулай да Сулъяк Болак урамында, реальный училище белән янәшәдәге йортта моның сөяркәсе тора, имеш. Бик тәртипле хатын, дилә, әмма ифрат йомшак күңелле булудан гына бераз кыенлык кичерә: үзенә күзе төшкән ир-ат җенесен кире борып җибәрә алмый икән.

Мусин үзенең корбанын әллә кайдан эзләп йөрмәскә булды. Әлеге юмарт хатынның адресын яхшылап белеште дә, шул тирәдә тыныч кына көтеп торуны хуп күрде.

«Кемнеңдер тамагына кылчык булып кадалган инде бу Дардиев,— дип фикер йөртте Фаикъ, шул ук вакытта әлеге кешенең төсен-битен нәкъ Серадов тасвирлаганча итеп күз алдына китерергә тырышты.— Ялган язулар, документлар ясау остасы, имеш. Шундый сәләтле кеше әрәм була, әх!» Бу минутта ул, куенындагы фин пыча-

гын кысып тоткан хәлдә, Газыйм Дардиевны чын күңелдән кызгана, хәтта аның шушы йортка, сөяркәсе янына кайтмавын да тели иде.

Әллә инде шушы теләк кабул булды, ул көнне Дардиевка охшаган кеше, чыннан да, күзгә чалынмады. Төн урталары җитәрәк, йомшак күңелле хатынның бүген ялгыз гына йоклыйсы беленгәч, Мусин: «Әллә?..»— дип, дәртсенеп караган иде... Сабадырев — чынлап та, алаша икән! —«Син нәрсә, фәлән-фәсмәтән»,— дигәләп, кызган ташка бер чиләк салкын су салды, анавы.

Икенче көнне, кичкырын, тәмам күз бәйләнеп, ә ишегаллары инде караңгыланып барганда, Сабадырев кына аңларлык итеп ишарә ясады Мусин: без көткән кеше кайта! Караңгы урамда эт тә юк иде. Шәһәрдә трамвайлар туктап калган кебек: ник бер тәгәрмәч, тукылдавы, кыңгырау чылтыратуы яисә борылышларда кискен шыгырдавы ишетелсен. Хәтта Болак буендагы камышларны кыштырдатып уйнарга яратучы җил дә тынып калган. Булса, җир астында гына мондый тынлык буладыр... Һәм шул тынлыкта Университет урамы белән Унъяк Болак чатында кинәт пәйда булган хәрби патруль анархистларның исен-акылын алды: гаскәриләрнең аяк атлаулары коточкыч тавыш, шау-шу кузгаткан кебек тоелды аларга.

«Шул гына җитмәгән иде»,— дип уйлап өлгерде Митька, күпер төбендәге камыш арасына сыенганда.

Винтовка тоткан өч солдат тиздән Сулъяк Болакка чыгып, ары таба китте. Алар үткәнче бер койма артына посып калган Дардиев та күпер аша сул ярга йөгереп, сөяркәсе яшәгән ишегалдына кереп чумды.

Шунда ук аны, әлбәттә, Мусин сагалап тора иде. Куркак җанвар кебек як-ягына карана-карана ишегалдына кергән ирне ул икенче кат баскычына ышыкланып күзәтте.

Дардиев, килгән шәпкә, шыгырдавык басмалардан икенче катка ук менеп җитә язды. Караңгы почмакларга текәлеп-текәлеп карады. Үзенчә саклык чаралары күрүе булдымы, әллә юмарт сөяркәсенең берәр кунагы посып утырмыйммы дип тикшерүе идеме — аңламассың. Аннары песи кебек йомшак кына басып кире төште, беренче кат ишегенә килеп, өч тапкыр әкрен генә шакып алды. Шул ук минутта эчке якта тимер бик шуган һәм чылбыр шылтыраган тавыш ишетелде.

Төнге кунакны болай зарыгып көтәрләр дип уйламаган иде Мусин. Ул зиһенен җыярга өлгергәнче, Дардиев каршындагы ишек тутырук ачылып та куйды.

Фаикъ үзе яшеренеп яткан зур әрҗә артыннан сикереп торды, агач баскычны авыр итекләре белән дөбер-шатыр китереп, мәтәләмәтәлә аска төште. Аның өчен ишекнең шулкадәр тиз ачылуы бер гаҗәп булса, Дардиевның бусагадан атлау белән, ишекне ябып куярга өлгерүе тагын да хәтәррәк иде. Аннары, сөяркәсенең итәк астыннан туп белән аттырып та чыгара алмаячаксың нәгъләтне — бусы көн кебек ачык. Шуннан соң бар, эзлә аны. Бу тарафларга бүтән аяк та атламаячак. Эшне сизенеп, күздән гаип булачак.

Баскычта авыр аяк тавышларын ишетеп, Дардиев бер мәлгә коелып төште. Әмма шундук аңлап алды: бу бәндә — аның газраиле, аны көтеп-сагалап торган булырга тиеш! Ачылган ишектән якты коридорга атлап, артыннан тиз генә бикләргә итте. Куркыныч төштәге кебек, вакыт туктап калды: зиһен богауланган, кул-аяк каушаудан оеган, коточкыч әкрен кыймылдаган төсле иде. Баскычтан өерелеп төшкән юлбасар күз ачып йомган арада ишек ярыгына аягын тыгып өлгерде. Тупас көч белән кисәк тартылган ишекне тотып кала алмады Газыйм. Газраиленең чалышайган танавы, алышынган бәбәкләре, ырҗайган тешләре, яшен яктысында күренеп калган кебек, берьюлы, бер тын эчендә чагылып үтте. Икенче мизгелдә баш очына күтәрелгән салкын йөзле фин пычагы ялтырады.

Урам караңгылыгын ачы тавыш телгәләде:

— Нишлисе-э-э-эң, парази-и-ит!!.— дип чинап җибәрде Дардиевның сөяркәсе.— Үтерә-ә-ә! Бандит-ит!..

Җан саклау инстинкты Газыймны кинәт этеп җибәргән кебек булды: пычак астыннан бөке сыман атылып чыгу гына түгел, үзенә һөҗүм итүченең күкрәк авызына бик каты китереп орырга һәм тез капкачына тибәргә дә өлгерде. Мусин аркасы белән кухня стенасына барып бәрелде. Стенага элеп куйган зур калай ләгән аның өстенә дөбердәп ишелеп төште.

Бер минутлык ыгы-зыгыдан файдаланып, Дардиев караңгы ишегалдына сикерде. Мусин, аңына килеп, пистолетына ябышканда, аның кайсы тарафка таба йөгергәнен дә чамалый алмый иде инде. Шулай да ачудан һәм гарьлектән ике тапкыр чакмага басканын сизми калды.

Ату тавышлары Сабадыревны сискәндереп җибәрде. Әлегә ул, патруль кире әйләнеп кайтмагае дип, һаман шул күпер төбендә посып тора иде. Инде атышуга барып житкәч, хәлнең катлауланганын аңламаска мөмкин түгел. Бил каешына кыстырган коралын алып, ул сагаеп кына урамга күз салды. Болакның аргы ягыннан бирегә таба бер ир-ат элдерә, үзе әледән-әле артына борылып карый шикелле. Мусинмы бу, әллә Дардиевмы — төн карасында төсен-битен аерып булмый. Сабадырев, тәмам тынычлыгын югалтып, аның каршысына чабып чыгардай хәлгә килде. Ниһаять, теге карачкы күпернең бу башына якынлашты һәм шунда гына аның Мусин түгел икәнлеге дә аңлашылды. «Азманны атып, кулдан ычкына бит бу!»— дип уйлап алды Митька. Шул уй аңа башсыз тәвәккәллек бирде: камышлыктан атылып чыгып, берничә тапкыр әлеге иргә төбәп дөпелдәтте. Качак кинәт кирегә борылып йөгерә башлаган иде, ләкин ике-өч адым атлауга, күпер өстенә киселеп төште.

Якындагы ишегалды түреннән зур йөнтәс эт чыгып, тирә-юньне яңгыратып өрә башлады. Шул ук мәлне караңгы тәрәзәләрдә пәрдә тибәрелгәне, аксыл тап булып куркынган йөзләр карап торганы күренде. Анархист, үртәлеп, артына борылды, якын ук килеп «һау-һау» иткән эткә төзәп тә тормыйча атып җибәрде. Эт шунда ук мескен тавыш белән чинап ишегалдына таба чигенде. Тәрәзәләрдәге ак йөзләргә дә ут белән төкереп-төкереп китәсе килде Митьканың,— курыкты: үзенә каршы ата башлаулары мөмкин иде.

Күпердән, бер аягына аксый-аксый, тагын берәү тыраклый, бусының инде, чынлап та, Мусин икәнлегенә шикләнмәде Митька.

— Алаша!.. Кайда ул?! Тот! Тот үзен!..— дип үкерде Мусин.

Сабадырев күпер өстендә яткан мәет янына йөгереп килде, тиз генә аның кесәләрен әйләндерде. Язуларын, коралын алды. Ниһаять, башын күтәреп:

— Акырма, Азман! Булыш ичмасам! — дип кычкырды.

Дардиевның гәүдәсен күпер култыксасы аша Болак суына тондырдылар да, Зур Проломныйга таба элдерттеләр. Шул ук мәлдә артта аяк тавышлары ишетелде.

— Патруль! — дип авыр мышнады Мусин.

Кайдадыр якында гына:

— Тукта! Атабыз! — дип кычкырдылар. Гаскәриләр үкчәгә басып ук киләдер кебек тоелды.

Сабадырев түзмәде, артына борылып, куа килүчеләр тарафына бер пуля озатты.

— Атма, юләр! — дип ажгырды Мусин.— Белгертәсең генә. Хәзер алар безне пешекләргә тотына.

Чыннан да, Болак ягыннан винтовкалар шарт-шорт килде. Мусин, «ә» дигәнче, авырткан аягын онытып, алга ыргылды. Ахириен узып, алдан юл күрсәтеп йөгерүе әйбәтрәк тә иде, хәер. Чөнки ша-

һәрне ул Сабадыревтан әйбәтрәк белә, кайсы тыкрыкка кереп качасы икәнен дә яхшырак чамалый иде.

Менә алар, ниндидер коймаларны сикерә-сикерә, сарай түбәләреннән үрмәли-үрмәли, караңгы ишегаллары аша уздылар. Кызу йөгерүдән сулыш кысыла, тәннең тырналган-сыдырылган төшләре ут булып яна иде. Берзаман, дөнья тынган кебек булганда, алар инде Зур Проломныйның аргы башына ук барып җитеп, янгын каланчасы кебек сузаеп торган кызыл чиркәү янына килеп чыктылар. Караклар төсле як-якларына каранып, Кече Проломная урамына күтәрелделәр. Аны да кисеп үттек дигәндә, якында гына гаскәриләр төялешкән машина туктап торуы мәгълүм булды. Мусинның нервылары түзмәде: ул, бәйдән ычкынган шикелле, җан-фәрманга чабып китте. Митькага да бүтән чара калмады: алар хәзер Университет урамы буйлап өскә йөгерәләр иде.

Машинадагылар бу сәер парны абайлап алдылар булса кирәк. Шул арада машина «пык-пык» итеп урыныннан кузгалды, Университет урамына таба борылды, таудан күтәрелгәндә авыр гүләп, төчкерә-төчкерә булса да, тизлеген арттыра башлады. Озак та үтми фаралар яктысы кәлтә кебек бик җәһәт кыланган ике ир-атны ялмап алды.

Алларыннан сузаеп йөгергән озын күләгәләр үзләренеке түгел, ә әзәрлекләп килүчеләрнеке булып тоела башлаган иде инде. Кинәт, аларның бәхетенә, ике күләгә дә бик тиз кыскара барып, юлдагы тонык шәүләгә әйләнеп калды. Хикмәти хода: качаклар үрне менеп җиткәннәр, ә куа килүче машина әле текә тар урам буйлап күтәрелеп кенә килә иде. Хәзер фараларның ике ут көлтәсе ике качакның баш өстеннән узып биеккә — болытларга таба сузыла.

Анархистлар, якты читлектән котылган куяннар кебек, икесе ике якка сибелделәр.

— Алаша, син кая?.. Борыл! — дип кычкырды Мусин.— Анда хәзер эләктереп алалар!

«Фаикъның киңәшенә колак салмау хата булыр. Университет ишегалдын камап алу бик җиңел шул»,— дип уйлап алды Митька һәм, Мусин артыннан ук юл аша йөгереп чыгып, университет каршындагы кирпеч арка астына кереп чумды. Кечкенә генә ишегалды аркылы үтеп, алар убылган яр читендә туктап калдылар. Яр шактый текә, шактый биек,— аның итәгеннән кырык-илле адым гына читтәрәк торган, кечкенә тәрәзәләрендә тычкан уты җемелдәгән ике катлы кирпеч йорт та каядыр аста, караңгы чокыр төбендә калган кебек иде.

Бу ишегалдын кысрыклап як-яктан кирпеч йортлар баскан, шуңа күрә моннан ычкыну юлы ике генә: йә кире, университет каршысына борылып чыгу, яисә текә ярдан аска төшү. Дөресрәге, артка чигенү инде мөмкин түгел: анда, ниһаять, баягы машинаның килеп туктавы, гаскәриләрнең шап-шоп итеп сикерешеп төшүе ишетелә...

Мусин яр читендә бәргәләнеп йөгерә иде, ниндидер бауга абынып чак кына аска мәтәлеп төшмәде. Ике кулы белән дә кармаланып, үзенә аяк чалган бауны эзләде. Тимер чыбыкның бер башы агачка бәйләп куелган булып чыкты. Шатлыклы тойгы аның бугазына менеп бөялде: «Котылдык, шайтан алгыры!» Агач ботакларын як-якка аерып, Мусин бик әкрен генә сызгырды:

— Әй, Алаша, монда! Монда кил...— дип эндәште һәм, ахириен көтеп тә тормастан, аска шуып төшә башлады.

Чыбык, утта тотып кыздырган төсле, уч төпләрен пешерә-әрнетә иде. Мусин, авыртуга түзә алмыйча, үзе дә сизмәстән, ике учын берьюлы язды. Күпмедер араны очып төшкәч, тезләре белән ярдан ишелгән туфрак өстенә килеп кадалды. Тиз генә сикереп торды, әченнән генә: «Аллага шөкер!»— диде, әлеге ике катлы йортка таба юыр-

тып китте. Йорт почмагына барып ышыклану белән, башын сузып карады: Сабадыревның кара шәүләсе тимер чыбык буйлап җәһәт кенә төште дә, Мусин кебек үк, аягында басып кала алмыйча, өелгән җир өстенә сузылып ятты. Ләкин шул вакыт яр башында аларны эзәрлекләп килүче мылтыклылар күренде.

— Әнә алар! — дип кычкырды яшь тавыш татарчалап.— Әнә, әнә!

Шатыр-шотыр китереп мылтык затворлары тартылды.

Сабадырев кисәк сикереп торып, үзенә сыеныр урын бирәсе йортка таба ук булып атылды.

— Тукта! Тукта дим! Югыйсә!..— дип акырдылар өстән. Бусы тупас — карлыккан тавыш иде.

Сабадырев, аңа карап, туктамады, әлбәттә. Яр башыннан дөп-дөп итеп ике тапкыр ут чәчрәттеләр. Беренче атуга ук Митька җиргә егылды. «Юри үлгәнгә сабышып ята»,— дип уйлады Мусин.

— Бусы булды,— дип куйды баягы яңгыравыклы яшь тавыш.— Икенчесе ычкынды тәки, контра.

Митька һаман тынсыз-хәрәкәтсез ята иде, кинәт, кузгалмаган килеш кенә:

— Мине каплап тор! — дигәне аермачык ишетелде.

Мусин беразга икеләнеп калды, аннары теләр-теләмәс кенә пистолетын алып, яр башындагы бер шәүләгә төзәп атты. Шәүлә чайкалып куйды, аннары кинәт, ярдан түбән сикерергә теләгәндәй, алга таба сөрлегеп китте. Ул мәлне үзе түгел, «а-а-а!» дип сузып кычкырган тавышы тәгәрәп төшкән кебек тоелды.

Шунда ук ярдагылар сузылып ятып, еш-еш ата башладылар. Болар татар-башкорт батальоны егетләре: дүрт ел буена герман фронтында итек туздырулары бушка китмәгән, күбесенең аткан саен каргага тия иде.

Мусинга бу атышуның яхшылык белән бетмәсе аңлашылды. Иң беренче пуля аның җилкәсен җимереп аяктан екты. Шунда ук бөтен тәнен утлы шөпшә күче тешли-чага башлаган кебек булды. Сүнеп баручы аңында, иң соңгысы булып, гаҗәпләнүгә тартым бер уй чагылып үтте: шулай ахмакларча бетүме бу?..

Ул үзенең бу уенга ничек килеп керүен белмичә үлде. Немец агенты Михаил Тряпкинга чекистлар корган тозакның бер корбаны булуын белмәде.

«Чыбыксыз телефон» аша хәбәр салганнар иде: ялган язулар, документлар ясап ятучы Газыйм Дардиев аша чека бик мәгълүм агентның эзенә төшәргә җыена, имеш! Тряпкин-Карачкы, бу җимгә кабып, тизрәк саклык чараларын күрергә ашыкты. Киләчәктә кирәге чыгар кебек күренсә дә, Дардиевтан котылу — аныңча, иң дөрес юл иде. Бу эшне ул Серадовка тапшырырга булды. Бердән, Чистайда бер мәртәбә сатып алгач, инде фахишә кебек үзе тагылып йөри башлаган Серадов үзе дә Дардиевтан ялган язулар әмәлләткән иде. Димәк, фаш булу куркынычы аңа да яный. Икенчедән, Серадовның кулын канга буяу — алга таба аны тагын да ныграк бәйләп кую дигән сүз!

Әмма Серадов моның ни белән бетәргә мөмкин икәнен үзе дә чамалый, тиктомалга башын югалтасы килми иде. Бу куркыныч һәм пычрак эшне ул, Тряпкин биргән түләүнең яртысы бәрабәренә, иплэп кенә сатып җибәрә алды. Хәзер кан эчендә яткан Мусин Фаикъ та, аның анархист дусты Сабадырев Митька да, әлбәттә, шул «сату-алу» корбаны икәнлекләрен белмиләр иде.

Митька, кызыл гаскәриләрнең Фаикъ белән атышуыннан файдаланып, сикереп торды да күз ачып йомган арада йортның икенче почмагына барып сыенды.

Ул арада атыш тынды. Митька йортны әйләнеп чыгып, тирәюненә сак кына күз салды. Мусинның үле гәүдәсен күрде. Артык бер

секунд та тукталып тормыйча, моннан таярга кирәк иде!

Кеше-кара күренмәгән, караңгы тын урамнар, тыкрыклар буйлап качып барганда үз хәле хәл булса да, дустының үлеме Митькага авыр тәэсир иткән иде. Кызганыч, бик кызганыч. Ни генә димә, шушы кыска арада байтак сират күперләрен бергә кичтеләр ич! Мусин шәһәрнең бөтен чатларын яхшы белә, монда аның үз элемтәләре, иске танышлары бар, алар ярдәме белән нindидер эшләр кырырга сәләтле иде, мәрхүм. Ләкин бераздан, башын эшләтеп карагач, Митька капма-каршы фикергә килде. Бәй, Фаикъның бүген аяк сузуы әлегә хәтле җан көеге булып йөрүенә караганда әйбәтрәк икән ләбаса! Азманны белмәгән шпана юк иде шәһәрдә, Коська Балабанов «күгәрченнәре» дә шуңа каныга башлаганнар иде. Үз ишләре бәреп үтерергә йөргәндә, уголовный розыск дигәне дә эзгә басып килә иде. Аның белән бергә булу гына да бик хәтәр нәрсәгә әйләнде бит. Азманга дип күтәрелгән күсәк Сабадыревның башына төшмәс дип кем әйтә ала!

Ул кичне бүресе улады Митьканың: куа килүчеләрдән котылып, тырналмаган да килеш диярлек әйләнеп кайтты. Кайтты дип, шул — бичара Мусин биләгән бүлмәгә инде.

Серадов аларның кайтканын көтеп торган иде.

Болак төбендә яткан Дардиевның язуларын өстәлгә ташлап, Митька кайгылы төскә керде:

— Безнең ахиринең генә юлы уңмады. Фаикъны — Федяны әйтәм...

— Син нәрсә?! Чека эләктердеме? — Серадов урындыгыннан сикереп торды, күзләре атылып чыгардай булып акайды.

Сабадырев башын чайкады, бинт белән бәйләнгән бармагына сак кына кагылып алды:

— Ходай каршына китте. Безне калдырып...

Серадов тиз генә чукынып алды, «уф» дип җиңел сулап куйды:

— Аллага шөкер. Тәмам котны ботка төшергән идең. Ходай каршында дәшмәс анысы. Ә менә чека кулына барып капса...— Ул янә бер мәртәбә «чебен куды»:— Ярый, авыр туфрагы җиңел булсын.

Шуннан соң Серадов иплә брәк утырып, Митьканың йөзенә текәлде. Тикшерүчегә генә хас бәйләнчек сораулар бирә-бирә, аның кемлеген, кайдан килүен, ни белән шөгыльләнүен ачыкларга маташты. Сабадырев башын җүләргә салып, теләр-теләмәс кенә җавап биргән булып утырды. Ул үзен гадәти бер кесә карагы — дөньяның кая таба барганын бигүк аңлап бетерми торган мужик итеп күрсәтергә тырышты. «Сәяси мәсләгең нинди?»— дигән кебек сорауларны гомумән аңламамышка салышты. Нинди мәсләк, нинди сәясәт ди! Патшасына да, комиссарларына да төкерә ул. Дөрес, элек әйбәтрәк кебек иде. Хәзер дөнья болганды. Кесә карагына да көн итүе читен була башлады. Бүтән ни әйтәсең: бетле башыңны төртергә урын калмады.

Серадовның бик төпченеп соравыннан Митька шуны аңлап алды: бу бәндә нинdидер бандада, яисә яшерен оешмада әгъза булып тора, үз ягына бүтәннәрне дә авыштырырга ниятли. «Кызык бит: миңа нинди вазифа бирмәкче икән? — дип уйлап алды Сабадырев.— Йомышчы малай итмәкчеме?»

Әмма Серадов сораштырудан ары китмәде, бернинди тәкъдим дә ясамады, бары тик иртәгә Митьканы бер кеше белән таныштырырга гына вәгъдә итте. Ул адәм, имеш, «баш төртергә» урын бирәчәк.

Алтынбай Серадов киткәч, Митька, чишенеп тә тормыйча, ятагына сузылды. Бүген көн дәвамында күргәннәрен-кичергәннәрен яңадан хәтер иләгеннән үткәреп, йоклый алмый озак ятты. Махно атакай куйган бурычны үтәү авырлыгы да аның йокысын качырган иде, әлбәттә.

Банкка ачыктан-ачык һөҗүм ясау уеннан ул күптән кире кайт-

кан иде инде. Шулай итеп, ике генә юл калды. Аларның иң кулае — бик ышанычлы кешеләрдән көчле төркем туплап, шәһәрдә берәр төрле фетнә кузгалганын көтү. Тирә-якта тыныч түгел, төрле көчләр бер-берсен изеп-сытып тәхеткә үрмәли. Әмма алар кайчан, үзара бугазга-бугаз килүдән туктап, Совет властеның эчен тишеп агызырлар? Тагын күпме көтәргә кирәк? Моны бит тәгаен генә берәү дә белми. Димәк, кул кушырып көтеп ятудан да әлегә мәгънә күренми. Инде икенче юл — шулай ук кабат-кабат уйдан-күңелдән кичерелгән юл — банкка җир астыннан юл салу. Теге Миргазияновның банкта эшләүче кардәшен дә тизрәк эзләп табарга кирәк.

«Торак якларын хәл итим генә, ныклап эшкә керешәм»,— дип үз-үзенә сүз беркетте Сабадырев. Күзенә йокы эленгәндә Тоськасының байлар түшәге кебек ап-ак йомшак түше исенә төшеп, йөрәк турысында нәрсәдер чәнчеп куйды.

* * *

Сөйләшенгән вакытта, сөйләшенгән урынга килеп баскан иде Митька. Серадов күренгәнен көтеп, бер сәгать вакытны «үтерергә» туры килде. Тегесе тагын, дәшми-тынмый гына арттан килеп, ялгыш кагылган кебек итеп, терсәге белән төртеп узды да урам буйлап салмак кына атлавында булды. Аңардан бераз гына арткарак калып, җеп белән тарттырылгандай, Сабадырев кузгалып китте. Аяк астында ни барын күрми, ялт-йолт як-ягына карана: Серадовның үз-үзен тотышыннан аңа да ниндидер киеренкелек күчте, өстәвенә соңгы арадагы уңышсызлыклар күңелгә чын-чынлап шик-шом салган иде. Уңда да, сулда да чекист яисә мильтон күзәтеп торадыр шикелле тоелды Митькага.

Әмма бу борынгы урам, рус һәм татар телләрендә сөйләшеп, үзенең гадәти тормыш-көнкүреше белән яшәп ятмакта иде. Әллә ни кыландырып эшләнмәсә дә, төрле-төрле язулы такталар, игъланнар, аннан да бигрәк шул такталар эленгән күп санлы кибетләр, ашханәләр, конторалар урамның ике ягыннан агылган халыкны төркем-төркем итеп үзенә суырып ала. Уртадан, таш юлны дагалары белән шакып, ике тарафка да атлы олаулар чабып тора. Бик сирәк кенә булса да, атларны өркетеп, машина үтеп киткәли.

Урамның шушы гадәти ыгы-зыгысы Сабадыревны да күпмедер тынычландыра бара иде. «Йә, нәрсә дип тарткаланасың инде? — ди ул үз-үзенә.— Монда сине этем дә белми. Уңышсызлыкка очравың әлеге дә баягы Мусин аркасында булды бит. Чека синең нигә дип бу шәһәргә килеп чыгуыңны уена да китерми. Язуларың да тәртиптә. Шулай булгач, артыңнан сулап яшәмә!»

Шулай үзен-үзе юатып, дәртләндереп атлаган иде,— Серадовның үкчәсенә баса язган икән. Ә тегесе, тәңкә-тәңкә гөмбәзле, дүрт катлы яшел йорт каршысында туктап калган да, авызын ачып нидер укыган булып тора. Митька аны узып алга таба берничә адым үтте дә, сиздермичә генә, артына борылып карады. Серадов урамда күренми иде. «Казанское подворье» ресторанына кереп китте, ахрысы, дип юрады Митька.

Чыннан да, Серадов аны озынчарак көзгеләр белән бизәлгән вестибюльдә көтеп тора иде. Кызыл розалар янып торган фарсы келәменә йомшак кына басып, мәрмәр баскычтан икенче катка күтәрелделәр. Серадов, гадәтенчә, сулга борылып, зал аша тәрәзә буендагы буш өстәлгә узды.

— Монда ярыйсы гына сыйлыйлар, җырчы-биючеләре дә күңелгә ятышлы,— дип сөйләнде ул, шул арада сәгатенә карап куйды.

Сабадырев ресторан залына күз йөртеп алды: мәрмәр колонналар арасында буш өстәлләр юк диярлек иде. Тирә-юньдәгеләрнең һәммәсе

бәйрәмчә күтәренке рухлы, шау-гөр киләләр. Аргы почмакта оркестр, тәбәнәк сәхнә. Ул да түгел, сәхнәгә зифа буйлы, матур аяклы дүрт кыз очып чыгып бии дә башладылар. Залда хуплап кычкыру, кул чәбәкләү дулкыны кузгалды. Бераз кызып алган кунакларның бигрәк тә тырышканлыгы күренә.

Серадов, аракылы рюмканы кулына алып, дуслык өчен эчәргә тәкъдим итте. Аннары алар гүзәл хатын-кызлар исәнлегенә, тормыштагы уңышлар өчен күтәрделәр. Музыкантлар да дәртләнебрәк уйный, кызлар да шәбрәк бии башлаган кебек тоелды. Серадов ак кәяз кулларын чәбәкләп, мыек астыннан гына такмаклап алды: «Ах, кызлар-йолдызлар, судагы кондызлар...» Кулы жилет кесәсенә чумып, Николай заманыннан калган өч алтын тәңкә әләктереп чыкты. Шуларны өстәл читенә куйганда Серадов моңсу төскә кереп башын чайкаган булды:

— Кыйбатка төшә, шайтан алгыры. Әмма ни хәл итәсең, мин сайлаган кыз күңеленә бүтән ачкыч ярамый.— Рюмкаларга аракы бүлеп салды, сер әйткән кебек, ярымпышылдауга күчте:— Әнә теге дүрт биюченең берсе минеке. Зинуля. Теләсәң, сине дә үзебез белән алабыз. Дус кызы бүген буш аның. Әнә уң як кырыйдагысы. Дөрес, анысына бер төн өчен дүртне куярга кирәк. Менә шундый дүрт алтын.

— Ә алар арасында әдәплеләре бармы соң? — дип сорау бирде Митька. Аның хәтта бу кызларга ачуы чыккан кебек иде.

— Ничек инде булмасын. Бар. Тик алар тагын да күбрәк калым таләп итәләр.— Серадов ыржаеп көлде.— Гыйффәтле кыз әләктерәсең киләме? Ба-рып-чык-мас! — дип иҗекләп әйтте ул.— Бу бит сиңа затлы кызлар институты түгел. Үзеңә мәгълүм, урак-чүкечле иптәш шартлатып япты аларны. Димәк ки, Советка инсафлы, күркәм кызлар кирәкми, дип аңлыйм мин бу эшне. Советка менә бу биючеләр кебек сиртмә койрыклар кирәк: уртак мал булсыннар, күпкә түзсеннәр.— Серадов иелеп, Митьканың йөзенә аракылы сулышын өрде.— Советлар илендә бары бергә, югы уртак бит. Синең хатыныңны да бер юрган астына тыгалар — урак-чүкечле иптәш арып-талып хезмәттән кайткач, аны да үзе теләгән җайга чүкесен дип. Төшендеңме?!

Сабадырев кулын бутап:

— Әйдә, артыгын шыттырып, агитлап утырма мине...— дип сүзне өзә башлаган иде, аларның өстәле янына бер ир-егет килеп басты. Аксыл чәчле, нык гәүдәле адәм, утыз биш яшьләрендә булыр. Җиңелчә баш иде һәм хәрбиләрчә төз итеп гәүдәсен турайтты:

— Яныгызга сыйдырмассызмы, әфәнделәр? — диде.

— Әйдүк, әйдүк,— дип урынында кыбырсып алды Серадов.— Көтә-көтә чәебез суына башлады, Әнвәр әфәнде.

Әнвәр дигәне бик эре генә кыланып буш урындыкка утырды, тәкәллеф белән елмайды.

Серадов, каударланып, пинжәк төймәләрен ычкындырды, кулларын кая куярга белмәде.

— Таныш булыгыз, эһем-эһем,— диде. Аксыл чәчле адәмгә таба кулын сузып, юмакай тавыш белән аның исемен атады:— Апанаев. Әнвәр әфәнде Апанаев.

Сабадыревның тыны кысылды, аркасына салкын тир бәреп чыкты. «Апанаев... Атакай ятьмәсенә барып эләккән теге байгураның кардәш-ыруыннанмы әллә? Хикмәтле карта хуҗасының нәсел-япьтереме?» Аннары: «Әй, юктыр ла. Татарда андый фамилияләр аз булыр дисеңме?»— дип, үз-үзен тынычландырырга ашыкты.

Апанаев исә, аның уйларын йөзеннән укып торгандай, көтмәгәндә:

— Безнең дуска минем хакта, яисә атам турында ишетергә туры килгәне бар, ахрысы? — диде.

— Бар шул, бар,— дип котылды Митька.— Казан губернасында сезне кем генә белми икән. Бөтен Идел буйларына даны-чабы таралган фамилия ләбаса.

— Яхшы сүзегезгә рәхмәт.— Апанаев кулларын күкрәгенә кушырды.

«Әгәр бу җилкуар минем Махно хезмәтчесе икәнемне сизсә, әтисенең башына шул Махно җиткәнен белсә, рәхмәт әйтеп торыр иде микән. Мөгаен, шунда ук тотып буар иде»,— дип уйлап алды Сабадырев. Ә теленнән, сүз юктан сүз булсын дип, нәрсә ычкындырганын сизми калды:

— Мин ишеткән идем, ни,— сезнең атагыз йортын Советлар казарма иткәннәр имеш, дип...

Апанаевның иреннәреннән елмаю качты. Йөзе таш кебек катты, күзеннән усал очкыннар чәчрәп китте. Әмма, бер сүз дә дәшмичә, ияк кагып кына җавап кайтарды. Митька аның авырткан сөяленә басуын аңлады.

— Сез гәпләшә торыгыз, туганнар...— Серадов өстәл яныннан торды.— Мин тагын мәхәббәт тагарагына чират алырга соңгармагаем. Зинуля хозурына барым килим әле. Әҗерен алдан биреп куйганны ярата, җанкисәгем.— Ул, тәҗрибәле официант кебек, өстәлләр арасыннан шома гына йөзеп китте.

Оркестр ниндидер ят көй — бармак очларына хәтле төшә торган танго уйный башлады. Урындык аяклары күчкәне ишетелде, бокаллар чылтырады — кайберәүләр бию уңаена чәкештерәләр һәм эчәләр иде. Аргы баштан бокал төшеп ватылганы, «Бәхеткә! Бәхеткә!»— дип кычкырып көлгән хатын-кыз тавышы ишетелде.

Апанаев күрше өстәлдә ялгызы гына утырган кызны күреп алды һәм, Сабадыревтан гафу үтенеп, аны биергә чакырды. Биегән арада алар, ялгыз калган Митьканың күңелен күрергә теләгәндәй, өстәл янына килеп киттеләр.

— Бу гүзәл кызның исеме Флора булыр,— дип таныштырды Апанаев. Аның күзләре утлы күмер кебек дәртләнеп яна иде. Бу утлы караш анархистның эчен яндырып, ниндидер аңлаешсыз көнчелек хисе уятты. Ләкин шунда ук ул үз-үзен кулга алды: «Ярамый! Хәзер синең язмышың бу кешеләр белән бәйле. Башыңа тай типмәгән булса, ресторан сөйрәлчеге аркасында юләрлек эшләмәссең». Өстәвенә тырнак астындагы ширпы булып Тоська искә төшә. Ул аны көненә, шәт, йөз тапкыр күз алдына китереп хыялланадыр. Күрешми торгач, азгын хатынның әшәкелекләре дә онытылып, сагындыра бара бит.

— Әй, асыл егет, нигә моңаясың-моңланасың, ә? — Күзләре майланган, йөзе канәгать балкыган Серадов урындыгын дөбердәтеп тартты, Митькага терәлеп үк диярлек утырды.— Кызыңны алып киттеләрме әллә, йә?

Сабадырев, дөньяда гаме юк кеше төсле, кулын гына бутады.

— Әйтсәм әйтим, Митенька: булдыклы мужик ул, атасына тарткан. Андагы колач киңлеге күпләргә җитешми.— Серадов рюмкаларның берсен алып эчеп куйды, артыннан берни дә капмыйча, кул аркасын гына иснәде.— Вәт шул. Сәясәт-политика дигәнең аның өчен дөм сукырга күзлек кидергән кебек бер нәрсә. Ул аңа сәүдә эшләрендә җилнең кайдан искәнен чамалау өчен генә кирәк. Чамасыз налог яисә мал-мөлкәтне тартып алу ише күсәк белән искәрмәстән ормасыннар өчен.

— Шулай да сыртына большевикларның бик авыр күсәге төшкән кебек күренә.

— Аны, асыл егетем, җегәре-малы булган һәркем татыды. Мисалга мин үземне генә алам. Гомерем буе кеше арасына керергә тырмаштым. Гыйлем эстәдем, карьера ясадым, кара эштән дә тайчын-

мадым. Тапканымны революция уты төбе-тамыры белән ялмап алды. Хәзер менә барысын да яңадан башлыйсы.

— Инде соң түгелме соң? — дигән булды Митька.

— Хикмәт тә шунда.— Серадов алдындагы рюмкага аракыны үзе салып эчте.— Синнән яшерергә исәбем юк.— Сабадыревның колагына иелде.— Шәп кенә итеп акча эшләп алырга җай бар. Тик ышанычлы кешеләр җитми.

— Ә мине ышанычлы дип уйлыйсыңмы? — Митька бу шома адәмнең ни белгәнен тикшереп-сынап карамакчы булды.

Серадов, шакал кебек телен салындырып, хихылдады гына.

— Әй, асыл егет, бөтенесен дә әйттереп бетермә инде. Бер генә киңәшем: кем белән очрашсаң да, мужик булып уйныйсы булма, зинһар. Сиңа килешми. Ресторан тәлинкәсе төсле, әллә кайдан күренеп тора кемлегең. Әйдә, без бер-беребезне алдарга маташмыйк. Югыйсә, хәйләли-хәйләли, этешә-төртешә торгач, Гирш Олькеницкий янына барып керүебез бар. Ә ул безнең килгәнне күптән көтеп ята. Почмакка оя корган үрмәкүч сыман.

Сабадырев майлы күзле бу шакалның үзе хакында күпмедер мәгълүмат җыярга өлгергәнен чамалады. Беренчедән, тәҗрибәле тикшерүче бит: ачыктан-ачык сорау алып утыруларыннан ук бер нәтиҗә чыгарга тиеш. Фаикъ Мусиннан да, Дардиевны үтерү турында килешкән чакта, ни белгәнен сыгып-сорашып калган, әлбәттә. Чыраенда төкерерлек урын калмаган адәмдер бу. Әнә күзеннән үткәрмичә, үзенең эшенә сине алыр ди, бар!

— Без төп сүздән читкәрәк киттек бугай,— диде Серадов, инде пышылдаудан туктап.— Әнвәр безне мәрхәмәтле канат астына сыендыра. Ул безне — димәк, акчалы итә. Әмма моның өчен, кабатлап әйтәм, ышанычлы, аңа бирелгән кеше булу кирәк.

— Ә син нәрсә, аның ярдәмчесеме?

— Алай дисәң дә була...— Серадов як-ягына каранды.— Нишлисен ул үзе әйтер сиңа. Иртәгә, менә шул адреста күрсәтелгәнчә, Печән базары янында үзеңә сыену урыны табарсың.— Ул тәмәке төрергә дип ертылган төсле бер кәгазь кисәге сузды.— Бу язуның икенче яртысы өй хуҗасы кулында булыр.

Сабадырев, төшенгәнен белдереп, ияк какты.

Музыка туктады. Флора белән аның кавалеры — Апанаев әйләнеп килделәр. Кыз, әллә ни тартынып тормыйча, аларның өстәле янына утырды. Сабадырев аларга илтифатсыз гына караш ташлап, ресторандагы кунакларны күзләргә керешті. Шул ук вакытта ул үзен дә чын-чынлап күзәткәннәрен белми иде, әлбәттә. Ә аның артыннан күзәтү кичә, Мусин белән икәү Дардиевны үтерергә киткәч башланды. Болак күперендә патруль пәйда булуы һич тә очраклы хәл түгел иде. Аны оештырган Серадов үзе дә кызыл гаскәри киеменнән шул «операция»дә катнашты. «Патруль» бу икәүнең ни кыланганын, кемнең нәрсәгә сәләтле булуын баштан ахыргача күзәтеп торды. Мусин Чистайдагы «эше» буенча ук таныш, революциягә кадәр үк рәшәткә артында утырырга өйрәнгән уголовникның кызыллар ягына чыкмасын Серадов бик яхшы белә. Ә менә аның иптәше... Мусиннан сораштырып кына ул «каты чикләвек»не ватып булмасы аңлашылды. Инде кызыл гаскәри киемендәге Серадов, боларны туктатып, бигрәк тә Митьканы үзе сынап карарга уйлаган иде. Әмма әлеге ике дус, «патруль»не абайлап алу белән, мәче кебек, койма, сарай башларына менеп киттеләр дә, «ә» дигәнче күздән юкка чыктылар... Шуңа күрә күзәтү бүген, ресторанда да дәвам итә иде.

Ә Митькага, үз чиратында, ресторан халкын күзе белән ялмап утыруның бер файдасы тиде. Ул берничә өстәл аша гына, чәчәк артына посып утырган хәләл җефетен күреп алды. Күреп алды да, авызындагы ризыгын чәйнәмичә йотып, тончыга язды. Серадов моңа

игътибар итте, авызына кереп китәрдәй булып, күзенә карады:

— Әллә танышларыңны күрдең инде, асыл егет? — диде.

— Юк, болай гына,— дип, кулын селтәп котылырга маташты Сабадырев.

— Ә син ашыгып җавап бирмә, туганкай. Синең язмышыңа хәзер без дә битараф кала алмыйбыз бит. Бергә-бергә киңәшкән эш таркалмас, диләр...

Серадов, җавап көтеп, Митькага текәлде. Ул, бер-бер артлы әллә ничә рюмка күтәрмәгән дә кебек, кинәт айнып киткән иде.

— Минем хатыным ул,— диде Сабадырев, авыз эчендә ботка пешереп.

— Аның янындагы байгыш кем була?

— Хатынның ухажеры.

— Гамәл фәрештәсе түгел икәнлеген күрәм.— Серадовның тавышында үртәлү сизелде.— Кем ул, дим: чека шымчысымы? Монархист яисә анархистмы?

— Анархист.

— Сиңа ияреп килдеме?

Җавап урынына бокал тутырып аракы салды да бер тын белән эчеп җибәрде Митька.

— Эш турында сөйләшеп туймадыгыз ла инде,— диде Апанаев, аскы иренен бүлтәйтеп.— Туташны да ялыктырып бетерәсез. Аның, бәлки, гөнаһлы мәхәббәт хакында бер-ике тарих ишетәсе киләдер?..— Башын юри кыңгыр салып, янында утырган Флорага текәлде.

Кызның каршы дәшмәвен барысы да ризалык билгесе дип аңладылар. Апанаев ак тастымал белән ирен читләрен сөртеп алды.

— Ә сез беләсезме, җәмәгать: мәхәббәткә иң хирес хатын-кызларның барысы да кияүгә чыгып бетә,— дип башлады ул.— Ягъни сазаган кыз булып та калмый андыйлар, алай-болай ирдән уңмаса — толлыкта да озак утырмый. Җир йөзендәге иң күп гөнаһ менә шундый хатыннарның иркен кочагына сыенып тора. Ирле хатын белән кетимети уйнаган өчен безнең брат арасыннан күпмесенең башы очкан! Әгәр ул кайнар башларны бергә өйсәң, дөньядагы иң биек тау шул булыр иде, шәт.

Бүтәннәр авыз ачып тыңларга керешкәндә, Митьканың чырае кара янды. «Бу байгура минем ярама тоз сибәргә маташа, күрәмсең»,— дип уйлап алды ул. Аның шушы хәлен аңлаган кебек, Апанаев туптуры карап, күз кысып куйды.

— Билгеле, кайбер ирләр өчен хатыннарының гүләйт итүе файдалы да булган. Англия короле Генрих Сигезенче, әйтик, бичәсен берәр тапкыр чит ир белән тоткач, беләсезме, нишләгән? Йөздән артык дошманын, хатынының сөяркәсе дип, астырган-кистергән. Королева белән яшерен гыйшык тотышу исә ул замада ватанга хыянәт итү белән бер саналган.

— Сезгә, Әнвәр, кайда өйрәттеләр соң мондый мәхәббәт тарихларын? — дип сүз кыстырды Флора.

— Тута-а-аш...— дип сузды Серадов, йөзенә ясалма елмаю җәелдереп.— Татар арасында да гыйлемле, зыялы кешеләр байтак бит ул. Безнең Әнвәр әфәнде дә,— ул Апанаевка таба башы белән ишарә ясады,— мәдрәсә белән генә чикләнеп калмаган. Ике университет бетергән. Казанда һәм дә Парижда. Во!

«Барыбер мөгез үсмәгән үзенә...— Көнче уй Митьканың эчен яндырып үтте.— Аныкыдай миллионнарым булса, Париж дип авыз суымны корытмас идем әле.»

— Мин дә бер газетадан укыган идем...— дип тагын сүзгә кушылды Флора.— Имеш, Африкадагы кайсыдыр кабиләләрдә хатыны кеше белән йөргән ирне бамбук таягы белән кыйныйлар икән...

Серадов ихахайлап көлә-көлә:

— Менә бусы шәп! Менә бусы дөрес! — диде.
— Ә мин һич аңлый алмыйм,— диде Флора йомры иңнәрен җыерып,— нигә дип аларның үзләренә түгел,— ирләренә таяк төшә? Ул ирләрнең ни гаебе бар?
— Ничек инде аларның гаебе булмасын! — Серадов кулларын бутый-бутый, өстәл янындагыларның әле берсенә, әле икенчесенә карады.— Ничек инде! Ул җүнсез ирләр бот күтәреп яталар, үзләренең төп вазифаларын да үтәмиләр. Ә мескен хатыннар, чыбыркысы яхшы шартлый торган ирләрне эзләп, «йомышка керергә» мәҗбүр булалар.— Серадов, үз-үзеннән бик канәгать төскә кереп, тагын авызын ыржайтты.— Хатыннарның нәсел черетүе — бары тик шул ялкау ирләр аркасында гына. Үтергәнче кыйнарга кирәк андый җебегән алашаларны. Безнең Рәсәйдә дә кертәсе иде шундый законны. Күпме ир үзенең хатынын тилмертеп йөртә. Шундый үшәннәр аркасында, тазатаза хатыннар арты белән мич җимерердәй булып йөри. Һәммәсенең күңелен күреп бетерү бездәй хезмәт сөючән ирләргә дә бик авырга килә.
Шул чак ресторан шау-шуы ничектер басыла төшеп, тирә-якта чыш-пыш килгән, тел шартлаткан тавышлар гына калды. Өстәл янында утыручыларның күбесе башларын борып ишек ягына карый, ә ул тарафтан күз явын алырлык итеп киенгән бер пар килә. Аяк атлаулары ук тәкәббер, борыннары өскә чөелгән. Болар кыл уртадагы бердәнбер буш өстәлгә таба киләләр.
«Благотич. Майор Благотич»,— дип пышылдый иде зал.
Серб батальоны командиры Благотичның кителендә ат башы хәтле кып-кызыл бант ут булып яна, ә муенында кар кебек ак ефәк шарф кычкырып тора. Янындагы озын буйлы, киң чатлы, коңгырт чәчле яшь хатын тәнендәге калку төшләрне дерелдәтеп-боргалап атлый, шуңа күрә аның күлмәк изүеннән менә-менә ап-ак имиләре атылып чыгар кебек күренсә, күк төстәге озын күлмәгенең итәкләре, көчле җил искәндәге кебек, як-якка җилфердәп бара. Ресторандагы ирләрнең күбесе, бигрәк тә матрослар, янәшәдә генә утырган тутый кошларын онытып, ач бүреләр төсле күз яндырып, шул хатынга текәлделәр: бу мәлдә аның очы гына капланган мул имиләренә, билгә кадәр шәрә аркасына әллә ничә күз угы кадалгандыр.
«Мария Нагая»,— дип чыш-пыш килде зал.
— Бу ни бу!..— Сабадырев, сукыр тавыкка барысы да бодай дигәндәй, әллә ни һушы китмичә генә, чибәркәй тарафына бармак төртеп күрсәтте.— Иван Грозный галиҗәнапләренең сигезенче хатыны яңадан терелеп, Казанда пәйда булганмы соң?..
И шәп булды әле! — Баягы сөйләшүләрдән соң, Митьканың да тарих җәһәтеннән бигүк төшеп калмаганлыгын күрсәтәсе килеп утыра иде.
Серадов, бик җитди кыяфәткә кергән булып, башын чайкады:
— Козгын кебек чукырга торган, чүкеч булып чүкергә торган халык монда, туганым. Патшабикә Мария Нагая, кабат терелеп дөньяга чыкса да, болар каршына мондый ук шәрә хәлдә чыгарга куркыр иде.
Апанаев, аны туктатырга теләгәндәй, кулларын бутады:
— Куй әле, Алтынбай Тархanович, андый сүзләр белән безне оялтма, зинһар. «Шәрә» Мариянең кем икәнен беләсең килсә, исеңә төшер: Явыз Иван бүтән хатыннары белән ничек кыланган!? Һәм нигә, ни өчен диген. Мария Долгорукаяны, әнә, зөфаф киченнән соң ук, буага батырып үтергәнме? Үтергән. Кызлыгын җуйган хәлдә үзенә кияүгә чыккан өчен. Мария Сабурова белән Анна Васильчикова да туйдан соң берничә атна үтүгә бик сәер-серле төстә генә гаип булалар. Ә Василиса Мелентьева — падишабызның җиденче хатыны,— анысы белән ничек? Тереләй җиргә күмеп куя аны Иван.
Хатынын чит кеше белән тоткан һәр ир шулай итә башласа, ай-

һай, бик аз калыр иде безнең җенес-ыру.— дип куйды Флора, артык исе китмичә генә. Әйтерсең лә сүз хатын-кыз турында түгел, кыш буе ягып чыгарлык утын турында бара иде.— Дөньяда ирләр генә калса, хатын-кызга да кыенгарак килә башлар бит.

— Юкка борчыласың, Флорочка,— дип телгә килде Сабадырев.— Әнвәр әйтергә генә онытты: Василиса-җанкисәге белән бергә аның сөяркәсен дә күмеп куя ич патшабыз. Кстати, анысын да тере килеш.

— Асыл егетләр без барыбыз да, ә менә чибәр хатынны күрү белән, узыша-узыша аны тарихның иң кара буяуларына манарга керештек.— Серадовның тавышы тантаналы, бу мәлдә ул үзе дә гаделлекне торгызу өчен җанын-малын кызганмас бер фидаи төсенә кергән иде.— Хәер...— Серадовның имән бармагы баш очына күтәрелде,— анысы да монысы, бу Мария белән патшабикә Мария арасында турыдан-туры якынлык бар, җәмәгать!

Аның өскә күтәрелгән бармагы хәзер шул фикерне раслаучы документ сыман иде.

— Китче!? — дип урынында сикереп алды Сабадырев.

— Әмма дә ләкин Мария Нагая турында сүз куертуыбызның хикмәте шунда,— Серадов нотык тотарга җыенгандай, кайнар кофе йотып куйды, имән бармагын янә өскә күтәрде: — әлеге патшабикә тәхетенә куеп караганда, безнең Флора туташның чын гүзәллеге алтын кысада җемелдәп киткән җәүһәр булып яктыра. Билләһи әгәр! Үткән заманнарда да, хәзерге көндә дә Флора туташка тиң хатын-кыз заты юк, булмады һәм булмас та.

Өч ир-ат, сүз куешкандай, бердәм чәкештереп, рюмкаларын күтәрделәр: синең исәнлеккә, Флорочка!

Аннары Серадов, һәммәсен дә белгән базар хатыннары кебек, майор Благотичның Мариясе турында сөйләргә керешә. Бу хатын — Петербург зыялылары нәселеннән: элеккеге патша министры Макаров кызы икән. Ул монда, Казанда элеккеге Вакытлы хөкүмәт министры Никитинның хатыны белән килгән. Мариянең ире — Алексей Нагойны Петроград чекасы кулга алган. Инде Никитинасы да кулда, имеш. Советка каршы эш алып барган өчен, ди. Ә бу чибәркәйгә исә диңгез тубыктан: мәхәббәт утраулары эзләп тик йөри. Менә, майор Благотичны очраткач, бөтен дөньясын оныткан. Бик кайнар мәхәббәт булса кирәк араларында.

— Ишетүемчә, әлеге майор «Шәрә» Мария белән генә мавыгып калмыйча, бүтән эшләргә дә вакыт таба, диләр, кһым-кһым...— Апанаев мәгънәле генә итеп тамак кырып куйды.

Әлеге имеш-мимешләрнең дә тиздән расланасы бар әле: Казан өчен авыр сугышлар барганда, Майор Благотич үзенең батальоны белән кызыл гаскәриләрнең аркасына пычак кадамаса, үлчәү, бәлки, ак чехлар ягына басмас та иде әле. Кем белә!

— Мариянең күзен кыздырган нәрсә — кызыл бант түгел, билгеле,— дип дәвам итте Серадов.— Кавалеры учлап-учлап алтын сибәргә ярата аның — шул бик ошый. Ә ул чибәркәй үзе бүтән яктан юмарт: әдәпле генә компания булганда, өстәл өсләренә менеп, тарантелла биергә ашкынып тора. Әлбәттә, анадан тума килеш!

Әле кияүгә чыкканчы ук Мария тәхеттә утыручыларга якын тора. Кияүгә чыккач та, бөек князь Михаилның хатыны янында статсдама булып кала. «Ахирәт-с» даманың Әби патша заманыннан килгән вазифасы мәгълүм. Бикәсенә чираттагы сөяркә булырга тиешле ир белән иң әүвәл ул йоклап карый. Шул төндә тегесе чын ирлеген исбатлый алса...

— Чынлап та шулай булды микәнни? — дип шик белдерде Сабадырев. Хәтта алдындагы бокалын да читкәрәк этәрде. Эчеп куйган саен Серадов аңа аракы өсти бара, ирексезләп диярлек кулына тоттыра иде.

«Мине исертергә тырышалар.— дип уйлады Митька.— Миңа бертуктаусыз салып-өстәп торалар, үзләре ялманып кына утыра. Күрәсең, шешә төбенә салып, пыяла аша карамакчы булалар мине. Аекның уенда — исерекнең телендә, диләрдер. Әллә кайчан үлеп беткән патшабикәләр, сөякләре таралган сөяркәләр турында сүз куертып җибәрүләре дә шуңа.— Сабадырев боларның асыл максатын аңларга тырыша иде.— Нинди эш өчен сынап-тикшереп карыйлар? Яисә телемнән нәрсә тартып аласылары килә?»

Ә бу вакытны Апанаев тона барган күзләре белән Флораны ашый һәм үз уйларына, хыялларына чумып утыра. Шул чибәр кыр кәҗәсен кулга ияләштереп, файдасын күрә торсаң, иллә шәп булыр иде, дип хыяллана ул. Тәтәйләр рәтендә йөргәнче. Яңа Татар бистәсендәге үз йортына кайткалар иде ичмаса. Ул йортның Апанаевларныкы икәнлеген белмиләр дә — чыбык очы кардәшләре исеменә язылган.

Болай, атасыннан биш йорт калган иде Казанда. Печән базары янындагы йортка иртәгәдән Сабадырев урнашып торыр. Анысы да бүтән кеше исемендә санала аның. Атасы уналтынчы елны ук, илдәге хәлнең тотрыксызлыгын алдан сизенеп, байтак милкен-мөлкәтен «кешенеке» иткән иде. Хәзинәдән бер өлешен Швейцария банкысына, Әнвәр исеменә күчереп куйды. Казанда да «кара көнгә» дип яшергән шактый маллары бар әле Апанайларның. Чит илгә сәфәр чыгар алдыннан атасы бөтен-бөтен кәгазьләрне дә күрсәтте. Әнвәр, киптергеч белән язу карасын сеңдергән кебек, барысын да бик яхшылап хәтеренә бикли барды. Ә бер кәгазьне күчереп-төшереп тә калды. Нәселдән-нәселгә килгән борынгы карта сыман нәрсә — хәзинәләр планы иде ул. Дөньялар тәмам бозылып киткәнче, менә шул кәгазьнең серен-тылсымын чишәргә кирәк. Ялгызы гына ерып чыгарлык күренми, ким дигәндә тагын ике-өч кеше табасы бар. Зиһенле, гыйлемле, шул ук вакытта бер нәрсәдән дә туктап калмый торган кыю-тәвәккәл егетләр булсын иде. Митька Сабадырев әнә шул эшкә ярамасмы әле, дип өметләнә Әнвәр. Алтынбай Серадов тәкъдим иткәч тә бу егетне ошатып өлгергән иде ул. Ә Серадовның үзе белән Апанаевның танышуы документлар аркасында килеп чыкты. Әллә каян гына ышанычлы язулар ясатып алды Алтынбай. Мондый болгавыр заманда тиешле кәгазьләр белән капланып ятсаң, җил-давыл да тимичә узып китүчән...

«Тагын ике генә кеше булса да кирәк».— дип үзалдына кабатлап куйды Әнвәр. Шул ук вакытта ачыктан-ачык җинаятьчеләр белән дә эш итәсе килми иде аның. Хәтәр бит. Үзләренә бәйле итеп куюлары бар. Талап-үтереп китәргә дә күп сорамаслар. Үзеңнән кала ышанычлы кеше юк бу дөньясында.

— Дмитрий...— Апанаев, уйларыннан уянып, томанлы тавыш белән Сабадыревка эндәште. Өстәл янындагылар аның хәзерге йокылы-уяулы халәтен күп эчүдән дип кенә аңладылар.— Дмитрий,— дип кабатлады Әнвәр,— синең хатының белән аның... иптәше ниндирәк кешеләр? Аларны четерекле эшкә җәлеп итәргә буламы? Әлбәттә, бушка — ходай ризалыгы өчен генә түгел.

— Буладыр дип уйлыйм... Була,— диде Митька, ничектер каушап.

— Ярар, Дмитрий, бүгенгә ашыкмыйк, алайса. Иртәгә сөйләшеп бетерербез ул хакта. Син бүген кайтып ял ит инде.

Бу үзенә күрә әмер булып та яңгырады. Шулай да Сабадырев урыныннан торып ишеккә түгел, хатыны белән Грязинюк утырган өстәлгә таба китте. Көнчелек, утлы тәмәке белән баскан кебек, аның эчен яндырып-көйдереп тора иде.

Сөйләшү төштәге сыман бер-берсенә бәйләнешсез, истә калмаслык хәл-әхвәл сорашудан гыйбарәт булды. Теленә ничек килгәндер: хатынын бүгенгә генә булса да үзе белән йокларга чакырды Митька. Әмма Тоська бу юлы да кәнтәйлеген итте: бүген синнән барыбер рәт чыкмый инде, диде.

Грязинюкның тук чыраен, оятсыз елмаюын күргәч, Сабадыревны очкылык тота башлады. Кулы үзеннән-үзе пистолетка үрелде. Ләкин нәкъ шул чакны кемдер арттан килеп аның җилкәсенә кулын салды. Митька сискәнеп китте, кисәк кенә башын боргалады. Аның куркуын сизмәгәндәй, Серадов йомшак кына итеп кулыннан тотып алды.

— Митюша, син асыл егет, синең белән саубуллашасым килә. Зинулям биисен биеп бетерде, хәзер өйгә ашыга.

Аны махночылар белән таныштырмый чарасы юк иде Митьканың.

Серадов, үзенең биючесен бөтенләй оныткан сыман, өстәл янындагы буш урынга җәелеп утырды. Башы томанлана башлаган булса да, Митька шундук аңлап алды: бу адәм — саубуллашырга түгел, әлеге икәүнең кем икәнлеген капшарга дип килгән иде.

Серадов сөйләшүне яңадан майор Благотич, «Шәрә» Мария тирәсенә күчерде. Грязинюк, очып баручы каз кебек, муенын сузып Мария Нагая тарафына текәлде:

— Менә бу, малай, эшкә яраклы хатын! Бер сәгать кочаклап яткырса, соңгы күлмәгеңне салып бирерлек! — дип аһ-уһ килде, урынында кыбырсый башлады.

Ә Митька эчтән генә сөенә, аның бөтен кыяфәте: «Күрдеңме, Тоська, мине кем белән алыштырганыңны! Ул бит сине ташлап, беренче очраган сөйрәлчеккә ияреп китәчәк!» — ди иде.

Серадов, эшнең нәрсәдә икәнен бик тиз чамалап, кинәт кенә Тоськаны мактауга күчте. Хатынның текә күкрәген күзе белән сыйпап:

— Әгәр дә Таисия исемле бу сылу ханымны шундый ук киемнәргә төрсәң, Мария Нагая, кояш каршындагы ай кебек, тәмам төссезләнеп калачак, валлаһи,— диде. Өстәл астындагы кулы белән Тоськаның йомры тезләрен сыйпый-сыйпый, Серадов берни дә булмагандай сөйләнде:

— Шәрә хатынның матурлыгы — учактагы ут сыман ул: күзне кыздыра, үрелеп тотарсың да алырсың кебек тоела; ә кулың белән кагылуга — пешереп-яндырып чыгара...

— Сез дә шактый янгансыз, ахрысы...— диде Тоська, өстәл астындагы әрсез кулны каты гына чеметеп.

Саубуллашыр алдыннан Серадов, һаман шул Тоська каршында үзенең белдеклелеген күрсәтер өченме: «Иртәгә булмаса, берсекөнгә бу ресторан ябыла. Мондагы номерларга Көнчыгыш фронтның штабы урнашачак»,— диде. Як-ягына каранып алгач, өстәлгә таба иелебрәк:

— Фронт сызыгы тиздән Казанга килеп җитәчәк,— дип пышылдады.

«Бу ата күркә хәрбиләр белән бәйледер, ахрысы. Тик нишләп әле Апанаевка тәлинкә тоткан булып кылана ул? Акчасы юклыктан дисәң, шансонетка куенында бер төн куныр чыгар өчен алтын сарыф итәр идеме икән?» — Шундый уйлар белән рестораннан чыкты Митька һәм җәяүләп кенә үзенең сыену урынына таба атлады.

Төн җылы, тыныч иде. Ай да, йолдызлар да күренми. Хәер, Митьканың күккә күтәрелеп карыйсы да килми. Аның күңелен болыт төсле төрле уйлар пәрдәләп алган. Йөрәге чәнчүен тоеп кайта. Һаман шул Тоськаны, аның чәченә күмелеп йоклаган татлы төннәрне оныта алмый егет. Нәкъ менә йогышлы чир булды инде ул хатын...

Кайтып җитәрәк, үзе яшәгән өй каршысында ук бер ир-ат басып торганын шәйләгәч кенә, кинәт айнып китте Митька. Өй турысыннан узып, күрше ишегалдына керде. Шуннан торып сак кына карады: теге ир юкка чыккан иде. Урам ягында да күренми. Димәк, өйгә кергән! «Кем булырга мөмкин бу?» — дип уйлады Митька. Яртылаш җиргә чумган беренче катта ике гаилә яшәгәнен белә иде инде ул. Әмма анда ир-ат заты юк. Мәрхүм Мусин сөйләгән бер җүләр кыз-тәкәне ир җенесенә санамасаң, әлбәттә.

Сабадырев колак торгызып бераз тыңланып-каранып торды. Ти-

рә-юньдә шылт иткән тавыш та юк, беренче катның тәрәзәсен генә эчтән сукыр ут яктырта иде. Митька, тәвәккәлләп, тәрәзәдән карарга булды. Әмма пәрдә аша берни дә күренмәде. Эчтә нәрсәдер сөйләшәләр. Колакны тәрәзә рамына куеп тыңласаң, шактый аңлаешлы булып ишетелә икән.

— Күрдем, күрдем,— диде малайлар тавышы белән бераү.— Икәү иделәр алар. Ике ир.

Сабадырев пыялага тагын да ныграк сыенды. «Кыз-тәкәдән сорашалар ахрысы! Безнең турыда түгелме соң бу?»

— Өскә менделәр алар. Өскә дим...— Кыз-тәкә үзенең белгәнен сөйли иде.— Исемнәре тас кебек шалтыр-шолтыр килде.

— Ничек соң аларның исемнәре? — дип сорады ир-ат тавышы.

«Сорау алалар! Уголовный розыск яисә чека шымчылары! — Митьканың тез буыннары йомшап китте. Ул ялт кына тирә-ягына карап алды да, колагын тагын тәрәзәгә ябыштырды.— Ничек монда килеп чыкканнар? Бу җүләр безнең исемне дә белеп өлгерде микәнни?»

Кыз-тәкәнең җавабы бик сәер иде:

— Исемнәре шундый кызык аларның...— Хихылдап алды шикелле.— Берсе — Дилбегә Арканов, ә икенчесе — Бастырык Камытшин!..

— Җитте! Синең белән шаярып сөйләшмиләр! — бу юлы баягы ир-атның тавышы ачулы-кырыс иде.

— Кулыңны күтәр! — Сабадыревның колак төбенә суккан кебек шундый әмер яңгырады. Шул ук мәлне биленә револьвер көпшәсе китереп терәгәннәрен сизде.

Митька әкрен генә кулын күтәрде, каударланып фикер йөртте: нишләргә!? Бөтен дөньяның асты өскә килүе шушымы?

Артында торган кешенең бер үзе генә икәнен чамалап, Сабадырев бөтен гәүдәсе белән кисәк борылды, тегенең револьверлы кулына китереп сукты һәм төн карасына таба җан-фәрманга йөгерә башлады.

— Тукта! Атам! — дип кычкырды тәрәзә төбендә револьверын эзли калган ир.

Митька аны атып та китә алган булыр иде: һәртөрле патруль һәм постта торучы милиционерларның дикъкатен җәлеп итүдән курыкты.

Бу төнне ул Татар зиратында үткәрде. Казанда шуннан да тыныч урын юк икән дип уйлады Сабадырев, ауган кабер ташы өстенә бөгәрләнеп яткач.

## VII. Хәзинә ачкычы кем кулында?

Печән базары янындагы йортта Митьканы Әнвәр Апанаев үзе каршы алды. Ул бу юлы гади генә итеп киенгән һәм тышкы кыяфәте белән ниндидер контора хезмәткәрен хәтерләтә иде.

— Иә, ничек ял иттең?— диде Әнвәр, күрешергә кулын сузып — Йокың туйдымы?— Җавап кайтарганын да көтеп тормастан, дәвам итте: — Куркыныч хәлләрдә дә каушап калмый торган егет икәнсең. Сакланганны саклармын, дигән шул...

— Нәрсә әйтергә теләвең бу, купец? Кичә кабыргаңа наган терәгәч тә үкчәңне ялтыратып котылдың, димәкче буласыңмы?

— Нәкъ шулай дим. Серадовның апасы йортында...

— Ул әле синең кешеләрең идемени?! — Сабадырев, күзләрен усал агартып, урынынннан кузгалды.

— Йә, йә, Дмитрий,— Апанаев аның җилкәсенә учын салды,— тынычлан. Алай шаярта торган гадәтем юк. Синең үлгән дустың эзеннән «угро» шымчылары иснәнеп килгән. Шул гына.

Митька шуны аңлап алды: кичә аны Апанаев яисә Серадов кешеләре «озата» барган булырга тиеш. Алар, ярдәм итә алмасалар да,

барысын да күреп торганнар. Шул ук вакытта Митька мәрхүм Мусинның әзенә ничек төшүләрен белми иде. Моның өчен аңа Фаикъ белән беренче очрашуларын, Кәҗә бистәсеннән кайткан чакта «ахир»енең нәкъ менә шул өйгә кереп чыгуын искә төшерергә кирәк иде.

Апанаев түр якка чыгып китте, шуннан торып кына Митьканы үз янына чакырып алды. Ул йомшак кәнәфигә хуҗаларча җәелеп утырган иде. Кунакка үз янындагы икенче кәнәфидән урын күрсәтте.

Баштарак сүз ялганып китә алмады. Бер-берсенә әле артык таныш булмаганлыктан, ахрысы, икесе дә ачылып китә алмыйлар. «Күңелдәге уй-ниятне әйтсәм, үкенмәмме икән?» — дигән кебек, сагаеп торалар иде. Шулай да Апанаев, бередә үзенең хуҗа булу хокукыннан файдаланып: «Алга таба ничегрәк яшәргә исәп? Нәрсәгә өметләнәсең?» — шикеллерәк сораулар биргәли башлады. Сабадырев үз нәүбәтендә артык җәелмичә генә булса да: «Кире кайтарып аласы маллар... Бу мәхшәр узгач...» — диебрәк, кинаяле җаваплар кайтарды.

Апанаев кәнәфидән кискен генә торып, өстәл янына китте, тастымал ябып куелган бер чынаякны күтәреп эчте. Чынаякта сөт булган икән. Ирен читләрен чигүле ак ефәк кулъяулык белән сөртте. Шуннан соң, идән уртасында басып торган көе, Митькага таба борылды:

— Бу «мәхшәр»нең узганын көтеп ала алмассың дип куркам, Дмитрий. Совет власте дигән хакимият бер көндә, бер елда гына җимерелеп төшмәячәк. Мин аны бик озакка килгәндер дип уйлыйм. Гомерлеккә булуы да бик ихтимал. Бу мәсьәләдә без әти белән гел капмакаршы фикердә булдык. Ул, ком бураны уйнар-уйнар да бер тынар, безнең юлларны күмә алмас әле, дип, үзенең кире әйләнеп кайтасына ышанды. Шунлыктан бөтен байлыгын диярлек монда, Казанда калдырды. Инде менә аның хаталарын миңа төзәтергә туры килә.

Купец янә үзенең кәнәфиенә килеп кунаклады. Киерелә төшеп сүзен дәвам итте:

— Беләсеңме, Дмитрий, нинди уй килде миңа...— Кыска гына тыныш ясады.— Безгә, кем әйтмешли, иңгә-иң торып эшче-крестьян банкына таба сәфәр чыгарга кирәк.

Апанаевның бу сүзләре генә дә Митьканы телсез калдырырлык иде. «Юри сөйләнәме бу сәүдәгәр калдыгы,— минем ният-планнарны белеп? Әллә моның да үзлегеннән шул фикергә килүеме? — дип гаҗизләнеп уйлады ул. Зәмһәрир суыктан кайнар мунчага килеп эләккәндәй тәмам йомшады, нәрсә дип әйтергә белми аптырады. Ниһаять:

— Бик мәслихәт эш булыр, бик мәслихәт,— дип мыгырданырлык көч тапты.

— Банк йортын өч ел гына элек төзеделәр әле.— диде Апанаев, аның болай мәлҗерәвенә игътибар да итмәгән кебек.— Ул эштә миңа әшнә тиешле бераү катнашкан иде. Менә ул сөйләде миңа: әлеге бинаның йомшак төше кайда икәнен; иреннәрен чытырдатып кыскан кебек күренсә дә, черек теше кайда икәнен... Ул чакны әле миндә банк басу уе бармы! Кызык итеп кенә тыңладым. Әмма аннан соң безнең нәселне большевиклар һәм аларның әләме астына сырышкан җыен хәерче-хөрәсән талады, җиде кат тиребезне тунадылар. Инде шул малларны кире костырырга вакыт җитте дип уйлыйм. Дөресме?

— Безнең юллар бер тарафка икән,— диде, ниһаять, исен-акылын җыеп өлгергән Сабадырев.— Минем нәкъ шул җәһәттән кайбер фаразларым бар.

Уртага салып сөйләшә-гәпләшә башлагач, Митька корган планның әле теге төше, әле бу төше уйланып җитмәгәнлеге ачыкланды. Иң әүвәл банк астына таба җир асты юлын казый башлау өчен кайсыдыр йортны сатып алу кирәклеге һәм моның бик күп өстәмә мәшәкать тудырасы билгеле булды. Ул арада Апанаев, бу ниятнең сөяктән салынган сарай икәнлеген тәмам күрсәтергә теләгәндәй, яңадан-яңа сораулар яудырды:

— Иң якын йорттан башлап китсәк тә, күпме вакыт казырга туры киләчәк — исәпләп карамадыңмы? — диде.

Чама белән ике айдан да тизрәк башкарып чыгасы түгел икән.

— Хәзергедәй заманда бу бик озак,— диде Апанаев, түшенкe кыяфәткә кереп. Сәгате — ай, бер көне — ел...

— Син җиңелрәк юл күрәсеңме?

— Анысы хак, җиңел юл юк бу эштә. Әмма кәсеп итәргә кирәк...— Әнвәр мәгънәле генә итеп каш сикертте.

— Ягъни мәсәлән?..

— Тарихны онытмаска кирәк, дустым, тарихны! — Апанаев кәнәфи артындагы артсыз урындыктан калай тартма үрелеп алды, аны ачып, бер сары ландринны авызына капты.— Ишеткәнең бардыр: Иван Грозный бу шәһәрне болай гына яулап ала алмагач, дивар-ныгытмаларны астан казып кереп, дары белән шартлаткан. Казып кергән икән, димәк, җир астыннан юллар салган. Шундый юлларның берсе Казан суы астыннан үткән. Ә берсенең банк тирәсеннән, хәтта нәкъ аның астыннан ук узуы мөмкин.

— Тарих та бит тынчып яткан күл түгел. Дүрт йөз ел эчендә күпме сулар аккан...— Сабадырев, син шул хакта уйлыйсыңмы соң, дигән мәгънәдә авызын чалышайтты.— Шартлау дулкынынннан ук җимерелеп беткәндер җир асты юллары.

— Һич тә борчылма: тулысынча ук ишелеп төшмәгән ул,— диде Әнвәр тыныч кына.— Крепость диварын җимергәндә җир асты юлына бер зыян да килмәгән. Аннары Казан суының аръягыннан гына түгел, Болак артыннан да казып килүләре яхшы мәгълүм.

— Ничек? Шул хакта документлар сакланганмы, яисә шаһитләр бармы?

— Тегесе дә, бусы да бар.— Апанаев шүрлектән юка гына бер дәфтәр алып, беренче битеннән үк укып китте: «Ә Казан-су астына, дәхи Болак астына, дивар вә манара тугрысына падишаһ-царь җирне казып керергә дә янә дарылы мичкәләр куярга кушты, болар барысы да һәм шулай эшләнде». — Әнвәр, дәфтәрне ябып, читкәрәк этеп куйды.— Мин моны шул заманнарның елъязмасыннан күчереп алдым. Соңрак нәкъ шул хакта Андрей Курбский да яза. Ул бит,— үзең беләсең, Иван Грозныйның якын дусты, аның белән бергә Казанны яулауда катнашкан князь.

Апанаев уенча, Болак астында шундый җир асты юллары берничәү булырга тиеш. Төп керү юлы бер, ә менә уртагарак җиткәч, төрле юнәлешләргә аерыла да китә.

— Нәкъ Одесса катакомбалары шикелле, Казанның «сукыр тычкан» юллары да тармаклы-тармаклы, димәк?

Әнвәр, күзләреннән хәйләкәр очкын сирпеп, Махно эмиссарына карады, әкрен генә әйтте:

— Син инде, Одессадагы кебек, безнең дә шәһәр астындагы юллар ниндидер схемага төшерелмәдеме икән дип уйлыйсыңдыр, ә?

— Анысы аңлашыла: Одессаның җир асты дөньясын табигать үзе ясаган, ә монда, Казанда — төрле заманда, төрле максат белән — кешеләр үзләре казыган юллар. Мин менә шундыйларның чиркәү, монастырьлар астыннан сузылып, төрле биналарны бергә бәйләвен беләм. Тик нигә кирәк булды икән бер үк ишегалдында, янәшәдә генә торган ике бинаны җир астыннан да бер-берсе белән тоташтыру? — монысы миңа бик сәер тоела.

Апанаев кесәсеннән баягы калай тартманы чыгарып, тагын бер ландрин алып капты. Аның ашыкмыйча гына сөйләвеннән шулай дип аңларга була иде: чиркәүнең җир астында үз тормышы бар, халык чуалышлары булганда, ул анда кереп качарга, бигрәк тә байлыгын яшерергә әзер тора.

— Сездәге чиркәүләр генә шул хәтле бай түгелдер инде? — ди-

де Сабадырев, ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

Апанаев иреннәрен бөрештереп кенә елмайгандай итте:

— Һәй, андый байлык синең төшеңә дә кергәне юк,— диде.

Анархистның комсыз күзләре, кәҗә бәрәнен күргән ач бүренеке кебек, ялтырады. Әгәр ул каһәр банкны басып булмаса, Казан чиркәүләренең берсен җиллэтергә туры килер, иншалла, дип үзалдына уй беркетеп куйды ул. Чиркәүләрдәге байлык-хәзинә турында Апанаевның сөйләве колакны иркәли, хәтта җиңелчә генә башны әйләндерә иде. Ә инде Благовещенский соборында унбиш пот бриллиант һәм энҗеләр белән бизәлгән алтын тәреләр булуын әйткәч, Сабадырев түзмәде, урыныннан сикереп торып, ишекле-түрле йөренә башлады. Ә Апанаев, аны үртәгәндәй, тагын тезеп китте: Сергий Радонежский чиркәвендә җиде пот көмеш, биш фунт алтын, йөз сиксән алты энҗе бөртеге саклана; изге Варвара чиркәвендә — биш пот көмеш, тугыз фунт алтын, җитмеш дүрт каратлык, туксан сигез бриллиант...

— Ну азынганнар, мин сиңайтим! — Митька инде Әнвәрнең тагын да газаплавына түзә алмый иде,— шулхәтле алтын-көмеш нәрсәгә аларга. Халыкның башына күпме сөрем җибәргәннәрдер әле, шул байлыкны сыгып алыр өчен! Юк, болай булмый. Алар гынамыни алланың кашка тәкәләре! Әйтергә туры килер: анархия хакына, Махно атакай хакына миңа да бераз өлеш чыгарсыннар.

Апанаев, кунагының болай очынуын эчтән көлемсерәп күзәтсә дә, сүзне баштагы эзенә кайтарып төшерде:

— Җир асты юлы белән тоташкан бүтән биналар да бар Казанда. Әйтик, аларның берсе Воскресенская урамы астыннан бара — университеттан Пассажга таба. Билгеле, әлеге юл инде университет төзелгәнче үк булган. Нигез казыганда төзүчеләр аны тапканнардыр дип уйларга кирәк, әмма күмеп калдырмаганнар. Университет бинасының ректор йортына якынрак канатында, подвалда канализация коесы кебек нәрсә бар. Менә шул «кое«дан бик озын җир асты юлына барып керәсең...

— Ярый, җир астына бер төшкәч, Казанны аркылыга-буйга йөреп чыгарыбызга ышандым инде,— диде Сабадырев сабырсызланып.— Син бит бая нindидер схема дип тә ычкындырган идең...

Апанаев учы белән тезенә шапылдатып куйды:

— Юк, җир асты юлларының сызымын мин төземәдем. Ул эш белән сәеррәк табигатьле бер бабай шөгыльләнгән. Әлеге картның хәтта Николай патшага, аннары Керенскийга кадәр хат язуы мәгълүм. Ул алардан үз карамагына ничәдер эшче бирүне сораган. Хан заманыннан калган чиксез хәзинәләрне җир өстенә чыгарып, Рәсәй казнасын баетыр идем, дигән.

— Ул нәкъ шулай дип язганмы? Әзләр өчен түгел, чыгарыр өчен, дигәнме?

— Нәкъ шулай: «чыгару өчен» дигән. Димәк, ул инде хәзинәнең кайда яшерелгәнен дә яхшы белгән. Кызганыч: минем әти аның түрәләргә, патшаларга хат язып азапланганын бик соң гына белеп алган. Югыйсә, ул эшчесен дә табар, акчасын да җәлләмәс иде...— Әнвәр авыр көрсенеп куйды.

— Өлгерә алмыйча калганмы атаң?

— Соңгарган! Бәлки бер-ике айга гынадыр... Әмма инде соң булган!

— Кем тартып алган соң ул картның серен? Шундый да көчле көндәшләргә тап булганмы?

— Көндәшнең бик көчлесе туры килгән шул, әйе... Авыру һәм үлем... Алар тартып алганнар — картның серен генә түгел, үзен дә.

Митька кабат-кабат алданып та, инде үпкәләгән нарасый төсле авызын бүлтәйтте. Әнвәр, аңа игътибар да итмәгән төс белән, сүзен дәвам итте:

— Әҗемнәр нәселеннән килүче ул бабайның исеме Илһам иде. Эти белән көрешкәндә инде әҗәл түшәгендә яткан булса да, әле һаман аякка басар кебек сөйләнгән. Өзелер алдыннан гына мендәр астыннан бер кәгазь алып биргән. Нindидер күмелгән хәзинәләр планы, дигән. Әмма рәте-чираты белән аңлатырга өлгермәгән. Эти ул кәгазьне бик зур акчага сатып алмакчы да булган, тик Илһам бабай дүрт куллап каршы килгән. Шулай да этидән ант иттергән: табыласы хәзинәнең яртысын ятимнәргә, караучысыз калган картларга, фәкыйрьләргә һәм гариплəргә ярдәм итү өчен тотарсың, дигән. Минем эти диндар кеше. Хәзинәгә тап булса, үзенең антын һич тә бозмас иде.

«Махно кулына барып эләккән сары пергамент менә нинди юллар үткән икән!» — Чак кына шуны кычкырып әйтми калды Сабадырев. Куркудан бөтен тәне куырылып килде.

Ә Апанаев, аның бу халәтен сизмичә, Әҗемнәр нәселе, ханнар хәзинәсе турында сөйләнүен белде. Митька ул арада тәмам тынычланып, аны илтифатсыз гына тыңлый башлады. «Пергаментта нәрсәләр ясалган иде икән?» — дип, читләтеп-читләтеп кенә сораштырган булды.

Апанаевның:

— Илһам бабай кәгазендә әллә нинди сызыклар бар, бөтен хикмәт менә шуларда...— дигәнен дә колак яныннан гына уздырды Митька. Әмма шуннан соң ук:

— Ә шулай да бер сызыкның серен чиштек бит! Җир астыннан ун фунт алтын тәңкә, бер фунт чамасы энҗе-мәрҗән казып алдык,— дигәч, анархистның чыраеннан кан качты.

— Кем белән? Кайчан?! — дип, кәнәфидән сикереп торды.

Апанаев сабыр гына җавап кайтарды:

— Узган ел. Эти белән икәү.

— Кайдан?

— Казан суы ярыннан.

Сабадырев тиз генә исенә төшерергә тырышты: теге сызыклар Сөембикә манарасыннан кайсы тарафларга таба сузылган иде әле?.. Соң, әлбәттә! — бер сызык-ук елга буена барып кадалган иде бит! Нәкъ шул төшкә беленер-беленмәслек кенә итеп агач күпер «сугып» куелган иде. Күрәсең, күперне, хәзинә урынын яхшырак тамгалар өчен, Апанаевлар өстәп куйганнар инде.

— Сиңа ни булды, Дмитрий? Йөзләрең агарынды, маңгаеңа тир бәреп чыкты...— Апанаев кызыл күн тышлы, гарәп язулы нindидер бер китапны алып, шуны актара башлаган иде.— Карале, әй, бөтен булмышың — кызыл малын урлаткан сәүдәгәргә охшаган,— диде ул, китабын бер читкә куеп.— Син дә шул хәзинәне эзләп килгәнсең имеш тә, син килер алдыннан гына аны без казып алганбыз диярсең!

«Үтәли күреп тора, каһәр!» — дип куркып уйлады Сабадырев. Куркуын сиздермәс өчен, теленә килгән беренче сорауны бирергә ашыкты:

— Күмелгән хәзинәләр барлыгын бераү дә белмәгәнме? Эзләүче булмаганмы? Ничә заманнар буе...

— Булган җиңел генә баерга теләүчеләр...— Апанаевның әле нәрсә әйтергә теләве ачык түгел иде. Кулындагы китапны кире шүрлеккә куйгач кына, сүзен әйтеп бетерде: — Мәгәр ул авыр эшне ходай үзе безнең өлешкә калдырган. Сукыр тәкә кебек капшанган атаклы Державиннардан да аермалы буларак, безнең кулда план-ачкыч бар. Әйе, «Сим, сим, ишекне ач!» — дигәндәй, шул план сихерле ишекләрнең күбесен ачтырыр әле.

Митька, ниһаять, әлеге пергамент белән кызыксынуын сиздерде. Сакланып кына, шик-күләгә төшмәслек итеп кенә.

— Шәт, ул планны миңа да күрсәтер идең? Әгәр сер булмаса... диде.

— Синнән яшерен сер булмас...— Апанаев күзләре белән чәнчеп карады.— Әмма һәр нәрсәнең үз вакыты бар.

— Ни, югалта күрмә, димен. Чекист яисә мильтон халкына эләксә, сиңа-миңа валчыгын да калдырмаслар.

Хуҗа бер күзен кыса төшеп, ачы көлемсерәде:

— Син мине кем дип уйлыйсың, Дмитрий, ә? Шуны бел: хәтта ки төп нөсхәсен эләктерсәләр дә, «урман эчләрендә урман» булачак әле ул!

Сабадырев бармак очлары белән колак йомшагын уган булып утыра иде. Ышанырга да, ышанмаска да белмичә:

— Әллә... Төптәге нөсхәсен дә үзгәрткәләдеңме? — дип сорады.

— Ә синең, Дмитрий, борын шәрифләрең бик сизгер. Томау гына төшә күрмәсен!

Сабадыревның аркасына бозлы су койган кебек булды:
Бу бит — каһәр суккан әлеге пергаментны икенче мәртәбә югалту белән бер иде! «Нык үзгәртелгән булды микәнни? Чын укларны юк итеп, нинди ялган сызыклар өстәде икән, нәгъләт?»

Апанаев тыныч кына дәвам итте:

— Мондый болгавыр вакытта куеныңа хәзинә ачкычын тыгып чыгу үзе үк хәтәр. Аның югалуы — чекистлар яисә тагын шундый әтрәк-әләмнәр кулына эләгүе — бигрәк тә зур ахмаклык булыр иде. Тыңламады шул сүземне эти. Бичарадан ничара, шулай үзгәртергә туры килде.

Балтасы суга төшкәнен сиздермәс өчен, Митька икенче яктан суктырды:

— Анысы шулай шулаен... Тик менә бүтәннәр дә синең кебек эш иткән булса... Ничә кул аша сезгә килеп ирешкән бит... Әлегәчә берәү дә үзгәреш кертмәгәндер дип уйлыйсыңмы?

— Билләһи, дурак түгел син, әй, Дмитрий. Без икебез дә бер юнәлештәрәк ишәбез төсле. Чыннан да, әлеге план, мәсәлән, явыз Иван кулына эләксә, аның чеп-чи ялган кәгазь ясап калдыру ихтималы бар. Мин ул якларын да уйладым, билгеле. Булгач-булгач, булсын инде дип, тарих чүплегендә шактый казынырга туры килде.

Ул тарихны Әнвәрнең бик тәфсилләп сөйлисе килә иде бугай. Әмма кадимдәге татар дәүләте, аның патшалары турында тыңлап утыру шактый күңелсез эш булып чыкты. Ханнарның хәрәмханәләрдә кол кызлар асравы, җир астына яисә күл төбенә хәзинә яшерүләре генә әзме-күпме кызыксыну уятырлык иде. Сабадырев җепнең очын ныграк тартты, хикәятнең агышын тизләтергә тырышты:

— Казан алынгач, Сөембикәнең Шигалига — сезнеңчә Шаһ-Алига — кияүгә бирелүен аңладым. Үзен алса да, ханбикәнең эч серләренә ия була алмагандыр Шигали. Әмма күмелгән хәзинә ачкычы Азимовлар кулына ничек килеп кергән соң? — диде.

— Сабыр. Сабыр... Тарихны ашыктырып та, сикереп үтеп булмый аны,— дип үзенекен тукыды Апанаев. «Профессор!» дип эченнән генә кушамат тагып мыскыллап куйды аны Митька. Шулай да, анархистның түземлеге төкәнгәнче, сүзен түгәрәкләргә җыена иде, ахрысы, «профессор»:

— Шундый кыйммәтле мирасның Сөембикәдән Әҗемнәр кулына калуы хак,— дип, мәсьәләгә якынрак килде.— Моңа сәбәпче булган хәлләр арасында мәгълүм Ливон сугышы да бар. Касыйм ханнарының нәселе шул заманда киселә бит. Шаһгали — Иванның зур хәрби начальнигы: әлеге яуга ул татар гаскәре белән генә түгел, рус полкларының да башында керә. Үкенечкә каршы, бердәнбер улын да шул сугышта катнашырга мәҗбүр итә. Улы һәлак, була. Шуның хәсрәтеннән озак та үтми, Шаһгали үзе дә дөнья куя... Сөембикә, билгеле, яшерелгән Казан малыннан үзенең улы файдаланыр әле дип теләгәндер. Аңа зур өметләр баглагандыр. Әмма егер-

ме яшен генә тотырган ханзадә дә һич көтмәгәндә гүр иясе була. Менә шул хәлләрдән соң Сөембикәнең якыннарыннан Әҗем Габдулласы гына торып кала...

— Кара син, ә, хәзинәнең үзен казырга керешкәнче, тарихтан әллә ниләр казып чыгаргансың,— дип бүлдерде Сабадырев.— Шулай да теге планның төп нөсхәсен нишләп атаңа биреп җибәрдең, әй? Үзең үк әйтеп торасың ич: болгавыр заман, чекистлар кулына әләгүе дә бар, дип. Чын нөсхәсе синдә калса, әйбәтрәк сакланмас идемени?

Апанаев мыек астыннан көлемсерәде:

— Менә синең кулыңа ике алма бирделәр, ди: берсе чын — күз алдыңда агачтан өзелеп төшкән, ә икенчесе алмага охшатып ясалган уенчык кына. Син шуларның кайсысын үзеңә алыр идең?

— Чын дигәнен, әлбәттә.

— Шул-шул! Бер үк документның ике нөсхәсен янәшә куеп карасаң да, нәкъ шундый ук хәл: төптәгесенә ныграк ышанасың.

— Анысы да хак,— дип баш какты Митька.

— Шуңа күрә үземә күчермәсен генә алып калдым да мин. Борынгы пергамент белән чагыштырганда, аңа ышаныч бөтенләй юк диярлек. Иллә мәгәр миндәге күчермә теге сары кәгазьдән йөз дәрәҗәдә кыйммәтлерәк. Чөнки ул хәзер төп нөсхә булып калды, ә төп нөсхә — үзенең асылында үзгәртеп-бозып бетерелгән күчермә генә! Ха-ха...

«Хәйләкәр, нәгъләт,— дип уйлады анархист, миллионер малаеның шапырынуын тыңлап торганда.— Төлке кебек, койрыгы белән эзен себереп бара. Кырган-бетергән, яңадан өстәп-сызган төшләрне теге пергаментта да чамалап булгандыр булуын. Нечкәләбрәк карыйсы калган, их!.. Ярый әле, язмыш туры китерде бу бәндәгә. Югыйсә, сукыр песи баласы кебек, танавымны кая төртергә белми йөрер идем».

— Карале, Әнвәр, сөйләгәннәреңне тыңлып-тыңлап торам да, үз колакларыма үзем ышанмыйм: син бит җаның-тәнең белән безнең брат икәнсең, әй.

Сүзнең мондый борылыш алуы Апанаевка бик сәер тоелды.

— «Без» дип кемне, нәрсәне күздә тотуың бу?

— Соң, анархистларны, билгеле. Менә син, миллионер варисы, хәзерге власть белән дә тыныша алмыйсың, патша галиҗәнапләрен дә куралмыйсың. Гәрчә ул заманнарда сезнең халык әле типтереп яшәсә дә.

— Халык дигәндә татарны күздә тотмыйсыңдыр бит? Минем халкымны дәүләтеннән мәхрүм итте ак патша. Диненнән, теленнән яздырырга маташты. Ә мин — милләтпәрвәр затлардан, Дмитрий. Тарихтагы барча империяләрнең җимерелү сәбәбе бер дип беләм: ул — милләтләр язмышына битарафлык. Ак патша утырамы тәхеттә, кызыл патшамы — һәр заманда аның баш өстендә милли мәсьәлә дигән авыр балта эленеп торачак. Рәсәйне халыклар төрмәсе дип, большевиклар башлыгы бик дөрес әйткән. Мин дә нәкъ шулай уйлыйм.

— Алай булгач, Әнвәр, син большевик икәнсең бит! — Митьканың саргылт тешләре ырҗаеп күренде. Алар да сине юксыналардыр, ә?!

— Большевикларның милли сәясәте әлегә кызыктырмаслык түгел. Әгәр сүзләрендә торып, татарга да үз дәүләтен тергезү мөмкинлеге бирмәсләрме!.. Миллионер Савва Морозов кебек янчыкны чишеп, беркадәр ярдәм итеп тә булыр иде аларга...— Әнвәр торып бүлмә буенча йөренә башлады. Тәрәзә каршысында туктап, авыр гына көрсенде.— ...Әмма бөтен бәла шунда: хәзер инде алар авызыңнан өзеп биргәнгә генә канәгатьләнер төсле күренмиләр. Бугазыңа басып җаныңны алыр кебек кыланалар. Ә минем әле яшисем килә. Хәер теләнергә каласым да килми. Гомумән, большевиклар безне бик каты итеп төп башына утыртырлар дип куркам.

Шул чакны Сабадырев та корт чаккан кебек сикереп торды:

— Син акыл иясе, Әнвәр әфәнде! Большевиклар да, бүтән власть та адәм баласының иңенә утырып аны эшкә җигәр өчен генә яратылган. Шуңа күрә без: «Яшәсен анархия-анакай!» — дибез дә бит инде. Янчыгыңны бераз чишсәң, Махно атакай янында беренче кеше булыр идең, ә?! Ул бит синдәй зирәк кешеләрне зерә дә ярата...

Апанаев, аны ишетмәгән дә кебек, тәрәзәдән тышка карап, уйланып торды.

— Янчыкны яңадан тутырабыз аны. Җиңеп кенә чыгыйк менә...— дип куйды Митька, аның тынып калуын үзенчә аңлап. Ул хәзер, үз алласына дүндереп йөрүче миссионер сыман: «Дөньяда иң хак дин — анархизм!» — дип кычкырырга әзер иде.

Ниһаять, Апанаев тәрәзәдән күзен алды.

— Мондый давыллы чорда сәяси тормыштан читтә каласым килми килүен...— Ул хәзер үзен бераз артистларчарак тота иде.— Шулай да бер уйлаган уемнан кире кайтырга исәп юк: чит илгә — Франциягә яисә Төркиягә китәм, боерган булса. Ризыгым шул тарафка тартадыр инде.

— Ә-ә-әй,— дип сузды анархист, өметен өзеп.— Атаң юлыңнан китсәң...— «...синең дә башың бетәр әле!» — дип ычкындыра язды, әмма ниндидер могҗиза белән генә тыелып калды: —...күмелгән маллар Совет кесәсен тишәсе икән,— дип очлап чыкты.

Киңәш-уңаш итүнең нәтиҗәсе икенче көнне үк сизелә башлады. Апанаев ниндидер юллар белән Серадовтан сораган, ә тегесе «Амур» мөсафирханәсендә очрашу билгеләгән иде.

Әнвәр белән Митька сүз куешкан сәгатькә килеп, «Амур» вестибюлендә байтак вакыт таптанып тордылар,— Серадов күренмәде.

— Вәгъдәле кеше ул Алтынбай; бер-бер хәл килеп чыккандыр,— дип пошаманга төште Апанаев.

Көтеп-көтеп тә килмәсе аңлашылгач, кайту юлына борылдылар. Ишектән чыгу белән, урамның каршы ягында басып торган Серадовны күреп алдылар.

— Анда буш урын юк икән, мин белештем инде,— дип кычкырды Серадов урам аша.— Әйдәгез, «Совет»ка барып карыйк. Моннан ерак түгел ич...

«Күзәтеп торган, карт төлке...— Хурланудан Сабадыревның йөзенә кызгылт тимгелләр бәреп чыкты.— Янәсе, без «койрык» ияртеп килмәгәнбезме. Ул гынамы әле, чекадагы чуртаннар авызына безне җим итеп ташлап каравы бу!»

Серадов исә, берни булмагандай, кул биреп күреште:

— Әзрәк эз яздырыгыз да, «Пассаж»га килегез. Мин сезне анда көтәрмен...

«Пассаж»да ул аерым бүлмә сөйләшеп куйган икән. Өстәлләр ризык-нигъмәттән сыгылып тора. Эреле-ваклы шешәләр гаскәр кеби тезелгән... Бәллүр кандил, алсу ефәк тартылган стеналар бу бүлмәнең дәрәҗәле-затлы әфәнделәр һәм асыл сөякле ханымнар өчен генә икәнлеген искәртә.

Сабадыревның әлегә кадәр мондый муллык, купшылыкны күргәне юк иде,— гаҗәпләнүдән үзе дә сизмәстән сызгырып куйды. Әйе, монда кергәч, ничәнче гасырда, кайсы патша хакимлегендә яшәвеңне дә онытасыңдыр. Халык хәерчелектән иза чиксен, бетсен, кырылсын,— биредә утыручыларның бер төге дә селкенмәячәк.

Табын уникe авызга исәпләнгән иде. Бүлмәгә җыелган халык та шул чама булып чыкты. Барысы да тезелешеп утыргач, күлмәгенең изүе бик тирән итеп уелган бер чибәр кыз Сабадырев белән янәшәдә генә булып чыкты. Әлеге — пәри затмы, адәми затмы — яшел мут күзләрен тутырып аңа карап-карап куя, бүлмәдә тыны

кысылгандай, тирән-тирән сулыш ала, мул күкрәге изүеннән ташып чыгардай булып күтәрелә иде. Бүтәннәр лабыр-лабыр сөйләшкәндә, бу кыз бала — ханыммы, туташмы — бит очларын ут яндырып үзалдына карап утыра: сүзгә катышмый; ризык-хәмергә дә оялып кына сузыла шикелле. Дөресен әйткәндә, Митьканы да ниндидер оялчан бер хис били: күршесендәге кызга ул туры карарга да кыенсына, аның күлмәк уентысын, яисә күкрәк тутырып сулыш алуын да, күрүдән бигрәк,— тоеп әсәрләнә... Әмма шул тарафтан килгән хушбуй исенә хәтле җанны кытыклый, тәнне йомрыландыра, Сабадыревның бөтен әгъзаларына киеренке ләззәт бирә, барча күзәнәкләрен аягүрә бастыра иде. «Затлы нәселдән килүче ак тәнле, пакь тәнле кыз булыр бу!» — дип уйлап алды Митька, әле һаман да күзен күтәреп карарга кыенсынып. Анархистлар башкаласы Гуляй-Полега алып китәсе иде бу кыр кәҗәсен! Хәтта Махно атакай үзе кызыгып, күзләрен яндырыр иде...

Рәттән берничә рюмка төшергәннән соң гына Сабадырев башын күтәреп тирә-ягына күз төшерә алды, өстәл тирәсенә сырышкан кешеләрнең күбесен беренче мәртәбә күрүе иде аның. Көнбагыш эшләпәсе төсле балкыган бу йөзләрнең кояшка таба борылгандай Серадовка багынулары да беренче карашка бик сәер-гаҗәп тоелды. Икенче мизгелдә, әлбәттә, аларның күбесе Алтынбайның тән сакчысы яисә аның бандасындагы «оҗмах егете» булуы аңлашылды. Бу табында бөтен кунаклар белән идарә иткән, үзе теләгәнне сөйләп, үзе теләгәнчә кыланган адәм — шул Серадов кына икән ләбаса. Үзен азмыкүпме ирекләрәк хис иткән янә берәү бар: анысын Әнвәр Апанаев дип беләбез булса кирәк. Ә янәшәдә утырган сылу — бармак очларына хәтле дәрт дулкыны йөгерткән хур кызы... Йа хода! Болай гына танырлык та түгел: теге көнне Апанаев белән әҗе-гөҗе килгән Флора туташ икән бит ул! «Флора туташ!..» — дип типте Митьканың йөрәге. «Теге көнне бу кадәр дә оялчан түгел иде...» — дип уйлап алды.

Шул вакыт бүлмәгә метрдотель керде: «Кайнар ашны кайчан китерәсе?» — дип сорады. Аннары, сүз арасында гына, беренче катта — «Москва» кафесында буыннарны яздырып, биеп алырга мөмкин икәнлеген искә төшерде. «Бар иде заманалар: шәраб алып килгән шикелле, музыканы да аерым номерга чакыралар иде...» — дип көрсенгән булды.

Флора белән Сабадырев, оялчанлыкларын җиңеп, бер-берсенә караштылар, сүз куешкандай, икесе берьюлы урыннарыннан торды: биюселәре килә иде.

— Әфәнделәр! — Серадовның тавышы нәкъ менә аларны кисәткән кебек яңгырады.— Әфәнделәр! Бик озакка югалмавыгызны үтенәм. Табындагы нигъмәтләр суына!..

Ишектән чыгып барганда гына, кемдер Митьканың җиңеннән тотып алды, Апанаев икән:

— Ул хатын белән саграк бул. Ыштансыз калуың бар...— дип пышылдады.

Сабадырев мыскыллап йөзен чалышайтты, бер кәлимә сүз дә кайтармыйча, Флора артыннан ашыкты. «Җүләргә чутлый бугай! — дип эчтән генә ярсыды ул.— Асыл кошны аягыннан әләктергәнгә эче поша. Теге юлы үзе булдыра алмагандыр да...»

Залда алма төшәрлек тә урын юк, пеләш башлар, купшы чәчләр өстендә зәңгәр болыт булып тәмәке төтене эленеп тора иде. «Түбәләре ялтырый, ә үзләре яшь кәҗә тәкәсе кебек кыланалар...— Сабадырев аларга карап шулай уйлап алды.— Матур кызларны, тән җылыткыч итеп, карт күкрәкләренә кысыпмы кысалар... Күбесе офицер халкына охшаган. Куркак-тәкәббер чырайлары, уклау йоткандай буй-сыннары әллә кайдан кычкырып тора. Болар монда яшен ут-

кәргеч төсле — чека берне китереп орсын әле, дип, үзләре чакыра. Алар өстенә җыелган болыттан бүтәннәргә дә чаткы чәчрәмәс дип кем әйтә ала!»

Шул уй Сабадыревның баш миенә шырпы булып кадалды. Соңгы вакыттагы бәла-казалар аны бүрәнә аша бүре күрергә өйрәтеп киләләр иде инде. Бераз биегәч тә, Флораны өскә, табын янына әйдәде Митька. Кыз күндәм булып чыкты — кире беткән Тоська түгел иде инде! — бер сүз дә каршы әйтмичә, ап-ак, тип-тигез тешләрен күрсәтеп елмайды гына. Ул озын кара керфекләр, ул матур яшел күзләр анархистның йөрәгенә ут салды.

«Фәрештә... фәрештә...» — дип кабатлады Митька үзалдына. Нәсел-нәсәбе хакында сорашканда, кыз үзенең борынгы морзалар нәселеннән — Тенишевлар ыруыннан икәнен әйтте. Теләндә тамчы да татарлык сизелми сизелүен, әмма йөзендә шәрекъ кызларына хас чалымнар бар шул, бар! Сабадырев бөтенләй башын югалтты. «Морза кызы, димәк! Княгиня! Шулай дип уйлаган идем мин аны! Муеныннан килгән затлы ис кенә дә княгиня икәнлеген әйтеп тора! — дип үз-үзен ышандырды Митька.— Ярабби, язмыш үзе аны миңа бүләк итә. Бу инде Тоська гына түгел. Печән чүмәләсендә аның да тиңдәше юк иде югын... Әмма менә кайларга менеп кунаклады абзагыз! Княгинялар өстендә эшләү бәхетенә иреште!»

Сабадырев озата барырга рөхсәт сорады. Кыз баштарак ялындырган төсле иде, аннары ачыграк итеп әйтте:

— Монда Петербург яисә Мәскәү түгел инде анысы... Мине белүче дә юк диярлек. Шулай да кешедән яхшысынмыйм. Оялам...

Аракы пары Митькага шактый кыюлык өстәгән иде: ул әрсезләнә төшеп, кыз янында берәр сәгать кич утырырга ук нияте барын белгертте.

— Ярый инде алайсам... Чирек сәгатькә булса да ризалашмый булмас. Берәр чынаяк кофе эчәрбез,— диде кыз, авызын уймакландырып.

— Биш кенә минутка...— дип кайнарланды Сабадырев, аның кулына үрелеп.— Кайда очрашабыз?

— Кичке унбердә... Шамов шифаханәсе артына килегез. Аллея башында көтеп торырсыз.

— Хезмәтчегез каршы алырмы?

— Юк, сезгә үзем каршы чыгармын...— Флора тешләренең аклыгы белән янә күзне чагылдырды. Аның көлүе назлы-дәртле дә, бер үк вакытта балаларча беркатлы да иде.

«Җир йөзендә күзгә күренеп йөри торган бер фәрештә булса, ул, мөгаен, княгиня Флора булыр иде».— Кызны җитәкләп табын янына кайтканда, шундый уйлар җылытты Митьканың күңелен.

Ә мәҗлес кызып кына килә иде әле. Сабадырев утырырга өлгермәдә, аны Серадов кул ишарәсе белән, үз янына дәшеп алды.

— Казанның җир асты юллары белән кызыксынасыз икән...— диде ул, нигәдер читкә карап.— Бик четерекле мәсьәлә кузгатасыз, асыл егет. Әмма сезгә тагын бер игелек эшлисе килеп тора. Ул хакта бөтен мәгълүматны җыйган берәү бар... Барын бар да, ул, ач әрвах, коры рәхмәткә генә риза түгел. Бик күп сорый. Алтын белән ун мең.

Болар янына Апанаев та килеп җитте. Аңа янабаштан сөйләп бирделәр.

— Бөтен мәгълүматны да җыйган дисезме? Шулай ук микән? Кырыгалдар гына түгелме? — Күренеп тора: Әнвәр инде сатулаша башлаган иде.

«Кырыгалдар» дигән сүздән Серадов кызарып киткәндәй булды.

— Байтактан таныш без аның белән. Якташлар диярргә дә була. Губерна жандарм идарәсендә эшләде. Ә инде жандармерия кызыксынмаган-белмәгән нәрсә юк, әфәнделәр. Җир асты юллары дисәгез —

бигрәк тә. Анда бит корал, прокламация ише нәрсәләр яшерергә, хәтта типография тотарга да була. Җир асты юлы белән хөкүмәт биналарына үтеп керергә мөмкин. Әйтик, банкка! Менә шундый «ихтимал»ларны жандармерия ничек истә тотмасын! Кыскасы, җир асты юлларының ул төзегән схемасы бик төгәл булыр дип уйлыйм.

Апанаев белән Митька сүзсез калдылар. Аларның икеләнүен күреп, Серадов чын-чынлап маклер кабыгына керде, пышылдауга күчеп:

— Үзара гына әйткәндә, ул схема — бәһасыз байлык бит, егетләр,— диде.— Мондагы кайбер яшерен оешмалар ике хак түләп булса да алырлар иде. Әмма агаем хәзер андый уеннарда катнашмый.

Ул кадәр акчасы булса, Сабадырев ике дә уйлап тормас. Серадов белән теге жандарм кире чигенгәнче, янчыгын чишәр иде. Сатулашырга, кул сугышырга өйрәнгән Апанаев исә ризалык белдерергә ашыкмады. Аннары куелган бәя дә бик кыйммәт иде бит. Каһәр, Серадов «ун мең алтын» диде дә катты, бүтән бер тиен дә төшәргә теләмәде. Алыпсатар идеме ул, әллә инде схеманы үзе төзегән яисә кулга төшергән булдымы — аңламассың. Әмма болар эзләгән нәрсәнең хәзинә ачкычы икәнлеген яхшы чамалый иде.

Ниһаять, Апанаев кулын селтәп куйды:

— Ярар, риза,— диде.— Кайчан бирә ала?

— Теләсәгез — хәзер үк... Ул үзе дә монда утыра.

— Бик хуп. Бирсен.

— Акча алдан йөри...

— Ул хәтле алтынны!.. Бу заманда!.. Кем инде кесәсенә тыгып килсен...— дип югалып калды купец.— Иртәгә иртүк...

Серадов ике кулын кесәсенә тыкты.

— Алайса, әфәнделәр... гафу — иптәшләр... сезнең белән бер-ике көннән күрешәбез.— Ул беркавым уйланып торды, аннары өстәп әйтте: — Мин сезне үзем табармын,— диде.

Өстәл янында бераз утыргач, Митька белән Флора янә күзгә-күз караштылар... Кафеда халык шулхәтле күбәйгән, бу юлы аларга ишек төбендә генә биергә туры килде.

Кафедагы мөхтәрәм җәмәгать шактый ук кызып өлгергән. Оятсыз итеп сүгенгән тавышлар да ишетелгәли. Якындагы өстәлләр сәяси темага бәхәс-ызгыш кузгатып җибәрде. Янәсе, Россиядә кем хакимлек итәргә тиеш тә, илнең киләчәге нинди булырга тиеш? Бер өстәл тирәсендәгеләр хор белән:

— Уч-ре-ди-тельное соб-ра-ние! — дип кычкыралар. Икенчесеннән күзләре тонган бер ир-ат торып баса:

— Пүчтәк! Безнең Рәсәй халкы демократиягә күнекмәгән, ә дөресен әйткәндә, җитлекмәгән әле. Император кирәк, әмма Петр Беренче кебек акыллы булсын!

— Әй сез, капкорсаклар!..— Күрше өстәлдәге матрос урыныннан күтәрелергә маташа, әмма, биленә авыр таш бәйләп куйган кебек, кузгала алмый, бөтен гәүдәсе белән алга таба авыша гына.— Яле, туктатыгыз мунчала чәйнәүне! Рәсәйдә һәм бөтен галәмдә анархия хакимлек итәчәк. Калганнар барысы да — чүп савытына!

Аргы баштан кайсысыдыр яшелле-күкле тавыш белән:

— Яшәсен большевикларсыз җөмһүрият! — дип кычкырды.

— Ходай, патшаны сакла! — Өстенә озын кара җилән кигән, ак күлмәк изүенә «күбәләк» кундырган берәү оркестр мәйданчыгына менеп басты.— Уйнагыз әле «Боже, царя храни»ны. Һәркайсыгызга берәр алтын тәңкә!

Музыкантларның берсе, уйнавыннан бүленеп кычкырды:

— Салып сөйләш, туган!

Флора кавалерын ишеккә таба тартты:

— Әйдә, чыгыйк моннан тизрәк. Хәзер бик хәтәр тамаша баш-

ланачак. Мин инде өйгә үк кайтып китәрмен. Алла сакласын!

Сабадырев аны озата бармакчы иде, әмма кыз кистереп баш тартты. Ике-өч адымга ераклашкач, килешле генә итеп кул болгады да, билен уйнаткалап тышкы ишеккә таба юнәлде.

Бая, биючеләр арасында Грязинюкны күреп калган иде Митька. Аның белән соңгы хәбәрләрне уртаклашасы килде. Әмма кире әйләнеп кергәч, Ильюшаны таба алмады, аны эзләп биючеләр арасыннан узды. Грязинюк печән кибәнендәге энә төсле югалды. Ә залда кызган ташка су сибү дәвам итә иде.

— Барысы да буш сүз, иптәш-әфәнделәр! — Юантык гәүдәле, тәбәнәк буйлы адәм урындык өстенә үк менеп баскан.— Ә-ә, республика кирәк булдымыни сезгә?! Автономия, демократия дисезме?! Бүген Рәсәй — мескен анакай — диктатурага мохтаҗ. Бөтен хәшәрәтләрне изеп-сытып бетерү өчен. Әнә, большевиклар, диктатурага таянасы икәнен шундук чамалап алдылар. Тиздән аларның диктатурасы барыбызны да сытарга керешәчәк.

— Патшаны кайтару мәслихәт! Патшаны!..— Баягы Кара җиләннең үз сиксәне сиксән иде.

— Яшәсен анархия! — дип кычкырды исерек матрос.

Алтынга сатылган оркестрның патша гимнын уйнап җибәрүе булды, әлеге матрос-анархист музыкантлар башына урындык белән тондырды. Бер таза егет шундук матросның якасыннан умырып алды. Аларны аерган булып, ике яктан да сугыш чукмарлары кузгалды. Савыт-саба чәлпәрәмә килгән, өстәл-урындык ауган-ишелгән, дөмбәсләшкән һәм сүгенгән тавышларны хатын-кыз чыр-чуы басып китте.

Ул да түгел, кафе ишегендә йолкыш кына бер ир-ат пәйда булып, әче итеп сызгырды:

— Чека!! Чека килеп җитте, әфәнделәр! Качыгыз!

Бер мизгелгә барысы да тынып-катып калды, ләкин икенче мизгелдә зал кырмыска оясы кебек кайный башлады: әле генә йөзгә-йөз килгән халык бер-берсен онытып ишеккә ташланды. Анда «ә» дигәнче бөке хасил булды. Баягыдан да яманрак этеш-төртеш, изү-сыту купты.

Кемдер тәрәзәгә урындык белән китереп сылады. Чалтырап пыяла коелды. Берничә ир-егет, тәрәзәдән чыгарга чамалап, ахрысы, шул тарафка ташланды. Идән уртасында бер ялгызы матрос-анархист кына торып калган иде. Үзен бәргәләп ташлаган ирләрнең тәрәзәгә таба йөгерүен күреп, ул кинәт бушлат астыннан наган суырып чыгарды, төзәп тә тормыйча аларның артыннан шатыр-шотыр ата башлады. Берсенә тидерде дә шикелле: ул ир тәрәзә төбеннән урамга кадалып төште. Икенчесе, моны күреп, артына борылды, ике атуда исерек анархистны идәнгә сузып салды.

Митька да үзенең котылу юлын әлеге тәрәзәдә күрде. Һәм бик вакытлы ычкынды: йортны кызыл гаскәриләр урап алганчы бу тирәдән тайган иде инде ул.

Кичерешләрдән бик нык арган булса да, Сабадыревның бу көнне матур итеп төгәллисе килә иде. Төнге унбер тулыр алдыннан Шамов шифаханәсе артына барып басты. Озак көтәсе дә булмады: төн пәрдәсенә уралып баручы аллеяның аргы башында ап-ак күлмәкле хатын-кыз гәүдәсе яктырып күренде. «Килгән! Сүзендә торган!» — дип сөенеп типте Митьканың йөрәге.

Флора, аны күрмәгән кебек, шактый еракта туктап, бер урында басып калды. Кызга каршы үзе атлаган иде, ак күлмәкле гәүдә борылып, әкрен генә кире китә башлады. Митька адымнарын эрерәк, кызурак алдырса да, аны куып ук тотмады. Шулай, күпмедер ара калдырып, оялчан егет белән тыйнак кыз шикелле, үзара сүз дә алышмый атладылар.

Калку урыннарда әле Идел ягыннан төшкән ниндидер яктылык

әсәре сизелсә дә, чокыр-ерганаклар төбендәге караңгылык күзгә сыланырдай булып куера бара иде. Митька инде аяк астын да күрми, кайсы тарафка юл тотканны да чамалый алмый: ул үзеннән берничә адымда яктырган ак күлмәккә генә йөз тота. Ике тапкыр ниндидер тирән чокыр аша үттеләр; иске коймаларга бәрелә-сугыла атладылар; ниһаять, тәрәзәләрендә ара-тирә утлар күренгән бер катлы йортлар урамына килеп керделәр. Флора барды-барды да, бер йорт каршында туктап калды, ачык капкадан эчкә үтте. Сабадырев та аңардан калышмаска тырышып, ялт кына ишегалдына барып керде. Керде... һәм — муенына кайнар беләкләр сарылганын, иренәнә кайнар сулыш орынганын тоеп, тетрәнеп китте. Шушы кыз эзенә баса-баса үзенең ник килгәнен белсә дә, хатын-кыз назына сусавы түзә алмаслык дәрәҗәгә җитеп бөтен буыннарын сызлатса да, бәхетнең бу кадәр якынлыгы аның өчен көтелмәгән бер хәл иде.

Өйгә керделәр. Флора караңгыда кармаланып ут кабызды. Шул арада да бер-ике тапкыр гәүдәсе белән аның беләгенә орынып китәргә җай тапты. Аннары елмаеп, гаҗәпләнгән төсле кулларын якякка җәеп, төнге кунакны табын янына чакырды. Ә өстәл өстендә чын-чынлап морзалар сые иде: кыздырылган боҗыр дисеңме, бал-май, һәртөрле җиләк-җимеш дисеңме... Ә каршысында татлыдан-татлы нигъмәтләр вәгъдә итеп гүзәл Флора утыра... Болар барысы да гаҗәп матур төш булып тоелды Митькага, аның бу төштән мәңге-мәңге уянасы килми иде.

...Сабадырев икенче көнне иртәнге якта гына аңына килде. Көнне-сәгатьне аерырлык ук дәрәҗәдә түгел иде әле, уянгач иң беренче тойгысы — үзенең тирән чокыр төбендә ятуына гына гаҗәпсенү иде. Тиз-тиз тормакчы, өстен какмакчы булды — башы бик каты чатнап, күзеннән утлар күренде. Кесәсен капшады: анда ни бар-булган алтыны белән янчыгы юк, бармагына ниндидер кәгазь кисәге генә ияреп чыкты. Кәгазьгә өч бармакны бергә кушып кукиш сурәте төшерелгән иде. Митьканың исенә төште: Костя Балабановның «Күк күгәрчен» бандасы үзенең корбаннарына шундый «чек» биреп калдыргалый, имеш. Янә шул исенә төште: Флора өстәлендәге гаҗәеп ризыкларга кагыла да алмый калды бит ул. Тагын да исендә калганы — Әби патша исеме язылган затлы бокал... «Мәхәббәт өчен!» дип күтәрелгән беренче тост... Ә шуннан соң... Үтер,— берни дә хәтерләми. Гүзәл Флораның затлы бокал төбенә һуштан яздыргыч порошок салганын күрми калган иде шул ул.

Сабадырев, яңа туган бозау кебек, дүрт аякланып урыныннан торды, дәрмансыз буыннарын өстерәп Печән базарына таба юл тотты. Андагы иң зур яңалык — үткән төндә чека тентү һәм облава үткәргән булып чыкты. Чокыр төбендә кунуның файдасы тиде тиюен дә, авырткан башка тагын бер тимер тарак иде бу. Митька газапланып уйланды, бу хәлләрнең очына чыгарга тырышты: чека аны каптырырга дип килгәнме, әллә Апанайнымы? Алай дисәң, нинди юллар белән Апанаевның эзенә төшкәннәр? Аның үзен кулга алганнармы, юкмы? Инде алга таба нишләргә? Серадов, вәгъдә иткәненчә, «хәзинә ачкычы»н алып килерме, килсә — аны ничек сатып алырга?..

Бу сорауларга җавап эзләрлек хәле калмаган иде Махно илчесенең: кичәге «мәхәббәт тосты»ннан тәне дерелдәп, башы ярыла, күңеле болгана иде.

Шулай да чыкмаган җанда өмет бар: Грязинюк белән Тоськаны эзләп Үтәмешев номерларына барырга карар кылды. Күңеле ул якка тартмаса да, бичарадан ничара иде бу. Ләкин юлың бер уңмаса уңмый икән: дүрт-биш көн генә элек әлеге номерлар ябылган, Грязинюк белән Тоська ниндидер бүтән сыену урыны табып, күченеп киткәннәр. «Менә хәшәрәтләр, теге көнне миңа әйтмәделәр дә»,— дип

үрсәләнде Сабадырев. Ачудан Үтәмешев йорты каршына утырып урам ташын кыйнады.

— Инде ят шәһәр уртасына ятып үләр хәл юк,— дип уйлады Митька. Тотынырга бер ботак та калмады. Өстәвенә эзгә баса-баса, чека килә... Мондый шартларда бердәнбер дөрес юл — яшерен квартирага, Жуковский урамындагы 5 нче йортка бару гына кала. Махно атакай: «Иң-иң ахыр чиктә шунда барып сыенырсың», — дигән иде бит. Күзгә мал түгел, газраил күренә башлаган икән, иң соңгы чиккә җитү шул буладыр инде.

*Хөрмәтле укучым! Романның алдагы бүлегенә күчкәнче, әйдә, бер тын алыйк әле. Минем каләмем азрак ял итсен. Синең дә күзләрең тала башлагандыр, бәлки... Сүзем озынга китеп, ялыктырмадыммы? Сабырлыгың төкәнмәдеме?*

*Маҗаралы китап язучылар җеп очын ераккарак яшереп, аның хикмәтен укучы арып-алҗып бетте дигәндә генә ачып салырга яраталар. Без андый юлга басмабыз. Казан алтыны тирәсендәге ыгы-зыгыларның ни белән төгәлләнәсе, яисә Апанаев, Костя Балабанов кебек «мәшһүр» каһарманнарның кая барып чыгасы Сиңа тарих китапларыннан да мәгълүм булса кирәк. Шулай да вакыйгаларны ашыктырмыйк. Адәм баласы үзенең күрәселәрен күреп бетерми җир йөзеннән китми, диләр. Кайнап торган казанга килеп төшкән Митька Сабадыревның башыннан үтәсе хәлләр алда әле. Тәмам эт каешына әйләнгән Ильюха белән бу ике егет язмышына юха елан булып уралган Тосканың да ниләр кичерәсен «бер алла белә». Ул йомгакны сүтү, ахрысы, алдагы сәхифәләрдә генә мөмкин булыр. Вакыйгалар агышы безнең көймәне хәзер бүтән тарафка бора. Герман Карачкысы яшеренеп яткан караңгы чоңгылларга керәсе бар...*

*Хөрмәтле укучым! Син тагын нидән канәгать түгел? Тәнен сатып көн күрүче Флоралар, азгын Тоскалар янәшәсендә гүзәл-самими мәхәббәт вакыйгаларын да күрәсең-кичерәсең киләдер, шәт. Мин үзем дә шундыйрак халәттә: болытлар арасыннан ялтырап кояш чыкканын көткәндәй, саф-кайнар хисләргә сусыйм. Гирш Ольконицкий, Шамил Измайлов кебек ир-егетләрнең сөю-сәгадәтле мизгелләрен тасвирлыйсым килә. Ләкин, нишлим, каләмем кырыс чынбарлык каршысында көчсез... Гәрчә мин әле өметемне өзмим: булыр,— якты мәхәббәт хисләренә манып язасы сәхифәләр дә булыр әле, дим...*

*«Лирик чигенеш» форсатыннан файдаланып, янә шуны да әйтепкисәтеп кую кирәк: әлегә Син укый торганы — романның өчтән ике өлеше генә булыр.* Күләмне чикләү ихтыяҗы байтак вакыйгаларны төшереп калдырырга, хәтта кайбер үзгәртүләр кертергә мәҗбүр итә. Хикәяләү җебен өзмәс өчен, әсәр каһарманнарының үй-кичерешләре тасвирланган урыннарны да шактый кыскартырга кирәк була. Бу югалтулар бөтенләй үк сизелми калмас... Шулай да, кечерәк кысага утырту гына зур манзараның асылын үзгәртә алмас дип ышанасы килә.*

*Менә шундый аңлашудан соң, мин Сине яңадан романга — унсигезенче елгы Казанга әйләнеп кайтырга чакырам...*

---

* Роман киләсе елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып тулысынча басылып чыгачак. (Ред.)

## VIII. Соңгы очрашу



Төн уртасында Кабан күле ягыннан җил кузгалды. Бик тиз көчәйде, ачык тәрәзәләрдән ургылып, өстәл өстендәге кәгазьләрне очырта башлады. Әрсез җил каршында беренче мәлгә югалып калса да, Ольkеницкий тиз үк торып тәрәзәләрне япты. Аннары идәнгә сибелгән кәгазь битләрен җыеп алды. Җиләс җил, каршысында яткан документларны буташтырса да, башны җиңеләйтеп, сафландырып җибәрде, уйларны тәртипкә салгандай булды.

Эссе, озын көн авырлыгы гына түгел, мәшәкатьле сорауларның күплеге дә баскан иде губчека рәисен. Өстәвенә Газыйм Дардиевның башына җиткәннәр диган хәбәр дә өстәлде. Теге чакта Миргазиянов Самат исеменнән чекага «сәлам хаты» язып салган ул адәмне анархистлар үтергән булса кирәк. Атышучыларның «Алаша» дип, «Азман» дип, бер-берсенә кушамат белән кычкыруларын ишетеп калганнар. Димәк, ул тирәдә тагын Мусин Фаикъ белән аның «кунак егете» кайнаша. Мусинның соңгы араларда Костя Балабанов белән этле-мәчеле яшәвен искә алсаң, Дардиевның кайсы шайтанга хезмәт иткәнен чамалау тагын да кыенлаша...

Икенче көнне иртүк Шамил Измайловны үзенә чакырып, шул хакта сүз башлады Ольkеницкий.

— Миргазияновның «чәки»гә язган хатын җавапсыз калдырганбыз бит. Болай илтифатсыз булу килешми...— диде.

Шамилнең йөзенә аптырау, сәерсенү билгеләре чыкты.

— Ничек инде... Ул иске тарихка кире әйләнеп кайтабызмыни? — дип куйды.

Губчека рәисе, егетнең аптырап калуыннан канәгатьлек тапкандай, мыек астыннан көлемсерәп, башын чайкады:

— Кирегә чигеник димим, алга таба барасы юлдан туктап калмаска кирәк. Чыннан да, әлеге хат тирәсендәгеләрнең җаны җәһәннәмгә очты. Миргазиянов, Санька-анархист, Дардиев Газыйм... Һәммәсе дә безнең күзгә чалынган бәндәләр. Шуңа күрә аларны берәм-берәм юк итә баралар да. Эз югалталар.

— Дардиев та теге хатны кемнеңдер кушуы буенча язгандыр, дисез инде?

— Нәкъ шулай. Алар барысы да әнә шул кемсәнең кулында биегән салам курчаклар гына. Курчак биетүче үзе әле дә булса күләгәдә кала...

— Немец агентын — Карачкыны күздә тотасызмы? — Шамил, уңайсызланып, аска карады: үзенең ачыгавызлык күрсәтүен оныта да, гафу итә дә алмый иде ул. «Доктор» Тряпкинны ничек җиңел генә кулдан ычкындырды бит!

— ...Шуңа күрә ике сорауга тизрәк җавап табарга кирәк,— дип дәвам итте Гирш Шмулевич.— Беренчесе: Миргазияновның Санька-анархист белән сөйләшүен кайда, кем тыңлап торган? Икенче сорау: Миргазиянов исеменнән хатны кем әйтеп яздырган?

— Хатта ап-ачык әйтелгән иде: Санька-анархист белән, имеш-тер, «Казанское подворье» ресторанында очраштык, дип... Урынын күрсәтеп тормаса да була иде бит. Күрәсең, безне эздән яздыру өчен, юри шундый «адрес» биргәннәр.

— Шулай булуына һич тә шик юк. Әмма «Казанское подворье»-ны телгә алу да, ихтимал, очраклы хәл түгелдер — минемчә, хат яздыручының фантазиясе үзе яхшы белгән ресторан тирәсеннән ерак китмәгән... Шул ук вакытта әлеге сөйләшү «Франция» номерларында булганга охшый.

— Мин дә шулай уйлыйм,— дип җөпләде Шамил.

— Ә син нигә алай уйлыйсың? Берәр дәлилең бармы әллә? — диде Ольkеницкий.

— Теге чакта бандитларның бик тиз пәйда булуы сәерсендерде мине. Әйтерсең лә кемдер аларга хәбәр салып өлгерде кебек...

— Хәбәр иясенең шул ук кунакханәдә эшләүче булуы бик мөмкин. Ә, бәлки, Санька-анархистның Миргазиянов Самат янына килүен күзәтеп, сөйләшүләрен тыңлап торган кеше дә шул үзедер?!

«Франция» номерларында кичергән халәт әле һаман күз алдында торганлыктан (сакланганны саклармын, дигән бит!). Воскресенская урамына Әскәр Хәйретдиновны да ияртеп китте Шамил.

Администратор карттан икенче каттагы бүлмәне ачтырдылар. Фойеда яисә коридорда булмаган ич инде ул сөйләшү! Һәрхәлдә, Саматның эш бүлмәсеннән дә кулайрак урын юк. Шул фикерне раслау өчен, кечкенә генә тәҗрибә үткәрү кирәк булды: Измайлов белән администратор бүлмә эчендә гәпләшә калдылар. Әскәр коридорга чыгып, ябык ишек аша аларның сүзен тыңларга тырышты.

Яшь чекист бүлмәгә әйләнеп кергәч, Шамил, сораулы караш белән, әкрен генә ияк какты: ничек ишетелә, янәсе? Әскәр, «юк, ишетелми» дигәнне аңлатып, башын чайкады.

«Такта ишек аша да ишетеп булмый икән, күрше бүлмәдәге кеше калын стена аша ничек тыңлый алсын?» — дип уйлады Шамил. Шулай да күрше номер белән ике арадагы стенаны шакып тикшерә башлады: тыңлау өчен яшерен тишек ясап калдырылмаганмы? Шикләнерлек бер ни дә табылмады.

Шуннан соң күрше бүлмәгә дә күз салырга кирәк таптылар. «Анда кичә генә Мәскәүдән килгән нindидер чиновник тора»,— дип аңлатты администратор. Кунак әле өйдә утыра икән, әмма кочак җәеп каршыларга ашыкмады. Ныгытыбрак дөбердәтә башлагач кына, түзмәде, сукрануы, мыгырдануы ишетелде:

— Кайсыгыз йөри анда? Ни хакыгыз бар?..

Чекистлар икәнен белгәч, инде бүтән чарасы калмаганлыктан, теләр-теләмәс кенә ишекне ачты.

Измайлов тиз генә аның документларын тикшерде. Чыннан да, Мәскәүдән, нindидер инспектор кисәге икән. Бүлмәдә тагын ярымялангач яшь хатын да бар, күзләрен оятсыз елтыратып, карават читенә торып утырган,— аңа күз дә салмыйча, яңадан стена шакырга кереште Шамил. Көтелгән нәтиҗә юк иде. Караватны стена буеннан этү өчен, хатынны кузгатырга туры килде. Һәм нәкъ менә шунда стенаның бала учы хәтле төше аз гына кабарып торуы күренде. Шамил, иелеп, кулы белән суккалады — идәнгә шыбырдап акшар коелды. Стенага тыгып куелган дүрткелле агач чөй ачылды. Чөй җиңел генә алына торган булып чыкты. Яңадан тикшереп карадылар: стенадагы шул чөйне алып, тишегенә колагыңны куйсаң, Миргазиянов бүлмәсендәге пышылдашу да аерымачык ишетелә икән.

Шулай итеп, сөйләшүнең «Франция» номерларында булуы, кемнеңдер аны тыңлап торып, Дардиев ярдәмендә чекага хат әвәләве дә расланды. Әмма кем эше булыр бу, апрель азагында әлеге бүлмәгә кем хуҗа булган? Бар, ачыклап кара: мосафирларның исемен теркәп баручы журнал да юк икән бит боларда. Акча кәгазьләреннән исә кайчан, ничә кеше яшәгәнен генә белеп була.

Җеп очын югалтудан гаҗизләнеп калды Шамил, чигә тамыры авырттырып тибә башлады. Батып баручы — саламга ябышкандай, администратор картка сүз юктан сүз булсын өчен генә сорау бирде:

— Бүтән номерларны да шулай, энә-җептән чыккан кебек итеп, өр-яңадан агартып торасызмы?

— Юк, шушы бүлмәне генә,— диде карт.— Ярты елга бер агарт-

мый-тәзәтми булмый шул. Бу бүлмәне тикшерү-мазар белән килгән түрәләргә, инспекторларга бирәбез.

— Күптәнме ремонт үткәрелде монда?

— Ике айлап бардыр инде, шәт...

— Шулаймыни?! Төгәлрәк белеп булмасмы?

— Нишләп булмасын. Һәр номерның исәп-хисап кәгазе бар. Шуны ачып карау белән, бу бүлмәгә ничәсеннән башлап кеше кертүләрен белешерсез...

Белештеләр: май бәйрәме узганчы кеше кертми торганнар,— димәк, ремонт әле төгәлләнмәгән булган.

Апрель аенда номер буш торган икән, димәк, анда буяучылар, осталар яисә мосафирханә хезмәткәрләре генә кереп-чыгып йөргән. Шуларның ким дигәндә берсе — стенадагы тишеккә мөнәсәбәтле адәм... «Болай булгач, шикле кешеләр даирәсе бик нык тарая, алар арасыннан берсен сайлап алу да җиңеләя бит»,— дип сөенеп уйлап куйды Шамил. Ул, нидер исенә төшкән сыман, яңадан Мәскәү кунагының ишегеп шакый башлады. Яшь хатын белән бикләнеп яткан инспектор тагын мыгырданды, авырсынып кына эчкә уздырды. Юрган астына чумган азгын күзле тәтәйне кабат кузгатырга туры килде. Бу юлы ул ярым-йорты да киенергә өлгермәгән иде, түшенә кадәр юрганга уралган хәлдә, яланаякларын чәпелдәтеп, почмакка барып басты.

Измайлов стенадагы чөйне кулына алып, әйләндереп-әйләндереп карады. Күренеп тора: хикмәтле «колак»ны әллә кайчан, бу бинаны салганда ук ясап калдырганнар, ремонт-агарту белән шөгыльләнүчеләрнең аңа һич бер кагылышы юк иде.» Болай булгач, тикшерүне кунакханә хезмәткәрләреннән башлау хәерлерәк»,— дип уйлады Шамил.

Хезмәткәр дигәннәре нибары биш кенә баш икән. Аларның да өчесе бирегә май аенда, кыскасы, «чәки»гә Самат исеменнән хат язылгач кына яисә тагын да соңрак эшкә алынган, ягъни, әлеге вакыйгага аларның һичнинди катнашы юк булып чыкты. Администратор исә шактый карт һәм колакка да саграк адәм күренә. Шулай итеп, шик-күләгә төшәрлек берәү калды: мич ягучы Хәйруллов Госман дигән кеше. Ул монда байтактан эшли, «Амур» ресторанында кыйнаш-талаш оештырганы өчен хөкем дә ителгән булган кайчандыр.

Һәм шунда көтелмәгән хәл туды: шушы көннәрдә генә Хәйрулловны үтереп ташлаганнар икән. Авылына — Әлдермешкә киткән булган. Кире әйләнеп кайтканда, инде шәһәргә кергәч, караңгы урамда башына балта түтәсе белән сукканнар. Аңына да килә алмыйча җан биргән... Дардиев үлеменнән соң бу һөҗүмнең очраклы булмавы ачык күренә. Димәк, кемдер шаһитләрне юк итәргә керешкән. Димәк, ашык-пошык эз яшерәләр...

Петропавел урамындагы бер йортта Хәйрулловның үз почмагы бар икән. Чекистлар килгәнче, анда кемдер булган, казынырга өлгергән иде инде. Фәкыйрь генә җиһаз, актарылып ташланган чүпрәк-чапрак арасында аһ итәрлек берни дә табылмады. Кыска тун кесәсеннән генә бик ваклап ертылган ниндидер фоторәсем кыйпылчыклары килеп чыкты. Кисәкләрне янәшә тезеп, сурәтне кире үз хәленә кайтарырга азапландылар. Ләкин бик ваклап теткәләнгән, җыеп алуы кыен: күмәк сурәт икәнлеге, берничә ир-ат арасында бер хатын-кыз төшкәнлеге генә абайлана.

— Мәрхүм, әлбәттә, бу фотоның кеше-кара күзенә чалынуыннан курыккан,— дип нәтиҗә ясады Шамил.— Ни өчен дип уйлыйсың?

Коридорда шыгырдый торган бер сайгак бар, ахрысы, шул ыңгырашкан саен, Әскәр әледән-әле ишеккә борылып карый иде.

— Куркып түгел, ачудан ертып ташлаган булуы да мөмкин.—

диде ул, фотодан бигрәк, коридордагы кешеләр турында уйлап.

— Хатын-кызга ачу итепме, әллә иптәшләренә үпкәләпме? — Шамил кайсы булса да бер фаразның җеп очына ябышырга тырыша, шуңа күрә Әскәрне бергәләп фикер куертырга кыстый иде.— Шулай да ул үзе фотодагы хатын-кызныңмы, бүтән берәүнеңме танылуыннан курыккандыр кебек. Күмәк фотоны үчлек белән ертмыйлар.

— Алай булуы да ихтимал,— диде Әскәр, бирешә төшеп.— Фаразан, «Күк күгәрчен» бандитлары, бер истәлек булсын әле дип, җыелышып сурәткә төшсә...

— Ә син алай үчекләшмә! — Шамил аның җилкәсенә шап итеп сугып алды. Аннары, беләгеннән тотып, ишеккә таба әйдәде.— Авыз ерып торыр чак түгел. Бу фоторәсемдә ниндидер ишекнең ачкычы булырга тиеш! Иманым камил. Хәйрулловның авылына барып килергә кирәк.

— Анда нәрсә булса да ачыкланыр дип уйлыйсыңмы?

— Һич югы, туган-тумачасыннан сораштырырбыз, белешербез. Ә бәлки туганнары, авылдашлары белән бергә төшкәндер фотога.

Җилнең кайсы тарафтан исүен шактый ук дөрес чамалаган булып чыкты Шамил. Хәйруллов Госманның авылда кардәш-ырулары байтак икән, ә төп йортта бертуган агасы яши. Энесе белән бигүк дус-тату яшәгән кебек күренмәсә дә, үлемен авыр кабул иткән. Фоторәсем турында сүз чыккач, абзый кеше каяндыр нәкъ шундый ук портрет табып килде.

— Биш ел элек Казанда төшкән иек,— диде.

Ир-егетләр арасыннан энесе белән икесен табып күрсәтте, «болары — Госманның дус егетләре»,— дип исемнәрен атады. Уртада, Госман янына басканы бер кашык су белән кабып йотарлык чибәр кыз иде.

— Һо! — дип, сурәттәге кызга соклануын яшермәде Әскәр.— Бер күрү белән гашыйк итәрлек туташ икән!..

— Башына шул сибәр марҗа җитте ис инде,— диде йорт хуҗасы, авыр көрсенеп.— Флүрә... Чын исеме ничектер, без шулай дип йөртәбез аны.

— Кеме: хатынымы, әллә яраткан кызымы? — дип сорау арты сорау тезә башлады Измайлов.— Кайтканы бармы? Кайда эшли?..

— Кайда эшли дип, кем белгән инде аны. Мин теге чакны кунакка барганда шәп кенә бер кунакханәдә эшлидер ие. Әфисиант булып... Ә безнең авылга кайтканы жук. Госман үзе дә алып кайтмый ие. Җөри торган нәстә диделәр лә аны. Ниндидер Микаил белән... Тоткан кеше жук-жугын да, ну утсыз төтен чыкмый инде, үзегез беләсез...

— Аның белән көрешү кирәк иде безгә. Ярдәм итәрсез бит? — диде Измайлов, агайга сынаулы караш ташлап.— Энекәшегезнең нидән үлүен ачыклау өчен дә кирәк бу...

— Үлгән артыннан үлеп булмый инде...— диде хуҗа коры гына. Ни өчендер күлмәгенең өске сәдәпләрен үк каптырып, урыныннан кузгалды.— Сез бу эшкә мине катыштырмагыз, җәме. Беребезнең башына җиттеләр, ярый әле аның балалары җылап калмады. Ә минем...

Абзый, чакырылмаган кунакларга каш астыннан карап, үзенең хафасын белгертергә теләде бугай. Әмма шул ук мәлдә егетләрнең таләпчән, кырыс чыраен күрде, чигенергә уйламаганнарын аңлады. Әтәчләнеп күтәрелгән иңнәре салынып төште. Тамак кырып куйды.

— Икенче тауда аның җорты. Шамов бүлнисеннән җырак та түгел. Чаттан бишенче ие бугай. Агач җорт. Нумеры исемнән чыккан.

— Адресы юкмыни? Хатны ничек язасыз соң аңа?

— Кем хат җазсын инде аңар... Хәбәрне Госман аша йөртәиек.

Баштарак Измайловка бу йомыкый агай барысын да белә, нәр-

сәнедер әйтеп бетерми кебек кенә тоелган иде. Госман турында, аның дус-ишләре хакында төрлечә сораштырып бакты, әмма абзый кеше колак торгызырлык бер яңалык та өстәмәде.

— Ике бармак арасына ит үсми, анысы хак,— диде.— Тик, әйткәнем шул: энекәш белән безнең аллабыз гына бер ие. Җук, анысы да бер түгелдер әле. Ул акча дип шашынды, матур марҗа дип шашынды. Шул марҗа киленгә карап алмасар булды. Безнең ыртак сүзебез-эшебез җук ие. Аны кайткан чагында бусагама аяк бастыруым да, бик беләсегез килсә — әнкәй васыятен үтәп кенә... Энекәшеңне ташлама, дип үлде мәрхүмә.

— Ничек алар икесе ике йортта тордылар соң? — дип сүзгә кушылды Әскәр Хәйретдинов.

— Ничек дип, җортка кергән — җукка кергән инде ул... Бер җайлашып, бер талашып тордылар бугай. Аннары тегесе куып ук чыгарган...

Шамил бу абзыйның сөялле зур учларына карап кына да, сүзләренең ихлас булуына, ни белгәнен әйтеп бетерүенә ышанды. Казанга әйләнеп кайткач, бу ышаныч тагын бер кат расланды: Суконный бистәсендә Госманның агасы әйткән йортны эзләп таптылар. Хуҗабикә үзе генә өйдә юк иде.

«Флүрә дигәннәре Костя Балабанов бандасы белән әҗе-гөҗе килә торган чибәр Флора түгелме икән?! Әгәр дә нәкъ шул фахишә булып чыкса...»— Бу уйлардан Шамилнең кинәт авызы кипте, тамагы чатнап авырта башлады.

Егетләр тирән чокыр читенә урнашып, йорт тирәсен күзәтә башладылар. Байтак вакыт узып, бер адәм заты күренмәсә дә, өметне өзәргә, кул селтәп китәргә ярамый иде. Көнозын чокыр төпләрендә яткан эңгер-меңгер текә яр буйлап өскә күтәрелә, тирәюньгә җәелә башлаганда гына, кече капка каршысына бер яшь хатын килеп басты. Үзе яланбаш, муенына чәчәкле кыекча салган.

Әскәр Хәйретдинов сикереп аягүрә басмакчы иде, Шамил иңеннән тотып калды:

— Чү, нишләвең... тукта...

Хатын капкадагы почта әрҗәсенә күз салды да, келәгә орынып та карамыйча, кире борылды.

— Менә сиңа мә!..— дип тел шартлатты Хәйретдинов.— Хуҗа үзе булып чыкмады бит әле бу. Нәрсә иснәнеп йөрүе дисәң...

— Килеш-килбәте, йөзе белән дә гүзәлләрнең гүзәленә охшамаган.— Измайлов як-ягына карап алды: күз күреме җирдә җан әсәре юк иде.— Флүрә-Флора ханым үзенең өенә күз-колак булырга җибәргәнме әллә моны?

Чекистлар, алдан килешеп куйган кебек, сүзсез генә кузгалып, хатынның эзенә баса-баса киттеләр. Хатын артына да, як-ягына да каранмыйча алга атлады, тар сукмактан үзәнлеккә таба төште. Туктап, кыекчасын башына бөркәнде, көзге каршында торган кебек, баскан җирендә бөтерелеп алды. Аннары ашыкмыйча гына каршы ярга таба күтәрелә башлады. Ул ярда да шырпы тартмалары кебек агач йортлар һәм сарайлар сибелгән иде.

Хатын кинәт еш-еш артына борылып карый башлады.

— Сизендеме икән әллә? — дип борчылып пышылдады Хәйретдинов. Югыйсә, хәзер инде хатынны ишегалларына, коймаларга ышыкланып күзәтәләр иде.

Беренче таудагы йортлар чокырның теге ярындагыдан әллә ни аерылмый икән. Хатын тәрәзәсе капкачлы бер өй каршында туктап алды, башыннан кыекчасын суырып төшерде дә, аны уң кулында җилфердәтә-җилфердәтә тагын алга атлады.

«Ниндидер хәбәр тапшырды ахрысы,— дип уйлап алды Шамил.— Тере почта әрҗәсе булып чыкты микәнни бу хатын?»

Шул вакыт якындагы бер йорттан милиционер килеп чыкты, урам буйлап алпан-тилпән атлап, туп-туры бирегә таба юнәлде. Бу — бая «Почта әрҗәсе» туктап торган өйдән чыкты, ахрысы.

— Менә тамаша! Тере милиционер! — дип пышылдады Әскәр.— Кайдан пәйда булды соң әле бу? Монда бит баштанаяк коралланган патрульләр дә борын төртергә курка, бигрәк тә кичкә каршы! Ә бу адәм япа-ялгызы, үз ишегалдында каз куып йөргән кебек, дөньяда һич гаме юк.

Милиционер, берни дә булмагандай, алар янынннан да узып китте чекистлар койма артына ышыкланып калдылар.

Урамның теге башыннан сиртмәле арбага җигелгән пар ат юыртып килгәне күренде. Милиционер янына килеп җиткәч, арбадан тагын өч адәм сикереп төште — алар өчесе дә милиция киеменнән иде.

«Уголовный розыск монда ниндидер операция үткәрә микән әллә? — дип уйлап алды Шамил, күзне бәйләгән әңгер-меңгердә милиционерларның йөзен танырга тырышып.— Алай дисәң, безгә хәбәр итми керешмәсләр иде мондый зур эшкә. Әгәр ашыгыч килеп чыккан операция булса? Ул чакта болар кызурак кыланырлар иде: туйга алданрак килгән кунаклар кебек кая барып сугылырга белмиләр ич. Нәрсәдер кыяфәтләре бик шикле. Өстәвенә йөзләре дә бөтенләй таныш түгел.

Дүрт ир-ат, үзара күңелле генә сөйләшә-сөйләшә баягы милиционер килеп чыккан йортка таба юл тоттылар. Алар ишегалдына кереп китү белән, чатта «Почта әрҗәсе» күренде. Килеп, өйнең урам ягындагы тәрәзә капкачларын япты. Бераз басып таптанып торды, як-ягына каранды, аннары әкрен генә кире китте.

— Болар нишләп йөрергә мөмкин, ә? — диде Измайлов, Әскәр ишетерлек итеп кенә.— Әгәр Флораны аулыйлар икән, анысы нинди максат белән? Чынлап та милициядән булсалар, ул ниятләре дә аңлашыла. Әмма милиция киеменә төренгән бандитлар дип уйласак... Флора үзе дә алар белән бәйле булса... Ул чакта мәсьәлә катлаулырак.

— Почта әрҗәсенә карап, теге хатын аның өйдә юклыгын белде... Ишек тоткасына да кагылып тормады...

— Безнең дошманнар ул хәтле үк беркатлы түгел, Әскәр. Әгәр Флора ханым газета-журналлар алдырса, яисә яңа көн саен хат килеп торса, бәлки, почта әрҗәсе буенча аның өйдәме-юкмы икәнен чамалап булыр иде. Шуның өстенә, мине дә күз салмагандыр дип уйлама: әрҗәдә бер кәгазь кисәге дә күренмәде. Алайга китсә, почтасын алган,— димәк, Флора өйдә булып чыга.

Әскәрнең дә бирешәсе килми иде:

— Бу шикле адәмнәр Флорага хат-мазар килмәгәнме дип тикшерәләр инде, синеңчә. Шулаймы? — дип карышты ул.

— Теге хатын почта әрҗәсенә генә караган икән, нәкъ шулай: Флорага дигән хат-хәбәр боларның барысына да ниндидер мөһим яңалык алып килә,— дип, үзенекен куәтләде Шамил.

— Димәк, бу милиционерлар Флораның кайда икәнлеген беләләр? Хәтта аның хакында кайгыртып торалар?..

— Ә нигә, шулай булуы бик ихтимал.— Измайлов кесәсеннән пистолетын алды, әкрен генә әйтте: — Болай итик, Әскәр: син хәзер извозчиклар тукталышына оч, бер олаучы белән сөйләшеп, аны бу тирәгә алып кил. Милиционерлар тарантасы күренеп торырлык төшкә туктагыз. Әнә, аларның извозчигы көтеп тора бит: озак юанырга җыенмыйлар булыр.

Хәйретдинов баш кагып куйды.

— Синең төп бурыч: аларның моннан соң кая юл тотуын белергә кирәк. Эзләреннән барганны сизмәсеннәр: исереккә салыш, исенә

төшкән җырларны рәхәтләнеп акыр. Аңладыңмы?

Әскәр, бер сүз дә кайтарып тормыйча, тәмам куера башлаган әңгер эченә кереп югалды.

«Чыннан да, ни кирәк боларга Флорадан? Әллә бәлки... Госманны юк иткәч, чират аңа килеп җиткәндер?»— Шамилне кинәт борчулы уйлар биләп алды, ниндидер фаҗига булмагае дип, йөрәге еш-еш тибә башлады. Ул тиз генә урам аркылы чыгып, каршыдагы иске йортның ачык капкасына ташланды. Милиционерлар кереп киткән өйгә кадәр әле ике ихатаны узасы бар икән. Берничә минуттан ул коймалар аша сак кына чыгып, теге йортның келәтенә барып җиткән иде инде. Борынына яңа тирес исе килеп бәрелде. Песи кебек йомшак кына басып келәтне урады, келәт почмагыннан башын сак кына сузып ишегалдына карады. Һәм шул ук мизгелдә — йөзенә кайнар пар бөркелдемени — ялт кына кире алырга мәҗбүр булды.

Келәт почмагыннан өч-дүрт адымда гына, баскыч төбендә милиционерларның берсе утыра: уң кулында наган, сул кулы белән авызына көнбагыш озатып тора. Көнбагыш чиртү белән шулхәтле мавыккан: келәт артыннан өстенә үк килеп чыккан чекистка да игътибар итми калды. «Ярый әле үрелеп кенә карадым,— дигән уй үтте Шамилнең чигәсен яндырып,— баш беткән иде югыйсә. Һәрхәлдә атыш кубар, бөтен эш пыран-заран килер иде.»

Измайлов, келәткә тоташкан койма артына ышыкланып, койма ярыгыннан ишегалдын күзәтте. Көнбагыш чиртеп утыручы агайдан тыш тагын ике милиционер өйнең аргы почмагында басып торалар, берсе әкрен генә нәрсәдер сөйли, икенчесе пырх-пырх көлә иде.

Шул чакта өйдә ут алдылар. Ишегалды ягындагы бер тәрәзәнең капкачы ябылмаган икән. Анда яшь, чибәр, таза хатынның зур көзге каршында чәч тарап торуы күренде. Биленә хәтле ялангач: яшь кавындай өрелеп тулышкан ак имиләре кулының һәр ишарәсеннән дерелдәп-дерелдәп ала... Тәрәзәгә тагын бер күләгә төшә: эчтә дә бер «милиционер» мәйханә кылә, ахрысы...

Болдыр баскычында утырган ир заты, көнбагышын онытып, муенын сузып, тәрәзәгә текәлде.

«Менә нинди икән син, гүзәл Флора... Госман белән төшкән фотодагы сурәтеңә бигүк охшамагансың. Хәер, теге чакта, Чистайда, читән арбада барганда да болай ук сылу хатын түгел идең шикелле...» Шамилнең колагына Флораның рәхәтләнеп, тирә-юньне яңгыратып көлүе ишетелгәндәй була:

— Әфәнделәр! Кичерегез, әфәндәләр! Йөз хатын турында сөйләсә дә, Мишель аларның йөзесенә торырлык бер хатынны гына күздә тота... Ул үзе дә дөньяда бер генә һәм бик бәрәгәйле ир!..

Әйе, бу шул үзе — Костя Балабанов кунакларының күңелен күреп яшәгән, немец агенты Михаил Тряпкинның һушын алган Флора. Моның шулай икәнлегенә хәзер тамчы да шикләнми Измайлов. «Каян чыгып әйтәсең?»— дисәләр, һич нинди дәлилләре юкюгын, әмма күңеле сизенә, барысының да бер җепкә теркәлгән булуын җаны-тәне белән тоя. Тик менә Флораның оясына кара карчыга сурәтендә очып килгән «милиционер»— кем ул? Юлбасарлар башлыгы Балабанов-«Әти»ме, әллә Карачкы-Тряпкин үземе?

Ул арада баскыч төбендә утырган ир-ат урыныннан кузгалды, «тфү» дип авызындагы көнбагыш кабыгын төкерде дә болдырга кереп китте. Өй почмагында торган милиционерларның берсе күрше йорт белән ике арадагы коймага таба юнәлде, ике такта башын җиңел генә читкә этәреп, койманың теге ягында күздән югалды.

«Бусы күршедә генә яши ахрысы...— дип уйлап алды Шамил.— Чибәр Флорага күз-колак булып тору өчен генә шунда килеп урнашканмы? Дөресрәге: урнашырга мәҗбүр булгандыр.»

Болдырдан борылып чыккан милиционер иптәшенә кул изәп куй-

ды. Димәк, Флораның эше беткән, хәзер инде кайтыр юлга җыеналар.

Ата мәченең өйдән чыкканын да озак көтәргә туры килмәде. Күзләргә ягыла башлаган төн караңгысында аның йөзен-чыраен күрергә тырышты Шамил. Әмма герман агенты Карачкы түгел иде бу, ниндидер ят, таныш булмаган адәм иде.

Инде чекистны биләгән уй бер генә иде: «Әскәр килеп өлгерде микән?» Милиция арбасына тагылып ук тагын бер олау кузгалганын күргәч кенә җиңел сулап куйды. Икенче олаудагы «лыгыр исерек» пассажир кабер такталарын кушып сүгенә, әллә нинди оятсыз такмаклар сибә иде. Шамил артына борылып карады: Флора өенең тәрәзә капкачлары ярыгыннан саркып чыккан ут шул мәлдә елт итеп сүнде. Алар өчен барысы да тәртиптә,— һәрхәлдә, яшь хатынның күңелен күрү операциясе төгәлләнгән иде... «Әскәрне эздән яздырып калдырсалар да, Флора аша боларның койрыгына басарбыз барыбер»,— дип уйланды Шамил.

...Губчека рәисе Гирш Олькеницкий аның хикәятен бүлдермичә тыңлады. Аннан соң урыныннан торып, тәрәзә янына китте, күн пинҗәк сәдәпләрен гасабиланып каптырды.

— Сезнең юл уңган бүген. Әйбә-әт...— Ул бүлмә буйлап йөренде.— Инде Хәйретдиновны гына көтәсе калды. Карап карыйк, нинди хәбәрләр алып кайтыр.

Әскәрне озак көтәсе булмады. Ишектән керә-керешкә, сулышы җитмәс дип курыккандай, бер тын белән әйтеп салды ул:

— Алар хәзер төрмәдә... Туп-туры шунда кайттылар. Үз кешеләре бар ахрысы. Анысын ачыклап тора алмадым. Тизрәк монда...

— Төрмәнең ишегалдына керделәрме. Әллә каравыл йортынамы? — диде Олькеницкий.

— Каравыл йортына. Аларның анда хезмәт итүләре дә мөмкин...

Губчека рәисе өстәл тартмасыннан маузерын тартып алды:

— Йөзләрен таныйсыңмы?

— Икесе бик ачык булып күз алдымда тора. Берсен, мөгаен, аера алмам...


...Берничә минуттан кызыл гаскәриләр төялгән йөк автомобиле, төчкерә-төчкерә, шәһәрнең борынгы үзәгенә таба юл тота иде.

Казан суының биек сул ярына император Александр I заманында ук салынган төрмә янына килеп туктадылар. Кешеләрне Олькеницкий үзе таратты. Шамилне, гаскәри егетләрнең бер төркеме белән, тышкы стенаны сакларга калдырды. Әскәр Хәйретдинов белән берничә сугышчы, губчека рәисенә ияреп, төрмә капкасына таба атладылар.

Ярымкараңгылыкка чумган төрмә ишегалдында саташкан күләгәләр биешә. Төнгә каршы күтәрелгән җил манаралардагы фонарь утын шулай чайкалдыра, ишегалдындагы күпсанлы корылмалар арасында адаштырып йөртә. Сыңар агач та үсмәгән бу төксе мәйдан әлеге салкын күләгәләрдән тагын да авыррак, шомлырак төскә кергән. Әйтерсең лә, ходай үзе бу төшкә каһәрле тамгасын салып куйган.

Каравыл йортының ишеге төбендә торган сакчы агай чекистларны бер дә өнәмичә каршы алды, шәхес таныклыкларын, энә күзләгәндәй, җентекләп-нечкәләп карады, бик шикләнеп, теләр-теләмәс кенә эчкә уздырды.

Таш идәнле тар коридор кызыл гаскәриләрнең ашыгып атлаган итек тавышлары белән тулды. Иң алдан баручы Әскәр Хәйретдинов дежурлар бүлмәсенә күз салды. Калын тимер рәшәткә белән бүлеп алынган бу чоланда балта әлеп куярлык төтен: биш ир-ат, бишесе бер булып тәмәке төтәтә-төтәтә, кәрт сугалар иде. Аяк очларында ук төрле кием-салым белән тулы ике ачык чемодан ята. Күренеп тора:


А. Тимергалина рәсеме

шул чүпрәк-чапракка очко уйныйлар болар. Бәлки, таланган малдыр әле. Кәрт сугучыларның берсен Әскәр шунда ук танып алды: болдыр баскычында көнбагыш чиртеп утырган, чибәр Флораның ап-ак имиләренә карап иреннәрен ялаштырган агай иде бу.

Гаскәриләр белән чекистларның пәйда булуы әлеге биш борын өчен һич көтелмәгән хәл булды: берсенең кулындагы карталары идәнгә коелды, икенчесенең авызыннан утлы тәмәкесе төшеп китте.

Хәйретдинов боларның югалып калуын да, чүпрәк-чапрак тулы чемоданнарын да күрмәмешкә салышты. Хәлләренә кергән тавыш белән:

— Җегетләр, сез монда тотенгә булыгып үләрсез ич! — дигән булды.

Куркыныч төштән айнымый торган кебек, ирләрнең йөзендә мәгънә әсәре сизелми, авызлары сүз ясый алмый, күзләре чакырылмаган кунакларга карап каткан иде.

— Исемең ничек соң синең, әй? — диде чекист, «көнбагышчы» агайның җилкәсенә кагылып.— Якыннанрак танышасы иде бит. Әйдә, чыгып сөйләшик әле.

Тегесе урыныннан торды, чалбар төймәләренең каптырылганмыюкмы икәнен тикшергән төсле хәрәкәт ясады, аннары, аякларын картларча лыштырдатып, чыгу юлына юнәлде. Шунда гына аның калган иптәшләре дә, кинәт уянып киткән сыман, ыгы-зыгы килә башладылар. Чемодан бикләре шылтырады, урындыклар урыныннан күчте, дагалы итекләр чык итеп таш идәнгә бәрелде.

Коридорга чыгу белән теге милиционер да исенә килгәндәй булды:

— Нәрсә бар? Нигә кирәгем чыкты?..

— Сабыр, гражданин милиционер, сабыр! — диде Әскәр, берни булмагандай тыныч кына,— хәзер барысын да ачыкларбыз. Һәммәсе дә көн кебек ачык булыр хәзер...

Нәкъ шул мәлне, аның «көн кебек ачык» дигән сүзләреннән мыскыллап көлгән шикелле, төрмәдә ут сүнде. Янәшәдә басып торган милиционер камчы белән китереп органдай, юлында очраган бар нәрсәне аударып-җимереп, караңгы коридор буйлап йөгереп китте. Әскәр, аяк тавышлары буенча, аның кайсы якка йөгерүен чамалап, берничә сикерүдә куып тотты, бәреп екты, әмма үзе дә таеп китеп, таш идәнгә барып төште. Ул арада теге адәм сикереп торып, икенче якка йөгерде.

Шул чакта төрмәдәге караңгы тынлыкны телгәләп, төрле тарафтан ут чәчрәде — аткан тавышлар ишетелде. Ә дигәнче токкыннар уянды. Астан да, өстән дә ярсулы шау-шу күтәрелде, тимер ишекләрне котырынып кыйнау башланды. Кыргый акырыш-бакырыш арасында аерым сүзләрне генә аерып аңлау мөмкин иде:

— Безнекеләрне үте-рә-ә-әләр!!! Туганна-ар!! Үтерә-ә-әләр!!

Атыш бер мәлгә тагын да көчәеп алды, әмма аннары, тоткыннарны тынычландырырга теләгәндәй, басыла төшеп, берән-сәрән генә ишетелә башлады.

Шушылай тынычлана төшүдән файдаланып, Хәйретдинов кычкырды:

— Төрмә чолганышта калды! Бирелегез! — диде.

Аның тавышы килгән якка шарт-шорт килеп бер-ике якты сызык сызылса да, атышу туктап калды.

— Берәм-берәм чыгарга! — дип әмер бирде Әскәр.— Тиз булыгыз!

— Бирeләм, туганнар! Бирeләм! — ниндидер изелгән, өзек-өзек тавыш иде бу.— Бер катнашым да юк минем монда! Мин монда...

— Чекистларга сатыласыңмы, тугач та эт ялаган нәрсә! — Караңгы почмактан кемнеңдер калын усал тавышы килде.— Моның өчен, беләсеңме, нишләтербез сине...— Шунда ук берәттән әллә ничә ату тавышы яңгырады.

Яңадан уңны-сулны белештерми атышу башланды. Ике яктан да шәһитләр һәм яралылар бар иде инде. Бандитларның көче бетеп килә дигәндә генә, икенче каттан ут ачтылар. Инглиз кул пулеметыннан сиптерәләр иде. Барысы да ишек яңакларына сыенырга мәҗбүр булды, кайсыберләрләре ишегалдына ук сикереп чыкты.

Шулвакыт биек төрмә диварының аргы ягыннан да берән-сәрән мылтык шартлаткан тавышлар килде. Бандитларның берсе сакчы манарасыннан бау баскыч төшереп, ничәдер талпынышта җиргә сикергән һәм яр астына таба йөгергән иде.

— Тукта! Атам! — дип кычкырды гаскәри егет.

Тегесе, төн караңгылыгына кереп чуму өчен, тагын да җәһәтрәк элдертә башлады. Әлеге сугышчы белән Измайлов аның әзеннән ут ачтылар. Качкын борылып та, төзәп тә тормыйча ата-ата ераклаша барды. Ләкин шул мәлне, нәрсәгәдер сөрлеккән кебек, җиргә егылды һәм сөзәк яр битеннән тәгәрәп китте. Пуля аның тез буынына тигән булып чыкты. Ямьсез сүгенә-сүгенә, соңгы патроны беткәнче атты бандит. Аны шуннан соң гына кулга төшерә алдылар...

Төп бинада атыш тәмам кызып җиткәндә, Гирш Олькеницкий пәйда булды. Каравыл йортында белешеп өлгергән иде инде: ул мондa Балабанов һәм аның кешеләре кереп оялаган икән. Чекистларның килеп чыгуы алар өчен һич көтелмәгән хәл, әмма каршы торырга көчләре дә, кораллары да җитәрлек булса кирәк.

Караңгы коридорда пулемет уты көлтә-көлтә очкын булып чәчри, алга таба үтү юлын кисеп, күзне әчетерлек якты буран уйната.

Ут көлтәсе бер читкәрәк авышып, уң як стенага килеп сыланган мәлдә, Олькеницкий тәвәккәлләп коридор буйлап ыргылды. Аның артыннан гаскәри егетләрдән дә берничәсе сикереп, шунда ук пулеметка каршы атарга керештеләр. Коридор караңгылыгын парә-парә китергән якты буран кинәт сүнеп калды. Өске каттан кемдер:

— Биреләбез! Атмагыз! — дип кычкырырга өлгерде.

Коридорның аргы башыннан да:

— Атмагыз! — дип тавыш бирделәр.

Кемдер әмер биргәндәй, атышу берьюлы туктап калды. Бу ярсу бәрелеш вакытында үзләрен тәмам онытылганга санап, тоткыннар да тынычланганнар иде инде. Һәм кинәт шул тынлыкны кыска гына ачы аваз телде:

— А-а!!!

Капчык кебек дөп егылып төшкән гәүдә тавышы ишетелде.

— Ут! Утны кабызыгыз! — дип кычкырды Олькеницкий.— Тизрәк!..

Ут кабынды. Шундагыларның һәммәсе күрде: тимер баскыч төбендәге мәйданчыкта өске каттан чәчрәп ир-ат йөзтүбән җәелеп ята, сулышы өзелгән. Баш очында ук — кул пулеметы да... Күз алдында коточкыч күренеш ачылды: коридор буйлап үле гәүдәләр сибелгән, яралылар ауный...

Яралы ике бандит шунда ук корал ташлап, җиңүчеләр хөкеменә буйсыну белгерттеләр.

Олькеницкий, эшне озакка сузмыйча, мәетләрне тану оештырды. Әскәр алар арасында «иске» танышын абайлап алды. Әле генә ярсыйярсый кәрт суккан бандит үз башына уйнаган икән: пуля аның күзен тишеп кергән.

Бау баскыч буйлап качарга маташкан адәмне дә тотып кайттылар. Ул тезе авыртуга түзә алмыйча сыгылып төшкән, әмма күзләрендә әле дә булса бүре уты яна. Баскыч янында йөзтүбән яткан бандитны күрү белән, ачыргаланып:

— Әти! — дип акырды.

Яралы ике «милиционер» да аның сүзен раслап баш кактылар. Ләкин Константин Балабановның үле гәүдәсен чалкан әйләндергәч, бандитларның берсе әллә ничек агарынып, аптыраган кыяфәткә керде. Ольkenицкийның үткен күзләре, әлбәттә, моны сизми калмады. Шунда ук «Эти»ның пуля тиюдән һәлак булмавы беленде. Күкрәк авызында батырып кадалган хәнҗәр сабы тырпаеп тора иде.

Гирш Шмулевич һич көтелмәгән карарга килеп, Әскәрнең беләгеннән тотып алды:

— Хәйретдинов... беләсеңме...— тиз генә як-ягына каранды,— хәзер үк ачыкла: кайсы камераның ишеге биктә түгел икән? Әмма үзең сак кыйлан! Иң яхшысы: камераны бикләп ал.

Берничә минуттан, итекләре белән тимер баскычны дөбердәтә-дөбердәтә, Хәйретдинов әйләнеп тә төште.

— Унберенче камера, икенче катта... Чынлап та ачык иде бит, әй!...

— Кем булса да бармы анда?

— Әйе, ниндидер мужик, алагаем зур гәүдәле. Бөтен тәненә инә белән чәнчеп сурәт төшерелгән.— Әскәрнең йөзендә сәерсенү чагылды.— Шул үзе Балабанов булыр микәнни? — диде ул, эшнең нидәлеген сизенә башлап.— Үз урынына тоткынны чалып ташлады микәнни?

— Шулай булырга охшаган.— Ольkенецкий үзенең егетләренә, уяурак торыгыз, дигәндәй бер ым кагып, икенче катка менеп китте.

Шул ук мәлне, аның каршысында, җир астыннан калкып чыккандай, надзиратель пәйда булды. Ольkеницкий пенсне аша кырыс карап, аны туктатты:

— Нишләп камераларыгыз ачык?

— Алла сакласын! — диде төрмә хезмәтчесе, каушап.— Булуы мөмкин түгел! — Сүзләренең хаклыгын расларга теләгәндәй, кулындагы ачкычлар бәйләмен шалтыратып алды.— Әле атыш-суеш башланыр алдыннан гына бөтен ишекләрне бер карап чыккан идем.— Карт, куркынып, муенын аска бөкте, аркасында бөкре хасил булды.

— Унберенче камерада кем утыра?

— Бик кансыз бер бәндә шунда, төзәлүдән узган сугыш чукмары. Исерек чагында, кулына кем килеп эләксә, шуның муенын бора. Иволгин фамилияле.

— Ничек соң: хәзер дә анда... ул утыра дип уйлыйсыңмы?

— Ә бүтән кем булсын?! — Надзиратель аяк астын кашып алды, күзләрен челт-мелт йомгалады.— Гомер буе шунда эшлим: тоткыннарның бер камерадан икенчесенә күчкәне юк әле.

Ольkеницкий бу табышмакның җавабын җиңел генә чишәргә чамалаган иде. Аның уенча, соңгы почмакка китереп кысылгач, Балабанов башын саклап калу өчен бердәнбер мөмкинлектән файдаланган: тоткыннарның берсе белән киемен алышкан, аннары аны үтереп, баскычтан ташлаган; тагын да ышандырырлык булсын дип, мәрхүмнең куенына пулемет тыккан; ә үзе җайлап кына унберенче камерага — әлеге тоткынның урынына кереп утырган. Шуңа күрә әлеге камераның ишеге бикләнмәгән булырга тиеш иде. Чөнки ишек тышындагы тимер бикне шудырырга кем дә юк. Надзиратель халкы бу мәхшәрдә тараканнар кебек ярыкка кереп качу ягын караган.

Ләкин... чама-чамага туры килми булып чыкты.

Унберенче камераны, чыннан да, әлеге сугыш чукмары Иволгин биләгән иде.

— Әйттем бит...— диде надзиратель, җанлана төшеп.

Губчека рәисе үз янына килеп баскан Әскәргә карады: син, янәсе, берәрсе белән бутамадыңмы, хаталанмадыңмы?

— Шушы камера ачык иде, нәкъ үзе инде...— Яшь чекистның тавышында үпкә, рәнҗү сизелеп китте.

— Бикләнми калган бүтән камералар да булдымы әллә? — диде Ольконицкий, үзе дә аптырый төшеп.
Хәйретдинов, төшенке кыяфәт белән башын чайкады:
— Барысын да тикшереп чыктым, Гирш Шмулевич.
Төрмә башлыгы килеп җитте.
— Моннан чыгу өчен башка ишек-тишек яисә яшерен юллар юкмы? — дип каршылады аны Ольконицкий кырыс кына.
Теге адәм хәрбиләрчә кыл булып тартылды, казармада кизү торучы солдат кебек кычкырып җавап бирде:
— Һич тә юк!
— Сезнең канат астына ничек итеп бандитлар сыенганын соңыннан тикшерербез,— диде губчека башлыгы.—Әйдә, унберенче камера хуҗасын үзегез тентеп күрсәтегез әле.
Тоткынның чүпрәк-чапрагы арасыннан тимер кисә торган пычкы табып алдылар. Бераз ык-мык итеп торса да, Иволгин дөресен әйтергә мәҗбүр булды. Күрше камерадагы таныш түгел мәхбүс биргән, имеш, пычкыны. Берничә минут кына элек. Аның камерасын тыштан бикләргә булышкан өчен.
Хәйретдинов уйлап-нитеп тормастан әлеге камера ишегенә ташланмакчы иде. Ольконицкий аның шул омтылышын сизеп, туктатып калды:
— Чү, Әскәр, ашыкма. Башыңны югалтырсың. Балабанов хәзер — тозакка эләккән бүре белән бер ул. Кулыңны сузсаң, чәйнәп ташларга да күп сорамас. Аннары, исән килеш кулга төшерү кирәк ул бүрене. Бары тик исән килеш!
Губчека рәисе кул ишарәсе белән генә надзирательне үз янына чакырды. Теге тикшерү сылтавы белән, күрше камерага күз салырга кушты. Кыскача гына киңәшен дә бирде:
— Саграк кыланыгыз. Без килеп кергәч, атарга яисә пычак белән кадарга маташуы мөмкин. Ирек бирмәскә тырышыгыз,— диде.
Шулайрак булып чыкты да. Камерага чекистлар килеп кергәч, «Эти» шундук эшнең нидә икәнен аңлап, куеныннан кечкенә «дамский» браунинг суырып алды. Ләкин надзиратель, үзенчә бер осталык, җитезлек күрсәтеп, аның кулындагы коралны күз ачып йомганчы бәреп төшерде.
— Кирәк түгел, Костенька. Ташла,— дип юмалаган-юаткандай итеп, әкрен генә әйтеп куйды төрмә хадиме.— Син оттырдың. Инде оттыргансың икән, башыңны ия бел.
Балабанов ерткыч җанвар тавышы белән улап җибәрде, кыргый бер талпынышта надзирательнең бугазыннан эләктереп алды. Ә тегесе, төрле алымнарны күрсәтүче көрәшче-тренер сыман, һич тә каударланмыйча гына, йодрыклары белән кисеп тегенең кабыргасына орды һәм икенче селтәнү белән касыгына берне тондырып, бандитны аяк астына бөгәрләнеп төшәргә мәҗбүр итте.
Коська Балабановның кулларын артка каерып, кесәләрен тентеделәр, икенче пистолетын да табып алдылар. Шулай итеп, «Эти» кушаматлы бандитның ямьсез данга уралган гомер юлы — Идел буендагы күп кенә шәһәрләрне дистә ел буе тетрәткән җинаятьләр йомгагы сүтелеп бетте. Аның белән бергә Суконный бистәсендәге «Күк күгәрченнәр»нең караклык һәм фәхеш оясы да тузды. Шул ук төнне «Эти» байрагы астындагы тагын берничә бандит һәм алар арасында аеруча «майлы калҗа» — чибәр Флора кулга алынды.
Балабанов башта бер сорауга да җавап бирергә теләмәде. Аннары чекистларның тел төбе кая таба барганын аңлап алды: болар аның үзеннән дә бигрәк Михаил Тряпкин белән кызыксына икән бит! Димәк, җавап бирү чекага ниндидер хезмәт күрсәтү кебек булачак; моның өчен хак сорарга да була...
Шулай да Балабанов белмәгән нәрсәләр күп иде. Мәсәлән, аңа

Михаилның кайда яшәве дә, асылда ни белән шөгыльләнүе дә мәгълүм түгел. Үз вакытында Тряпкинның «Зингер» исемле немец фирмасы белән бәйләнгән икәнлеген генә белә. Мишель белән аларның алдан килешеп-билгеләп куелган очрашу урыны һәм вакыты булмады. Тегесе үзенә кирәк чагында гына әллә кайдан килеп чыга. Коськаны тау-таш арасыннан да эзләп таба торган иде.

— Сәер адәм, анасын эт еккыры...— дип сөйләнде Балабанов.— Бу яклардан бөтенләйгә китеп югалырга да әллә ничә тапкыр талпынды. Флорочка теше-тырнагы белән каршы төште. Әйе, Флора белән алар соңгы араларда ир белән хатын булып яшиләр иде...

— Ә Госман? Госман Хәйруллов... Андый кешене беләсезме? Флора белән ул нинди элемтәдә иде? — диде Измайлов, «Эти»нең сүзен бүлдереп.

— Усман...— Мыскыллы елмаюдан Балабановның авызы чалышайды.— Да, бар андый алаша. Бар иде... Флора — гәрчә тәүфикъ иясе булмаса да ул кызый — аның белән ник бер мәртәбә йокласын. Кызганыч хәтта. Усман, үгез артыннан ияреп йөргән маэмай шикелле, бик ымсынып карый иде Флорага... Анысы хак.

Балабановның бу уңайдан сөйләр сүзе тел очында гына тора икән. Әмма озын сүзнең кыскасы: Госман Хәйрулловка әлеге фахишәнең рәсми «ире» булу бәхете генә тигән булып чыкты. Шул ук вакытта Мишель белән Флораның «ир белән хатын» булып яшәве турында да тозлы-борычлы тарихлар сөйли иде «Эти». Аның үзенә бик авыр бурыч йөкләтелгән, имеш. Бер яктан, Мишель югында азгын Флораның нинди маҗараларга дучар булуын ящерү. Икенче яктан, тагын да мөһиме — шәп кенә хак бәрабәренә, әлбәттә! — Флораны чит-ят күзләрдән саклау.

Флораның дәртле хатын икәнен белгәнгә, Мишель аны бик нык ярата да, бик каты көнли дә икән. Шунлыктан ул бу чибәр хатынны өйдә генә яшереп тотарга тырыша, аның беркайда да күренеп йөрүен теләми. Әмма теге кәнтәй моңа һич иләшә дә, күнә дә алмый. Бер генә ирнең хатыны булып, өйдә бикләнеп утыру аңа гомумән таныш халәт түгел. Ул рестораннарда типтерергә, ирләрнең күз белән дә, кул белән дә капшавын тоеп яшәргә ярата...

— Дөресен әйтсәм, Тряпкин да аңа чын-чынлап ир түгел: хатынын икешәр атна буе ач тоткан ир — ир буламыни.— Коськага бу турыда сөйләү рәхәт, ул хәтта чекистлар кулында икәнлеген дә онытып тора кебек иде бу мәлдә. Күзләре майлана, иреннәре дымлана.— Да... Сәер адәм ул Тряпкин. Күп вакыт өенә кайтып тормый, малай, көязләнеп кая да булса очрашуга чакыра. Өенә катыргы гына язып сала, авызын фәлән итим. Казанның йә теге, йә бу күренеше төшерелән открытка. Ягъни мәсәлән, кайда очрашасын күрсәтә. Ул хатларның хикмәтен миннән башка адәм заты белми, анасын корт чаккыры!

Флораны саклап торуның тагын бер катгый шарты булган: бүтәннәрдән тидермәү генә түгел, үзең дә каныкмаска.

— Флораның кайчакта юлы уңмый, мескеннең. Дәртен ничек басарга белми стенага үрмәләгән чаклары була,— дип дәвам итте Балабанов.— Әмма горурлык көчле кәнтәйдә: миңа якын да килми. Михаилның аны миңа хәрәм-нәмәхрәм иткәнлеген белә. Бүтәннәр белән кылган гөнаһыңны ачам дип, куркытып та алып булыр иде, айт-майт. Алай миңа кызык түгел. Заманында ни дәрәҗәдә тәмле калҗа икәнлеген үзем шактый сынап караган кызый бит ул... Шуңа күрә мин инде аны күрергә-тикшерергә барганда чамадан узып шаярмый идем. Анадан тума чишендерер идем дә, әйләндереп-әйләндереп карыйм үзен. Тимим. Валлаһи әгәр, шуңа риза булып кайтып китә идем.

Флора исә бу серләрнең ачылуына эче пошкан кебегрәк күренде.

Мәхәббәт мажаралары турында иркенләп сөйләргә аның һич исәбе юк иде. Шулай да Мишель белән очрашуларын яшермәде. «Ирем» дип авыз тутырып та әйтмәде. Мишель аның өендә бөтенләй диярлек булмаган, очрашу урынын һәрвакыт үзе билгеләгән. Һәм тагын бер сәер гадәте: әлеге очрашага төшкә барганда, ярты юлны үтү белән, үзе каршы чыга икән...

Димәк, ул һәр юлы тикшереп торган: Флора артыннан күзәтү оештырылганмы-юкмы, эзенә басып кемдер килмиме? «Бу хатын — пәрәвез җебе кебек бик нечкә, бик зәгыйфь булса да, Карачкыга таба илтүче бердәнбер юл»,— дип нәтиҗә ясады Олькеницкий. Шуңа күрә Флорага тимәскә, хәзергә аны җибәрергә кушты.

Сорау алу әле күп мәсьәләләрне ачык калдырды. Һәрхәлдә, Константин Балабановның кинәт кенә сүзгә юмартлануы Флораның әллә ни ачылып китмичә генә җавап бирүеннән артык түгел иде. Шул ук Балабановның Газыйм Дардиев ясап биргән ялган документлардан файдаланып, милициягә эшкә урнашуы да, мәсәлән, хәзер һичнинди әһәмияткә ия булмаган бер мәгълүмат сыйфатында гына калды.

Чекистларга бигрәк тә шундый сорау тынгы бирми иде: Карачкының кайда яшеренгәнлеген белмәгәч, аңа нинди юллар белән бик тиз хәбәр салып өлгерәләр соң? Әйтик, төрмә срогын тутырып чыгучы тоткыннар аша чека юри хәбәр тарата: фәләнне кулга алырга уйлыйлар, аның ярдәмендә бүтәннәрнең эзенә төшәргә җыеналар, дип. «Хәбәр» үзенең эшен эшләп тора. Шул рәвешчә, әнә, Газыйм Дардиевны бандитлар үзләре үк «исемлектән сыздылар». Өч-дүрт көн дә үтмәгән иде әле, югыйсә, Карачкы ике атнадан соң, ким дигәндә атна-ун көннән соң гына чаралар күрә башларга тиеш иде. Димәк, аның тагын ниндидер элемтә юллары бар... Олькеницкий шушы уйларын Шамил Измайлов белән дә уртаклашты.

— Карачкы үзенең хатыны-сөяркәсе белән шушы арада — әле өч көн генә элек очрашкан. Болай булса, безгә аны тагын ун көнләп көтәргә туры киләчәк,— диде губчека рәисе.—Ничектер вакыйгаларны ашыктырасы иде бит, ә? Флора белән тизрәк очраштырасы иде.

— Гирш Шмулевич, безнең инде ике тапкыр сыналган юл бар бит,— дип сак кына башлады яшь чекист.— Әгәр губерна газетасына белдерү бирсәк: Балабанов тотылды һәм атылды дип... Бу хәбәр кемгә ничек тәэсир итәр, әмма Михаил Тряпкинны һич кенә битараф калдырмас иде.

— Карачкы өчен, чыннан да, яңалык булырга мөмкин бит бу...— Олькеницкий, уйланып, кулындагы карандашын өстәлдә биетеп алды.— Хәбәр басылып чыгу белән, каравылчысыз калган Флорасы янына йөгерергә тиеш ул. Әгәр инде ул тирәдә борынын да күрсәтмәсә, бөтенесен белеп-күреп тора, саклык чараларын онытмый дигән сүз.

Гирш Шмулевич әлеге тәкъдимнең кызыклы булуына тәмам ышанып җитте бугай:

— Шәп. Белдерүне үзең әзерлә, Шамил. Хәзер үк утырып яз. Ышанычлырак булсын өчен, атаклы бандитның тормыш юлын да беразтасвирларга онытма,— диде.

Икенче көнне «Знамя революции» газетасында шундый хәбәр-игълан басылып чыкты:

**КОНСТАНТИН БАЛАБАНОВНЫ АТУ**

Балабанов шайка төзегән... Талаган һәм үтергән. Революциягә кадәр үк бөтен Идел буена билгеле аферачы булган. Күп тапкырлар хөкемгә тартылган...

Соңгы вакытларда, ялган документларга таянып, атлы милиция отрядының башлыгы булып җитешкән. Вак-төяк каракларны гына кулга алган. Үзенең иптәшләренә качарга ярдәм иткән. Отрядына кеше талаучыларны җыйган... Талаган малны бергәләп бүлгәннәр...

Суконный бистәсендә ул «король» булган, бөтен караклар һәм шунда яшәүчеләр аңардан куркып торганнар.
Шайканың калган кешеләрен эзлибез.

**Губчека.**

Балабанов кулга алынган һәм инде атылган булса да, Флораның исән-имин котылуын белү немец агентын тынычландырачак, ул артык сагаеп тормаячак, дип уйладылар чекистлар.

Чыннан да, газета чыкканның икенче көнендә үк Суконный бистәсе офыгында Карачкының күләгәсе күренә башлады. Дөресрәге, Флораның почта әрҗәсендә хат-открытка пәйда булды. Бер ягына Сөембикә манарасы төшерелгән, ә икенче ягына: «Сөеклем! Мин Мәскәүгә китәм. Берсекөнгә (чәршәмбе) 16.40 та каршыла. Мишель»,— дип язылган иде.

Чекистлар вакыйгаларны алдан юрарга, бу хәбәрнең хикмәтен табарга тырыштылар: чынлап та Мәскәүгә китkәнме, әллә юкмы Тряпкин? Әгәр көнче ирнең бер кыланмышы гына булса бу, алар вокзалда түгел, ә Сөембикә манарасы янында, яисә Флора шунда таба барган чакта ярты юлда очрашачаклар... Шамил Икенче таудан Сөембикә манарасына таба иң туры юлны күз алдыннан кичерә башлады.

— Казандамы Михаил хәзер, Мәскәүдәме — иң мөһиме ул түгел.— Ольkеницкий пенснесын салып, аның пыяласын чиста кульъяулык белән тырышып-тырышып сөртә башлады.— Хикмәт шунда: Карачкы үзенең Флорасын яшерү өчен нинди чара күрергә мөмкин? Хәзер ул хатын, йомырка өстендә утырган тавык кебек, өйдән чыкмый тора алмый ич. Сорау алганда Коська Балабановның да аны сатуы бар,— Карачкы моны гына чамалый.

— Шуңа күрә ул хәзер бик сак кыланырга тиеш. Чеканың Флора артыннан күзәтү оештыру ихтималын да күздә тотадыр,— дип өстәде Шамил.

Ольkеницкий, нәрсәнедер күрергә теләгәндәй, кисәк кенә алга таба авышып, муенын сузды:

— Менә без баш ватабыз: агент үзенең сөяркәсе белән кайда очрашырга мөмкин, дибез. Сөембикә манарасы янындамы, әллә вокзалдамы? Шулай, без яңадан кәкре каен тирәтеп калачакбыз. Кайзер агенты нәкъ шуңа исәп тота да! Бу открытка,— мин менә хәзер аңлый барам,— яшелчә бакчасында эленеп торган карга үләксәсе яисә кеше карачкысы гына, бүтән берни дә түгел! — Губчека рәисе урынынннан сикереп торып, телефонга ябышты: — Алло! Егетләр! Тизрәк машинаны әзерләгез. Нәрсә? Ватылганмыни!.. Алайса хәзер үк тарантас кирәк.

Ольkеницкий телефонны ташлап, ялт кына Шамилгә борылды:

— Әгәр агент, боларны алдадым, открыткадагы очрашу урыны һәм вакытына ышандырдым, дип уйласа, хәзер нишләргә тиеш?..

— Ул иң көтелмәгән юлны сайлаячак.— Шамил, табышмак әйтешкәндәге кебек, ашыгып-кабаланып җавап бирде.— Флорасы янына Карачкы үзе килеп чыгарга тиеш!

— Кайчан?

— Бүген, әлбәттә! Һәм кичкә таба, яисә төнлә, без көтеп торганда түгел, ә иртәдән үк,— инде хәзер ул анда булырга мөмкин.

— Менә шул-шул! — Ольkеницкий билендәге коралын тикшерде һәм җил-җил атлап ишеккә юнәлде.

...Ату тавышларын алар ерактан ук ишеттеләр. Коры ботак сынган кебек револьвер тавышлары каяндыр астан, Шамов хастаханәсенең сул канатыннан үтүче чокыр төбеннән килә иде.

— Ку атларны! Икенче тауга ку! — дип әмер бирде Ольkеницкий.

Читән арба больница янына килеп туктау белән, чекистлар текә ярдан түбән тәгәрәделәр. Шунда алар яралы Әскәр Хәйретдиновка юлыктылар. Ул көнне Флора йортын күзәтү Әскәр белән аның иптәшләренә тапшырылган иде.

— Теге якка йөгерделәр,— дип наганы белән ишарәләп күрсәтте яшь чекист.— Балык базары тарафына!..

Берничә минуттан чекистлар инде Карачкының үзен күрделәр. Йөз адымда гына булыр. Аның белән бергә яшь хатын йөгерә, бусы, әлбәттә, Флора иде.

— Тукта! — дип кычкырды Измайлов.— Тукта! Югыйсә атабыз! — Шундук, кисәтеп һавага атты.

Кинәт Флора кулындагы төенчеген җиргә ташлады, аннары, Карачкыдан аерылып, бөтенләй икенче якка таба йөгерә башлады. Карачкы бер мәлгә аптырашта калып, як-ягына каранды, хатынына иярмәкче дә булды ахрысы. Тик, икәүләп барыбер кача алмасларын чамалапмы, сул кулын селтәп куйды, артына борылып төзәмичә генә ике тапкыр атты да, бер ишегалдына йөгереп кереп китте. Һәм шул керүдән юкка чыкты. Нәкъ менә печән кибәненә төшкән энә кебек.

— Булмады,— диде Ольквеницкий, ишегалдындагы бөтен сарай-корылмаларны тагын бер «тарап» чыккач.— Соңгы ботак кулдан ычкынды. Балабанов әйткән иде бит: аны монда Флора гына тота, дип...

Аягы яраланган Әскәрне Шамов шифаханәсенең операция бүлегенә керттеләр. Кире кайтканда күзләр берни күрми, телгә җүнле сүз килми иде...

Ярты сәгатьтән губчека рәисе Измайловны үзенә чакырды. Аның йөзендә әле бая кара күләгә булып куерган кырыслык һәм төшенкелекнең эзе дә калмаган иде.

«Нинди нык ихтыяр көче! — дип ихтирам белән уйлап алды Шамил.— Менә кемнән үрнәк, гыйбрәт алырга була...»

Тиздән ишектә Вера Брауде күренде. Ольквеницкий, менә барыбыз да җыелып беттек, дигән төс белән әйтеп куйды:

— Карачкыны ычкындырып кайтканыбыз өчен рәхмәт йөзеннән Вера Петровна безгә бүләк әзерләп куйган.

— Бүләкне чишеп-сүтеп карыйсы бар әле,— диде Брауде, чыннан да нииндидер кечтәнәч турында сүз барган кебек итеп.

— Йә, ярый, мәсьәләгә якынрак килик.— Ольквеницкийның йөзе җитдиләнде.— Безне хәзер кем белән очраштырырга иде ниятегез?

— Балабановның иң ышанычлы кешесе — Перинов Семен Семенович белән. Йә, йә, аптырашып калмагыз. Карачкы үзе түгел, әлбәттә. Бу Периновның кушаматы да бүтән — Корчаңгы.— Брауде йөзен Шамилгә таба борды.— Төрмәдән бау баскыч белән качарга маташкан адәм инде. Сез аны аягына атып кына туктаткансыз...

Ольквеницкий бүлдерде:

— Ул үзе икърар иттеме? «Эти»нең ышанычлысы булуын дим...

— Юк, кая ул! Теше-тырнагы белән каршы тора. Башкалар гына шул серне чиште. Балабанов үзе дә бөтенләй үк кире какмый. Әмма әлеге Семенның бер зур кимчелеге бар — ул нәкъ балык кебек: авызын ача — сүзе чыкмый.

— Тагын бер Перинов, ә! Семен Семенович җитмәсә...— дип, үзалдына сөйләгәндәй, кабатлады Ольквеницкий.— Ә Балабановны ату турындагы газетаны күрсәттеңме? — Ул газета губчека рәисенең өстәлендә үк ята иде.

— Юк әле. Ул аннары бөтенләй ачылмас дип курыктым. Ни әйтсәң дә, уйланырга вакыт сорады.

— Әле безнең дә озак уйлап торырга вакыт юк, ә ул, күр әле...—

Олькеницкий торып, алгы бүлмәгә чыкты. Анда аның көр тавышы ишетелде: — Яле, егетләр, кулга алынган Периновны тиз генә монда алып килегез.

Яше илледән узган бу ир-ат, сорау биргәнче үк телгә килеп, зур авызындагы тимер тешләрен сызгыртты:

— Әйттем бит инде сезгә: берни дә белмим, белергә дә теләмим, дип. Юк! Вәссәлам!

— Син белмисең икән, безгә бик яхшы билгеле,— диде Олькеницкий коры гына.— Балабановның бөтен серләрен бер кешегә җиткереп torгансың.

— Кайдан беләсез?!.— Бандитның күзләре маңгаена менде, үзе урыныннан кузгала башлады.— Тряпкин Михаилны да тоттыгызмы әллә? Юктыр ла... Ул бит елан кебек мәкерле, елан кебек елгыр...

— Анысы яңалык түгел. Син безгә шунысын әйт: хәзер кайда ул?

— «Эти»дән сорагыз... Әйтсә — ул гына әйтә алыр...

Олькеницкий өстәлдә яткан газетаны Периновның күз алдына ук шудырып куйды. Корчаңгы «Константин Балабановны ату» дип зур итеп язылган игълан башын гына укыды да, бизгәк тоткан кебек калтыранып куйды:

— Әгәр сөйләсәм... Барысын да әйтеп бирсәм... миңа нинди рәхимлек булыр? Ярлыкарсызмы?

Перинов кинәт утырган урындыгыннан шуып төште, яралы аягына көч килмәсен өчен, ике кулы белән дә идәнгә таянды.

— Ардым мин! Түзәр хәлем калмады! Сез ул еланны тота алырсызмы соң? — Кичәге бандит үзе өчен ниндидер мөһим чикне узарга тырыша, әмма шул ук вакытта курка — үлемнән дә, Карачкының каһәреннән дә шүрли иде.

— Әгәр син дә ярдәм итсәң, тизрәк тотар идек, — диде Олькеницкий, болай, «солых»ка баруына уңайсызланган сыман. Аның ишарәсен аңлап, ике гаскәри егет Периновны кире үз урынына утырттылар.

— Минем болай булуыма Флора сәбәпче...— дип, чекистларны аптырашта калдырды Корчаңгы.— Хәер, мин аны гаепләмим. Үскәндә үк тәүфикъсыз булып үсте әмма. Малайлар белән шаярды, артык тиз житлекте...

— Сез аны үсмер чактан ук беләсезмени? — дип сүз кыстырырга өлгерде Шамил.

— Беләм. Белми ни!.. Флора — минем кызым ич ул... Кызым...— Перинов күзендәге яшьне сөрткәләп алды.—Үскән саен күбрәк мәшәкать ясады. Итәгенә салып кайтса, бәлки, әйбәтрәк булыр иде. Ә ул... Көннәрнең берендә әлеге шул мәлгунь белән бәйләнешкән. Тегесе чат ябышты шуннан соң. Балам хакында мине бөтенләй үзенең хезмәтчесе итте. Флора кулы белән «Эти» отрядына илтеп кертте. Аннары шунда булуымны Советка фаш итәм дип тә куркытты. Үземне белгәннән бирле күн заводында эшләгән идем. Шуннан кузгатып, госпитальгә дворник итеп урнаштырды.

— Сез аның чын исемен башта ук белә идегезме? — дип яңадан Шамилнең тиктормас теле кысылды.

— Бүлдермә, Шамил,— дип әкрен генә әйтеп куйды Гирш Шмулевич.

— Беләдер идем, билгеле. Кешеләр арасында Тряпкин Михаил булып йөри иде ул. Тора-бара минем гәүдәмне генә түгел, исемемне дә үзенеке итте.

— Дары заводындагы диверсия белән бәйләп, бервакыт үзегезне кулга алмадылармы?

Перинов, болар монысын кайдан беләләр икән дип тә аптырап тормады, якын танышлары белән сөйләшкәндәй, җөпләп кенә куйды:

— Дөрес, кулга алганнар иде шул. җибәрделәр, гаебем булма-

гач — диде. Аннары кинәт исенә төшкәндәй:

— Сез белмисезме... Кызым. Флора ни хәлдә икән, аны харап итмәделәр микән? — дип сорады.

Флораның исән-имин икәнлеген, аның янына килгән Карачкының гына качып котылуын әйттеләр.

— Тота күрегез аны, зинһар тота күрегез! — дип такмаклады Перинов.— Коткарыгыз безне дә!

Михаил чәршәмбе көнне Мәскәү поезды белән китәргә тиеш. Кем беләндер очрашырга бара. Аны вокзалга мин озата төшәсе идем. Әмма ул албастының бүген үк җыенып китүе бар. Муенын урап алган үлем элмәгенең кысыла баруын тоядыр ич — тоймый булмас...

— Хикмәтле балык булып чыктың әле син, агай!..— дип куйды Вера Брауде, телефонга үрелеп.

Мәскәү поездының ярты сәгатьтән кузгаласы мәгълүм булды.

Ольконицкий тиз генә күрсәтмәләр бирде:

— Периновны әлегә алып китегез. Бөтен буш кешеләрне хәзер үк вокзалга! Анда Мәскәү поездына Карачкы утырырга тиеш!

Аннары, бүлмәдә Брауде белән Измайлов кына калгач, сөйләшүгә йомгак ясагандай, әйтеп куйды:

— Менә бу Периновны бер эләктереп алгач, немец агенты һәрвакыт үзенең карачкысы итеп тоткан. Барометрга караган кебек, аны күзәтә-күзәтә эш иткән: көннәр аяз торамы, әллә баш өстендә болытлар куерамы? Ярты гына көнгә югалсын Перинов — бу инде куркыныч турында беренче хәбәр булган.

— Шуңа күрә ул аны үзеннән читкә җибәрмәгән дә,— дип элеп алды Вера Петровна.—Госпитальгә өстерәп алып киткән, аннары милициягә урнаштырган. Димәк, теге чакта «милиция» алып киткәннән соң бүгенге көнгә хәтле ул үзе дә шул тирәдә чуалган...

— Нәкъ шулай булырга тиеш. Периновның фамилиясен дә, үзен дә яшен үткәргеч итеп файдаланган Карачкы. Башы түгәрәк шул, ни әйтерең бар!

...Поезд китәргә ун минут кала вокзалга килеп җиттеләр. Измайлов уникe вагонны да йөреп-әйләнеп чыкты: пассажирлар арасында Карачкы юк иде. Поезд һәрвакыттагыча кичегеп кузгалды, шунлыктан тагын бер кат карап чыгарлык вакыт-ара булды.

— Ә син аның урынында булсаң, нишләр идең? — Ольконицкий яшь чекистның иңенә кулын салды.— Күрәләтә башыңны элмәккә тыгар идеңме?

—Минме...— Шамил башын күтәреп поездга карады.— Мин, мөгаен, икенче станциядә утырыр идем. Беренче тукталышта... Яисә икенчесендә!

— Менә, күрәсеңме, ә син немецның кадровый шымчысын үзеңнән наданракка чыгармакчы буласың.

Фараз кылуы җиңел, ләкин Юдинода утыручылар арасында да Карачкы юк иде. Васильевога килеп җиттеләр.— таныш йөз күренмәде. Иң соңгы вагондагы чекистлар перронны уч төбенә куйгандай күзәтеп торалар иде. Менә поезд, кайнар пар бөркеп, инде бу станциядән дә кузгала. Состав тартылып кую белән, кинәт вагон астыннан ук иңенә юл капчыгы аскан озын буйлы бер ир-ат суырылып чыкты. Чыкты да тамбур басмасына сикерде. Һәм шулчак... аларның күзләре очрашты.

— Йә, Мишель,—Измайлов келәшчә белән каптырып алган кебек аның беләгеннән кысты,—сине күрүемә мин бик шатмын. Чистайда — бер булган иде, Казанда — ике, инде менә тагын... Бусы — өченче, соңгы очрашу.

*Беренче китап тәмам*

# ШИГЪРИЯТ

## Рашат Низамиев

### Кем баласы?

Атна саен көтә аны өйдә,
Нәүмизләнеп, ата-анасы.
Кайта, китә... Шулай гомер итә
Шәһәрләшкән авыл баласы.

Таш урамнар, трамвайлар җыры
Сеңеп бара инде канына.
Кыен чакта туган яклар назы
Маңгаена килеп кагыла.

Төрле яктан җилләр кысып тора
Туган телнең чиста һавасын...
Урысчаны ватып-җимереп сөйли
Шәһәрләшкән авыл баласы.

Рок-музыка әле тилертмәгән,
Джинсылар инде үз иткән.
Тулай торак сыендырсын гына —
Бүгенгесе өчен шул җиткән.

Белми әле, белми чын бәхетне
Кайдан, ничек эзләп табасын.
Кино карый, тик ятудан арый
Шәһәрләшкән авыл баласы.

Кырлар көтә: ашар икмәгеңне
Үстерә бел, диеп, иң элек.
Кызыктыра шәһәр... Җаны шулай
Кыл урталай яши бүленеп.

Яшьләр китә...
Ни югалттың, авыл?
Син ни таптың, Казан каласы?
Кайта, китә — шулай дөнья көтә
Шәһәрләшкән авыл баласы.

### Сөембикә манарасы

Антеннадай күккә чөелгән дә,
Көн каршына баскан Сөембикә.
Үз-үзеңне шулай мәгърур килеш
Тотып торулары кыен бит, ә?

Кыйбла якка авышкан ул, дибез —
Кыек тора, бәлки, заманасы?
Киләчәк көн татлы тоеладыр,
Ә үткәннәр ләкин һаман ачы.

Җир-су өчен көрәш барган чакта
Яуга каршы яулар чакырылган.
Нигезеңдә фидаилар ятса,
Авышырсың хәтта акылыңнан...

---

Рашат НИЗАМИЕВ *(1950) — шагыйрь, прозаик. «Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй» һ. б. шигырь китаплары, «Язмыштан көчлерәк» исемле роман-хроника авторы. Казанда яши.*

Кыршау белән билен ураганнар:
Кыршау кыршау инде — кысып тора.
Һәр кирпече, күзәнәге саен
Күпме легендалар посып тора!

Ә кичләрен серле, сәер кошны
Хәтерләтә, бәлки, күпләр өчен,—
Күр, томшыгын күккә таба сузган
Төнге йолдызларны чүпләр өчен.

Җим булырга теләмидер, ахры —
Күкнең читен йолдыз кыеп китә.
Шәһәр йоклый. Айны томшыгына
Элэктерде әнә Сөембикә!

## Архивта уйлану

Өем-өем кулъязмалар монда —
Йөрим гүя тарих урманында.
Чал кайтаваз булып үткәннәрдән
Хәтер агып керә кулларыма.

Ак патшалар, байлар заманында
Йөз ел элек нинди булган тормыш?
Кемгә каршы кемнәр кылыч тоткан —
Бөртеген дә түкми сөйлә, язмыш!

Берәү әнә гарәп хәрефләрен
Үзгәртмәкче булып латинчага,
Кулындагы айбалтасы белән
Меңәр еллык тарихыма чаба...

Тән түзәр ул, җан кыйналса читен.
Җанга суккан палач куштаннары.
Аралагыз безне ялганнан, дип,
Күтәрелә «халык дошманнары».

Юк, карадан гына тормый дөнья!
Якты сәхифәләр куя балкып.
Төн эченә йолдыз сипкән сыман,
Гәүһәрен дә күп кабызган халкым.

Сүзсез генә бер өн чыңлап тора —
Кичләрен дә шулай, иртәсен дә...
Сугылмаган арыш көлтәседәй,
Ята тарих архив киштәсендә.

## Миләш турында баллада

### 1

Җәй авышып бара иде көзләргә,
Ромашкалар бәрелеште тезләргә.

Кайнар иде кыз баланың кочагы...
Кабынды җилдә миләшләр учагы.

Мәрҗән ясыйм, диде егет талпынып,
Кыз күкрәге җавап бирде калкынып.

Түшкәенә ятты кызыл муенса!
Китте алар яшьлек язы буенча...

2

Яңа җәйгә житәкләшеп керделәр.
Миләш яшел, өлгермәгән — күрделәр.

Өлгергәнен көтәр чама калмады,
Офыкларны кара ялкын ялмады!

Кайчан гына җиңеп кайтыр сугыштан?
Кыз егетнең иңнәренә елышкан.

Басып калды яшел миләш төбендә,
Яшел миләш ачылары — телендә.

3

Алар бар да яшь-яшь егет иделәр,
Утка-суга без керәбез, диделәр.

Сазлыкларга төште егет — батмады,
Саклый иде аны сөю хатлары.

Сукты әҗәл — ул монысын белмәде,
Хәтерендә кызыл миләш дөрләде...

Кайтмый калды егет туган йортына.
Каберендә миләш үсеп утыра.

❋

«Куркынычлы» диеп, китапларны
Учакларда яктык.
Бөгәрләнеп сүзләр янган чакта
Кайда идең, хаклык?

Искелек дип, мәчет-чиркәүләрнең
Нигезләрен ваттык.
Айлы манаралар ауган чакта
Кайда йөрдең, хаклык?

Туры сүзле асыл егетләрне
Сайлап-сайлап аттык.
Диварларга кан чәчрәгән чакта
Кайда идең, хаклык?

Ялган пәрдәләрен ертып атты
Илгә килгән аклык.
Мең газаплар аша эзләп таптык,
Китә күрмә, Хаклык!

## Кабанны яклап бер сүз

Кабан күле черен бара,
Балыгы — чирле, ябык.
Терелтәсе иде күлне
Берәр дәвасын табып.

Чаң кагасың — ишетмиләр,
Белмим кемгә язарга?
Бер «Черек күл» болай да бит
Җитеп ашкан Казанга!..

Вакыт-вакыт була шундый вакыт:
Төшенкелек баса уйларны.
Читлектәге коштай бәргәләнәм
Төзәтәсе килеп дөньяны.

Вакыт-вакыт була шундый вакыт:
Якты чәчә башлый уйларым.
Көрәшләргә тагын ташланам мин
Яхшыртасы килеп дөньяны!

Уй җитмәслек могҗизалар,
Буй җитмәслек киңлекләр,—
Дөньяны танып-белүдә
Никадәр мөмкинлекләр!

Буыннан-буынга күчә,
Мәхәббәт тере бит ул,—
Дөньяны танып-белүнең
Бер генә төре бит ул.

Кайгы-хәсрәт күләгәсе
Кагылсын сиңа бары —
Дөньяны танып-белүнең
Киңәя офыклары.

Килсен, керсен матурлыклар,
Әйдә, күңел капкаң ач!
Дөньяны танып-белгәннәр
Дөньяга үч сакламас...

## Чернобыльдән соң...

Сызымнар сөйли, аңлата:
Шундый көннәр киләчәктер,—
Кама буендагы алан
Илгә атом бирәчәктер...

Яшәү өчен торак кирәк,
Планнарны үтә генә!
Тиражлап-тиражлап әнә
Яңа йортлар күтәрелә.

Җирне казып кирә-кирә,
Тәмам түргә атлаганнар.
Кызыл авызларын ачып,
Өнсез ята котлаваннар.

Техниканың беләкләре
Тау-таш яра — ни горурлык;
Бер котлаван эчләренә
Авыл кереп утырырлык...

— Юк, кирәкми хәвефле эш!
— Илгә кирәк энергия!

Әнә шулай дия-дия
Бәхәсләшә ике төркем.
Хакыйкатьнең чын дөресен
Әйтеп бирә алмый беркем.

Атом-сарай кирәктер ул —
Ышанычлы булса гына,
Яшәмәсә табигатьне
Рәнҗетүләр хисабына!

Күрсәтмәләр өстән килә,
Кысып ала тормыш астан.
Үз-үзеңә яман кабер
Казый күрмә, Татарстан...

## Дүртьюллыклар

Кырдан-кырга ашламалар чәчтек...
Исем китеп карыйм мин шуңарга —
Өстәлләрдә икмәк арткан саен,
Җирнең мае кими басуларда.

Башкаладан искән яңа җилләр
Кыю йөрәкләрне, әй, җилкетә!
Инерция белән яшәүчеләр
Һаман әле өстән боерык көтә.

Нотык сөйләү җиңелләрдән түгел:
Тирли маңгай, калтырана тезләр.
Сөйли-сөйли трибунаны күмдек,
Нәтиҗәсе — җилгә очкан сүзләр!

Сатлык җаннар, шома алдакчылар,
Кача-поса ришвәт алучылар —
Кешеара мөнәсәбәтләрдә
Матурлыкка аяк чалучылар.

Туу дигән могҗизалы көннән
Без яшәргә дучар ителгәндер.
Карыйк әйдә: кемнәр күпме алып,
Күпме файда илгә китергәндер...

Күккә таба карап үсә чәчәк,
Җиргә ләкин чәчри орлыклары.
Нигезләрен ташлап киткәннәрнең
Туган җиргә кайтсын оныклары!

Туктап-туктап төшә сары яфрак,
Манчылган да көзнең төсләренә.
Озайтмакчы булып гомеркәен,
Килеп куна чыршы өсләренә...

# Клара Булатова

## Бер җәйге көн миңа бирегез сез!

Бер җәйге көн миңа бирегез сез,
Кыр юлларын монда сузыгыз,
Болыннарны монда китерегез,
Урманнарны биреп торыгыз.

Мин аларны изеп, таптап йөрмәм,
Күзләремә генә алырмын.
Һәр үләнен, гөлен берәм-берәм
Көйләремә генә салырмын.

Күбәләкнең тыйнак лепердәвен,
Юкәләрнең өнсез дәшүен,
Ут сагышын сары гөлбәдрәннең,
Гөлҗимешнең нечкә чәнчүен,

Каеннарның кайнар пышылдавын
Җырларыма гына теркәрмен.
Мин шуларның җырга салып барын,
Үзегезгә бүләк итәрмен.
Бер җәйге көн миңа бирегез сез!..

*

Зәңгәр күкләр, ак болытлар...
Болытлар ак, күк зәңгәр.
Ах, ни булыр, ак болытлар
Кара яңгыр түксәләр?

Ах, ни булыр, ак болыттан,
Аяз күктән боз яуса?

Ах, ни булыр, бер дә юктан
Илдә давыл кузгалса?

Ах, ни булыр, бер дә юктан
Җимерелсә бу нигез?
Син дә, мин дә чынбарлыкка
Ни дип җавап бирербез?

*

Бөреләрнең кипшенүен күрдем,
Чәчәк атмас инде гөләбем,
Мин-беркатлы хәтта көзге көннең
Гөлгә күмелүен теләдем.

Күрдем, юкса, баш өстендә йөзгән
Болытларның куера барганын.

Мин-беркатлы хәтта кара күздән
Аязулар көтеп алдандым.

...Раслап килде тормыш «түрәләр»дә
Орлыклык та хаклык калмавын —
Мин-беркатлы хәтта шундыйлардан
Гаделлекләр көтеп алдандым.

---

Клара БУЛАТОВА — *шагыйрә, «Язлар алда», «Җәйләр җитсә», «Гел кояшка карап» һ. б. шигырь китаплары авторы. Әлмәттә яши.*

Илдән читкә чыгып йөргән
күпне күргән,
Кайчагында чит җир әйбәт
туган җирдән...
Әмма ләкин вакытлыча,
ә башлыча
Туган илдән газиз җирне кемнәр белгән?
Анысы хак: илдә дә бит
төрлесе бар,
Адәмнәрнең җаны-тәне
керлесе бар.
Якташыңда җан урынында
бозык кан бар,
Ят дигәнең йөрәгендә
олы җан бар.

Исемен-атын атамый,
Кемлеген әйтми генә,
Кемгәдер бүген бер сорау
Бирәсе килде менә.

Армасмы халык колагы,
Туймасмы тагын бер чак
Атналар, айлар буена
Бер сүзне туглап торсак?

Ярый ла бары сөйләүдән
Күктән мал ява алса!
...Соң, сүздән эшкә күчәргә
Бик вакыт инде ласа...

Башыма кояш суга дип
Ышыкта ятмам инде,
Үземә төбәлгән уктан
Борылып качмам инде.

Тарихта калган бабамнар
Рухлары шулай диләр:
Төбәлгән укны читкә бәр,
Дошманга кире җибәр!

Мескенгә кайчан көн булсын?
Кыюлык көтә Дөнья.
Бу кайнап торган тормышның
Мәгънәсе бары шунда.

«Бу айлы кич кире килмәс,
кайтмас узгач,
Бер тамган яшь керфегеңә
кире кунмас.
Үлчәү белми чәчмә, түкмә,
әрәм итмә,
Җилгә сипмә гомереңне, шулай булгач».

Үз-үземә шундый киңәш бирә алам,
Димәк, әле аңым гел үк югалмаган?
Әмма... акыл дыңгычлаган башка авыр,
Рәхәтрәк яши бер дә уйламаган.

### Флүс Латыйф

# АЯКЛЫ КАЗА

хикәя



Искәндәр Болак аръягындагы шушы мунчага яратыбрак йөри. Дөрес, соңгы елларда бистәне кысрыклап килүче, бер-берсенә шырпы капларыдай охшаш күпкатлы йортларда яшәүчеләр аны бик өнәп бетерми. Аскы каттагы тәрәзәләре җиргә иңә башлаган, ел тәүлегендә юеш пар йотып яткан кирпеч стеналарындагы акшары купкан, арзанлы буяу белән кат-кат сыланган ишеге калҗаеп, салынып төшкән мунча, тыштан караганда, бер дә кешене җәлеп итәрлек түгел. Әмма Искәндәрнең җаны утрак, бер иялңгән җирдән тиз генә аерыла торган кеше түгел ул. Һәрхәлдә, өченче дистәне куып килүче өйләнмәгән ир-егет һәр шимбә кич тәне кызыша башлаганчы озаклап чабыну һәм атна буе ватылып эшләгән кешеләр арасында ашыкмый гына сыра чөмереп, гәп корып утыруны язылмаган канунга әйләндергән иде.

Тик, үч иткәндәй, кеше артык күп иде бүген.

Ерак сәфәргә чыгар алдыннан кием-салым әзерләргә, әйберләрен тәртипкә китерергә җыенган, «Кичен иртәрәк ятармын да, таң белән үк кузгалырмын»,— дип уй корган, башка вакытта чират зурлыкка мыегы да селкенмәгән Искәндәр үртәлә үк башлады. Әш болай барса, кичке унсыз-унберсез кайтып та керелмәс. Җитмәсә, бистәнең гомер бакый бергә аралашып көн күргән ир-атлары артык тәкәллеф саклап тормый чираты җиткән берәү янына күз ачып йомганчы биш-алты танышы җыелып өлгерә. Әйтерсең лә күрешмәгәннәренә мең ел, җилкәләренә шап-шоп сугып телләнәләр:

— Һа, кордаш, себеркең шәп күренә, рәхәтләнеп чабынабыз икән!

— Монда киткәнеңне ник әйтмәдең? Берәрне кыстырып килгән булыр идем!..

Шау-шу, ыгы-зыгы. Әтиләренә ияреп килгән бала-чага газлы су автоматы янында мәш килә. Тамагы кипкән Искәндәр автомат янына үтә алмады, дөресрәге, чыр-чу килгән шул бала-чаганы аралап узуны яхшысынмады. Алар, әйтерсең, эссе көндә чабыштан кайткан: берсе эчеп бетергәнне икенчесе көтеп тормый, стаканны кулдан тартып ала.

---

*Флүс ЛАТЫЙФ (1943) — проза һәм публицистика өлкәсендә эшли. «Кыргый», «Вөҗданыңнан сора» исемле проза һәм очерк китаплары авторы. Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Бер өлеш ширбәт кенә дә ярамый үзләренә, икешәр бакыр акча белән баллы су эчеп кинәнәләр. Искәндәрнең кесәсеннән тәмәке вагына уралып ике өчтиенлек чыккан иде. Ул аларны уч төбендә биетте дә, мунча чыккач тынычлап сусынны басармын дигән сылтау белән үз-үзен тынычландырып, кире чалбар кесәсенә шудыртты.

Гаилә башлыклары малайларының үзара көрмәкләшүенә мыек астыннан гына елмая.

— Бу ташбашыңа күпме инде?

— Унынчы белән бара. Егет булып килә, егет!..

— Әйдә, бәхет-тәүфикълары белән үссеннәр. Дөнья шулар белән кызык...

— Шулай шул! Әле менә кечесе елап калды, мин дә эти белән барам, ди...

«Тапканнар сөйләшер нәрсә. Өйләрендә күреп туймаганнардыр, мунчага килеп тә шуларны сөйләмәсәләр.— Чиратының бер урында таптануына ачуы кузгалган Искәндәр аяк астында буталучы балачагага каш җыерды.— Әле боларына да аерым урын ала торганнардыр. Аларның пычтырдаганын көтсәң!.. Әллә «Сәламәтлек» комбинатына гына китәсе инде. Анда бу вакытта этем дә булмый!..»

Эче пошканын басар өчен букчасына тыгылды, дүртләп бөкләнгән гәҗит чыгарып, соңгы битеннән укырга керешге. Ләкин юньләп укый алмады. Иртәгә юлга чыгасы булу, бөтенләй белмәгән-күрмәгән якларда ай буе эшләргә тиешлеге, әллә нинди бер билгесезлек шаукымы булып, җанын тырнап тора иде. Дөрес, бәрәңге алу чорында чит өлкәгә беренче тапкыр гына китүе түгел. Элегрәк автохуҗалыктан егерме-утыз шофер бергә була иде. Ә быел, нишләптер, берүзен озатасы иткәннәр.

Шулчак, кемнеңдер үзенә карап торганын сизеп, башын күтәрде. Гадәттә мунчага киелә торган иске җәйге пәлтә кигән, гади ситса яулыкны маңгаена ук төшереп бәйләгән хатын иде ул. Дымлы һавада сүрән җемелдәгән ут яктысында аның яшь чамасын да абайламый калды Искәндәр, «Ирләр бүлегендә нишләп йөри икән бу?» — дип сәерсенергә генә өлгерде. Җитмәсә, чишенү бүлмәсенең ачык ишегенә эленгән юка пәрдә ялан саен күтәрелә, эссе, парлы һавада тәннәре кызарган шәрә ир-атларның йөренүе, яшь-җилкенчәкнең тугарылып шаярышуы аермачык күренеп тора.

Хатын кыенсынып кына эндәште:

— Зинһар өчен, үзегез белән минем малайны да алып керегез әле?..

Хатынның алты-җиде яшьләр тирәсендәге бала җитәкләгән булуын Искәндәр шунда гына күреп алды.

— Юк, юк! Мин озак юынмыйм. Бер генә коенам да чыгам,— диде ул ризасызлыгын яшереп тормыйча.— Алып керә алмам...

Хатын чарасыз иде. Ул, нәүмизләнеп, Искәндәрне үзенчә тынычландырырга ашыкты:

— Сез борчылмагыз. Аңа берни дә кирәкмәс. Үзегез белән чишендереп, бер-ике ләгән су китереп бирсәгез, шул җитәр. Ул сезгә мәшәкать ясамас. Үзе юына ул... Янәшә утыртсагыз...

Каршы төшәрләр, бүлдерерләр, риза булмаслар, дип шикләнгән хатын гозерле сүзләрен ашыга-ашыга тезде. Аның уңайсызлануы, үзенә текәлгән дистәләгән ир-ат күзеннән тизрәк китәргә ашыгуы әллә каян сизелеп тора иде. Кашларына кадәр төшкән яулыгы астыннан күренгән, зур булып ачылган зәңгәр күзләрендә ялвару да, өметләнү дә, чарасызлыктан аптырау һәм гаҗизлек тә чагыла иде.

Аның шушы халәтен күзләреннән, гәүдәсен тотышыннан аңлаган, кешенең түбәнсенүен яратмаган Искәндәр хатынны уңайсыз хәлдән коткарырга ашыкты, теленнән рөхсәт сүзләренең ычкынганын сизми дә калды:

— Ярар, алайсаң...

Үзе ирексездән уйлап куйды: «Шушы йолкыш кына җитмәгән иде ди миңа!..»

Әллә инде берәр тамгасы бар аның — кайда гына чират тормасын, беренче эләккән кеше аңа эндәшә. Еш кына шуңа үртәлә Искәндәр. Өлкәнрәкләре: «Энем, миңа да берне алырсың»,— дип килеп җитә, яшьтиләре алай нечкәләнеп тормый, бер ишегалдында яшәгәндәй, җилкәгә сугып кына күз кыса. Кечерәкләренең үз сүзе: «Абый, алдыңа керим әле!» Гараждагы иптәшләре дә, тулай торактагы бүлмәдәшләре дә көлә:

— Йөзең мәрхәмәт иясе икәнлегеңне ярты чакрымнан кычкырып тора бит, синә дәшми кемгә дәшсеннәр!..

Моны беренче тапкыр ишеткәч, көзгедән карап, озаклап шул билгене эзләгән иде. Юк, берни дә кычкырып тормый. Гап-гади түгәрәк йөз, куе кашлар астында көрән күзләр, калын иренле олы авыз, бераз җәенкерәк туры борын, шуларны бер түбә астына җыйнарга теләгәндәй, тыңлаусыз коңгырт чәчләре бүрексыман кабарган. Дөрес, кешегә күтәрелеп авыр сүз әйтергә яратмый ул. Нәрсә дә булса сорасалар, баш тартуны өнәми, кире җавап кайтара белми. Шуларны белгәнгә күрә, чират торырга яратмый Искәндәр, торса да йөзенә битараф ваемсызлык чыгарырга тырыша, йә булмаса читкә карап баса. Янәсе, беркемне дә күрми. Инде көтмәгәндә менә тагын бүген...

— Йокладыңмы әллә? Нигә кермисең?

Аркасына төртүдән сискәнеп китте. Уйга чумып, чираты килеп җиткәнне дә сизми калган икән. Пәрдә артыннан мунчачының карлыккан тавышы ишетелде:

— Следующий...

Ишек яңагына сөялгән һәм әнисе киткәннән бирле бер сүз дә дәшми басып торган малай күзләрен тутырып Искәндәргә карады, биштәрен бер кулыннан икенчесенә күчерде.

«Бу аяклы казадан котылып булмас, ахры». Үзенә тапшырылган малайга әчтән генә шундый кушамат тагып өлгергән иде инде ул. Әллә соң юынмыйча кайтып китәргәме дип, эче пошып утырган Искәндәр көрсенеп куйды һәм малайның аркасыннан әтәрде.

Каен себеркесе, сыра һәм дым исе аңкыган чишенү бүлмәсендә буш урыннар юк иде. Малайны берәр җиргә урнаштырырмын да котылырмын диебрәк кергән Искәндәр күзләре белән бүлмәне тагын бер кат айкап чыккандай итте. Юк! Билетын мунчачы өстәлендәге тимер әрҗәнең тар тишегенә төшереп җибәрде дә малайны эзләп якягына каранды. Тегесе, суга чумгандай, каядыр югалып та өлгергән иде инде.

Искәндәр, өстеннән олы йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды һәм урын табу өмете белән биек аркалы эскәмияләр арасыннан атлады. Урыны булмаган көйгә керергә чакырган мунчачы картны әчтән генә тозлап-борычлап сүгеп куйды, икенче рәттәге эскәмияләр ягына борылды. Юеш идәндәге резин келәмчекләр тайгак, аяк басуга шуып китәргә генә тора. Карамыйрак атласаң, бөтен буең белән сузылып ятуыңны көт тә тор. Ул сакланып кына түргә узды һәм иң почмакта әлеге дә баягы малайны күреп алды, теше сызлагандай йөзен чытты. «Аяклы каза» буш эскәмия тапкан, әйберләрен куйган һәм чишенмичә аны көтә иде.

Искәндәр сүзсез генә аның янына килеп утырды, малайдан барыбер котылып булмаячагына үртәлеп, чишенергә керешә, коры гына итеп әйтте:

— Чишен! Өстеңне сал...

Шуны гына көтеп торган малай иплэп кенә күлмәген, майкасын, бераз мыштырданып алгач, чалбарын салды, әнисе әзерләп биргән төргәктән мунчала-сабын чыгарды.

— Бар, кереп урын ала тор!

Барыбер кичем әрәмгә узды, дип уфтанган Искәндәр үзе керергә ашыкмады. Таш юынгычлардагы урынның бушавын көтеп-эзләп интегәсен белгәнгә, кеше өстендә торып, күз көеге буласы килми иде. Чыгар әле берәрсе! Үзенә тагылган малай турында исә ул инде бөтенләй оныткан иде. Алып керде, эше бетте. Юынып чыгар әле шунда!..

Юыну бүлмәсендә гадәти шау-шу. Мәрмәр вагыннан ясалган тәбәнәк таш эскәмияләргә бәрелеп калай ләгәннәр шакылдый, чажлап су акканы ишетелә, шушы тавышлар, ир-атның өзек-өзек авазларына кушылып, ниндидер бер тоташ гүелдәү хасил итә, керә-керешли ук башны урап ала. Искәндәр өчен бу тавыш, мондый гүелдәү таныш кына түгел, хәтта тансык иде. Танышлардан берәрсе очрар, рәхәтләнеп, арка тиреләре суела башлаганчы чабынырбыз дигән өмет тә юк түгел иде.

Килеп керүгә ук нәкъ ишек төбендәге утыргычта «аяклы каза»ны күреп алды. Ул таш эскәмиягә ике ләгән китереп куярга өлгергән, сабын-мунчаласын таратып ташлаган. Башы аска иелгән. Кабыргалары беленеп торган юка, арык тәненә су тамчысы да тимәгәнлеге әллә каян күренеп тора иде. Шулчак Искәндәрнең йөрәген моңарчы булмаган әллә нинди сәер бер авырту чеметеп куйды. Күптән, бик күптән мондый хисне татыганы юк иде аның. Кызганумы ул, шушы үтә садә һәм ярдәмгә мохтаҗ, ышанучан җан иясенә ярдәм итәргә теләү идеме — анысын үзе дә аңламады.

— Иә, урын таптыңмы? — дип эндәште моңарчы юньләп сөйләшмәвенә үкенеп өлгергән, шул ук вакытта мәгънәсез сорау бирүен абайлап алган Искәндәр. «Тапкан бит инде, урнашкан. Ахмак! Шушындый сорау бирәләр димени?!» «Аяклы каза» белән ничек сөйләшергә, ничек аңлашырга кирәклеген Искәндәр, чынлап та, белми иде. Бу сиңа ике сүзнең берендә кемнеңдер анасын искә төшереп, яисә җилбәзәк хатыннарны аңлатучы канатлы гыйбарәләрне кыстырып сөйләшү, тулай торакның азау ярган мужиклары белән аңлашу түгел шул. Әмма ни гаҗәп, шушы мәгънәсез сорау да малайга җитә калды, ул башын күтәрде һәм, «Әйе!» дигәнне белдереп, рәхмәт тулы күзләрен аңа төбәде. Алары нәкъ әнисенеке икән. Зур, моң тулы зәңгәр күзләр. Искәндәр бер мизгел эчендә шуларны абайлап өлгерде.

— Әйдә, юыныйк инде, алай булгач!.. Аркаларны ышкышырбыз...

Әйтеп бетерүе булды, тагын үз-үзен тиргәп куйды. «Юк инде, бала-чага белән бала-чага булып булмый. Әнә, малайлары әүмәкләшкәндә авыз ерып утырган адәмнәргә тагарга кирәк иде моны». Эчтән генә «аяклы каза»ның әнисенә төбәлгән, баштан ук аңа әйтергә кирәк булган сүзләрне уенда кабатлады Искәндәр һәм барысына да яңадан кул селтәде. «Ярар, су китереп бирсәм, укам коелмас тагын...»

Малай урыныннан сикереп төшкән дә, ләгәнен күтәреп, Искәндәрне көтеп тора иде инде. Егет кайнар су белән эскәмияне юып төшерде, пешекләде, ләгән күзеннән тутырып, җылымса су китереп куйды.

— Әйдә, башла! Мин бераз чабынып чыгам...

«Аяклы каза» ризалыгын белдереп беренче тапкыр елмайды, нәзек беләкле кечкенә кулларын суга тыкты. Ә Искәндәр, каен себеркесен култык астына кыстырып, чабыну бүлмәсенә китте. Ишекне ачар алдыннан гына кинәт сизде: үзенә кемдер карап тора кебек иде. Мондый тоемны аңлатып булмый. Ул баш чүмеченең, арка сөякләренең чымырдап китүе шикелләрәк сәер бер тойгы. Борылып карады һәм... ишек янындагы утыргычтан үзенә төбәлгән зәңгәр күзләрне күрде. Малай керфеген дә какмыйча аңа карап тора иде. Ишек ачарга су-

зылган кулы кире төште, юк, төшмәде, баш биеклегенә күтәрелде дә чакыру ишарәсе ясады. Бусы Искәндәрнең үз ирегеннән башка килеп чыкты бугай. Шушы ишарәне генә көтеп утырган кебек, малай эскәмиядән сикереп тә төште, очынып, чабып-йөгереп, юеш идәннән тая-тая Искәндәр янына ашыкты.

— Аһ, шайтан алгыры, егылмаса гына инде!..— дип, уйлаганын пышылдап өлгерде Искәндәр һәм малайны беләгеннән эләктерде.

Чабыну бүлмәсенә җитәкләшеп керделәр. «Аяклы каза»га әйтерсең лә җан керде. Ул, әйткәнне дә көтеп тормыйча, ләүкәнең аскы бүлеменә үрмәләде, аякларын асылындырып, менеп тә утырды.

Пар эчендә изрәгән, чабыну ләззәтенә чумып ухылдашкан ирләрнең себеркесеннән җилләнгән кайнар һава колакларны өтеп ала. Ләүкә такталары астындагы торбадан сызгырып пар чыга, тынга каплана. Искәндәр бер-ике тапкыр тирән сулады да ләүкәнең иң өске катына менеп басты. Мәтрүшкәле каен себеркесеннән борыннарын ярып хуш ис таралды, чалт та чолт суккан тавышларга тагын бер аваз өстәлде. Тәне кызарып чыкканчы, кызыша башлаганчы чабынды ул.

Ир-атлар ах-ух килештеләр, кемдер йөрәкләнеп: «Давай, парны өстә!.. Тагын... Тагын!»— дип кычкырып җибәрде. Аста утыручы егетләрнең берсе, хәйләкәр елмаеп, кранны соңгы чигенә җиткереп ачты. Тыгыз, куе, кайнар пар түшәмгә ыргылды, анда сыешыр урын таба алмыйча аска таба ургылды.

— Кем малае бу?..— дип кычкырды эссе парга чыдай алмыйча ләүкәдән төшеп барган ир-атларның берсе.— Алып чыгыгыз моны, янып үлә бит бала!..

— Аһ, шайтан алгыры! — Чабынган арада бөтенләй онытып җибәргән иде, Искәндәр шунда гына «аяклы каза»ны исенә төшерде. Астагы ләүкәдә кулларын күкрәгенә кушырып, туңгандай бөрешеп утырган кечкенә гәүдәне табуга «исемен дә белмим бит» дип уйлап алырга өлгерде. Малайның күзләрен күрергә теләп аска иелде. Олы зәңгәр күзләр дә аны эзли иде булса кирәк, менә карашлары очрашты. Искәндәр аңа күз кысты, үз итеп елмайды:

— Чыдап буламы?

«Аяклы каза»ның бөтен бите җәелгән, бу минутта малай рәхәтләнеп елмая иде.

— Бар, чыга тор! — дип кычкырды Искәндәр ишеккә күрсәтеп.— Юына тор! — Куллары белән юыну хәрәкәтләре ясап алды.

Малай баш чайкады. Бусы — «Синең белән бергә чыгам» дигәнне аңлата иде булса кирәк.

Шулчак егетнең башына суктылармыни, олы ирләр чак түзә торган эсседә ничек утыра соң бу малай? Кеше баласы ич ул!.. Бер-бер хәл булса... Ләүкәдән ничек сикереп төшкәнен сизми дә калды Искәндәр.

...Ишек төбендәге эскәмиядә бер ир белән кечкенә малай юына. Читтән күзәткән кешеләр аларны ата белән ул дияр иде, яшь этинең күнекмәгән хәрәкәтләрен дә абайламый калмас иде.

Тагын бер кат чабынасы килсә дә, Искәндәр үзен тыеп калды. Җылылыгын чамалап кына ләгәннәргә тагын су тутырды. Аның гәүдәсенең һәр бөгелешен, ничек атлавын, ничек елмаюын, сөйләшүен күңел дәфтәренә сеңдереп утырган малай беренче булып телгә килде:

— Абый, әллә син татармы?

— Әйе.

— Мин дә татар!

Аның ничектер сузып, «мин дә» дигән сүзгә үзенчә басым ясарга тырышып әйтүендә шушы көчле абый белән бер кавемнән булуга, шул ягы белән генә булса да аңа охшаганлыгына горурлану, беркатлы, самими сөенү ярылып ята иде. Күрәсең, малай ике арада охшашлык табарга тырыша, шуны эзли.

Искәндәр елмаймыйча булдыра алмады, аның юеш сары чәчләреннән сыйпап куйды, икесе өчен дә уртак телгә — туган телгә күчте. Бу телгә күчү рәхәт иде, тансык иде. Теш арасында буталып, тел очында әйләнгән теге паразит сүзләр бу телдә бөтенләй кирәк түгел, алар юк...

— Исемең ничек синең?

— Азат! Ә синең?..

— Мин Искәндәр абыең булырмын. Иә, үскәнем, әйдә, юынып җибәрик әле. Юкса, кызлар яратмас үзебезне.

— Яратмасынна-а-ар,— дип сузды малай.— Мин дә аларны яратмыйм.

— Менә тагы... Нигә?

— Алар елак!..

— Ә кемне яратасың соң син?

— Әниемне яратам, әби-ем-не-е...

— Тагын?..

Азатның күзләрендә моң, зурларча җитдилек тоеп, Искәндәр үзенең урынсызрак сорау бирүен аңлап алды. Әмма соң иде инде. Малайның башы акрын гына аска иелде. Үзеннән тагын нинди җавап көткәннәрен ул бик яхшы аңлый иде булса кирәк. «Елап җибәрмәсен тагы. Шул гына җитмәгән иде. Чистый нәнкәгә әверелдем. Тизрәк юынырга да котылырга кирәк моннан». Искәндәр — уйлаганын тиз эшли торган кеше, учына сыек сабын агызып, куе, тыгыз чәчләрен юарга кереште. «Бетмәс монда!» Әмма үзе ышандырып алып калган «аяклы каза»га күз-колак булмыйча да ярамый иде.

Сиздермичә, каш астыннан гына күзәтә башлады. Азат кулларын озаклап сабынлады, юка тиресе аша кан тамырлары беленеп торган ябык гәүдәсен сыйпап юарга кереште. Көчле абыйның үзенә карап торуын сизгәч, бик җитди итеп аңлатып бирде:

— Мине әбием шулай юындыра.

Искәндәрнең күңелендә ниндидер бер кыл тартылып өзелгәндәй булды, туган авылы, гомерендә бер тапкыр да күтәрелеп кешегә авыр сүз әйтә белмәгән ак йөзле әбисе күз алдына килде. Нәни чагында үзенең дә әбисе белән мунчага йөргәннәре, аның назлап кына, иплән кенә чабындырганы, юындырганы исенә төште. Кечкенә малайның бер сүзе хәтер чоңгылларында мәңгелеккә күмелгән дип исәпләнгән, моңарчы беркайчан да уйланмаган, әллә нинди үтә якын, үтә дә газиз истәлекләрне яңартты.

— Их, син,— дигәнен сизми дә калды Искәндәр, малайны кулыннан мунчаласын алып мул итеп күбекләде дә ничек тотынырга белмичә, аптырап, як-ягына каранды. Әнә, башка аталар малайларын эскәмиягә менгереп яткырганнар, шау күбеккә батырып, кычкыртып мунчала белән ышкыйлар. Алсу тәннәре генә ялтырап тора бахырларның. Искәндәр бер үзенә, бер «аяклы каза»га күз төшерде дә тәвәккәлләде: кочаклап, малайны эскәмиягә бастырды, иңсәсеннән тотып, мунчала белән аркасын, беләкләрен ышкып юарга кереште. Башкалар кебек шырыйлап кычкырмады малай. Ул сүзсез иде, ул бу мизгелләрне хәтеренә мәңгегә сеңдереп калдырырга теләгәндәй күзләрен йомган, тавышсыз гына елый шикелле иде. Аркасын юып бетерде, үзенә каратып борды, кинәтрәк тотындымы — егылып китә язган малай ике куллап аның муеныннан кочып алды. Шул чакта әллә нәрсә булды, Искәндәрнең бугазына төер килеп тыгылды, сабын күбеге чәчрәдеме — күзләре ачытып-ачытып яшьләнде. Бу минутларда аңа шушы ябык, бөтен барлыгын аңа ышанып тапшырган, аңа сыенган «аяклы каза»дан да кадерлерәк нәрсә юк иде сыман. Аның көче, шыгырдап торган мускулларындагы гайрәт кемгәдер кирәк икән бит, моңарчы үзе белмәгән кемнедер яклау, таянычы, арка терәге булу хисе котылгысыз дулкын булып күтәрелә, шушы ярдәм-

чесез җан иясе өчен утка-суга керергә әзерлеген күрсәтергә чакыра иде кебек.

Әле генә ничек тотынырга белмәгән арык гәүдә хәзер куркытмый да, берәр җирен авырттырырмын дип шикләндерми дә иде. Искәндәр малайны очыртып кына душ астына кертеп чыгарды һәм култык астына мәче баласыдай кыстырып, җиңел хәрәкәтләр белән чишенү бүлмәсенә алып чыкты.

Мунчага кергәндә үзе үртәлеп утырган бала-чагага, басынкы гына елмаеп аларны күзәткән ир-атка хәзер бөтенләй башка күз белән карый башлавын ул үзе, әлбәттә, сизми иде. Алар янәшәсендә чишенгән ир дә яңа гына чыккан, күрәсең. Тәненнән бөрчек-бөрчек тир ага, аркасына, ботларына ябышкан себерке яфракларына да игътибар итмичә, кечкенә малае белән әвәрә килә. Утыргычка тастымал җәеп бастырган да: «Әй, шәп тә булды! Чәп-чәп иттек...» — дип сөйләнә-сөйләнә улының тәнен корыта. Менә икенче тастымалга төреп утыртты, киемнәр арасыннан пыяла савыт тартып чыгарды:

— Менә хәзер карлыганлы чәй эчеп җибәрәбез дә, өйгә — әниең янына... Сагынып беткәндер инде. Ие бит. Коймак пешереп көтә торгандыр.

Искәндәрнең үзенә карап-карап алуын сизеп булса кирәк, борылып Азатка ишарәләде:

— Улыңа чәй алып килмәгәнсең икән. Мунчадан соң минеке бер банканы эһ тә итми...

— Зыян юк. Чыккач без газлы су эчәбез. Иеме, Азат,— диде Искәндәр бер дә исе китмәгәндәй.

Букчасыннан киң, озын тастымалын чыгарды, малайны төреп утыртты да пинҗәк кесәсеннән сигарет алды. Аны бармаклары белән йомшарткалап, авызына капты, шырпы сызар алдыннан кылт итеп кайдадыр укыганы искә төште: «Тәмәке төтене балаларга аеруча зарарлы!» Үзалдына көлемсерәп, читкә — тәмәкечеләр өчен өчпочмаклап куелган буш эскәмияләр янына китеп барды.

«Улың!» Күршедәге ир әйткән сүзнең мәгънәсе зиһененә әле яңа гына барып җиткән иде аның. «Улың!.. Улым! Минем малай!» Теле сүзсез генә үтә дә газиз, кадерле тоелган сүзләрне кабатлый да кабатлый: «Улым! Улым!» Ничек моңарчы белмәде икән, җир йөзендә моннан да матур, моннан да мәгънәле, якын, кадерле бүтән сүз бар микән?! Юыну бүлмәсендәге халәте кабатланды, бугазына утырган төер тәмәкесен юньләп тартырга ирек бирмәде...

Киенеп чыктылар. Әле генә кояштай балкыган малай сүлпән генә елмайды, йөзенә өлкәннәргә хас киеренкелек, җитдилек кайтты. Үзенең учында кечкенә, җылы кул тоюдан рәхәт бер горурлык кичереп атлаган Искәндәрнең аны тагын елмайтасы, рәхәтләндереп көлдерәсе, нәни йөзендәге авыр җитдилекне алып ташлыйсы килә иде.

— Ә хәзер, әйдә, туйганчы су эчик! — диде ул тавышына шаянлык, шуклык өстәргә тырышып. Тик сүзләре ясалма килеп чыкканын үзе дә сизде. Кесәсеннән ике өчтиенлекне эзләп тапты, берсен автомат ярыгына төшереп җибәргәч, ширбәт агып бетүгә, стаканны читкә алып торды һәм малайларча мутланып Азатка күз кысты, икенче бакырны ташлады. Малайларның ике ширбәтле су эчәргә яратуын ул белеп өлгергән иде инде.

Азат стаканны авызына китергәнче Искәндәргә күтәрелеп карады:

— Ә үзең... эчәсеңме?..

— Мин соңыннан,— диде Искәндәр. Бүтән бакыр акчалары юклыгын белсә дә, кесәләрен капшаган булды. Аның һәр хәрәкәтен күзәткән малай буш стаканны автоматка куйды һәм тез башлары бүлтәеп чыккан сары вельвет чалбары кесәсеннән өчтиенлек табып, Искәндәргә сузды.

— Менә, әнием биргән иде...
Искәндәр тагын су агызды.
— Ю-у-ук! Мин бүтән эчмим... Ә-ә... — Малай нииндидер сүзне әйтеп бетермәде, әллә тотлыкты — бите алсуланып китте, зәңгәр күзләре озын, куе керфекләре арасына кереп поскандай тоныкланып калды.
Искәндәрнең йөрәге дерт итеп китте. Нигә тотлыкты соң әле бала? Ни булды? Әллә...
Тамагыннан су үтмәде Искәндәрнең. Малайны да, үзен дә артык сынамаска, җан кыйнамаска карар бирде. Бу очрашу әллә нинди газаплы төшкә охшый башлаган иде.

Мунчаның алгы ягында кеше аз. Стена буена тезелгән урындыкларда берничә карчык кына гәп куерта. Азат тиз генә залга күз йөгертеп чыкты, йөзеннән нииндидер караңгы күләгә узгандай булды.
Икесе дә бер-берсенә карашып, сүзсез калдылар.
— Ярый, Азат, мин китим инде. Сау бул! — Искәндәрнең олыларга биргәндәй сузган учына малайның кулы теләр-теләмәс кенә ятты.
— Сау бул,— диде ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.
— Хуш! Киттем...
Кай арададыр үзенә якын, кадерле булып өлгергән бу малайдан аерылу Искәндәргә авыр иде. Китәсе килми, аның белән җитәкләшеп, нәрсә турында булса да сөйләшә-сөйләшә, бергәләп урамнардан атлыйсы иде!.. Ләкин ничек кенә сузмасын, барыбер китәргә, аерылырга туры киләчәк. Шушы сәер халәттән тизрәк котылу өчен кырт борылды да эре адымнар белән ишеккә таба атлады. Тик соңгы тапкыр малайны тагын бер кат күреп каласы, үзендә моңарчы барлыгы да беленмәгән хисләр өермәсен кузгаткан кечкенә кешене хәтеренә сеңдерәсе килү теләге аны тукталырга мәҗбүр итте. Ишеккә җитәрәк адымнары әкренәйде, күзгә күренмәс киртәгә барып төртелгәндәй туктап калды һәм артына борылды. Хатыннар янындагы буш урындыкка чүмәшкән малай яңгырда күшеккән чыпчык баласын хәтерләтә иде. Менә карашлары очрашты. Малай кыяр-кыймас кына Искәндәргә якынлашты, хуҗасының күзенә карап әмер көткән тугрылыклы эт мисалында сүзсез басып калды. Тын гына тордылар.
— Әнием миңа шушында көтәргә кушты,— диде, ниһаять, малай акрын гына.
— Ярый, Азат, син көт инде!
Искәндәрнең аны башыннан сыйпыйсы, кочаклап юатасы килеп китте. Ләкин үзен тыеп калды... ишекне акрын гына ачып урамга чыкты.
Шәһәр өстендә кичке утлар кабынган. Тагын да җиләсләнә төшкән. Мунчадагы эсседән соң Искәндәрнең бөтен тәне әллә ничек куырылып килгәндәй булды. Ул якаларын торгызды да, якынаеп килүче трамвай утларын күреп, тукталышка ашыкты. «Иртәгә таң белән юлга чыгасы! Алда — бер айлык командировка!» Шәһәр урамнарындагы кичке тормыш аны яңадан көндәлек мәшәкатьләренә кайтарды.
Трамвайның ишекләре ачылды, килгән шапкә сикергән Искәндәрнең миеннән яшен тизлеге белән бер уй йөгереп узды: «Бер айга бит! Тоташ бер айга!..» Инде ябыла башлаган ишекләрне үз-үзен белештермичә көч белән каерып ачты да яңадан төнге утлар балкыган урамга килеп төште. Трамвай йөртүченең: «Хулиган!» — дип артыннан кычкырып калуы да, тукталыштагы кешеләрнең шелтәле баш чайкавы да аңа хуплау гына булып тоелды. Эре-эре атлап яңадан мунчага таба китеп барды. Бүген аңа Азатны да... аның әнисен дә, һичшиксез, тагын бер кат күрергә кирәк иде...

*М. Сеспельнең тууына 90 ел*

# ЯҢА ЧОР ҖЫРЧЫСЫ

*Михаил Сеспель (1899—1922) чуваш поэзиясендә аерым урын тота. Аңардан соң килгән шагыйрьләргә аның йогынтысы искиткеч көчле булды.*

*Сеспель — чуваш телендә умырзая дигән сүз. Җир үзенең уянуын һәм яңаруын дөньяга шул яз чәчәгенең керфек кагышы белән белгертә. Шагыйрьнең исеме җисеменә бик тә туры килә: чуваш халкының күп гасырлык йокыдан уянуы, аларның милли изелүдән котылуы турында беренче авазны салучы нәкъ менә Михаил Сеспель иде.*

*М. Сеспель (Михаил Кузьмич Кузьмин) Чувашиянең Канаш районы Шөгер авылында (хәзер ул шагыйрь исемендә) ярлы крестьян гаиләсендә туа. Шихазан авылындагы ике класслы мәктәпне тәмамлагач, булачак шагыйрь 1917 елда Тәтешкә килә һәм укытучылар семинариясендә укый башлый. Сеспель биредә комсомол ячейкасын оештыруда башлап йөри, ә 1918 елда яшь шагыйрьне партия сафларына кабул итәләр. Бер елдан соң ул Мәскәүдәге пропагандистлар курсына укырга килә һәм Ленинның чыгышын тыңлау бәхетенә ирешә. Әдәби иҗатын шагыйрь иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән бергә бәйләп бара. 1920 елның язында Казанда чуваш яшьләренең Беренче Бөтенроссия съезды уза. Биредә аны комсомолның Казан губерна комитетындагы чуваш секциясе бюросы әгъзасы итеп тәкъдим итәләр. Чуваш автономияле өлкәсе төзелгәч, шагыйрь Чабаксарга күчә һәм өлкә башкарма комитетының юстиция бүлеге мөдире булып эшли башлый. Ләкин революциягә бөтен күңеле белән бирелгән Сеспельгә нахак гаеп ташлыйлар, ул кулга алына. Бала чактан ук сөяк туберкулезы белән изаланган шагыйрьнең авыруы көчәя. Озак вакыт госпитальдә ятканнан соң шагыйрь Кырымда дәвалана һәм Киевка килеп, Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Бераздан Сеспельне Чернигов губерниясенең Остер өязенә эшкә җибәрәләр.*

*Чабаксарның үзеннән йөз чөерүе, чит җирләрдәге кыенлыклар шагыйрьнең рухын сындыра. 1922 елның 15 июнендә ул үз-үзенә кул сала.*

*Аның язган күп әсәрләре безнең көннәргә килеп җитмәгән, төрле сәбәпләр аркасында юкка чыккан. Әмма Михаил Сеспельнең революция идеалларына тугрылыклы ялкынлы шагыйрь булуы сакланып калган шигырьләрендә дә ачык күренә.*

**Юрий СЕМЕНДЕР.**

Чувашстан комсомолының М. Сеспель
исемендәге премиясе лауреаты.

## Михаил Сеспель

### Киләчәк

Жил-давыл үтәр дә
Илаһи табигать
Сөенеп кушылыр тынычлык җырына.
Һәм гүя әкияти көмеш йорт шикелле
Җемелдәр бу дөнья ал кояш нурында.

Азатлык өчен дип җан биргән затларның
Каннары сеңәр дә чәчәкләр таҗына,
Коелган күз яше сарылыр гөлләргә —
Чык булып тибрәнер Кешелек язында.

Югалыр ярлылык — шул каһәр төшкере!
Өр-яңа тормышта урын юк аңарга.
Тигезлек, туганлык, мәхәббәт хакына
Без әзер һәрвакыт ут булып янарга.

## Чуваш улына

И туган җир, әйтче миңа:
Күңелем моң-зар тулы —
Кайчан туар бу халкымның
Телен данлыйсы улы?

Дәшегез, чуваш уллары! —
Кемнең йөрәге кайнар?
Ил-халык өчен андыйлар
Соң минуткача янар.

Күтәрелер чуваш халкы,
Без — беткән түгел әле.
Шигырең белән дөрләт тик
Сүрелгән күңелләрне.

Чабаксардан Кавалгача
Халкың җырыңны ятлар.
Илеңдәге һәрбер чуваш
Исемеңне кабатлар.

Бу чакыру юкка булмас,
Ышанам, килер ул көн:
Яңгырар чуваш шигыре —
Шаккатып тыңлар төркем.

## Яңа көн

Таңгы шәфәкъ дөрли төрәннәрдә,
Тәртәләрдә — кояш.
Бәхет җырын
Көйләп
алтын чәчле бу көн
Эшкәртергә чыга чуваш кырын.
Алсу төрән җиргә батып керә,
Бураэналар артта. Кешем, күр, син! —
Чувашларның зары, кара көне
Аста кала шулай.
Кала күрсен!
Көн кулында алтын сабан балкый,
Чишмәләрнең алкын, саф сулары
Йөгерәләр яшел болын аша,
Сугарырга иркен басуларны.
Өр-яңа көн кайнар кулы белән
Йолдызларны үрелеп ала тагын —
Орлык итеп сибә киң кырларга,
Уңыш җыяр тиздән туган ягым.
Чувашларның якты язмышы бу!
Җилләр орыныр да әкрен генә,
Халкымның зур сөенече булып
Шыпыр[1] моңы сибелер җир йөзенә.
Яңа чорда үскән чуваш улы
Иңе белән тотар күк гөмбәзен.
Аның рухын яңгыратыр өчен
Кирәк булыр җырга яңа вәзен.

*Ркаил ЗӘЙДУЛЛИН тәрҗемәләре.*

---

[1] Шыпыр — чувашларның уен коралы.

# ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫН АЧКАНДА ӘМИРХАН ЕНИКИ СӨЙЛӘГӘН КЕРЕШ СҮЗ

Хөрмәтле иптәшләр! Кадерле кунаклар!

Вакыт — аяусыз, бер генә мизгел дә туктап тормый ул! Унынчы съездан соң менә 5 ел үтеп тә китте. Бу вакыт эчендә без күп кенә каләмдәш дусларыбызны югалттык. Рөхсәт итегез, аларның исемнәрен атарга:

**Әминә Бикчәнтәева, Ян Винецкий, Мөхәммәт Гайнуллин, Гариф Галиев, Тихон Журавлев, Газиз Иделле, Эдуард Касыймов, Галимҗан Латыйп, Мөнир Мазунов, Гөлсем Мөхәммәдова, Газиз Нәбиуллин, Зиннур Насыйбуллин, Ринат Рәхимов, Мәҗит Рафиков, Дмитрий Сычев, Сибгат Хәким, Шамил Шәһгали.**

Иптәшләр, арабыздан вакытсыз киткән бу кадерле каләмдәш дусларыбызны аягүрә торып, бер искә төшерик!..

Сез беләсез инде, шәхес культы хакимлек иткән заманда күпме халыкның төрмәләрдә үтерелгәнен, лагерьларда кырылганын. Аеруча, безнең татар культурасы, татар әдәбияты ул елларда кайтарып ала алмаслык зур югалтуларга дучар ителде. Әнә шул һич гаепсезгә, нахакка һәлак булган Сталин корбаннарын да, иптәшләр, аягүрә басып башларыбызны түбән иеп, искә төшерик!..

Безнең съезд бик җаваплы һәм, әйтергә кирәк, бик киеренке бер вакытта җыелды. Менә дүрт ел инде, илебездә үзгәртеп кору дәвам итә. Бу вакыт эчендә халык аңында зур үзгәрешләр туды, халыкның күп нәрсәгә күзе ачылды һәм, иң мөһиме, канына сеңгән иске карашларны җиңә-җиңә, ул инде дөньяга яңача карый, яңача фикер йөртә башлады... Без язучылар да нәкъ шушы процессны кичерәбез. Иске карашлардан әкренләп арынабыз, яңача уйларга, заманны яңача аңларга тырышабыз. Мәгәр язучы исемен йөрткән кешедә бу процесс тизрәк тә һәм тирәнрәк тә булырга тиеш, минемчә. Чөнки без үзебезнең иҗатыбыз белән турыдан-туры халыкның аңына һәм рухына тәэсир итүчеләр. Моның шулай икәнен соңгы 3-4 ел бик ачык күрсәтте, бигрәк тә рус әдәбияты бу җәһәттән искиткеч үрнәкләр бирде. Ләкин татар әдәбиятының бу өлкәдә мактанырлык эше һич тә җитәрлек түгел әле.

Хәлбуки, үзгәртеп кору безнең алдыбызга бик күп җитди проблемалар китереп куйды. Алар илебез язмышына кагыла, җәмгыятебезнең киләчәген билгели. Шуның өстенә безнең эчке хәлебез бөтен кешелек дөньясы мәнфәгатьләре белән дә тыгыз бәйләнгән... Димәк, болар барысы да хәзерге татар әдәбиятында да үзенең чагылышын табарга тиеш булачак.

Әмма һәрбер милли әдәбиятның үзенә генә хас проблемалары да була. Булмыйча мөмкин түгел. Татар әдәбиятына карата бу икеләтә дөрес. Оешмабыз Татарстан исемен йөртсә дә, без бит барлык татар халкының язучылары... Һәм әдәбиятка да без төрле яклардан килдек. Безнең укучыларыбыз да Балтик буйларыннан алып, Тын океан ярларына чаклы җирләрдә яшиләр. Мәгәр кайда гына, кемнәр арасында гына яшәмәсеннәр, алар бөтен бер милләт! Дене дә, теле дә, мәдәнияты да бер. Моның шулай икәнен җиде миллионга якын халкыбызның бөтен үткән тарихи юлы күрсәтеп тора.

Кызганычка каршы, соңгы 40—50 ел дәвамында милли мөнәсәбәтләрне билгеләгән Ленин принциплары бик нык бозылды. Нәтиҗәдә милли тигезлек, милли гаделлек, милли хокуклар онытылып бетә язды. Күп өлкәләрдә мәктәпләрнең ябылып бетүе, газета-журналларның чыгудан туктавы, китапларыбызның аз таралуы, читтәге укучыларга барып җитмәве шуның бик ачык мисалы... Хәзерге вакытта татар халкы туган телен әкренләп югалту куркынычы алдында тора. Бу арттырып әйтү түгел, иптәшләр! Матбугатта чыккан мәгълүматларга караганда, Татарстанда татар балаларының

12 проценты гына. Россия күләмендә исә бары 7 проценты гына ана телендә укытыла. Ә телне югалту ул милләт булудан туктау дигән сүз. Бу инде, иптәшләр, язмыш мәсьәләсе!

Әйе, заман язучылар алдына зур проблемалар китереп куйды. Без сулый торган һавабызны, эчә торган суыбызны, ашый торган ризыгыбызны сакларга тиешбез. Әмма шулар белән бергә без үзебезне, башка халыклар шикелле үк, милләт буларак та сакларга тиеш булачакбыз. Бу кирәк, бу да заман таләбе. Чөнки шунсыз халыклар арасында тигезлек тә, чын дуслык та була алмаячак.

Әнә шул изге максаттан чыгып, без үзебезнең иҗатыбыз белән халкыбыз аңын уятырга, рухын яңартырга, иманын терелтергә тиешбез. Халкыбыз шуңа мохтаҗ, аның милли тигезлеккә һәм милли гаделлеккә хакы бар. Моны ул шушы 70 ел эчендә үзенең фидакарь хезмәте һәм Ватан өчен түккән каны белән исбат итте. Партиянең милли мәсьәләләргә багышланган Пленумын без зур өметләр белән көтәбез.

Билгеле, без бу съездда үзебезнең төрле жанрдагы иҗатыбыз турында да, союзның эшенә карата да төпле, җитди сүз алып барырга тиешбез. Әйтер сүзләр, хәл ителәсе мәсьәләләр 5 ел эчендә аз җыелмагандыр... Кыскасы, беренче мәртәбә бөтенләй яңа шартларда җыелган безнең бу съездыбыз хәбәрдарлык таләп иткәнчә, чын демократик рухта үтәр дип ышанасы килә... Инде, иптәшләр, рөхсәт итегез, Татарстан язучыларының XI съездын ачык дип белдерергә!.. Хәерле сәгатьтә!

## Туфан Миңнуллин

# КАЛӘМЕБЕЗ, СҮЗЕБЕЗНЕ ЭШКӘ ҖИГИК!

Бүген минем, сезнең белән бергәләп, язучыларны гына түгел, ә бар кешене дә дулкынландыра торган проблемалар хакында уйланасым, фикер йөртәсем, гомуммилли культурабызның бер өлеше булган әдәбиятыбызда эшнең торышына җентекләбрәк күз саласым килә. Биредә безнең уйланырдай, сөйләшердәй нәрсәләребез җитәрлек.

Хәзер бездә үткәннәрне тәнкыйть күзлегеннән уздыру, аларга яңача төшенү процессы бара. Бу закончалыклы хәл. Чөнки моңарчы илебездәге хәлләрне үз вакытында һәрьяклап, хәбәрдарлык һәм демократия шартларында фикерләү мөмкинлегебез булмады. Тәнкыйть фикерләре барыбызда да тупланып килде, һәм алар менә хәзер, партиябезнең җәмгыятьне демократияләштерү политикасы үткәрүе нәтиҗәсендә тышка бәреп чыкты. Табигый ки, безнең съездыбызда да үзебезнең иҗади һәм оештыру эшчәнлегебезгә карата тәнкыйтьчел бәяләмәләр аз булмастыр.

Шулай да, әйдәгез әле, башта үзебездә булган нәрсәләргә күз салып үтик. Чөнки булган нәрсәләрне генә тәнкыйтьләргә мөмкин ич.

Соңгы вакытта радио һәм телевидение тапшыруларында, матбугат битләрендә соңгы унъеллыкларда иҗат ителгән нәрсәләрне кире кагуларны ишетергә-күрергә мөмкин. Кайбер белдерүләргә һәм раслауларга караганда, әдәбиятыбыз тирән кризис хәлендә, ул вак темалар, региональ һәм провинциаль проблемалар белән генә мавыга, философия концепциясе юк... һәрхәлдә, миндә шундыйрак тәэсир кала. Мондый раслаулар белән тулысынча килешеп буламы икән? Бездә сенсацияле, аяктан егарлык әсәрләр булмагандыр, бәлки. Әмма, минем уйлавымча, бездә спекуляциягә нигезләнгән, конъюнктур әсәрләр дә алай күп түгел. Безнең әдәбиятыбызга тотрыклылык хас. Бу, миңа калса, татар язучыларының барысының да диярлек авылдан чыккан булуы белән аңлатыладыр. Ә авыл кешесенең характеры тотрыклы, һәм аның үз-үзен тотышында утраклык, даимилек һәм консерватизм күбрәк, бер яктан икенче якка ташланулар азрак. Татар язучылары тормышыбызны нәкъ менә шушы даимилек күзлегеннән чыгып өйрәнделәр һәм өйрәнәләр. Аларның әсәрләрендәге геройлар, үзләре кебек үк, безнең «бөек үзгәрешләребез»не һәрвакытта да аңлап ук бетермәделәр, аларның чынбарлыкны аңлау ритмы хәзерге тормышның ярсулы ритмына туры да килми. Шунлыктан алар рәхимсез һөҗүм итүче «цивилизация» белән һәрвакыт диярлек эчтән генә конфликтта яши-

лар. Ихтимал, менә бу кемнәргәдер провинциальлек булып, региональ проблема булып күренәдер. Болай дип белдерүчеләр, мөгаен, дөнья проблемалары белән, космос белән эш итәләрдер. Әмма мондый нәтиҗә ясау белән кайчак үзләренең ни сөйләгәннәрен дә ачык аңлап җиткермәүче кешеләр шөгыльләнә. Андыйлар миңа бер авыл малаен хәтерләтә: шәһәрдә йөргәндә ул берничә сәер сүз өйрәнеп ала да, авылга кайткач шуларны кабатлап, мактанып сөйләшергә ярата, ә үзе бу сүзләрнең мәгънәсен белми дә. Әйдәгез, прозаикларыбыз тарафыннан өйрәнелә торган кайбер проблемаларга дикъкать беләнрәк карыйк әле.

Авыл үзенең гасырлар буена килгән традицияләрен җуйды, ә аларга алмашка берни дә ала алмады: буыннар арасындагы бәйләнеш бозылды; бушап калган авыллар— бушап калган күңелләр; җир үзенең кайгыртучан хуҗасыннан мәхрүм булды. Әйтегез әле, бу региональ проблема гынамыни? Йөрәк җылысын кешеләргә бүләк итүче хатын-кыз моңа алмашка берни дә алмый. Бу хатын-кызның тормышы провинциальлекмени? Кешеләр башкаларга төшкән кайгы-хәсрәтне аңламый һәм сизми башладылар; үзенең туган җиреннән куылган крестьян кайдадыр каңгырап йөри; яшәүне бәхет дип кабул иткән утызынчы еллар яшьләре үзләре кебек миллионнар белән бергә, җәһәннәм михнәте кичерә; ниһаять, халкыбызның әле өйрәнелмәгән яки халыкка кыргый җимерүче ярлыгы тагу өчен генә өйрәнелгән ерак тарихы... Провинциаль проблемалармыни болар?

Ә шигъриятебез нинди безнең? Бүген бездә Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан традицияләрен талантлы дәвам иттерүчеләр бармы? Бар, иптәшләр! Һәм алар берәү-икәү генә түгел. Иң яхшы шагыйрьләребез кеше алдындагы җаваплылык хисен беркайчан да югалтмадылар, алар үз халкының сызланулы уй-фикерләрен һәрвакыт күңелләрендә йөрттеләр. Әйе, безнең шагыйрьләребезнең җитешсезлекләре аз түгел, әмма алар арасында битарафлыктан симергән шагыйрь кисәкләре булмады, юк һәм, мин ышанам, булмас та. Безнең поэзиябез, әдәбиятның башка жанрлары кебек үк, ныклы нигездә тора. Ул үзенең һәвәскәрлек чорын моннан мең еллар элек үк үтте инде. Безнең поэзиябез үз эшләренең профессионаллары белән иҗат ителә. Шунлыктан һәртөрле мавыгулар, төрле модалар аның нигезен какшата алмый. Тумыштан сәламәт организм һәртөрле авырлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле.

Балалар әдәбияты турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Безнең балалар язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез үз укучылары белән беркайчан да уен уйнамадылар, ә алар белән һәммәсе дә аңларлык итеп җитди сөйләшү алып бардылар. Кызганычка каршы, үсмерләр белән уртак тел таба алмыйбыз әле. Контактыбыз җитми. Массовый культура яшьләребезнең рухын агулый, аларны бездән аера. Кешелек культурасының шушы куркыныч дошманына каршы тору формаларын табасы иде.

Драматургияне без я чиктән тыш мактап күкләргә чөябез, я рәхимсез төстә тәнкыйтьлибез. Әмма ул, шөкер, яшәүчән булып чыкты һәм яшәр дә. Аның тамырлары нык, кәүсәсе сәламәт, шулай булгач, яшь ботаклары үзеннән-үзе чыгар.

Публицистикага җентекләбрәк тукталасы килә. Чөнки ул бүген әдәбият фронтының алгы линиясендә. Әйе, бу жанрда безнең темалар төрлелеге җитми, проблемаларның киңлеге һәм тирәнлеге канәгатьләндерми. Без күбрәк мәгърифәтчелек белән мәшгуль. Без үз мәкаләләребездә татар интеллигенциясе тарафыннан моннан йөз ел һәм аннан да күбрәк элек күтәрелгән проблемаларны кузгатабыз. Әмма бу безнең язучыларыбызның гаебе түгел. Октябрь революциясе нәтиҗәсендә канат җәйгән татар милли культурасы һаман чәчәк атуга таба барды. Ләкин тора-бара ленинчыл милли политиканың бозылуы аның үсешен туктатты. Без бүген туган телебезнең юкка чыгуы чигендә торабыз. Кешелек мөнәсәбәтләренең әле өйрәнелмәгән тирән катламнарын эшкәртәсе урында, без туган телебезне саклау кирәклеге турында язарга, ике икең дүрт икәнлеген исбатларга мәҗбүр булабыз. Әйе, безне моңа мәҗбүр иттеләр. Һәм без башкалар мондый хәлнең куркыныч булуын аңлаганга кадәр шуны исбатларга бурычлыбыз. Без моны туган телебезне өйрәнү турында сүз боткасы тукталганчыга кадәр, бетерелгән милли мәктәпләрне, балалар учреждениеләрен торгызу өчен шартлар тудырылганга кадәр сөйләячәкбез. Гомуми мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында туган телне өйрәнү түгәрәкләре — бары тик кислород мендәре генә алар.

Әмма туган тел проблемасы ничек кенә тормасын, безнең башка мөһим гомумкешелек мәсьәләләренә кул селтәп карарга хакыбыз юк. Мәсәлән, без «экология» сүзен еш кулланабыз. Ләкин сөйләшүне профессиональ дәрәҗәдә алып бару өчен аны һәрвакытта да тирәнтен өйрәнмибез. Заман хәзерге публицистлардан экономика, социаль һәм политика мәсьәләләрен дә тирәнтен белүне таләп итә. Әгәр моннан ун-унбиш ел элек дилетантлык бик үк сизелмәсә дә, бүген, кем әйтмешли, белемнән башка ерак бара

алмыйсың. Ә өйрәнелә торган теманың эчке серләрен яхшы белү бер публицистикага гына кагылып калмый.

Безнең бай традицияләребез, әдәби иҗат мәктәбебез бар. Шунлыктан үз алдыбызга катлаулырак бурычлар да куя алабыз. Бигрәк тә художество чараларын үзләштерү, осталык кирәк безгә. Әдәбиятның билгеле бер карарларга гына җайлашуы, аңа бәя бирүне тематика белән генә чикләү кайбер язучыларда әдәби хезмәткә җиңел мөнәсәбәт тәрбияләде. Кызганычка каршы, сүзгә ихтирам берникадәр йомшарды, без аны һәрвакытта да тоемламыйбыз. Һәм тәнкыйтьчеләребез дә әдәбиятыбызны художество ягыннан аз өйрәнәләр. Милли әдәбиятта милли телне белүнең мәҗбүри булмавы турындагы фикерләр шуннан килеп чыга торгандыр, мөгаен. Татар телен белмәүләренә, хәтта аңа кимсетеп карауларына карамастан, татар халык язучысы роленә дәгъва итүче иптәшләр барлыкка килде. Әдәби телгә мондый мөнәсәбәт бүген бик тә куркыныч. Кеше теләсә нинди телдә язарга хокуклы. Моның өчен талант кына кирәк. Татар милләтендәге күп кенә язучылар башка халыклар әдәбиятына намус белән хезмәт иттеләр һәм итәләр. Аларның күбесенә без хөрмәт белән карыйбыз. Әсәрләрен тәрҗемә итәбез, китапларын чыгарабыз. Ләкин язучының билгеле бер милли әдәбиятта булуы, барыннан да бигрәк, тел буенча билгеләнергә тиеш. Мин моны съездыбыз резолюциясенә кертүне сорыйм. Чөнки хәтта үз әдәбиятыбызда татар телен белүне мәҗбүри түгел дип тану юлы белән телебезгә рәхимсез һөҗүм итү бара. Шуннан соң нәрсә кала инде? Әгәр татар әдәбияты татар теленнән башка да чәчәк ата ала икән, милли мәктәпләр турында сөйләшү нигә кирәк?

Әйе, мин сизеп торам: нәрсә турында гына сөйләшә башласам да, туган тел проблемасына килеп төртеләм. Нишлисең, һәркем авырткан җире турында сөйләргә ярата бит. Чөнки әдәбиятыбызның киләчәге бөтенләе белән һәм тулысынча туган телнең киләчәгенә бәйле. Кызганычка каршы, безнең башка юлыбыз юк.

Үткәннәргә тәнкыйтьчел бәя бирү белән бергә, тормышыбызга сәламәт булмаган гомуми инкарь итү рухы үтеп керә бара. Барысын да инкарь итәбез: үсешебезне тоткарлаган начар якларны да, аталарыбыз каны белән, намуслы хезмәтебез белән яуланган һәм рухи байлыгыбыз булып торган яхшы якларны да.

Соңгы вакытта СССР Язучылар союзына карата да инкарь итү рухы барлыкка килде. Кайбер кызу канлы кешеләр Язучылар союзын таратырга, анда утыручы аппаратчыларны куарга һәм шуның белән әдәби бюрократия басымыннан котылырга үгетлиләр. Гадәттәгечә, бу кампанияне Мәскәү язучыларының бер өлеше башлады, ә безнең кайбер язучыларыбыз моны эләктереп алды. Беренче карашка бөтенесе дә дөрес кебек. Актуаль, әһәмиятле, кыю фикер. Ә тирәнгәрәк карасак: Язучылар союзы кемгә кирәк соң? Нәкъ менә аны җимерергә чакыручыларга кирәк. Аларның күпчелеге Язучылар союзының членлык билетыннан башка берниндн кыйммәтне күз алдына китерә алмый. Халык тарафыннан танылган талантлы язучыга бу билет, ай-һай,кирәкме икән. Ләкин алар шауламый, тавыш күтәрми. Союзны тарату турында кычкырмыйлар, киресенчә, аның эшчәнлеген камилләштерү турында уйланалар. Сүз уңаеннан әйтим, талантлы язучы һәртөрле исемнәр һәм премияләрне бетерү турында да кычкырмый. Әгәр дә инде аның мондый исемнәре һәм премияләре булса, ул аларны беркайчан да үз фамилиясе артыннан санап китми. Ә инде исемнәрне бетерергә өндәүче урта кул язучы, нинди дә булса значок алуга ирешсә, ул аны шундук үзенең халыкка билгеле булмаган фамилиясе астына теркәп тә куя.

Язучылар союзы нәрсәдә камилләшергә тиеш соң? Әлбәттә инде, демократияләштерүдә. Әмма моны җитәкчеләрнең дүрт аяклап тырышуын һәм һәрвакыт гаепле кеше сыман елмаеп йөрүен таләп итү дәрәҗәсенә кадәр китереп җиткерергә кирәкми. Шунлыктан Союз җитәкчесен съезд турыдан-туры һәм яшерен тавыш белән сайларга тиеш. Шул чагында гына җитәкче үзен җаваплы итеп кенә түгел, бәлки ышанычлы итеп тә сизәчәк, чөнки күпчелек аңа ышаныч белдерә. Председательгә администраторлык сыйфаты да кирәк, әмма иң мөһиме — ул үз коллегалары арасында шәхес буларак та, язучы буларак та абруйлы булырга, лидер буларак, мораль хокукка ия булырга һәм үз фикерен ачык итеп әйтеп сала белергә, язучыларның мәнфәгатьләрен яклый белергә тиеш. Безгә съездда шундый кешене табарга кирәк.

Әгәр инде Язучылар союзының кирәклеге турында сүз кузгатсак, ул безгә төп ике сәбәп буенча кирәк.

Беренчесе. Әдәбиятыбызны пропагандалау буенча планлы эш алып бару өчен. Иҗади мирасыбыз бай булганлыктан, бу безгә бигрәк тә мөһим. Союздаш республикаларда әдәбият мәсьәләләрен фәнни нигездә өйрәнү белән берничә институт шөгыльләнә. Ә бездә андый институтлар чикләнгән, шунлыктан мирасыбыз өчен җаваплылык та Союз өстенә төшә. Татарстан Язучылар союзы тормыштан киткән язучыларның иҗатын пропагандалау юнәлешендә бик актив эшли. Аларның әсәрләрен татар телендә чыгару, тәрҗемә итүне оештыру һәм аларның китапларын үзәк нәшриятларда бастыру бик тә мәшә-

катьле эш. Бу мәсьәләләрне үзешчәнлек юлы белән генә хәл итеп булмый. Ә бит бездә иҗатларын башка халыклар да белергә тиешле шагыйрьләр, язучылар аз түгел.

Гәрчә кайбер язучыларыбыз юбилейлар үткәрүгә каршы чыксалар да, без әдәбиятыбыз классикларының иҗатын пропагандалауның мондый нәтиҗәле формасыннан баш тарта алмыйбыз. Юбилейларны оештыру һәм үткәрүнең бөтен авырлыгы, әлеге дә баягы, шул бичара әдәби бюрократия җилкәсенә төшә.

Икенчесе. Союз безгә әдәби алмаш тәрбияләү өчен кирәк. Бу — мәсьәләләрнең мәсьәләсе. Элегрәк, утызынчы елларга кадәр, татар әдәбияты кадрларны бик күп региондардан ала иде (Башкортстан, Чувашия, Мордовия, Пенза, Горький, Оренбург, Ульяновск, Куйбышев, Саратов, Астрахань, Свердловск, Төмән һ. б. өлкәләр). Татар мәктәпләренең бетүе сәбәпле бу регион Татарстан һәм Башкортстан республикалары чикләренә кадәр тарайды. Элегрәк безнең әдәбиятка яшь авторлар стихияле рәвештә килә иде. Язучылар союзы арадан иң яхшыларын сайлап алу белән шөгыльләнде, ярдәм итте, кем әйтмешли, кондициягә җиткерде. Хәзер исә әдәби иҗатка сәләтле егетләр һәм кызларны үзебезгә эзләп табарга, аларны мәктәп эскәмиясендә чагында ук тәрбияләп үстерергә туры килә. Моннан ун-унбиш ел элек Язучылар союзы яшь авторларны һәм башлап язучы авторларны үзенә бертөрле тикшерү-барлау (инвентаризация) үткәрергә карар биргән иде. Яңа гына шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр яза башлаучылардан алып үз әсәрләрен республика матбугатында бастыручыларга кадәр — бөтенесе исәпкә алынды. 700 ләп кеше җыелды. Яшьләр белән эшләү комиссиясе аларны ничектер күзәтеп торырга һәм аеруча сәләтлеләренә игътибар беләнрәк карарга тырышты. Нәтиҗәдә әдәбиятка дистәләгән сәләтле яшь язучы килде. Безнең бу тәҗрибәбезне РСФСР Язучылар союзы секретариаты да хуплады. Ләкин кемгәдер, ни өчендер бу эшнең яманатын сатарга кирәк булды. Башлап язучы авторларның санына бәйләнүче, моны «арттырып язу» дип игълан итүче иптәшләр табылды. Гәрчә сүз башлап язучы авторлар турында барса да, алар ни өчендер гел «яшь язучылар» дигән сүзне кулландылар. Кызганычка каршы, мондый хәл әлегәчә дәвам итә. Инде башка санны да (800) уйлап таптылар.

Нәтиҗәсе нинди булды соң? Энтузиастлар бу эштән суынды, ә Союз җитәкчеләренең ныклыгы җитмәде, шунлыктан бу бик кирәкле эш формасы онытылды диярлек. Моның өчен Союз җитәкчеләре дә, явыз максатлар хакына мондый буталчыклыкны китереп чыгарган кешеләр дә җаваплы.

Әлбәттә, кече яшьтән үк чиктән тыш зур игътибар биреп, даими бәяләп торсаң, инфантиль әдәби малайлар һәм кызларны да үстерү куркынычы бар. Андыйларның эшкә сәләте дә, нык торучанлыгы һәм чыдамлылыгы да җитми. Андый иждивенецлар балигъ булып җитлекмиләр, ә картая гына баралар, пенсия яше җитүне түземсезлек белән көтәләр, бу исә аларга, ниһаять, әдәбияттан котылу өчен кирәк. Шулай да без язарга омтылучы һәр малайга һәм кызга бик игътибарлы булырга тиешбез. «Мәче балаларын сукыр чагында батырып үтер» дигән метод безгә бармый. Мондый гамьсез булу өчен без сәләтләргә алай ук бай кешеләр түгел (хәер, гамьсез кеше беркайчан да бай була алмый). Тумыштан талантлы кешеләр җирдә аунап ятмый, аларны түземлелек белән эзләргә кирәк. Өмет уятучы йөзләгән кеше арасыннан бер генә талантны табып алсак та, бу безнең тырышлыгыбызны аклый. Мөгаен, бездә алмаш әзерләүнең шундый формасын пропагандалау һәм Язучылар союзын уртакул иҗатчылар белән тутыру куркынычы арасында каршылык та бардыр. Әмма, инде әйтелгәнчә, бөтенесе Союзга алганда үзебезнең таләпчәнлеккә бәйле булачак.

Съездыбызда язучының әдәбият алдындагы, халык алдындагы җаваплылыгы турында әйтәсе килә. Билгеле, биредә бу сөйләшүне үгет-нәсихәт формасында алып барасы килми. Без барыбыз да — тормышка карашыбыз формалашып җиткән кешеләр. Илебездә бара торган процессларны яхшы аңлыйбыз. Шулай да без фикер йөртүебез белән аерылып торырга тиешле кешеләр, теләсә нинди вакыйганы кайнар хисләр белән кабул итәбез. Бездә максимализм да җитәрлек. Шунлыктан, әгәр без җәмгыятьтә үз-үзебезне тотышыбыз турында, сүзебезнең нәтиҗәлелеге һәм үзара ихтирам итешүебез турында биредә бергәләп уйлансак, һич тә артык булмастыр, дип уйлыйм.

Билгеле булганча, иҗат интеллигенциясе арасында язучылар хәбәрдарлыкны, демократияләштерүне, җәмгыятебезне үзгәртеп коруны иң актив этәрүчеләр булып торалар. Алар үз эшләренә идеология өлкәсендә генә җаваплылык алып калмадылар. Инде әйтелгәнчә, язучылар экономика, экология, социология, политика өлкәләренә дә кыю үтеп керәләр. Кайчагында язучыларны компетентсызлыкта гаепилиләр. Ләкин әлегә фикердәшләребез, каләмдәшләребез мондый ударларга түзә. Безнең халык ышанычын югалтканыбыз юк, сүзебезнең дәрәҗәсе бар.

Язучы, барыннан да бигрәк, шәхес ул. Кызганычка каршы, кайчак без моны онытып җибәрәбез. Үзара мөнәсәбәтләребез турында берничә сүз. Без барыбыз да кешеләр, һәркайсыбызның симпатиябез, антипатиябез бар. Беркем дә берәүне дә «җене сөймәгән»

кеше белән кочаклашып йөрергә мәҗбүр итә алмый. Ләкин бит элементар әдәплелек кагыйдәләре бар. Без аларны беләбез, ләкин һәрвакытта да саклый белмибез. Бу барыннан да элек матбугаттагы, радио һәм телевидениедәге чыгышларыбызга кагыла. Кайчагында без дәлилле, нигезле, объектив тәнкыйть белән бергә, шәхесне мыскыллауга юл куябыз. Еш кына укучыларыбыздан үз арабыздагы, мөнәсәбәтләр хакында замечаниеләр ишетергә туры килә, тотнаклылык күрсәтмәвебез, мәгънәсез сөйләшүләр язучылар тормышы турында гайбәтләр таралуга булышлык итә. Әгәр дә инде без бәхәсләшә, дискуссия алып бара алмыйбыз икән, бу кимчелегебезне бөтен халык алдында ачып салмыйк, бер-беребезне фаш итмик. Югыйсә, үз сүзебезгә ихтирамны югалтуыбыз бар.

Сүзебезгә ихтирам турында уйлаганда язучыларның пропаганда бюросы линиясе буенча укучылар алдындагы чыгышлары турында әйтеп үтәсе килә. Бу хакта инде күп тапкыр әйтелгәне бар. Ләкин кайбер иптәшләр аудитория алдында һәрвакытта да җаваплылык сизмиләр. Миңа калса, аларны күбрәк язучы сүзенең дәрәҗәсе түгел, чыгыш өчен гонорар кызыксындыра. Кайбер автомашиналарның бортына шоферларны кисәтү өчен: үз-үзеңә ышанмасаң — узып китмә, дигән сүзләр язып куела. Моны безгә дә истә тотарга кирәк. Язучыларыбызны гүзәл, зирәк, интеллигентлы кешеләр итеп, кешелек дәрәҗәсен тиз тоя торган әдипләр итеп күрәсе килә.

Безгә тарихыбызның гаепсезгә репрессияләнгән миллионлаган совет кешеләренең исемнәре язылган караңгы сәхифәләренә дә һәм мәгълүм сәбәпләр аркасында да җинаятьчел процесска тартып кертелгән кешеләргә дә үз мөнәсәбәтебезне булдырырга кирәк. Аларның кайберләре җинаять юлына үз аңнары белән басты, андыйлар, табигый ки, берничек тә гафу ителә алмый. Күпләр йомшаклык, сукырлык күрсәтте, үз гамәлләренең нәтиҗәләрен күз алдына китерә алмады; коточкыч газаплар вакытында ялган күрсәтмәләр бирергә мәҗбүр булган кешеләр дә күп. Без бу язмышларның катлаулы бәйләнешен аңларга, күзгә карап дөресен әйтә белергә тиешбез. Кызганычка каршы, язучылар арасында (исәннәр һәм үлгәннәр арасында да) ул елларда үзләрен яхшы яктан күрсәтмәүчеләр булды. Без бу әхлаксызлыкны аклый алмыйбыз, язучы әдәбиятыбыз тарихында нинди генә урын алып тормасын, мондый гамәлне кичерә алмыйбыз.

Шул ук вакытта дөреслек җәза бирү чарасы гына түгел, бәлки сафландыру чарасы да булып хезмәт итәргә тиеш. Әгәр дә без дөреслекне ачу кайтару һәм үч алу өчен, спекуляция максатларында яки сенсация хакына файдалансак, әдәбиятта әрле-бирле йөренүчеләргә әверелүебез мөмкин. Безгә рухи таркаулыктан сакланырга кирәк. Безгә бүген кайчандагыга караганда да рухи ныклык, карашларның ачыклыгы, эшләребезнең зирәклеге кирәк. Чөнки безнең алда гаять зур бурычлар тора. Безнең алда — киләчәк һәм аның алдында барыбыз да җаваплы. Киләчәк буыннар бездән күпме таләп итәр.

Съездда без бүгенге көннең тагын бер актуаль мәсьәләсе турында әйтми кала алмыйбыз. Бу — милләтара мөнәсәбәтләр. Ленинчыл милли политиканың бозылуы аркасында илебездә булган фаҗигале вакыйгаларны искә төшереп тормыйм. Шуңа гына шатланам, бу яктан алганда, безнең республикада тыныч. Әмма бу бөтенләй тынычланып калырга хокук бирми. Бернича дистә еллар буена милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кискенләштерүгә китергән сәбәпләрне бетерә барып, милли культураны саклау һәм үстерү позицияләрендә калып, без башкаларга да бик игътибарлы булырга, туганлык законнары бозылмасын өчен бөтенесен эшләргә тиеш.

Без бер-беребезне сүгәргә яратабыз, кайчак үз әдәбиятыбызга артык иркенлек бирәбез. Ә бит без, татар язучыларының бер генә әсәрендә дә каршылыклар идеяләре, татар халкын башкаларга караганда өстен кую идеяләре пропагандаланмады һәм пропагандаланмый, дип горурлык белән белдерә алабыз. Тукай үзенең туган телен бөек, куәтле тел дип атамады. Аның өчен ул туган тел, әти-әни теле булды. Классикларыбыз һәм аларны дәвам иттерүчеләр бердәмлек турында, туганлык һәм дуслык турында яздылар һәм язалар. Без бу изге традицияне сакларга тиеш. Үзебезнең милли культурабыз өчен барыбыз да кайгырта. Әмма башка халыклар белән мөнәсәбәтләр турында сүз барганда, бер яктан икенче якка ташлану куркыныч ул. Бүген кибетләрдә шикәр җитми — монысы начар, әмма түзәрбез, сабын юкка чыкты — аның булырына ышанабыз. Без — совет халкы — узындырылган халык түгел, кыенлыкларга түземле халык. Әмма безнең иң мөһим байлыгыбыз бар: ул — бердәмлек. Саклыйк аны!

Менә ничә ел инде яхшылыклар көтеп яшибез. Тормышыбызда үзгәртеп кору процессы бара, хокукый дәүләтнең шытымнары — хәбәрдарлык, демократия барлыкка килде. Ләкин без тагын да күбрәген көтәбез. Кайберәүләр могҗиза көтәләр — ниндидер тылсымчы килеп чыгар да, күз ачып йомганчы бөтенесен үзгәртер дә куяр, янәсе. Әмма планнарыбыз тормышка ашсын өчен, кемнәрдер актив көрәшергә дә тиеш бит. Безнең өчен берәү дә килеп эшләмәс, безнең өчен берәү дә талантлы әсәрләр язмас, бигрәк тә татар телендә. Әйдәгез, үз каләмебез белән, үз сүзебез белән үзгәртеп коруның актив, сәламәт көчләренә кыенлыкларны җиңәргә, партиябезнең XXVII съезды билгеләгән максатларга ирешергә ярдәм итик.

## Ренат Харис

# ӘЙТӘСЕ СҮЗЕБЕЗ СОҢГАРМАСЫН

Ике съезд арасында татар әдәбияты, әлбәттә, сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан да үсештә булды. Моңа дәлилләр җитәрлек. Минем шуларның берсен генә әйтеп үтәсем килә: татар телендә укый белүчеләр саны елдан-ел кимүгә карамастан, «Казан утлары»ның тиражы 12 меңгә артты, ә анда басылган әсәрләр хакында кызыксыну белдергән хатлар саны ике мәртәбә үсте. Вакытлы матбугаттагы рецензияләргә, укучы хатларындагы фикерләргә, әдәбият сөючеләр белән күп санлы очрашулар нәтиҗәсенә таянып шуны әйтергә була: бүгенге татар әдәбиятының ихласлыгы күзгә күренеп арта, ул хәбәрдарлыкка ныграк таяна бара. «Казан утлары»ның соңгы елларда укучысы алдында абруе күтәрелү, минемчә, иң беренче нәүбәттә татар әдәбиятында һәм гуманитар фәннәрдә үзгәртеп кору йогынтысы астында көчәеп киткән уңай күренешләр һәм административ басымның кимүе белән бәйле.

Мин бу җәһәттән республика мирас комиссиясенең бик вакытлы төзелеп, иҗат оешмаларының эш атмосферасына шифалы йогынты ясавын да билгеләп үтәр идем.

«Казан утлары» — бүгенге татар әдәбиятының көзгесе. Кульъязмаларыбыз аның битләрендә басма әсәрләргә әверелә һәм халыкка юл ала. «Казан утлары» — Татарстан Язучылар союзының да иң зур, иң катлаулы эше. Шуңа күрә съезд каршында журнал турында кыскача гына булса да хисап бирүне кирәкле дип саныйм.

Ике съезд арасында 21 мәртәбә редколлегия утырышы булды, һәм аларда әдәбиятыбызның юнәлеше, жанрлар үсеше, конкрет әсәрләребез, мирас һәм аңа яңача караш мәсьәләләре буенча асылда төпле, принципиаль фикер алышулар барды.

Әйтергә кирәк, соңгы елларда Язучылар союзы иҗат мәсьәләләренә игътибарын киметте, дигән фикерләр ишетелә. «Казан утлары» редколлегиясе һәм редакциясе башкарган практик һәм теоретик эшләрне Язучылар союзы эшеннән һич тә аерып карарга ярамый. 5 ел эчендә «Казан утлары»ның дөнья күргән 60 санында 1246 авторның әсәре басылды, әмма редакциягә үпкә белдерүчеләр, әлбәттә, бар. Турысын әйтсәк, алар һәрвакыт булырга да тиеш. Беренчедән — һәр язганыбыз, кызганыч ки, шедевр түгел. Икенчедән — бердәнбер әдәби журналыбызның күләме бүгенге татар әдәбияты өчен кечкенә. Һәм, бәхеткә, язучыларыбыз әлегә сайлап басарлык итеп күп язалар. Кем әйтмешли, ходай безне әнә шул бәхеттән мәхрүм итмәсен. Июль аенда чыга башлаячак «Идел» журналы, ихтимал, «Казан утлары»ндагы чиратны һәм тыгызлыкны киметүдә ярдәм итәр. Яшь брадәребезгә уңышлар телик! Елга Иделдә су күп булсын, журнал «Идел»дә су аз булсын!

Әмма безнең өчен проблеманың иң мөһиме, иң үзәге — журнал белән укучы арасындагы бәйләнеш, мөгамәлә. Чөнки укучы — халык ул. «Казан утлары» ул татар халкының иҗтимагый аңын тәрбияләүдә катнашучы зур идеологик көч тә. Һәм шушы рухи көчне журналның редколлегиясе, редакциясе берсен-берсе баетып тора торган өч максатка юнәлтте:

— төрле төбәкләргә сибелеп яшәүче, күпмедер дәрәҗәдә телен, культурасын, гореф-гадәтләрен онытa баручы, болгар, мишәр, типтәр, татар, керәшен дип бүлгәләүнең куркыныч икәнен тоймый башлаган 7 миллионлы татар халкын бербөтен халык итеп туплау;

— татар халкының интернациональлек хисен, революцион, тарихи үзаңын, милли горурлыгын тагы да күтәрү, камилләштерү;

— татар халкының эстетик аңын милли рухлы, башка халыкларның тарихына, сәнгать казанышларына ихтирамлы, игътибарлы итеп тәрбияләү.

Соңгы елларда «Казан утлары» инициативасы белән «Идегәй» дастаны халыкка кайтарылды, «Кыйссаи-Йосыф»ның, «Мәҗмугыл-хикаят»нең бүгенге татар теленә тәрҗемәсе басылды, Тукайның, Мәрҗанинең шәҗәрәләре булдырылды, дөнья шигърияте шедевры буларак Коръәннең берничә сурәсе татарчага тәрҗемә ителә, Н. Г. Чернышевскийның татар телендә язган мәкаләләре эзерләнә...

Быелдан башлап, Татарстан АЭСы төзелешендәге әдәби пост урынына, журналда «Экология» әдәби посты булдырылачак.

Борынгы Болгар шәһәрләренә, Уральскида, Оренбургта, Уфада, Казанда татар мәдәнияты белән бәйле урыннарга багышланган материаллар, журналыбыз аша бүгенге татар укучысына тарихыбызда беренче тапкыр җиткерелгән Ш. Мәрҗани, Риза Фәхретдинев әсәрләре, халкыбызның ювелир, чигү-нәкыш сәнгатенең кабатланмас

кыйммәтен күрсәткән мәкаләләр һәм рәсемнәр. Фатих Кәрими, Һади Атласи, Г. Исхакый, М. Солтангалиев турындагы материаллар, төрле милләт тәнкыйтьчеләренең татар әдәбияты һәм сәнгате турында язганнары, халыклар дуслыгына багышланган мәкаләләр журналны әнә шул юнәлешләрдә тотрыклы итеп алып барырга ярдәм итте. Гарәп әлифбасы нигезендә укырга һәм язарга өйрәтү дәресләре, сигез йөз еллык татар әдәбиятын, китап нәшриятлары ярдәменнән башка, бүгенге тормышыбызга алып кайтуда бер практик адым дип санала ала. Казанның үзендә, республикабыз шәһәрләрендә, илебезнең төрле төбәкләрендә яшәп, татар телен өйрәнүдән мәхрүм ителгән 5—10 яшькәчә балаларны өй шартларында ана теленә өйрәтү өчен журнал быелның сентябрь аеннан «Татар теле дәресләре» дигән рубрика ача. Киләсе елның маена чаклы бу дәресләрне республикабызның күренекле методистлары һәм язучылар алып барачак. Бүгенге көндә исә редакция татар мәктәпләрен шефлыкка алу планы турында уйлана. Хокукый дәүләт төзелгән шартларда татар халкының мөмкинлекләрен ачыклау да күз уңыбызда тора.

Соңгы 30-40 ел дәвамында татар әдәбияты катастрофага тиңләшерлек бер югалту кичерде. Бу — илебез шәһәрләрендә, шул исәптән Татарстан шәһәрләрендә туып үскән татар кешеләрен ана телебездә укучы буларак югалту. Бу процесс алда да дәвам итәчәк әле. Шуның өчен «Казан утлары» үткәрә торган чаралар гына мәсьәләне хәл итмәячәк. Илебездә татарлар күмәкләшеп яшәгән 54 төбәкнең 50 сендә татар мәктәпләре дә, татар балалар бакчалары да тиз арада мәсьәләне хәл итәрлек күләмдә артмаячак. Безгә «Колобок», «Веселые картинки» кебегрәк журналларны күпмедер дәрәҗәдә берләштергән ана телебездә чыга торган журнал кирәк. Хәзергә фәкать шушындый, татарча «сөйләшә» белә торган журнал гына Татарстаннан читтә булган регионнарда, Казанда, Чаллыда, башка шәһәрләрдә мәктәп вазифасын үти ала... Халыкның, милләтнең киләчәге балаларыбыз кулында.

Татар халкының иҗтимагый аңын үзгәртеп кору чоры рухында тәрбияләү өчен без журналның әнә шул юнәлешләрен бигрәк тә мөһим дип саныйбыз. «Казан утлары»ның йөзен шулар билгеләячәк, аның барлык материалларына шулар замана төсмере биреп торачак.

Без «Казан утлары»н Татарстанныкы гына дип түгел, бөтен татар халкы журналы дип хис итеп эшлибез һәм аның статусы, республикабыз җитәкчелеге дә булышса, союздаш республикалар журналлары белән бертигез булыр дип ышанабыз. Әгәр дә съезд хупласа, бу юнәлештәге эшне редакция партиянең XIX Бөтенсоюз конференциясе карарлары яктылыгында тагы да киңәйтә һәм көчәйтә ала.

Ике съезд арасында татар әдәбияты үсештә булды дидек, ләкин ул электән килә торган кайбер җитешсезлекләреннән барыбер арына алмады кебек. Шуларның мин берсен генә, журнал өчен бигрәк тә мөһимен генә, әйтеп үтәм. «Казан утлары»на бүген, кичә кергән яңа әсәрләр күрсәтә ки, безнең төп игътибарыбыз колхозлашу, Бөек Ватан сугышы алды, сугыштан соңгы авыр чорларга төбәлгән. Һәм бу аңлашыла да — татар әдәбиятының шул еллар хакында әйтелмичә калган сүзе күп, бигрәк тә сталинщина турында. Үзләре шул чорда формалашкан язучыларыбызга аның хакында вакытында язарга мөмкинлек бирмәгәннәр. Без, алтмышынчы-җитмешенче елларда әдәбиятка килүчеләр, шулай ук брежневщина турында берни дә әйтә алмадык. Ишеткән, отып алып үзебез сөйләп йөргән тозлы-борычлы социаль анекдотларның үткерлегенә, кыюлыгына шаккатудан, сокланудан уза алмадык. Күңелдә бер фикер йөртеп, кәгазьгә шуның капма-каршысын язарга күнегеп бетә яздык... Нәтиҗәдә, сихәтле Апрель Пленумы (1985) җилләре исә башлагач та татар әдәбиятының тирән өстәл тартмасыннан элек язылган һәм үз заманын беразга узып киткәнлеге аркасында гына басылмый калган бер генә әсәр дә чыкмады дисәк тә ярый. Бу уйландыра, иптәшләр.

Үзгәртеп кору гаҗәеп зур мөмкинлекләр ачты. Бүген без әдәби фонендоскобызны, бернидән дә курыкмыйча, үзгәртеп коруның күкрәгенә куеп, аның йөрәк тибешен тыңлый алабыз, әдәби градусникыбызны заманның култык астына кыстырып, үзгәртеп коруның кайнарлыгын күрә алабыз. Әмма өр-яңа әсәрләребез һәм аларда сурәтләнгән вакыт арасында дистәләрчә елларга сузылган дистанция саклanып килә. Зур романнарга күпмедер ташлама ясап була, ә оператив жанрларга ташлама ясарга сәбәп юк. Әлбәттә, без иске материаллар нигезендә дә үзгәртеп кору рухында язарга тырышабыз һәм уңышка да ирешәбез. Әмма әсәрләребездә үзгәртеп коруны башкаручы кешенең уй-фикерләрен, кылган гамәлен тизрәк күрәсе килә. Ул кешенең рухы, өмете киңәя барган космос кебек, ә тәне-бәдәне көнкүреш мөмкинлекләре кысыла барган чынбарлыгыбызда. Романнар, поэмалар, драмалар нигезенә шекспирча конфликт булып ятарлык киеренкелек түгелмени бу? Татар әдәбиятының вакытында әйтелми калачак, аннары соңгарып, ерактан торып әйтеләчәк сүзләре, минемчә, бүген үк барлыкка килде инде. Һәм бу дефицит «Казан утла-

ры»нда үзен инде бүген үк сиздерә. «Казан утлары» дигәннән... сез беләсезме икән — безнең журнал турында бернинди энциклопедиядә дә, хәтта әдәбиендә дә, бернинди энциклопедик сүзлектә дә мәгълүмат юк. Ә башкортның «Агидел», бурятның «Байкал», каракалпакның «Амударья», карело-финның «Пуналиппу», якутның «Хотугу сулус» журналлары турында БСЭдан да, төрле сүзлекләрдән дә укып була. Без редакциядә бу сәер хәлнең сәбәбе турында уйландык. Юк, моны энциклопедия төзүчеләрнең татар халкына булган игътибарсызлыгы белән аңлатырга ярамый, чөнки һәр сүзлектә татар әдәбияты хакында тирән һәм күләмле мәкалә бар. Моны фәкать татар мәдәниятының, татар әдәбиятының илкүләм абруе хакында кайгыртырга тиешле даирәләрнең, беренче чиратта үзебезнең Язучылар союзы идарәсе һәм фәнни оешмаларның, дистәләрчә еллар буена шушындыйрак мәсьәләләрне күз уңында тотмаулары белән аңлатып буладыр. Мисал өчен ерак йөрисе юк, хәтта съездыбыз докладында да Язучылар союзы органы булган «Казан утлары» телгә дә алынмады, ә республика рәссамнарының күптән түгел булып узган съездында журнал хакында җитди сүз барды. 1984 елда Татарстан Язучылар союзы оешуның 50 еллыгына багышланган докладында хәтта партия өлкә комитеты секретаре да дөньяда бердәнбер татар әдәби журналы барлыгын онытты.

Әгәр дә шушындый игътибарсызлык «Казан утлары»на карата гына булса, мин аны әйтеп тә тормас идем. Рус телендә басылган гомумсоюз чыганакларында язучылардан Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, композиторлар С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, рәссам Б. Урманче, галим Ш. Мәрҗани кебек халкыбызның олы шәхесләре дә күренми бит.

Татар халкының, татар мәдәниятының һәм әдәбиятының халыкара данын балкып туган даһи әсәрләр генә түгел, менә шушындый «вак-төякләр» дә ныгыта икәнен безгә — иҗат союзларына да, фәнни оешмаларга да, республикабызның директив органнарына да онытырга ярамый. Халык милли ренессанс кичергәндә вак-төякләр булмый ул!

Безнең халыкка әйтәсе сүзебез соңгармасын, вакытында әйтелсен иде. Бу татар әдәбиятын халкыбыз күңеленә тагы да якынайту юнәлешендә тагын бер хәлиткеч адым булыр иде.

## Фәрваз Миңнуллин

# КИЧЕРМӘСЛӘР БЕЗНЕ, КИЧЕРМӘСЛӘР...

*Тукайлар, Бабичлар, Такташлар, Мусалар,*
*Кутуйлар Бурнашлар, Камаллар йортына*
*Әрсезләр, гамьсезләр, дөм сукыр тычканнар,*
*Бөҗәкләр ябырыла, абына-сөртенә.*
*Галимҗан абыйлар, Әмирхан өенә*
*Намуссыз, битсезләр өерелә...*

Бу юлларны Хәсән ага Туфан 1960 елда ук язган булган. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәбият дөньясындагы һәр төрле әрсезләр һәм битсезләргә каршы көрәшеп яшәде.

Нинди дер могҗиза булып, Хәсән Туфан белән Ибраһим Газилар, Мирсәй Әмир белән Шәйхи Маннурлар, бер генә сәгатькә мәңгелек йокыдан уянып, әдәбият-мәдәният дөньясындагы бүгенге хәлләргә күз сала алсалар, ни диярләр иде икән?! Һәрхәлдә, аларның берсе дә: «Без сездән разый, егетләр!» — дип әйтмәс иде...

...Бер мәктәпнең алдынгы пионерын колхозның алдынгы сыер савучысы янына интервью алырга җибәрәләр. Бәлки, ишеткәнегез бардыр, аңгәмә менә болаерак барган:

— Гөлбикә апа, Сез үзегезгә беркетелгән һәр сыердан 16шар литр сөт савасыз икән. Бик кыенмы шулхәтле сөт савуы?

— Кыенмы дип?.. Тырышабыз инде, акыллым, тырышабыз...

— Ә 18 әр литр савып буламы?

— Ник булмасын?.. Була, бик була.
— Ə 20 шәр литр?..
— Бик тырышканда, 20 шәр литр да була!
— Ə 26 шар литр?
— Юк, булмый, үскәнем, булмый!..
— Нигә?
— Ул чагында сөт чат суга әйләнә...

Күрәсез, сөт суга әйләнә торган мәгълүм бер чик бар икән. Тормыштагы һәр нәрсәдә бар андый чикләр. Шул чикне узгач, ир кеше — карт кешегә, әле кайчан гына ыжгырып торган хатын — карчыкка, дару агуга әйләнә...

Чын сәнгатьне — халтурадан, профессионал әдипне һәвәскәрдән аера торган шундый чик, һичшиксез, әдәбиятта да бар. Без шул чикне югалттык...

Әдәби җәмәгатьчелек дигән төшенчә бар иде, әлегрәк тагын әле җәмәгатьчелек фикере дигән төшенчә бар иде. Без шул төшенчәләрне югалттык... Шуларны югалтуга яхшыны яманнан, талантны графоманнан аера торган критерийлар да буталып бетте.

Күзгә туры карап, дөресен әйткәндә, үзгәртеп кору дәвере, минемчә, бездәге әдәби атмосфераны бары начарайтты гына. Карьеристлар яңа шартларга һәммәбезгә караганда да тизрәк һәм яхшырак яраклаштылар. Ялгышмасам, дилбегәне үз кулларына алып та киләләр инде. Шул рәвешчә, чираттагы съездыбызны без критерийлар һәм чикләрнең шактый буталган бер чагында, үзебездәге иҗади атмосфераны елдан-ел ныграк югалта барган уңайсыз шартларда каршылыйбыз.

Ике съезд арасында 17 яңа роман басылган. Шуларның күбесе-йомшак һәм сыек романнар. Моннан биш ел элек («Романга ни булды?» дигән мәкаләдә) безнең романнарга хас кимчелекләргә бераз тукталган идем. Әйтик, ул мәкаләдә сугыштан соңгы чорда, 50 еллар ахырында һәм 60 еллар башында нык активлашып алганнан соң, татар әдәбиятында роман жанрының пассивлаша, тоныгая һәм ваклана төшүе турында, аннары безнең романнарда олы характерларның аз булуы, бүгенге татар романына масштаблык, эпик киңлек җитмәү турында да бераз сүз булган иде. Әлеге кимчелекләрнең байтагы ике съезд арасында дөнья күргән романнар өчен дә хас...

Әдәби планкаларны елдан-ел түбән төшерә бару аркасында, роман булып оешып җитмәгән язмалар саны туктаусыз арта тора. Әйтик, әлеге 17 романның 6 сы төрле редакцияләрдә еллар буе этелеп-төртелеп йөргәннән соң гына дөнья күргән. (Мин, беренче чиратта, Э. Касыймовның «Җир балкышы», Җ. Рәхимовның «Кыядагы чәчәкләр», Х. Хәйруллинның «Ургыл», Я. Зәнкиевнең «Иртеш таңнары», И. Салаховның «Имәннәр тамыр җәйгәндә» кебек әсәрләрен күздә тотам). Кода- кодагыйлыкны оныта төшеп, таләпчәнлекне аз гына арттырганда, аларның санын җиңел генә 10 га җиткереп булыр иде. Чиле-пешле 10 роман басылмый калганнан, билгеле, татар прозасы берни дә югалтмас иде.

Шул 17 романның тагын 3 се (Х. Хәйруллинның «Ургыл»ы, И. Салаховның «Имәннәр тамыр җәйгәндә»се, Я. Зәнкиевнең «Иртеш таңнары») кеше ярдәмендә, ягъни әдәби эшкәртү юлы белән дөнья күргән әсәрләр. Шул юл белән язылган роман һәм повестьлар, пьесалар һәм шигырь китаплары саны, шул юл белән Язучылар союзына кергән графоманнар саны гел арта бара.

Миңа әлеге романнар уңае белән язылган бик күп мәкалә һәм рецензияләрне укырга туры килде. Ул романнарның барысы да, баксаң, иң элек һәм беренче чиратта әһәмиятле һәм актуаль темага багышланган булулары өчен мактала икән. Әйтик, «Язмышыңа ышан» — АЭС төзүчеләргә багышланган беренче роман, «Иртеш таңнары» — Себер татарларына багышлап язылган беренче роман, «Имәннәр тамыр җәйгәндә» — татар казакларына багышланган беренче роман, «Җир балкышы» — КамАЗның авылга тәэсире турындагы беренче роман, «Кыядагы чәчәкләр» — Себердә газ торбалары салучылар турындагы беренче роман икән...

Шул рәвешчә, рәттән 17 романны санап чыгыгыз. Барысының да темалары үтә актуаль, үтә мөһим булуын күрерсез. Әдәбиятта кызыксыз, әһәмиятсез темалар юк, була алмый. Әмма әдәби әсәрнең кыйммәтен һәм кадерен һич тә тема билгеләми, ләбаса. Авторның таланты, әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше билгели.

Актуаль тема артыннан куып бер хаталансак, производство мәсьәләләрен күтәрү, производство романы язу абруйлы эш дип уйлап икенче ялгышабыз. Алда телгә алган чиле-пешле әсәрләрнең, бассаң да ярый, басмасаң да ярый торган әсәрләрнең күбесен производство романнары тәшкил итә.

Производство романнары дигәндә, мин эшче темасына караган әсәрләрне генә күздә тотмыйм. Талантсыз язучы кулына эләккән теләсә-нинди материал «производствога» әйләнә. Теге яки бу автор крестьян хезмәтенең технологиясе турында язарга керештеме — бу инде производство романы була.

һәр эшнең үз җае, үз көе була. Берәү тегүче, берәү тимерче, берәү күмерче булып тамак туйдыра. Шигырьче булып, язучы булып тамак туйдыру өчен, тел белү, сүзләр ярдәмендә җанлы сурәт, тормышчан, динамик картина тудыру сәләте кирәктер, дисәң — юк икән... Тырышлык белән әрсезлек җитә икән. Бүгенге роман-повестьларның, бүгенге хикәяләрнең күбесен телсез авторлар язган. Баксаң, җанлы сурәт, динамик картина дигәнебез үзе дә дефицитка әйләнеп бара, безнең әдәбиятны, безнең прозаны эчтәлек сөйләү алымы, информацион стиль басып-күмеп килә икән.

Әгәр шул рәвешчә, шул алым белән, М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романындагы кебек, авыр һәм катлаулы язмышлы геройлар, тетрәтерлек мәхәббәт фаҗигаләре турында сөйләнсә, бер хәер иде. Юк бит. Тимер-бетон тел белән производство процесслары хакында, теге-яки бу эшнең технологиясе хакында сөйлиләр.

«Язмыштан көчлерәк» дигән әсәрендә Р. Низамиев татарның ике мәшһүр композиторын — Салих Сәйдәшев белән Фәрит Яруллинны «очраштыра» («Казан утлары», 1989 ел, 11 сан, 60 бит). Бу очрашу безгә гади информация генә бирә.

Шул рәвешчә язылган ялыктыргыч һәм пассив стильле романнар арасында, соңгы могикан кебек күңелле сюрприз булып, ике әсәр калкып тора. Аларның берсе — Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» дилогиясе, икенчесе — М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы.

Нурихан романындагы таң калырдай осталык белән сурәтләнгән сугыш картиналарына игътибар иткәнсездер. Шулар янына меңәрләгән кешенең берьюлы аугa чыгуын, төрле-төрле ыруларның җәйләүдән кышлауга һәм, киресенчә,кышлаудан җәйләүгә күченүләрен тасвирлаган урыннар, корбан биру һәм корбан бәйрәмен уздыруга бәйле йолаларны сурәтләгән сәхифәләр, гаҗәеп матур табигать күренешләре килеп тоташа. Күпме динамика, күпме җанлылык, күпме табигыйлек аларда!

Шундыерак сурәт-картиналар М. Хәбибуллин романында да байтак. Әйтик, Илбарыс белән Чәчкә арасындагы интим хисләрне сурәтләгән битләр, Илбарысның грек иленә һәм төньяк халыкларына сәяхәтен сурәтләүгә багышланган бүлекләр, хазарлар белән болгарлар арасындагы сугыш күренешләре...

Икесе ике стильдә язылган (М. Хәбибуллин романында халык әкиятләренә тартым романтик стиль өстенлек итсә, Н. Фәттах дилогиясе заманча аваздашлыгы, чынлык һәм реальлек хисенең зурлыгы белән аерылып тора), сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан икесе ике биеклектә торган (Нурхан дилогиясе, һичшиксез бер баш югары тора) әлеге әсәрләрне бер-берләренә иң элек җанлы сурәт һәм динамик картиналар муллыгы, аннары төп геройларның эшләнеше якынайта.

Ике съезд арасында басылган романнардагы уңай геройларны рәттән барлап чыгыгыз: Г. Ахуновның Нуриясе («Идел кызы». Икенче китап); Я. Зәнкиевнең Мөхәммәте («Иртеш таңнары»); Г. Кашаповның Дикопольцев белән Айбулатовы («Язмышыңа ышан»); Э. Касыймовның Хәнәфие («Җир балкышы»); М. Маликованың Суфиясе («Басып сайрар талы бар»); М. Мәһдиевнең Әхияры («Мәңгелек яз»); И. Салаховның Госманы («Иманнәр тамыр җәйгәндә»); Х. Хәйруллинның Якуп белән Хәмзәсе («Ургыл») һ. б. һ. б. М. Хәсәновның Иргалиен санамаганда, сез алар арасында Н. Фәттахның Албуга белән Туман каганы, М. Хәбибуллинның Илбарыс белән Кубрат ханы янына янәшә куярлык геройлар тапмассыз. Истә калырдай, колоритлы геройлар икенче, өченче дәрәҗәдәге персонажлар арасында күпмедер очрый әле: Г. Ахуновның Бүре Бадулы, М. Мәһдиевнең Мәгыйзе, И. Салаховның Иркәтае, М. Маликованың Шәфикасе һ. б. Ни хикмәттер, безнең әсәрләрдә нәкъ менә төп, уңай геройлар укучыны үзләреннән биздерерлек дәрәҗәдә төссез, чырайсыз һәм җансыз булып чыга.

Иҗатларының характеры белән гомуми төркемнән аерылыбрак торган тагын ике кешегә тукталмый булмый. Сүз Хисам Камалов белән Мәхмүт Хәсәнов хакында барачак.

Мин үзем Х. Камалов романнарының теленә, сюжет-композиция төзелешенә артык мөкиббән китүче кешеләрдән түгел. Русча уйлап төзелгән яки тәрҗемә юлы белән ясалган җөмләләрнең күп булуы эчне пошыра. Х. Камалов романнарын укыганда үзеңне очраклы рәвештә чит хәрби частька килеп эләккән журналист яки репортер хәлендәрәк сизәсең. Буйдан-буйга килүче вакыйгалар да, геройлар да юк диярлек. Эреле-ваклы геройлар керә тора, чыга тора. Кемнәрдер үлә, кемнәрнедер хәрби госпитальләргә озаталар, аларны берөзлексез яңа солдатлар, яңа геройлар алмаштырып тора...

Шул ук вакытта мөһим бер моментны да истән чыгарырга ярамый. Үзенең сугыш романнары белән Х. Камалов — хәрби теманы яктыртуда яңа юнәлеш башлап җибәргән кеше. Бик тә гадиләштереп һәм гомумиләштереп әйткәндә, аны сугыш турында дөресен язу, сугышның кырыслыгын һәм рәхимсезлеген күрсәтү, кырыс буяулар белән язылган хакыйкать дип атарга булыр иде.

Х. Камалов романнарында башкаларга гыйбрәт һәм үрнәк булырдай кызыклы алым һәм адымнарның мул булуын билгеләп үтәргә кирәк. Төрле милләт язучыларының

сугыш темасын яктырткан роман-повестьларын укыганым бар Еш кына күңелдә ниндидер юшкын, ризасызлык хисе утырып кала. Һәр язучы үз халкын гына күтәрә. Җиңүнең язмышын фронтовик язучыларның үз милләттәшләре генә — руслар яки белоруслар, молдованнар яки украиннар, грузиннар яки яһүдләр генә — хәл иткән булып чыга...

Х. Камалов бу яктан биш баш өстен тора. Хәбиров һәм Мостафин, Мирхас һәм Сөенчалин, Рифа һәм Фира кебек татар кешеләре белән бергә, сез аның романнарында башка милләт вәкилләренең үзгә бер ихтирам һәм ярату белән иҗат ителгән дистәләрчә образларын очратырсыз.

...«Үлгәннән соң яздым» романының соңгы өлешләрен тетрәнми уку мөмкин түгел. Сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән гарип солдатлар... Үзләре гарип калып булса да, дөньяны, илне, халыкны фашизм афәтеннән саклап калган батыр солдатлар... Шуның өстенә кешенең кадере беткән чынбарлык шартларында гомер буе ун кайгыга бер шатлык кичереп яшәячәк мескен кешеләр...

Тыл кешеләренең һәм тыл күселәренең аларга мөнәсәбәтен карагыз. Коточкыч битарафлык... Соң чиккә җиткән шәфкатьсезлек. Нишлисең, әхлаксыз шартлар әхлаксыз кешеләр тәрбияли...

Ниһаять, Мәхмүт Хәсәнов романы, «Язгы аҗаган» феномены хакында берничә сүз. Әсәрне күккә чөеп мактаучылар күп булган кебек, аны юкка чыгарып ташлаучылар да булмады түгел. Әмма бер нәрсә бәхәссез: «Язгы аҗаган» — Хәсәнов иҗатының зур казанышы, бүгенге татар прозасының бер уңышы. Әдәбият-сәнгать өлкәсендәге гомуми хәлләрне истә тотканда, ул — Тукай премиясенә лаек әсәр, дөресрәге, лаек әсәрләрнең берсе. Һич тә икеләнми-шикләнми әйтә торган төп фикерем шушы.

Әгәр роман уңае белән кирәксез шау-шу купмаган булса, һәм ул шау-шуга тора-бара автор үзе дә ияреп китмәгән булса, сүзне шушы төштә туктатырга мөмкин иде. Әмма нишлисең? Эш болайга киткәч, кайбер нәрсәләргә ачыклык кертергә туры киләчәк.

«Язгы аҗаган»ны Хәсәнов 1984 елда тәмамлый. Бу — кульязмага автор үзе куйган дата. Шул ук елны автор аны ике урынга: «Казан утлары»на һәм нәшриятка тәкъдим итте. 1984 елның 21 сентябрендә нәшриятка кергән беренче вариантның күләме 50 табакка якын иде. Бергәләп эшли торгач, ул 35 табакка калды. Нык куллы редакторга туры килгән очракта 30 табакка калдырып була иде. Гениаль әсәрне бу хәтле кыскарту мөмкин түгел. Бу — мәсьәләнең бер ягы.

Аннары, баштарак беркем дә роман бестселлерга әйләнер дип уйламады. Мавыгып укылуын әйтсә дә, нигездә уңай бәя бирсә дә, Аяз Гыйләҗев 12 битлек рецензиянең нәкъ 11 битен кимчелекләр санауга, язучыга төрле-төрле киңәшләр бирүгә багышлаган иде. (Мәгълүм булсын, автор аларның күбесен игътибарсыз калдырды.)

Актив эшләүче тәнкыйтьчебез Ф. Галимуллин, гомумән, романның Иргали образына бәйле сызыгын тәнкыйтьләп чыкты. «Советская Татария» газетасында булса кирәк, Рифат Сверигинның: «Иргали линиясен генә калдырып, өр-яңадан эшләгәндә, бу романнан җыйнак кына повесть чыгар иде», дигән фикере дә истә калган. Кыскасы, «Язгы аҗаган»ны гап-гади язмыш көтә иде. «Язгы аҗаган» безнең әдәбиятта романга кытлык көчле чакта дөнья күрде. Аннары укучыларның юньле әсәрләргә тәмам коргаксыган чагында басылды, дип өстәргә мөмкин. Киексез урманда йөргән аучылар кебек, без татар прозасына җитмәгән, әмма татар прозасында булырга тиешле сыйфатларны, үзгәртеп кору чорына хас яңа тенденцияләрне шушы романда күрергә тырыштык. Булмаганнарын бар иттек, яралгы хәлендәгеләрен нык күпerttек.

Әйтик, язучы баштан-ахырга кадәр Иргалинең хезмәт кешесе булуына басым ясый. Кешенең бөтен олылыгы да, байлыгы да һәм дәрәҗәсе дә — хезмәттә, бары тик хезмәттә, дип расламакчы була. Бу — ялгыш караш. Кайчандыр хезмәт дан, батырлык эше дигән сүзләр модада иде. Анысы да — ялган лозунг. Халык:

*Ходай бәхетне бирмәсә,*
*Баеп булмый эшләп тә,*

— дип җырламас иде...

Хикмәт — «бәхеттә»...

Эшләп баеп булса, хезмәт дан, батырлык эше булса — дөньяда бездән дә баерак, бездән дә данлырак халык булмас иде.

Ил белән алга таба да хәзерге экономистлар, хәзерге плановиклар идарә итсә, тагын 10 елдан халыкның 80 проценты хәерчелекнең соңгы чигенә килеп җитәчәк. Аларга саклык кассаларында, матрас капчыклар эчендә яткан миллиардлар тынгылык бирми. Май чүлмәге тирәсендә чабышкан мачылар кебек, ничек тә шул акчаны, халыктан суырып алып, әйләнешкә кертү турында баш ваталар. Бервәлексез бәя күтәрәләр, бервәлексез дефицит тудыралар. Ә бит тик яткан теге миллиардлар асылда хезмәт кешесенеке

түгел — гади халыкныкы түгел. Каракларныкы, спекулянтларныкы, түрәләрнеке. Хезмәт кешесенең эш хакы аракы алырга да чак-чак җитә...

Шуларны белә торып, ничек итеп хикмәтнең — башы хезмәттә, дип, яки Иргали эшләп баеды, дип язарга мөмкин?! Хикмәтнең башы хезмәттә түгел, ә бәлки эшләп тапканны гадел итеп бүлүдә. Иргали эшләп баемый, аңа аталы-уллы Клочкиннар, Кузька-Бурлак кебек бандитлар булыша. Романның ак җеп белән тегелгән бер йомшак урыны — шул.

Икенчесе — турыдан-туры Иргали образына бәйле. Соңгы вакытта басылган мәкаләләрдә Иргалине ничектер шәхес культы корбаны, колхозлашу елларында, ялгыш кулакка саналып, хаксызга рәнҗетелгән герой итеп күрсәтергә тырышу тенденциясе көчәеп килә. Хәлбуки, ул Себергә кеше үтерүдә гаепләнеп сөрелә. Болар икесе ике нәрсә. Аннары М. Хәсәновка мондый яңа тенденцияләрне көчләп тагудан һичбер төрле мәгънә юк — НЭП турында булсын, колхозлашу хәрәкәте хакында булсын, башка бик күп мәсьәләләрдә булсын, ул тулысынча иске карашларда калган кеше.

Алайса, «Язгы аҗаган» романының сере нидә соң?..

Сюжет-композиция бөтенлегендә дияргә мөмкин. Бу — шактый дөрес сүз булачак.

Язучының телендә, хикәяләү стилендә дияргә мөмкин. Роман халыкның маҗаралы әкиятләредәй мавыгып укыла. Теле җырлап тора.

Сер романның геройларында дияргә мөмкин. Иргали, Гази, Лачын, Рәхимҗан, Һади, Сираҗи, Җәүһәрия, Зәйтүнә, Гөлүсә, Миңсылу кебек геройлар язмышына берегез дә битараф калмагансыздыр, дип уйлыйм. Әчтән генә булса да аларны кызганып һәм җәлләп тә утыргансыздыр әле. Күбегезнең күңелендә аларны Халәп, Кадыйр, Шаһи белән Шаһбаз кебек явызлардан саклау теләге уянгандыр...

Теле, стиле, композицион төзелеше,вакыйгаларның характеры, геройларның бирелеше һәм бүленеше, фәлсәфәсе, кыскасы, барлык яклары белән «Язгы аҗаган» — безнең укучы бик тә ярата торган мелодраматик әсәр. Безнең әби-бабайлар җылый-җылый укыган, теге пәйгамбәрләр тормышын чагылдырган кыйссалар кебегрәк әсәр. Минемчә, уңышның төп сере шунда.

«Атаклы кешеләр тормышы» дигән серияне, халык шагыйре Габдулла Тукайга багышланган китабы белән, моннан ун еллар элек Ибраһим абый Нуруллин башлап җибәргән иде. Ике съезд арасындагы биш ел вакыт эчендә әлеге сериягә тагын өч китап өстәлгән. Турыдан-туры повесть жанрына кучканче, шул китаплар хакында берничә сүз әйтәсе килә.

Баштан ук шул кадәресе мәгълүм булсын: аларның өчесе дә: «Җәмәгать, без яңа тәпи йөрергә өйрәндек, әмма безгә игътибар юк»,— дип кычкырып торалар. Димәк, кичекмәстән җыелып сөйләшергә кирәк.

Арада уңышлырагы — Фатих Әмирхан турындагы китаптыр, мөгаен. Хәтта ул да күңелдә төрле-төрле ризасызлыклар уята. Әдипнең тормышына, иҗатына караган күп фактлар ачылмаган. Ачыкларга мөмкин булганнары да шул килеш калган. Язучының революциядән соңгы иҗат эволюциясен бәяләүдә булсын, Фатих Әмирханның революциягә һәм Гражданнар сугышына, Татарстан АССР төзелүгә һәм Совет хөкүмәтенә, Ленинга һәм коммунистларга мөнәсәбәтен ачыклауда булсын, автор әледән-әле кыен хәлләрдә кала, гаҗизлек күрсәтә.

Хәсән Хәйринең Такташка багышланган китабы бөтенләй аптырашта калдыра. Шагыйрь иҗатына тематик һәм хронологик күзәтү рәвешендә язылган бу китапта һәммә нәрсә искечә, вульгар социологизм чорындагыча. Колхозларга дан җырлана, сыйнфый көрәш кызганнан-кыза бара, «бөек борылыш елы» мактала... Башкасын әйтмим, әйтерсең, әле XX съезд да булмаган, шәхес культы да фаш ителмәгән.

Бер нәрсәне истән чыгармау кирәк, татар халкы өчен шәхес культы белән бәйле репрессияләр 1937 елдан түгел, шактый иртәрәк — солтангалиевчелек хәрәкәте дигән карачкы, бүки уйлап чыгарылган көннәрдән башлана. Такташ шуның әдәбият өлкәсендәге беренче корбаннарыннан була.

Ниһаять, соңгы фикер. Әсәр ахырында, «Гаилә дулкыннары» кебек, шагыйрьнең шәхси тормышына караган һәм китапка ямаулык кебек тегеп куелган бер-ике бүлекчә булмаса, аны берничек тә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән чыгарып булмас иде...

Якын итмәсәм, бәлки файдам тияр дигән күпмедер ышаныч булмаса, ниһаять, үзе журналда утырмаса, берәр җаен табып, Р. Низамиевның «Язмыштан көчлерәк» әсәрен әйләнеп тә узар идем.

Билгеле булганча, ул — мәшһүр композиторыбыз Фәрит Яруллинның тормышы һәм иҗат юлына багышланган әсәр.

Әсәрнең баштагы бүлекләре аеруча йомшак эшләнгән. Теле авыр. Үзенңе, күзен җир туңгач, сукалаган басу өстеннән ат арбасына утырып барган кеше кебегрәк сизәсең. Фронт вакыйгаларына җиткәч, эшләр бераз җайлана тагын.

Рашат Низамиев үз героен намуслы солдат һәм намуслы композитор итеп бирергә тели. Бу җәһәттән ул «планын» тотырып үти алмаган. Әсәрдә совет солдаты Фәрит Яруллин образы бар. Ә менә мәшһүр композитор Фәрит Яруллин образы сыеграк.

Дөрес, автор сәнгать белгечләренең «Шүрәле» балетына караган хезмәтләрен намус белән укып чыккан. Ул хезмәтләрнең эчтәлеген безгә дә сөйли. Ләкин балетка бәя һәм анализ язучыныкы түгел, музыка белгеченеке.

Аннары, үзе яшәгән чор белән ныклап бәйләми торып, Яруллин иҗатын аңлау һәм аңлату мөмкин түгел. Ә чор — үтә катлаулы. Бер якта — гигант заводлар, яңа шәһәрләр, аскетлык дәрәҗәсенә җиткән фидакярлек, стахановчылык хәрәкәте. Икенче якта — иге-чиге булмаган репрессияләр. Бер якта — милли культураларның гөрләп чәчәк атуы. Икенче якта — шул ук, милли культура вәкилләрен күпләп кыру. Кайсы ялган, кайсы чын? Кайсы чын казаныш? Кайсы «показуха?» Шул сорауларга җаваплар тапмый торып, чорның төгәл, тулы концепциясен булдырмый торып, ул заман хакында тормышчан әсәрләр язу кыен булачак. Бу — бер Низамиевка гына карый торган нәрсә түгел.

Китапта пафослы, төче сүз күп. Р. Низамиев ялтыравык бизәкле, купшы тел белән язарга ярата икән. Әмма теленә эчке ритм, динамика һәм төгәллек җитми. Бер урында: «Фашизм көчләп таккан сугыш һәм талантны саклауда битарафлык күрсәтүчеләр татар Моцартын үтерде», дигән җөмлә очрый. Буйдан-буйга үстерелә килмәсә дә, болай шактый кыю һәм мәгънәле фикер үзе! Инде җөмләнең төгәллегенә һәм яңгырашына игътибар итегез: т а л а н т н ы  с а к л а у д а  б и т а р а ф л ы к  к ү р с ә т ү ч е л ә р...

Әсәрнең исеме дә («Язмыштан көчлерәк» — шушы исем булдымы?), бүлек башлары да («Авторның күзаллавы», «Казанга кайту», «Үз-үзеңне җиңү батырлыгы», «Атылган йолдыз эзләреннән» һ.б.ш.) — бу егетнең телгә тоемы әллә кем түгел дип торалар.

Бер кызгач, күптән күңелне борчып йөргән тагын бер фикерем белән уртаклашыйм әле.

Игътибар итәсезме икән, әдәбият мәйданына килгән яшьләр арасында бик тә сәер егетләр очрый башлады бит әле. Әйтик, син аңа татар поэзиясенең язмышын ышанып тапшырсаң, ул иртәгә үк үзенең поэмасын «ходка» җибәрә. Син аны татар прозасының язмышын хәл итә торган урынга куясың, ул иртәгә үк үзенең романын яки повестен бастыра башлый. Кая гына куйсаң, нинди генә эш тапшырсаң да — шул ук хәл. Һавага чөйсәң, шунда ук канат чыгып, оча башлыйлар. Суга ташласаң, шунда ук яры үсеп, йөзә башлыйлар. Кеше турында уйлау юк. Гаделлек турында уйлау юк. Нәрсә бу? Кайбер картлардан үрнәк алумы? Әллә инде өстәлгә утырганда бисмилла әйтергә онытумы? Нәфес — шайтан, диләр. Туктый белмәсәк, әллә кайларга барып җитүебез бар лабаса. Бу, шулай ук, бер конкрет кешегә генә карап торган сүз түгел.

Роман белән хикәядән аермалы буларак, повесть — татар прозасының нык үзләштергән, аеруча якын һәм үз иткән жанры. Бездә бу жанрның бай традицияләре, исемнәре бөтен илгә таралган осталары бар. Бу өлкәдә безнең хәлләр беркайчан да артык мөшкел булганы юк. Заман җилләренә үтә сизгер, тормыштагы яңа тенденцияләрне иң элек күреп ала торган жанр буларак та — бүгенге тормыш сулышы, үзгәртеп кору рухы повестьларда ныграк чагыла. Соңгы биш ел эчендә язылган повестьларга күз ташлау белән, моның шулай икәнен үзегез үк күрерсез.

Шул хакта сөйли торган иң характерлы мисал, һичшиксез, И. Салаховның «Колыма хикәяләре». Мин ике съезд арасындагы прозабызның иң зур уңышы һәм дә казанышы шушы повесть дип уйлыйм. Ул җанны тетрәтерлек бик күп вакыйгалары, иң кыен хәлләрдә дә сынмаган-сыгылмаган трагик шәхесләре белән истә кала (К. Абрамов, С. Атнагулов, Алкин, М. Баһаутдинов, Г. Гали, Г. Ильясов, З. Имәнкулов, Г. Камай, М. Мутин, Г. Нигъмәти, К. Тинчурин, Әбҗәлимов һ.б.һ.б.). Шулай да әсәрнең кыйммәтен, зурлыгын һәм яңалыгын болар гына билгеләми. «Колыма хикәяләре» — укучының күзен ача, аңын уята, фикер үсешен тизләтә торган әсәр.

Без фашист концлагерьларындагы вәхшилекләр, коточкыч хәлләр турында күп яздык, күп укыдык. Инде менә үзебездәге хәлләр белән таныштык: үзебездәге төрмәләрне һәм лагерьларны, үзебездәге следователь һәм конвоирларны күрдек. Авторның уңышы — шуларны шомартмый-нитми, арзанлы фәлсәфәгә, акыл сатуларга бирелми язып чыгуда. Башы булган кешегә уйланырлык, җаны булган кешегә борчылырлык хәлләр бар монда!.. Бик тә рәхимле һәм китап җанлы, шул ук вакытта бераз гына беркатлы һәм самими күңелле татар укучысына шушындыерак бер китап кирәк иде.

Биш ел вакыт эчендә, минем исәп буенча, прозаикларыбызның 74 яңа повесте дөнья күргән. Бу — елга уртача 15 повесть дигән сүз. Күтәргән проблемалары, характерлары, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан алар бик тә төрле-төрле.

Кемнәр янына, кайсы киштәгә куярга икән дип аптырап йөрдем-йөрдем дә, сүзне

Батулланың «Алып батыр маҗаралары» повестена сокланудан башлап китәргә булдым. Батулла — әкият язып теш чыгарган кеше. Аның балалар өчен әкиятләрен укымаган яки ишетмәгән кеше юктыр. «Алып батыр маҗаралары» — ул язган әкиятләрнең аеруча шәбе. Бу әсәре белән ул әкият жанрын тагын да яңарта төшкән, аңа яңача яңгыраш биргән, заманча рух өргән. Ныклап караганда, ул әле әкият тә түгел, ә бәлки, тылсымлы әкиятләргә таянып, аларның мотивларыннан файдаланып язылган чын социаль повесть. Формасы — әкиятнеке, эчтәлеге күбрәк — бүгенге дөнья мәсьәләләре, бүгенге кешеләр тормышы турында. Көлә-көлә укып киләсең дә, ахырга таба никтер моңсу була башлый. Күңелне борчулы уйлар, гамь баса. Герое да шундый: үсә-үзгәрә торган, үз йөзе, индивидуаль характеры булган герой. Гомер буе халык кайгысын кайгыртып яшәгән кеше. Шул юлда йөреп, ахырдан йортсыз да, хатынсыз да, малсыз да кала. Күктә ажаган уйнаган саен, күз алдына шул бәхетсез карт килеп баса...

Бик телэсәм дә, мин һәр кешегә, һәр әсәргә туктала алмам. Шулай да ике авторның әсәрләре хакында бөтенләй дәшмәсәм, мине кичермәсләр. Аларның берсе — Ринат Мөхәммәдиев. Икенчесе — Фәүзия Бәйрәмова.

Ике съезд арасындагы биш ел вакыт эчендә Р. Мөхәммәдиев «танылган тәнкыйтьчедән» тәмам «танылган прозаикка» әйләнеп бетте. Бүгенгесе көндә ул — күп кенә хикәяләр, дүрт повесть һәм бер роман авторы. Р. Мөхәммәдиев беренче проза әсәрләре белән үк үзенә өмет һәм ышаныч уята алды. Көчәнми-азапланмый язуы, йөгерек каләме һәм телгә тоемы, аннары, заманча фикерләве белән.

«Кенәри — читлек кошы» турында әсәр басылып беткәч сөйләшербез. Басылып беткәннәре арасыннан «Ак кыялар турында хыял» повесте аеруча матур тәэсир калдыра. Проблемасының яңалыгы белән (кемгә ак кыялар, кемгә яшел болыннар кадерле), фәлсәфи мәгънәсе (һәркемгә үз эше кадерле), тормышчан һәм матур картиналары белән. Авылда беренче көтү чыккан иртәне сурәтләгән битләрне хәтта М. Мәһдиев тә: «Кара, бу чукынмышны!» — дип, сокланып укыгандыр, дип уйлыйм.

Республика язучыларының XI съездына Фәүзия Бәйрәмова дүрт яңа повесть белән килде. Повестьларының һәркайсы кызыклы һәм үзенчәлекле, һәркайсы үзенчә кызыклы. «Болын» — «Битлек»кә, «Битлек» — «Чакырым баганалары»на охшаган кебек, «Күл балыгы» әлеге өч повестьның барысыннан да нык аерылып тора. Шул ук вакытта барысы да Фәүзиячә кабынып-кайнарланып, дуамалланып язылган. Барысыннан да хис ташкыны бөркеп тора. Повестьларын укыганда, үзеңне әле кайнар җилләр искән ком чүлендә итеп сизәсең, әле бер-бер артлы ишелеп, тәгәрәшеп килгән диңгез дулкыннары уртасында калгандай буласың...

Биш ел эчендә басылган әсәрләргә сан ягыннан караганда, автобиографик характердагы, документаль һәм тарихи-документаль повестьларның аеруча күп булуын билгеләп узарга кирәк. Сыйфат ягыннан караганда исә күңелдә өмет уятырдай күренешләрнең, заманчарак тенденцияләрнең көчәя баруы шатландыра.

Рус язучыларының табигатьне һәлакәттән саклап калу өчен ничек һәм ни рәвешле көрәшкәннәрен беләбез. Без моңарчы табигатьне һәм табигый байлыкларны саклау мәсьәләләренә гафу ителмәслек дәрәҗәдә битараф булдык.

Шома-шома егетләр 25—30 ел эчендә йөз елларга җитәрлек татар нефтен әрәмшәрәм итеп бетергәндә дә, матур-матур егетләр, республика табигатенең иң гүзәл төшләрен пычратып, гигант заводлар, яңа калалар салганда да без, язучылар, аларның шул эшләрен мактап, кул чабып тордык. АЭС төзелгәндә дә нәкъ шул хәл кабатланды. Республика, район, колхоз җитәкчеләре иген кырларын химик ашламалар белән эштән чыгарып бетергәндә дә дәшмәдек. Ярамас, «дәү абыйлар» ачуланыр дип курыктык.

Республиканың иң күренекле өч прозаигы Тукай районының «Гигант» совхозы директоры Нәҗип Зиатдинов турында «Игелек» исемле махсус китап язып чыгардылар. Мәсьәләнең мондый четерекле якларын алар да читләтеп үтте.

Экологик катастрофа, кырыс реальлек булып, тәмам алдыбызга килеп терәлгәч кенә, ниһаять, без дә уянырга булдык. Р. Мостафин, Ә. Баянов, Ә. Гаффар, Ф. Бәйрәмова, М. Хуҗин, К. Тимбикова, Ф. Яруллин кебек прозаикларыбызның әсәрләрендә табигать дөньясын, кеше белән табигать арасындагы бәйләнешләрне саклау мәсьәләләре шактый җитди һәм калку итеп куелды.

Минем үземә шундый әсәрләрдән аеруча нык ошаганы — М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повесте булды.

«Бәхилләшү» — авылның үткәнен һәм бүгенгесен, авылның авыллыгын, татарның татарлыгын күп еллар буе бөтен нюанслары белән сурәтләп килгән популяр язучының элекке әсәрләреннән үсеп чыккан повесть. Мең төрле җепләр белән ул М. Мәһдиевнең моңарчы язган барлык әсәрләренә тоташып, уралып, чорналып беткән. «Бәхилләшү» — моңарчы язылган әсәрләренең соңгы аккорды. Повесть, авторның барлык әсәрләре кебек үк, ирекле стильдә язылган. Ул берсеннән-берсе кызыклы эпизодлары, бик тә колоритлы аерым геройлары белән истә кала. Язучы җиңел генә чордан —

чорга, геройдан — геройга, авылдан — шәһәргә, бер төрле настроениедән икенчесенә күчә. Әсәрдә кырыс реализм юмор белән, лиризм сатира белән чиратлаша.

Шулай да, «Бәхилләшү» — асылда моңсу әсәр, сагышка, моңга, күз яшьләренә манып язылган повесть. Моның, ягъни шулай язуның, сәбәпләре тирәндә ята.

Язучыны гасырлар буена туплана килгән, халыкны халык итеп, милләтне милләт итеп яшәткән матур йолаларның, әхлак нормаларының, гореф-гадәтләрнең онытыла, югала баруы борчый. Кешенең җирдән, табигатьтән бизә баруы аның бәгырен телгәли. Бу процесс хәзергәчә дәвам итсә — табигать бетәчәк, кеше дә бетәчәк. Авылны ничек яшәтергә? Кешене ничек саклап калырга? Авторга шул сораулар тынгылык бирми. Аптырагач, методик күрсәтмәләр яза башлый. Мин аны аңлыйм: Мәһдиевнең белгәннәрен кәгазьгә теркәп калдырасы килә. Ник дигәндә, ат җигә, печән чаба, чалгы яный, чалгы саплый, кибән куя белмәгән ир — кеше булудан туктый. Ул кибет, ындыр, ферма тирәсендә тәмәке тартып, аракы эчеп тәмам сасып-күксеп беткән карт тәкәгә — Р. Мөхәммәдиевнең «Ак кыялар турында хыял» повестендагы Микәйгә әйләнә... «Бәхилләшү» повестен мин шулайрак аңлыйм.

Мәрткә киткән кешеләр кебек, без күп еллар буе артык ваемсыз яшәдек. Бүген килеп җитәр, иртәгә килеп җитәр, дип — коммунизмны көттек. Без көткән гадел җәмгыять һаман күренмәде. Хыялыбыз тормышка ашмады. Экономик, экологик, социаль мәсьәләләр, ниһаять, милли мәсьәләләр көннән-көн кискенләшә барды. Табигатьне пычратып, табигый байлыкларны әрәм-шәрәм итеп бетердек. Битарафлык, рәхимсезлек арта барды. Нигә шулай килеп чыкты? Без кайда ялгыштык? Без кайчан ялгыштык? Бу хәлдән ничек чыгарга? Илне үзгәртеп кору юлына китергән шундыерак сораулар акрынлап безнең язучыларны да борчый башлады. Соңгы елларда басылган әсәрләргә шушы ноктадан карап та күз ташлыйсы килә.

Моның өчен иң кулай әсәрләрнең берсе Әмирхан Еникиның «Соңгы китабы» булыр төсле. Сез инде беләсез: ул документаль характердагы автобиографик әсәр. Беренче чиратта, Әмирхан аганың үзен, тормышын, әсәрләрен аңларга булыша торган әсәр, аннан килеп, әдәбият тарихын, иҗат эшенең, иҗат процессының хасиятләрен аңлата торган әсәр. Шуның белән бергә, әсәрдә гаҗәеп матур табигать күренешләре, төрле сословие, төрле милләт вәкилләренең коеп куйган образлары күп. «Соңгы китап»ның тугандаш башкорт халкына, Башкортстан табигатенә тирән хөрмәт һәм ихтирам белән сугарылуы басым ясап әйтәсе килә.

Әмма бу очракта мине матур табигать күренешләре дә, коеп куйган образлар да түгел, ә бәлки ике бәләкәй, эпизодик образ кызыксындыра. Берсе — Коръәнхафиз кушаматлы мишәр егете. Икенчесе — Казакъ Усман. Төп сыйфатлары шул: үз мәнфәгатьләренә ирешү өчен, болар теләсә нинди явызлыкка бара торган имансыз кешеләр. Хикмәт аларның явыз һәм имансыз булуларында да түгел. Хикмәт яңа җәмгыять тудырган мөмкинлекләрдән, гадел җәмгыять тудырган шартлардан шундый әшәке кешеләр файдалана алуда. Шуңа мөмкинлек, зәмин булуда. Дөрес, боларның берсе дә: Коръәнхафиз да, Казакъ Усман да әллә ни эре балыклар түгел. Әмма аларның эреләре дә булган, билгеле. Әсәрне укыганда бу сизелә. Яңа җәмгыять һәм шәхес, яңа җәмгыять һәм гаделлек мәсьәләсе повестьның буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла.

Г. Бәшировның «И язмыш, язмыш» повестендагы Зәйни бу мәсьәләдә М. Хәсәновның «Язгы аҗаган»ындагы үшән Халәптән дә, «Соңгы китап»тагы Казакъ Усман белән Коръәнхафиздан да уздыра. Шәхси карьерасы өчен, ул хәтта вәгъдә һәм ант бозуга барып җитә. Үсәргә, түрә булырга комачау итәр дип куркып, яраткан кызыннан баш тарта. Җитмәсә, шул әтлегеләр аклар өчен, демагогларча төрле сәбәпләр эзләп маташа. Антын бозган кешегә, хәлбуки, аклану юк, аклану була алмый! Яңа, гадел җәмгыять төзү кебек изге эшкә әнә нинди имансыз кешеләр алынган!

Ә. Еники, Г. Бәшировлар башлаган бу эшне алга таба, үзләренең яңа повестьлары белән, В. Нуруллин, Г. Кашапов, А. Гыйләҗевләр дәвам иттерә.

В. Нуруллинның Хәнәфиен («Җавап бир, кеше!»), бер тапкыр номенклатурага кереп калгач, кем икәнен белеп, кулыннан эш килмәслеген күреп торсалар да, бөке урынына бер эштән икенче эшкә күчереп тик йөртәләр. Колхоз председателе итеп куялар. 3—4 елдан менә дигән колхозны эштән чыгара. Авыл советы председателе итеп күчерәләр, авылны таратып бетерә. Аптырагач, бригадирлыкка куеп карыйлар, анда да аракы эчеп, кеше кыерсытып йөрүдән башканы белми.

Ләкин эш хисап бирүгә, тәүбә кылуга килеп терәлгәч, кылган әтлекләре өчен дә, явыз эшләре өчен дә Хәнәфи башкаларны гаепләп маташа: аның булдыксызлыгына район түрәләре гаепле — янәсе, моны кулда тота алмаганнар; авыл халкы гаепле — янәсе, электкечә тәлинкә тотарга теләмиләр; малай белән хатын гаепле — янәсе, миһербансыз һәм каты бәгырьлеләр; күп санлы сөяркәләре гаепле — янәсе, картайгач оныткан-нар h.б.h.б.

Г. Кашаповның «Убырут» повестендагы Мәүләви дә — шундыерак бәндә. Хәнәфи

белән Мәүләвинең табынган деннәре, дөресрәге, денсезлекләре, яшәү принциплары гына түгел, кылган явызлыклары, хәтта хезмәт урыннары да бер төслерәк. Хәнәфи кебек үк, Мәүләвине дә эштән-эшкә күчереп йөртәләр: авыл Советы секретареннан председательлеккә күтәрәләр, аннары колхоз председателе итәләр, ниһать, урманчылыкка күчерергә мәҗбүр булалар. Хәнәфи кебек үк, ул да тол хатыннарны каһәрли, авылдашларын кыерсыта, авылны таратып бетерә... Бу ике образ арасында күпмедер аерма да бар. Әгәр В. Нуруллин героеның этлекләре күбрәк гади көнкүрешкә караса, Г. Кашапов герое, моңардан тыш, социаль һәм сәяси явыз да. Асыллары барыбер бер: икесе дә авыл дошманнары. Авыл хуҗалыгын, колхоз авылын бүгенге кызганыч хәлгә Хәнәфи, Мәүләви кебек номенклатура бөкеләре китереп җиткерде.

Форсаттан файдаланып, Г Кашапов адресына да берничә җылы сүз әйтәсе килә. «Убырут» — хәзергә аның иң көчле әсәре. Шушы биеклектән беркайчан да төшмәсен иде.

А. Гыйләҗевның «Яра» повестен хәзер тикшергән әсәрләрнең дәвамы дип тә, шул ук вакытта күпмедер дәрәҗәдә аларның антиподы дип тә карап була. Моны мин бигрәк тә, Г. Бәшировның «И язмыш, язмыш» әсәрен күздә тотып әйтәм.

«Яра» — фәлсәфи повесть, заман җилләренең уңай тәэсире турында сөйли торган әсәр. Аның үзәгенә антка тугрылык, мәңгелек яшәеш, мәңгелек мәхәббәт, мәңгелеккә омтылыш кебек җитди мәсьәләләр куелган. Повестьта кешелекле мөнәсәбәтләр, матур йолалар, гореф-гадәтләр турында сүз бара. Шул мәсьәләләргә булган карашларыннан чыгып, геройлар төркемнәргә бүленәләр, үзара төрле-төрле мөнәсәбәтләргә керәләр. Гыйләҗев үз геройларын экстремаль хәлләргә куя, аларның шундый ситуацияләрдәге рухи халәтен аеруча оста сурәтли. Язучы кеше рухының бөеклегенә, кеше җанының түземлегенә соклана.

Шул рәвешчә, өстән-өстән йөгертеп булса да, биш еллык прозабызны күзәтеп чыктык. Без теләгән дәрәҗәдә булмаса да, талантлы һәм кызыклы әсәрләр язылып торган, басылып торган. Алга таба да шулай булачак. Безнең прозада талантлы кешеләр бар һәм булачак. Әмма җитди бердәмлек, гомум күтәрелеш, зур эшләргә тотыныр алдыннан була торган күтәренкелек хисе җитми.

Ике съезд арасында басылган роман-повестьларның һәм хикәяләрнең күп өлешен стандарт әсәрләр тәшкил итә. Ерактагы, бигрәк тә капиталистик илләрдәге, бөтен-бөтен кимчелекләрне ифрат ачык күрсәтеп тә, якындагы, үзебездәге, бер генә кимчелекне дә күрсәтми торган «серле күзлек» кигән иске язучылар һич кенә дә позицияләрен ташларга җыенмыйлар. Аларның шул күзлекне киеп язган һәм инкубатор чебешләредәй игезәк әсәрләре кибет киштәләрен тутырып ята.

Әле кайчан гына порнографиягә, арзанлы күз яшьләренә исәп тотып язылган массовый әдәбиятка йөз тоталар дип, капитализм илләрен сүгеп йөри идек. Карыйбыз — массовый әдәбият үзебезгә килеп кергән. Китап кибетләрендә укучы көне буе көнкүреш ваклыкларын, җенси мөнәсәбәтләрне тәмләп сурәтләгән арзанлы әдәбиятка һәм детективка чират тора...

Кайчандыр: «Талант — халык байлыгы», дигән сүз бар иде. Торгынлык елларында без аны: «Талант — хатын байлыгы» дип үзгәрттек. Форсаттан файдаланып, әсәр арты әсәр бастырып, китап арты китап чыгарып, акча эшләргә тотындык. Шул хәл дәвам итә.

Эшләр хәзергәчә барса, татар әдәбиятын нинди язмыш көткәнен күз алдына китерәсез булыр. Әйдәгез, уйлашыйк! Бу, бәлки, соңгы мөмкинлектер?!. Шуннан файдаланмасак, кичермәсләр безне, кичермәсләр...

**Тәлгать Галиуллин**

# ШИГЪРИЯТТӘ — ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

Сиксәненче елларда татар әдәбияты ике олы язучысын, халык киләчәге белән яшәгән намуслы шәхесләрен югалтты. Исән чакларында да гел янәшә йөргән бу исемнәр йөрәктә, күңелдә мәңгегә бергә кушылдылар: Хәсән Туфан, Сибгат Хәким... Арабызда вакытта да аларның фикерләре, уйлары, ниятләре белән санашмаган, алар-

дан тәүфикълылык, шәфкатьлелек дәресләре алмаган татар әдибе юктыр. Туфан белән Хәким янында һәрвакыт һәм һәркайда, саф һавага бай урмандагы шикелле, иҗади һәм әхлакый сәламәт рух яшәде. Өлкән шагыйрьләребез халык язмышы белән иҗат юлларын аерылгысыз бер бөтен итеп кушу бәхетенә ирештеләр, үзләреннән соң яшәүчеләр өчен изге хыял һәм максат үрнәге булып калдылар.

С. Хәким, бигрәк тә Х. Туфан, соңгы елларда илдә барган үзгәреш-яңарышларның шаһитлары булмасалар да, хәзерге шигъри эзләнүләр юнәлешен, мәйданын, сурәтле фикерләү эстетикасы үсү юлларын алар эшчәнлегеннән башка күзаллавы кыен. Чынбарлыкның рәсми-хыялый сурәтчәсе артына яшеренгән чын тормышны, кешенең кайгы-хәсрәтен, эзләнү-үкенүен, гади сөенечләр өчен фаҗигале күрәшен сурәтләү юлына сугыштан соңгы татар поэзиясен Хәсән Туфан алып чыкты. Соңрак аңа үз тавышы, үз моңы белән С. Хәким кушылды. Әле алар, үз чиратында, татар һәм башка милләт поэзияләре ачышларына таяндылар, иң яхшы традицияләрне дәвам иттерделәр, үстерделәр.

Шуңа күрә дә татар поэзиясенең хәзерге халәтен һәм үсеш мөмкинлекләрен тарихи үткәннән, дөресрәге, XX гасыр шигъриятенең гомуми контекстыннан башка аңлавы мөмкин түгел.

Хәзер соңгы унъеллыгына якынлашкан өермәле XX гасыр башында татар поэзиясе үсешенең яңа — реалистик чорына килеп керә. Татар әдәби теле тулы көчкә яңгырый. Шигърият кешелек серләренә, әйтелмәгән, сәер, кинаяле тирәнлекләргә юл ала, зиһен эшчәнлегенең, кичереш үсешенең иң нечкә катлауларына, тибрәлешләренә үтеп керү алымнарын ача. Сурәтле фикерләү биниһая байый, төрләнә, сүзобраз ифрат тыгызлана. Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиев, Бабич, Такташлар чорыннан алып, утызынчы еллар башына кадәр татар поэзиясе шигъри тыгызлыкка омтылышын, яңа образ, ритм, рифмалар өчен көрәшен туктатмый. Еш кына эчтәлекне дә сурәтле киеренкелек баета, тулыландыра. Мәсәлән, Х. Такташның «Җир уллары» трагедиясе, Х. Туфанның егерменче еллар поэмалары.

Тик сугыш алды унъеллыгы башында канатлы ат булган шигърият үзенең илаһи юлыннан бәреп чыгарыла, аңа тимер авызлыклы йөгән һәм бугазга чаклы төймәле мундир кидерелә.

30—50 нче елларда аерым көчле поэтик системалар хәрәкәт итсә дә (Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Җәлил, Ф. Кәрим), сугыш еллары шигъриятьтә героик аккордларны үстерсә дә, татар поэзиясе тулаем көпшәкләнә, образлы тыгызлыгын җуя, шәхси башлангычны — гомуми сүзләр, җир кешесен — «юлбашчы» сурәтчәсе алыштыра.

Сталин илгә көчләп таккан политик һәм бюрократик тышау террорыннан иң зур зыян күргән милләтләрнең берсе — ил буйлап сибелгән татар халкы булгандыр. Иң аянычы шунда: аңа «классик халыклар» күптән узган милли бердәмлек процессын тәмамлау мөмкинлеге бирелмәде.

Шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да татар мәктәпләре (уку-укыту башка телгә күчерелү сәбәпле) бик нык кими, чит өлкәләрдәге газета-журналлар ябыла, яклаучысыз татар баласы бер төрле язуны «йотып» өлгерә алмый, аңа икенчесен, өченчесен китереп сылыйлар. Халык үзенең тамырыннан, тарихыннан, әдәп-әхлак, тәрбия эшенең нигезе булган әдәбияттан аерыла. Кеше анасын оныткан, «халыклар атасыннан» башка берәүне дә танымаган Чыңгыз Айтматов әйткән манкортка әверелә.

Утызынчы еллардан башлап, әдәбиятка Ф. Әмирхан, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Н. Исәнбәт кебек төпле белемле, интеллектуаль-фәлсәфи көчкә ия шәхесләрнең аз һәм берәмтекләп кенә килүе аңлашылса кирәк. Әлбәттә, поэзиянең төп көчләре юкка чыгарылгач та, иҗаттан читләтелгәч тә, изге урын бушамый. Әдәбиятка завод-фабрика ударниклары, колхоз алдынгылары чакырыла. Тик поэзиядә соры шигырьләр, уртакулдан түбән кәсепчеләр дә бик күбәя.

Югарыда аталган сәбәпләр нәтиҗәсендә, татар әдәбияты үз эчендә бикләнеп калды, олы чыганагын, бай чишмәсен югалтты. Пенза, Тамбов, Оренбург, Ульяновск, Куйбышев, Чиләбе, Тобол кебек татарлар күп яшәгән өлкәләр хәзер татар әдәбиятына үз вәкилләрен җибәрмиләр диярлек. Урта Азиядән, Себердән, Чувашстаннан да талантлар берән-сәрән генә килә. Уфа сәләтле татар яшьләрен үзендә калдыру хәстәрен күрә.

Башка милләтләр (бигрәк тә рус, башкорт һәм Урта Азия халыклары) татар этносын үзләштерү, «эретү» исәбенә кан яңартса, ыруын баетса, безнең андый мөмкинлек киселгән, чикләнгән булып чыкты. Тыйнак, эшчән, ягымлы, гаиләгә турылыклы татар хатыннары башка халыкларга ничаклы булдыклы, талантлы, хәтта гениаль (Чыңгыз Айтматов кебек) ирләр тудырып бирделәр. Әмма аннан татар исемле халыкка әллә ни файда тимәде, әдәбиятына шөһрәт өстәлмәде. Башка милләткә хезмәттә гомерен уздырган аналар, аң-белем алып килгән татар зыялылары, мулла-мөгаллимнәре шикелле үк, онытылдылар.

СССРда яшәүче олы тарихлы мәдәнияты булган милләтләрнең чит илләрдә иҗат ителгән эмигрант әдәбияты бар. Хәзер ул мирас, озын юлларны үтеп, шартлы киртәләрне ватып, үз халкына әйләнеп кайта. Рус, украин, Балтик буе халыклары, әрмән, әзербайҗан, уйгур әдәбиятлары — шуның ачык мисалы.

Хәзерге хәбәрдарлык, демократия чорында да без ил чигенең аргы ягындагы татар әдәбияты, анда калган мирасыбыз турында аз беләбез. Заманында Көнбатыш Германиядә, Төркиядә басылган китапчыклар Казанга да килеп җиткәли иде. Читтә яшәгән каләмдәшләребез белән элемтәгә кереп, үсешләренә идея-эстетик ярдәм күрсәтәсе, ахыр чиктә, юнәлеш бирәсе урынга, без аларны тупас рәвештә кактык, үзебездән катгый рәвештә аерып куйдык.

Заманында читкә тибәрелгән рухи байлыкларны кире халыкка кайтару — тарихи хәтерне торгызу эшенең мөһим юнәлеше. Бу нисбәттән озак еллар буена нахакка рәнҗетелә, кыерсытыла килгән «Идегәй» дастанының халыкка әйләнеп кайтуы демократиянең зур җиңүе булды.

Шәхес культын фаш итү илдә яңа өметләр, хыяллар уятты. Татар поэзиясе 60 еллар башында халыкның рухи тормышында элек уйнаган абруен, урынын кайтару юнәлешендә кыю адымнар ясый. Ләкин язмыш аны тагын бер җитди сынау алдына куя.

60—70 еллар аралыгында татар әдәбиятының яшәешенә, киләчәгенә тагын бер удар ясала. Халыкның иплелек, әдәп, инсаф буенча гасырлар дәвамында канга сеңдерелә килгән, гореф-гадәтен саклаучы тарихи чыганак, этник һәм психологик нигез — авыл күз алдында юкка чыга башлый. Бер яктан, аны һәртөрле уйдырма сәбәпләр, налоглар, кечкенә мәктәпләрне ябулар аша рәсми кысу башланса; икенчедән, авыл халкын неон утлары, асфальт юллары, җылы сулары, кызыктыргыч киләчәге белән шәһәр үзенә суыра.

Ерактан килгән кала мәдәниятыбыз сакланмау, үз телебездә укытыла торган югары уку йортларыбыз булмау (татар теле һәм әдәбияты белгечләреннән башка) сәбәпле әдәбиятыбызның киләчәге авыл язмышына бәйле булып чыкты.

Әдәбият авылны кызганып яшәгән арада, цивилизация дигән көч тимер тырнакларын Татарстан җиренә тирәнрәк батыруын дәвам итте. Кара туфраклы җир өстенә төтен бөркүче гигант корпуслар, күп катлы йортлар килеп утырды, урманнар киселде, елга-күлләр кипте. Кара алтын чыгару буенча ничәмә еллар беренчелекне алып килдек, илебезне алдынгы мәмләкәтләр рәтенә чыгарабыз дип тырыштык. Тиңе булмаган КамАЗ төзедек. Түбән Кама, Әлмәт, Җәлил, Лениногорск шәһәрләрен ил картасына керттек. Алабугада әүвәл трактор заводы, хәзер җиңел машиналар заводы корыла дип шауладык.

Мәскәүдән һәм бүтән шәһәрләрдән килгән кунак-әдипләрдән калышмаска тырышып, алар белән ярыша-ярыша, татар шагыйрьләре дә республиканың тимер адымнарын данлап, озын-озын поэмалар, шигырьләр, гимннар, ораторияләр яздылар. Әмма татар шигыре әлләни отмады, укучысы артмады.

Берничә ел элек Чулман елгасы буенда, Кама Аланы куенында, табигатьнең гүзәл бер почмагында атом станциясе корыла башлады. Бу төзелеш Татарстанда тереклекне, табигатьне, димәк, кешене саклап калу өчен көрәш башлап җибәрүгә, халыкта, бигрәк тә бу эшнең оештыручысы — яшьләрдә экологик аң тәрбияләүгә этәргеч бирде. Яңа объект «Челнобыль», атом каласы дигән кушамат алды. Татар язучыларының төзелешкә мөнәсәбәтләре ничегрәк булды соң?

«Казан утлары» журналы, авторлар коллективын туплап, бу хәвефле эшкә җанытәне белән каршы күтәреләсе урынга, атом станциясендә әдәби постын ачып җибәрде, даими рәвештә материаллар бирә башлады. Әлеге төзелешне «зурлауда» журналистлар катнашуы бер хәл, ә инде шагыйрьләрнең, йөзләренә ясалма елмаю чыгарып, бу эшкә тартылулары аңлашылып бетми.

Ил әдипләре язу өстәлләрен калдырып, каләмнәрен читкә куеп, табигатьне коткару өчен дауны җитәкләгән чорда, без үлеменә якынлашуны хуплап кул чапкан ахырзаман балаларын хәтерләтмибезме? Әдәби постларны сукыр күзеннән соңгы тамчы суын сыгып яткан, инешләр бетүгә, урманнар кырылуга каршы көрәш әмәлен эзләгән авыллар тирәсендәрәк ачу хаерлерәк, саваплырак булмасмы? Табигать өчен көрәш — кеше күңелендәге иң изге тойгыларны, матурлык хисен саклау, яшәеш өчен тартышу икәнлекне онытмыйбызмы? Ваемсызлык, гамьсезлек, агым буенча хәрәкәт итүебез киләчәктә кыйммәткә төшмәсме?

Эндәшмичә баш иеп, кул кушырып утырсак, болай да кысылган җиребездә яңа объектлар пәйда булыр. Шәһәрләр үсүнең икенче ягы да бар. Тәүфикъ Әйди саннар белән күрсәткәнчә, бабаларыбыз җирендә татар халкы процент ягыннан елдан-ел кимүгә бара («Татарстан яшьләре», 1989, 3 январь). Казан шәһәре буенча да статистика шатландырырлык түгел (Кара: Сидорова Т. «Перспективы и реалии»,

«Советская Татария», 4 май, 1989 ел). Башка республикаларда соңгы елларда барган милли уяну хәрәкәтенең нигезендә теге яки бу төбәктә экологик һәм демографик ситуациянең кискен үзгәрүе ята. Эстония Фәннәр Академиясе академигы М. Л. Бронштейн болай дип яза: «Промышленностьның интенсив үсүе һәм эшче көчләрне башка регионнардан кертү нәтиҗәсендә республикада эстон халкы саны кимүгә йөз тотты: 90—80—70—60 процент. Шул хәл сакланса, җирле халык үз илендә азчылыкны тәшкил итәр иде... Бу хәл халыкның үз җирендә үзе хуҗа булып калуга омтылышын кискенләштерде» («Правда», 1989, 16 январь).

Хәзер көчләрне туплау, фикерләүне, күзаллауны төрле бәйләрдән азат итү дәвере килде. Үзен ирекле сизгән, тар киртәләр белән чикләнмәгән шигърият кенә кешеләргә яңалык һәм аралашу шатлыгы алып килә ала.

Табигать ярлылану, авыллар юкка чыгу кебек фаҗига татар шагыйрьләре игътибарыннан читтә калды дип раслау дөрес булмас иде. С. Хәким, Г. Афзал, Ә. Баянов, Ш. Галиев, И. Юзеев, К. Сибгатуллин, Р. Фәйзуллин һ. б. тирәлеккә һәм ахыр чиктә кеше тормышына янаган куркыныч турында үтемле яздылар. Ә. Баяновның «Сәяхәтнамә», И. Юзеевның «Карурман», К. Сибгатуллинның «Авыл урыны» кебек колачлы һәм сәнгатьчә тәэсирле әсәрләре хәзер дә урынлы яңгырый. Шул темага язылган иң соңгы әсәрләрнең берсе «Ташландык авыл». Шигъри уйланышы һәм бирелеш рәвеше буенча әсәр Г. Афзал дәрәҗәсеннән тирәнрәк торса да, анда җанга үтеп керерлек, күңелдә авыр яра булып калырдай күзәтүләр бар: «Мал таптап бетергән каберләр. Зираты коймасыз, киртәсез». «Кешеләр шәһәргә китәләр, ни көтеп яшәсен чүплектә!» И. Юзеев та «Соңгы егет китте авылдан...» шигырендә шул ук проблемага килеп чыга.

Табигатькә янаган куркыныч төрле буын шагыйрьләрен борчый, уйландыра, эзләнүләр юлына алып чыга. «Җир хуҗасы булсак...» шигырендә Акъегет һәркемнең күңелендә йөргән фикерне әйтеп бирә алган:

*Әйе, Кеше хуҗа шушы җиргә,*
*Җир язмышы адәм кулында...*
*Хуҗа була белгән онытмасын —*
*Табигатьнең ул бит улы да.*

Шул ук мәңгелек хакыйкатьләр һәм яңа туа килгән кыенлыклар турында Зөлфәт «Чегем шарламалары», «Эт тоту көне», «Ат йокысы» шигырьләрендә уйлана. Яңа табигать, яңа мохит җирлегендә эре, масштаблы һәм нәтиҗәле уйлана.

Хәзерге поэзия турында сүз чыкканда, шагыйрьләр иҗтимагый гаделлек, тулы хакыйкать өчен илдә җәелеп киткән көрәшкә ничегрәк карыйлар, әлеге хәлләр алар иҗатында илһам учакларын кабыздымы?— дигән сорауның тууы табигый. Яшеренбатырын түгел, тормыштагы үзгәртеп корулар поэзиягә турыдан-туры кагылмый, татар шигъриятенә элек-электән дөрес юлдан үсте, аңа кыйбласын үзгәртеп торуның хаҗәте юк дигәнрәк фикердә торучы шагыйрьләр да бар. Чырайларына акыллы, ваемсыз төс чыгарып, читтәрәк калырга хыялланучылар да юк түгелдер. Әмма күпчелек татар шагыйрьләре хәрәкәт һәм эзләнү заманы килеп җитүне, иҗат кешеләре өчен дә яңа мөмкинлекләр ачылуны дөрес сиземлиләр, яңача фикерләүнең шигъри сынын әсәрләргә төшерү нияте белән яшиләр.

Үзгәртеп кору процессын М. Шабаев «Ачыктан-ачык» поэмасында турыдан-туры, публицистик рух белән тасвирлый. Сәнгатьчә эшләнеше, гомумиләштерү алымнары ягыннан бәяләгәндә автор камиллеккә ирешә алмаса да, әсәр ваемсызлыкка, мәгънәсезлеккә, битарафлыкка кискен каршы чыгуы белән җирле бурычын үтәде.

«Ярым дөреслек» шигырендә Н. Әхмәдиев йокы баскан, мүкләнгән, алдауга, шомартуга күнеккән бәндәләрнең намусын, вөҗданын уяту чараларын эзли: «Ярымдөрес — шул ук ялган бит ул, ялганнан да әллә ялганмы?»

Н. Арсланов «Гласность» турында», Г. Рәхим «Бөек хаклык», К. Сибгатуллин «Хөкемдар», К. Латыйп «Юл бирегез, гамьсезләр» әсәрләрендә иҗтимагый тормышта барган яңачалыкның күңел, йөрәк һәм хис хакыйкате дәрәҗәсенә күтәрелүе юлындагы кыенлыклар хакында фикер йөртәләр. «Гаделлеккә сусап алҗыган Кеше җаны өчен көрәш бара, Кеше җаны тора уязкта»,— ди К. Булатова «Соң булса да...» шигырендә. Яшәүгә, сүзгә ирек бирелгәч тә, шәхес рухында яңага борылыш авырлык белән бара. Р. Харис «Үзгәрәбез» әсәрендә шул хакта уйлана: «Ихлас сүзгә әле җылы җитми», «...уйга ирек бирдек — ул сугыша, телгә ирек бирдек — сүгенә...»

Хикмәт «яңартып кору» кебек сүзләрне тәкрарлауда түгел, ә язучының тормышчан позициясендә, чынбарлыкка актив мөнәсәбәтендә. И. Юзеев «Тиз үзгәрүче» бәндәләрне шик астына алуы белән дә, бәлки, хаклыдыр. «Сызыла-сызыла, кайчак өзелә-өзелә, Авыр үзгәрүчеләргә ныграк ышан»— ди ул «Үзгәрүчеләргә» әсә-

рендә. Кайбер шигырьләрдә яңадан кору темасы Сталин, аның репрессияләре турында уйлануларга алып чыга (Н. Арсланов «Каршыма», М. Әгъләмов «Остаз»). Фатих Кәримнең Сталин төрмәсендә язган шигырьләре үзенә бер ачыш булды. Чынлыкта шул ук явызлыкны рухи кабул итмәү, рухи сафлану, чистару ята.

Хәзерге татар шигъриятe, тормышның үзе шикелле, бай һәм төрле. Бәхетебезгә арабызда С. Баттал, Н. Арсланов кебек шигърият баһадирлары яшәп, эшләп килә. Үз буыны турында Н. Арсланов шаярып-көлеп, фәлсәфи моң белән яза:

*Хәят белеп тора:*
*Картлар үлеп тора,*
*Яшьләр күреп тора,*
*Язмыш көлеп тора...*

М. Садри, З. Нури, Х. Камалов, М. Хөсәен, Ә. Маликовлар халык кичергән олы фаҗига — сугыш турында күп язалар, мәңгелек темаларга да халык башыннан узган афәтне искә алу аша киләләр.

Әле кайчан гына яшь шагыйрьләр рәтендә йөргән, сурәтле фикерләүләре белән шаккатырган Э. Мөэминова, Г. Афзал, Ә. Баянов, Ш. Галиевләр алты дистәне алыштырып, татар поэзиясенең язмышы, киләчәге өчен янып-көеп йөриләр. Өлкәннәрнең эзенә басып килүче И. Юзеев, М. Шабаев, Р. Гәрәй, Н. Мадьяров, Ф. Гыйззәтуллина, Я. Игәнәй, К. Булатова, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин, Ш. Маннаповлар язучыларның олуг җыелышына буш кул белән килмәделәр. Һәркайсының иҗаты, киеренке фәлсәфи-әхлакый эзләнүе, иҗтимагый тормышта барган үзгәрешләргә шигъри мөнәсәбәте игътибарга лаеклы.

Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гатауллиннар иҗатында да яңарыш җиле тәэсирендә фәлсәфи уйлану, чынбарлыкны катлаулы каршылыклары аша аңлауга омтылыш, вакыйганы, кичерешне дәвамлылыкта тасвирлау рухи көчәя. Алар элеккечә күп язалар, татар, рус телләрендә китаплары басылып-таралып тора. Иҗтимагый активлыклары күз алдында.

Ләкин әлеге буын тиешле профессионал югарылыкта эшләсә дә, мин Р. Харис соңгы елларда иҗади үсешенең яңа бер чорына керде. Р. Фәйзуллин көтелмәгән ачылышлары белән, нәкъ менә алтмышынчы еллардагы төсле, укучыны сискәндереп, уятып җибәрде. Г. Рәхим юксыну, сагыну хисләрен яңа мохиттә, яңа җирлектә ачты. 80 еллар азагы кешесенең хыялый омтылышын, уңышын һәм сөрлегүен Р. Гатауллин кабатланмас шигъри сыннарда тулы гәүдәләндерүгә ирешә дип раслый алмыйм.

Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллин, Зөлфәт иҗатларында хәзерге чор терминнары белән мавыгу, теманың исемен атап сурәтләү очракларын күп тапмабыз. Алар йолдызстанга менмәделәр, җирдән аерылмыйча, яшәү белән үлем серләре, шәхес язмышының сикәлтәле борылышлары, сәер буыннары, хәзергене үткән белән бәйләүче кешелекле хисләр турында уйлануларын дәвам иттереп, татар поэзиясендәге җитди эзләнүләрнең алгы сафында кала алдылар. Ничәмә еллар буена алар ярдәмче юлдан атлаучы шагыйрьләр рәтендә йөрделәр. Бу — берьяклы караш иде. Әлеге сүз осталарының уңышлы әсәрләрендә заманчалык, туган җир чалымнары күзгә бәрелеп тормаган матурлыклары, илаһи мизгелләре, милли бизәкләре, сурәт тыгызлыгы, тел сыгылмалылыгы белән үрелеп ачыла. «Тарихымның утлы сүзләреннән, Заманамның нурлы күзләреннән эзлик әйдә яшәү мәгънәсен»,— ди Р. Әхмәтҗанов «Ак әремнәр кемне әрләсен» шигырендә.

Р. Миңнуллин, Х. Әюпов, Р. Вәлиев, Ф. Сафин, Ә. Мәхмүдов, Р. Низамиев, З. Мансуров, Н. Акмалов, Н. Измайлова, Р. Әхмәтовлар кеше рухының яңа матурлыкларын, шәхес белән җәмгыять, шәхес белән тирәлек арасында яшәп килгән каршылыкларны шигырь юлларына чыгару дәрте белән иҗат итәләр. Уңышлы шигырьләрендә безне түендырып, киендереп, рухи баетып килгән замана, шәхес эшчәнлеге лирик күренешләр, табигать хозурлыгы фонында ачыла.

Л. Шакирҗанова, С. Гәрәева, Э. Шәрифуллина, Э. Мөэминова, Ф. Гыйззәтуллина, К. Булатова, Ф. Зыятдинова, Б. Рәхимова, Р. Хәлиуллина, Ф. Низамова, К. Шәфыйкова һ. б.лар үз әлгәрләренең казанышларын дәвам иттереп, туып-үскән җирнең матурлыгы, бүгенгесе һәм киләчәге, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, гаилә, әдәп-әхлак, сөю һәм сөелү хисләре турында һәркайсы үзенчә уйлана. Араларында С. Сөләйманова кебек көчле талант булмау үзен сиздерсә дә, шигъриятькә килгән яңа көчләр стилистик бертөслелекне, хыялны чикләгән нормативлыкны, бер «кылылыкны» җиңеп, традиция колы булудан котылып, поэзиянең офыгын киңәйтергә омтылалар.

«Без хәзер сатираны онытып барабыз түгелме?!— дип яза Фәнис Яруллин.—

Кайчандыр шәп-шәп сатирик әсәрләр язган Г. Афзал, Ш. Галиев бу жанрдан читләште. Г. Афзал лирикага күчеп бара, Ш. Галиев талантын бөтенләе белән балаларга багышлады». («Социалистик Татарстан», 1986, 22 январь).

Дөрес, бу жанрда каләм тибрәтүчеләр аз түгел. Сатира үсеше өчен борчылып яшәгән Ф. Яруллинның кешелекле юморы, М. Саттаровның сәер хәлләрне үзәккә алган сатирасы, Х. Гатин тәҗрибәләре, А. Вергазов мәсәлләре укучыга таныш. Г. Рәхим, Р. Зәкиев, Р. Миңнуллин, Р. Юнысов кебек шагыйрьләрнең эзләнүләре игътибарга лаек.

Яшәп килгән җитешсезлекләр, кешенең тышкы кыяфәте артында яшеренгән эчке бушлыгы, ваклылыгы, комсызлыгы белән көлә-көлә саубуллашу өчен яңа мөмкинлекләр ачылды. Хәзер кинаягә, ишарәгә, эзоп теленә, символларга мөрәҗәгать итү мәҗбүри түгел. Ябык темалар юк. Кызганычка каршы, төп үзенчәлеге сатира һәм юмор булган әсәрләр аз языла, татар поэзиясенең бу өлкәдәге Акмулла, Тукай, Такташ, Ә. Фәйзиләрдән килгән йолалары тиешенчә үстерелми.

Шагыйрьләр «тыелган тема»ларга алынмыйлар, һаман да нәрсәдер көтәләр. Чабуга тотынып чорлар үтте, бәйгегә беренче булып йөгереп чыгар вакытлар җитте. Гомумән, татар характерына-холкына хас булганча, соңарып өлгерәбез.

Поэма жанры үзенә игътибар җитмәүгә үпкәли алмас. Соңгы елларда дистәләрчә поэмалар дөнья күрде, аның үсеше, уңышлары һәм йомшак яклары поэзиягә багышланган дискуссиянең үзәгендә торды. Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасы яшь тәнкыйтьчеләрне түгәрәк өстәл янына җыеп алды. И. Юзеевның «Сез кабызган утлар», Ә. Рәшитовның «Автопортретка штрихлар», Р. Зәйдуллинның «Күпер» кебек чынбарлыкны тормышчан конфликтлар һәм лирик герой кичереше аша иңләргә омтылган поэмалары хакында сүз күп булды.

Уңышлы поэмаларда лиро-эпик жанрның төп сыйфатлары ачык чагыла: лиризм көчәя, сурәтле фикерләү катлаулана, күләм кыскара, авторның үз шәхесе, тормыш юлы белән бәйле лирик герой үзәк фигура буларак калка, шигъри деталь гомумиләштерүгә юл ача. «Фатыйма мәхәббәте»— яшь шагыйрь Р. Шәриповның иҗат казанышы. Ул халык лирикасыннан, Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Кандалый поэмаларыннан килгән моңы, сагышы, салмак, саллы иҗеге белән җәлеп итә. «Каян алып нинди сүзләр белән генә ясыйм икән, Фатыймакай, сурәтеңне» кебек юллардан борынгы аһәң, халык җырына, рухына якын матурлык сирпелеп тора.

Поэма жанры, җәмгыятьнең бүгенге рухи тормышына бәя бирү белән генә чикләнмичә, тарихи тәҗрибәгә, үткәнгә мөрәҗәгать итеп, замандашыбызның эчке дөньясы нинди кыйммәтләргә таянып үсүе турында уйлана. Хәзерге поэманың дәрәҗәсен нәкъ менә шул төр әсәрләр билгели.

Шагыйрьләр тарихка шлюзларны ачканны, яшел ут кабызганны көтеп кенә торганнар, диярсең. Тиз вакыт арасында берничә тарихи поэма укучыга ирешә. «Ант суы»нда Р. Харис Рус белән Болгар дәүләтләре арасындагы мең ел элек килешүгә кул кую вакыйгасын үзәккә алса, Г. Рәхимнең «Аяз көнне яшен», Ә. Баяновның «Алтын кашбау» әсәрләренең нигезендә халык тарихының аянычлы бер чоры — Бөек Болгар дәүләтенең дала варварлары тарафыннан туздырылуы ята. Ә. Рәшитов ярым тарихи, ярым легендар Сөембикәнең кешелекле, тормышчан образын тудыруга ирешкән («Сөембикәнең Казан халкы белән хушлашканы»).

М. Әгъләмовның матбугатта уңай бәяләрен алган «Акмулла арбасы», «Тукай хатлары» янына З. Мансуровның «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Балкыш», Р. Харисның «Борылышта» поэмалары килеп өстәлде. Әсәрләрне документаль нигез якынлаштыра. Ленин, Акмулла, Тукай, Хәйретдин Мөҗәй кебек олы һәм фаҗигале язмышлар эшчәнлеге һәркемне бүгенге көн, үзе, намусы, кылган гамәлләре турында әхлакый-фәлсәфи уйланулар юлына алып чыга.

Соңгы бер-ике елда «Татарстан яшьләре» газетасы шагыйрьләргә урынны кызганмый, аларның шактый кыю, фикер уятучан чыгышларын укучыга ирештерә тора. Ләкин яшь шагыйрьләр еш кына үзара аңлашу, тәнкыйть белән мөнәсәбәтне ачыклау кебек мәсьәләләргә көчне сарыф итеп, олы проблемалардан читләшеп тә куялар. Яшьләр республиканы, халыкны кыздырган бәхәсләргә катнашудан читләшәләр. Нәтиҗәдә татар халкының тарихы, иseme, киләчәге һәм милли статусы турындагы сөйләшүләрдә иҗтимагый фәннәр әһелләре, очраклы кешеләр инициативаны үз кулларына алып баралар. Безнең заманда, тәвә кошы төсле, башны комга тыгып кына тормыш кутәргән җилләрдән качып котылып булмый.

Шагыйрь — чор, җәмгыять кешесе. Аның иҗади эшенә бик күп объектив һәм субъектив хәлләр тәэсир итә. Ләкин, шигъриятнең иң гүзәл үрнәкләре үз халкының нигезен, асылын тирәнтен аңлап, ачып бирү сәләтенә ия сүз осталары иҗатында туа. Төрле буын һәм юнәлеш шагыйрьләре бердәмлеген тәшкил иткән хәзерге татар совет поэзиясе андый исемнәргә һәм халык күңелендә үз урынын алырдай әсәрләргә бай.

# Азат Әхмәдуллин

# ДӨРЕСЛЕККӘ ИРЕШҮ ЮЛЫНДА

Татарстан язучыларының соңгы съездлары арасында драматургия үткән юлны күзәтеп, аңа бер генә төрле бәя бирү, анализда бер генә төрле үлчәүләргә таяну мөмкин түгел. Бер караганда, жанр хәрәкәте үз агымы белән бара бирде: пьесалар языла тора, театрлар афишалары да яңа әсәрләргә ярлы түгел. Бу чорда 50 гә якын (ягъни ел саен 10) пьеса язылган һәм сәхнәгә куелган. Куелмый калганнары яки чират көтеп ятучылары да бар — бу сан 60 ка якынлаша. Болар янына 20 гә якын җыентыкны кушып сөйләргә мөмкин. Сан ягыннан тәртип. Һәрхәлдә узган бишьеллыктан әллә ни аерма юк: алга китү дә, артка калу да күзәтелми. Һәм монда гаҗәпләнергә урын юк: тормыш, чынбарлык ихтыяҗы тәкъдим микъдарын тудыра. Бездә 4 драма театры бар, алар елына 5—6 премьера чыгара. Бер өлеше классика, аз гына булса да тәрҗемә бар, калганы — оригиналь әсәрләр. Драматургларыбыз чынлыкта артыграгын яза алсалар да, сәхнәдә куелу саны шул ук кала бирә. Ә сәхнә күрмәгән әйберне матбугатта бастыру, китап итеп чыгару бездә юк дәрәҗәсендә сирәк була.

Без еш кына «драматургиягә килүчеләр аз!» дип зарланырга яратабыз. Шулай да бу юлы аз килмәде яңа авторлар. Менә бу ике съезд арасында гына да театр афишаларында берничә яңа исем күренде: Ф. Бәйрәмова, Р. Сәлимҗанов, Д. Салихов, Ф. Галиев, М. Гыйләҗев... Ф. Шәфигуллин пьеса язып калдырды. Әйтүләренчә, Равил Бохараев та пьеса язган. Шулай, һәр елны бер генә драматург туып торсын иде әле. Шунысы куанычлы, бу яшь авторларның сәхнәгә беренче адымнары асылда өметле чыкты. Мәсәлән, «Акъярда ахырзаман» (Р. Сәлимҗанов) комедиясе үзенең шартлы ситуациягә корылышы белән дә, көлкеле күренешләргә һәм комик характерларга ия булуы белән дә, чор билгеләре шактый ук төгәл чагылган булуы белән дә җитлеккән пьеса. Төп фикере дә ачык. Ахырзаман киләчәгенә ышанып яшәп яткан 55 яшьлек Җиһан карчык бер дә бер көнне Шири дигән сөннәтче картның даруына (яшәртә торган дару, имеш) шулкадәр ышана ки, елдан-ел яшәрә барып, 105 яшендә 16-17 яшьлек кызлар кыяфәтенә керә, яшьләрчә кыланып яши. Тик эшкә генә урнаша алмый, паспортындагы туган елы комачаулый. Тагы да малае — 80 яшьлек Хөсәен карт аңа үзенчә йөрергә ирек бирми. Ширинең даруы ялган икәнлеге ачылгач, Җиһанны аңарчы гел яшәртеп килгән әчке ышаныч шартлап сына һәм ул 1 айда үз асыл кыяфәтенә кайта. Шундый фантастик сюжетка корылган пьеса оптимистик фикерне үзенчәлекле итеп раслый: «Һәрнәрсә — кешенең үзендә! Үзенең әчке ныклыгында, ныклы ышанычында!» «Барлык әшәкелек күңел картаюдан килеп чыга, — ди автор. — Күңел яшь булсын!» Асылда автор уздырган шушы фәлсәфи фикер дөрес һәм урынлы яңгырый. Шуның белән бергә бу фикернең дәвамы бәхәс тә уята. «Дөньда түгел хикмәт, — ди яшь автор Җиһан авызыннан. — Кешенең үзендә!» Моңа тагын 30 елларда Хөсәеннең ансат кына мәчет манараларын кисеп-аударып йөрүенә каршы булган Шири кебекләрне, Сөембикә һәм Гөлбикә кебекләрне комик-сатирик яссылыкта гына алуны өстәргә мөмкин. Бу дингә һәм динчеләргә карата әлек урын алып килгән, кичәге караш. Болар драматургның яшьлегеннән киләдер, күрәсең.

Р. Сәлимҗановның әсәре драматургиябездәге җанлы, халыкчан, традицион сызыкны чагылдырса, икенче дебютант — Ф. Бәйрәмова пьесалары ихтимагый-политик сызыкны публицистик юнәлештә үстерә. Минзәлә театрында уңышлы куелган «Һәркемгә бер кояш» исемле драмасы игътибарны бөтендөнья проблемаларына, сугыш һәм тынычлык, кешелеклелек һәм рәхим-шәфкать, рухи ярлылык, вөҗдансызлык мәсьәләләренә юнәлтте.

Мондый рухтагы пьесалар язуга омтылыш тагын да булмады түгел. Ә. Гаффарның «Килер бер көн!» исемле публицистик драмасын, Р. Батулланың «Мин Америка ачтым» дигән трагипамфлетын күрсәтергә була. Художество эшләнеше, фикер ачыклыгы белән М. Галиевнең «Әлегә соң түгел» дип аталган драмасы да уңай тәэсир калдыра. Бу — агитдрама алымнарыннан үсеп чыккан публицистик драма. Әкият һәм легенда элементлары, Адәм һәм Хава образлары проблеманы калкурак итеп, аның мәңгелек әһәмияте барлыгын әйтү өчен уңышлы кулланылган. Әкияттән реальгә, реаль дөньядан хатирәләр дөньясына (һәм киресенчә) күчешләр оста эшләнгән. Дөрес, кайвакыт әкият-легенда алымнары да, искә төшерүләр дә күпкәрәк китә. Ләкин нигездә автор легенда һәм әкият шартлылыгын, реаль чынбарлык атрибутларын уңышлы куша, синтезлый һәм асылда агитацион фикер булган төп идеяне катлаулы сентенцияләр аша укучыга җиткерә.

Бүгенгенең ачы хакыйкатен яктырту ягыннан Ф. Бәйрәмованың «Безне онытмагыз!» дип исемләнгән драмасы игътибарга лаеклы. 30 еллардагы сталинчылык законсызлыклары нәтиҗәләре белән бүгенге яшь буынның миһербансыз, каты бәгырьле булып формалашуы арасында автор эчке бәйләнеш күрә. Әсәргә иҗтимагый үткенлек, мәсьәләне тиешенчә, таман гына итеп ялангачландырып куя белү хас. Шәхес язмышын тарихи шартлар белән бәйләп, бөтен катлаулылыгында ала белү хас. Айсылу, Суфия, Гадилә, Исламия, Җамаллар бер-берсеннән характерлары белән дә, ачы язмышларына реакцияләре һәм бер үк шартларда үз-үзләрен тотышлары белән дә кискен аерылып торалар. Ирексездән аларның палачларыннан берсе булып әверелгән, ләкин намусын саклап кала алган Кыяметдин образы кызыклы. Ул мондый типтагы НКВД хезмәткәрләренең билгеле бер штампка әйләнгән образлары арасында үзенчәлекле булып аерылып тора. Бүгенге шәһәрдә хакимлек иткән урам сугышлары сталинчылыкның безнең көннәргә дә, киләчәк буыннарга да тәэсире сакланырга мөмкин булуы турында сөйли.

Сәхнә әдәбиятында беренче адымнарын атлаган Фәнәвил Галиев «Элмәктәге язмыш» драмасында, Данил Салихов «Туй күлмәгем — соңгы бүләгем» пьесасында шулай ук кайбер заман билгеләрен чагылдыра алдылар. Ч. Айтматовның атаклы романындагы аерым мотив-фикерләрне М. Гыйләҗев оригиналь эшләнгән «Ахырзаман» исемле инсценировкада әйбәт гәүдәләндерде.

Әлбәттә, яшьләрнең пьесаларында аерым кимчелекләр дә юк түгел. Ләкин алар съезд кадәр съезд югарылыгында торып сөйләшерлек түгел. Яшь авторларның фикер ачыклыгы җәһәтеннән дә, драма техникасы ягыннан да җитлеккән беренче заявкалары күңелдә өметләр уята.

Ни өчен мин сүзне дебютантлар әсәрләрен күзәтүдән башладым? Яшьләр — безнең киләчәгебез, драматургиябезнең иртәгәсе, өмете һәм кайгысы булганы өчен генә дә түгел, әлбәттә. Боларда, тегеләйме-болаймы, бүгенге милли драматургиябезнең аерым тенденцияләре чагылышын таба. Болар — безнең кичәге һәм бүгенге көндә җанрыбыз ирешкәннәрнең һәм аерым кимчелекләрнең үзенчәлекле чагылышы.

Шулай да драматургиябезнең төп үсеш сызыгы Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеевләр иҗаты аша дилбегәне үз кулларына ала барган Р. Хәмид, Р. Батулла, Р. Мингалим, Ә. Гаффар, Ф. Садриевлар иҗаты аша үтә. Бүгенге югарылыктан торып, без аларның иҗатында үзгәртеп кору процессын хәзерләшүгә керткән яңалыкларны күрә алабыз. Хәзер без бөтен ачыклыгында сөйли һәм тәнкыйтьли торган аерым кимчелекләр бу драматурглар әсәрләрендә инде 70 елларда һәм 80 елларның башларында ук фаш ителгән, кире кагылган. Шундый фикер килеп чыга: татар драматургиясе үзенең алга таба хәрәкәтендә хакыйкатькә якынлашу процессын туктаусыз алып барган (ни дәрәҗәдә көчле һәм туры сызыклы булган — анысы икенче мәсьәлә). Теориядә Н. А. Добролюбов ачкан канун — әдәбият торган саен демократик нигезләргә, ягъни халык тормышына якыная, димәк, хакыйкатькә, дөреслеккә якыная бара, дигән фикер бу очракта драматургия мисалында да раслана.

Мәсәлән, бүген дә демократиягә бик аз бирелә торган өлкәләрнең берсе — мәктәп. Анда еллар буе кимчелекләр тупланып килде, алардан арыну авыр булачак. Ни өченме? Чөнки мәктәптәге тәртипләрнең нигезендә «зурлар сүзе — балага закон», дигән язылмаган кагыйдә ята. Ясле яшендәге һәм беркадәр бакча балалары өчен яраклы булган бу кагыйдәне мәктәп югары класста укучыларга да күчерде, алай гына да түгел, аны абсолютлаштырды. Нәтиҗәдә мәктәптә, хәтта югары класс укучылары арасында да мөстәкыйль фикерләү, үз баш эш алып бару куып чыгарылды. Без еш кына күңеле каткан, мие түнгән, уйлый белми торган, үзлегеннән бер эш тә эшли белми һәм теләми торган солдафоннар хәзерлибез.

Мәктәптә тамыр җәйгән бу тәртипләрне бүген без ачыктан-ачык сөйли башлаганчы ук драматургларыбыз үз әсәрләрендә яктырткаммар. Әле 1967 елда ук язылган «Җиргә тапшырылган серләр» драмасында А. Гыйләҗев аны бөтен кискенлеге белән куйган. 1972 елда язган «Үзебез сайлаган язмыш» драмасында Т. Миңнуллин ялган өлгереш артыннан куып укучы балалар язмышы турында кайгыртмау кебек хәлләрне фаш итте, мәктәпнең бетүгә баруы турында чаң сукты.

Шөкер, драматургиядә гомумкешелек мәнфәгатьләре алгы планга чыга. Мондый казанышларны күпчелек драматурглар иҗатында табарга була. А. Гыйләҗев, мәсәлән, бу юнәлештәге кичәге казанышларын соңгы ике съезд арасындагы пьесаларында да дәвам иттерергә, үстерергә омтылды. Кешенең рухи дөньясына игътибар, һәр затны үзе бер кабатланмас дөнья итеп карау аның соңгы елларда сәхнә күргән «Тын урамда таугa», «Баласын җуйган болач әзеннән» драмаларын характерлый. «Көттереп искән җил» комедиясендә торгынлык чорының конкрет билгеләре чагыла.

Бүгенге драматургия процессында А. Гыйләҗевнең соңарып сәхнә күргән «Өч аршын җир» трагедиясе сизелерлек роль уйный. Иң беренче, монда тулы бер дәверне

һәм билгеле бер катлам крестьян психологиясен төгәл чагылдырган образ иҗат ителгән. Чор фаҗигасе, көчләп колхозлаштыру процессы тудырган трагедия аерым шәхеснең кара язмышы рәвешендә алга килеп баса, шулай ук саф күңеллелек символы дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләнгән Шәмсегаян язмышында да ачык чагыла. Язмышы оешмаган, характеры сынган кешенең сәхнә образы буларак тамашачыга тәэсир көчен арттыру өчен автор әсәрен гомумиләштерелгән һәм персонажлаштырылган Җир һәм Күк, Урман һәм Сулар, Заман һәм Хәтер, Бәрхет керфекле ат кебек символик образларга мөрәҗәгать итә, классик Хорның бер формасын эшкә җигә. Аларга кешенең җирдә ни өчен яшәвен, ягъни төп билгеләмәсен ачыклау, аның уңай сыйфатларын хасил иткән якларны олылау, җир хуҗасы булырга тиешле затны, аның рухи ныклыгын, аның һәртөрле социаль гаделсезлекләргә чиксез түземлеген данлау кебек вазифалар йөкләнгән. Реалистик һәм романтик сурәтләү үзенчәлекләренең синтезына ирешеп, драматург илебез тарихындагы сталинчылык дәверенең характерлы картинасын тудыра алды. А. Гыйләҗевнең күпчелек пьесаларына хас булган драматик хәрәкәт сүлпәнлеген җиңеп узу ягыннан да бу әсәр аерылып тора. Сүз уңаеннан шунысын да искәртеп үтик: пьесада бик оригиналь эшләнгән, фәлсәфи тирәнлеге белән көчле тәэсир ясый торган Хор образы Татар дәүләт академия театрында да, Минзәлә театрында да үзенең сәхнә чишелешен табып бетерә алмаган.

Заман рухына сизгерлек Т. Миңнуллин драматургиясе өчен һәрчак хас булды. Ул аның соңгы биш елда иҗат иткән әсәрләрендә дә ачык чагыла. Сүз бара торган вакыт аралыгында ул 6 пьеса язды. Алар арасында «Авыл эте Акбай» кебек, Академия театры балалар өчен уңышлы сәхнәләштергән, кече күләмле, ләкин шактый җитди фикерле комедия дә, «Тал бөресе имәндә» исемле моңсу комедия дә, «Гармун уйный беләсеңме?» дип аталган детектив комедия дә, — ягъни, җиңелчә кулдан эшләнгән, Т. Миңнуллинга хас тапкырлыкка ия булган әсәрләр бар. Бу иҗатның үсеш юнәлешен исә Г. Тукайга багышланган «Без китәбез, сез каласыз» исемле тарихи-биографик драма һәм «Вөҗдан газабы» дигән драматик хикәя билгелиләр. «Ат карагы» исемле пьесаны кайберәүләр узган елларда, торгынлык чорында язылган, вакытында хаксызга тыелып килгән әсәр дип раслыйлар, ләкин аны Т. Миңнуллинның соңгы иҗат җимешләреннән берсе дип карарга кирәк.

Үзгәреш чоры тудырган проблемаларга да беренчеләрдән булып Т. Миңнуллин мөрәҗәгать итте. Революцион яңарыш, хәбәрдарлык һәм ачыктан-ачык сөйләү күпләрнең акылын чуалтып күңелләрен иләсләндереп ташлады, кемнәр өчендер ул хәтта фаҗигага әйләнде. Шундыйларның аерата җитәкче оешмадагылар арасында булуын драматург дөрес тотып алган. Партия оешмалары совет оешмаларының вазифаларын тәмам үзләренә алып бетергән, административ-командалык эш алымына күнеккән, шуны иң дөресе дип инанган, башка төрле эш стилен күз алдына да китермәгән бер чорда яңача эшләргә өйрәнергә, яңача яшәргә кирәк. «Вөҗдан газабы» драмасында менә шул хәл авыл райкомының беренче секретаре Тимергазинны тәмам бутап ташлый. Аңарда үз көченә, үз эш тәртибенә, хәтта яшәү принципларына тамырдан үзгәрергә тиешле караш тиз генә барлыкка килми, оеша алмый. Намуслы кеше буларак ул моңа тирән борчыла, пошына, җәфалана, эзләнә һәм бәргәләнә. Дөрес, бу бәргәләнү тиешле фикер тирәнлегендә бармый, Тимергазинның икеләнүле уйлары да, аларны төрле катлау вәкилләре, үз якыннары (хатыны, әтисе, абыйсы) белән уртаклашу да еш кына артык гади яссылыкта, сай һәм гадиләштерелгән дәрәҗәдә бара. Тимергазинның үз хәлен ачыклау өчен биргән сораулары риторик характерда, аларга җавап инде күренеп тора. Тимергазинның бюро членнары белән дә, якыннары белән дә бу темага сөйләшүе һәрчак кырт өзелә, сөйләшү-бәхәс логик нәтиҗә белән бетми, күбрәк автор теләге белән икенче яссылыкка яки бөтән урынга күчерелә. Пьесаның финалы да шул рухта тәмамлана. Мондый алым күп тапкырлар кабатлану сәбәпле тамашачыны ялыктыра. Шуларга да карамастан, драматург үзе теләгәнме-юкмы (әгәр дә теләгән булса: афәрин! ул бик тирәнгә яшерелгән), әсәрдән бер төп фикер килеп чыга: үзгәртеп кору һәркемнең үзеннән башланырга тиеш. Моңар ихтыяҗ иң зур булган кеше — партия хезмәткәре дип күрсәтеп, автор административ-командалык системасының урнашуына төп җаваплы оешмага тәнкыйди һөҗүм ясый. Чөнки чылбырның ныклыгы аның иң йомшак буыны белән билгеләнә. Үзгәртеп кору процессында һәртөрле демагоглар, авызына шайтан төкергән бушбашлар активлашуы мөмкин булуын чагылдырган Куразов образы — драматургның икенче табышы. Бу әсәрне кулуарларда конъюктура җимеше дип бәяләргә тырышулар булды. Мин моның белән килешмим. Аерым кимчелекләренә карап кына пьесаны сызып ташларга ярамый. Күз алдында иҗтимагый фикер художестволы аңга караганда тизрәк үсә. Драма шуның ачык чагылышы.

Ике съезд арасында Р. Хәмид, Р. Батулла, Ф. Садриев драматургияләре яңа бизәкләр белән баеды, хәтта, әйтер идем, фикер һәм сәнгатьлелек ягыннан өлгереп җитте. Бигрәк тә Р. Хәмид актив булды. Аның бу елларда 7 драмасы дөнья күрде.

Автор драматик ситуацияләрне әхлакый дөньядан, рухи хәзинәләргә, кешелекле мөнәсәбәтләргә илтүче катлаулы үзара мөнәсәбәтләрдән табып алырга омтыла. Аның геройларының күпчелеге — үз якташлары, авылдашлары, шуңар да алар тормышка якын килеп чыгалар. Тагын да бер үзенчәлек — бу драмаларга бөек Аристотель әйткән нәрсә дә хас: геройлар үзара якын туганлык мөнәсәбәтендә торалар, алардагы киче-решләр тирәнлеге һәм тәэсирлеге шуның белән дә аңлатыла. Р. Хәмид пьесаларының төп юнәлеше — җәмгыятебезгә югары әхлакый кыйммәтләр җитмәүне күрсәтү, фән-ни-техник революция дәверендә кешелеклелек сыйфатлары кысрыклануны күрсәтү. Безгә иң әүвәл рухи атмосфераны торгызырга кирәк, дип куя мәсьәләне драматург. Бу — безнең тормышыбызның барлык өлкәләре өчен мөһим, ахыр чиктә безнең бүгенге барлык проблемаларыбызны уңышлы хәл итү шуннан тора.

Табигате буенча шаян-тапкыр Р. Батулланың интермедияләре тупланган «Чебен гөмбәсе» исемле оригиналь китабы, бигрәк тә Минзәлә һәм Академия театрларында куелган «Ярым ятларга кала» исемле комедиясе ныгыган юморист каләме белән язылган. Гомумән Р. Батулла драматург буларак үсеп бара.

Ф. Садриев кызыклы, халыкчан рухлы драматург. «Ач тәрәзәң...», «Иртәгә нидер булачак», «Тозлы бал», «Кондырлы кодачасы», «Әхти, егетләр!», «Оҗмах ишеге төбендә» кебек пьесалар ныклы кул белән язылган. Бу иҗатта ошаган яклардан тагын да берсе — жанр ачыклыгы, җанлы тел, хәрәкәтчән характерлар. «Ач тәрәзәң...»дәге ачык билгеләнгән, төгәл чагылган драматизм, «Кондырлы кодачасы» трагикомедиясендәге тормышчан ситуация һәм мәгънәле сатира — Ф. Садриевның шиксез уңышлары һәм табышлары. Киләчәктә бу авторга үзәк сәхнәбез ТДАТ та игътибар итсен иде. Шуның белән бергә халыкчан характерларга, җанлы ситуацияләргә омтылуны фикер тирәнлеге һәм яңалыгы белән бәйләсә, авторның уңышлары тагын да саллырак булыр иде.

Бүгенге драматургия алып бара торган эзләнүләрдә Р. Мингалимовның сизелерлек өлеше бар. Съездга ул «Мин сине шундый сагындым», «Кире уйларга соң иде», «Кунак кызы гел килмәс», «Тау астында 50 бүре», кебек драма һәм комедияләре белән, «Шүрәлеләр үч алмый» исемле әкият-пьесалары белән килде.

Р. Мингалимов асылда — фикер драматургы, җитди хәлләргә, драматик характерларга тартым иҗатчы. Еш кына ул пьесаларын фикер бәхәсенә кора, ягъни драматик хәрәкәт вазифаларын фикер динамикасы үз өстенә ала. Шагыйрь-Мингалимовны борчыган кебек ук, драматург-Мингалимовны да җәмгыятебез үсешендә баш калкыткан, яисә инде ныгып җиткән аерым күренешләр, аларның җәмгыятькә, аның рухи дөньясына тискәре йогынтысы борчый.

С. Шәкүровның «Саф күңелгә тап төшми» исемле драмасы К. Тинчурин исемендәге театрда, Ф. Яруллинның «Эти килде» комедиясе һәм «Кызлар күңеле тирән сер» дигән лирик драмасы Әлмәт һәм Минзәлә театрларында куелып үтте. Беренче ике әсәр жанр ачыклыгы белән аерылып торалар. С. Шәкүров гомумән хәрәкәтчән сюжетлы, җанлы телле, фикере ачык пьесалар авторы буларак билгеле. Ул сәхнәне яхшы тоя, характерларны бер-берсеннән кискен аерып куя, мәгърифәтчелек традицияләреннән иркен файдалана.

Ф. Яруллин көндәлек тормыштагы аерым күренешләрне тотып ала белә. «Эти килде» — комедия төрендә авторның чираттагы уңышы, кешеләр арасында акчага, мещанлык туклыгына омтылуны үткен камчылый. «Кызлар күңеле тирән сер» драмасы бик вакытлы төстә анонимкаларның һәм анонимщикларның тормыштагы җирәнгеч ролен һәм агулы тәэсирен сөйләп биргән. Автор алдан күрә белгән: аноним хатларга һәм шикаятьләргә бездә хәзер юл бирелми.

Ике съезд арасында иҗат ителгән драма әсәрләрен һәм драматургиядә хәлнең торышын кыскача карап үткәннән соң, кайбер нәтиҗәләргә килергә мөмкин.

1. Сәхнәдә шактый тар интереслар өстенлек итә. Ә бит тормышта бүгенге кеше дәүләт күләм, дөньякүләм мәсьәләләргә чыкты. Конституция нинди булырга тиеш дип бәхәсләшә ул, милли республикаларның статусын яңадан карауны таләп итә, партия оешмалары хәзерге шартларда ничек эшләргә тиеш, дип эзләнә, совет органнарын сүлпәнлектә гаепли, милләтне һәм телне ничек саклап калырга дип кайгырта... Пьесаларда боларның бик азы гына чагыла.

2. Бүгенге сәхнә әдәбиятына иң җитмәгәне — уңай герой образы. Драматургия фаш итү, кимчелекләрне эзләп табу белән артык мавыга. Әдәбиятның һәм сәнгатьнең иң җаваплы вазифаларыннан берсе — тәрбия итү, әдәпкә өйрәтү, кешене яратырга һәм алдынгы идеалларга өндәү икәнен искә алсак, уңай герой образының, үрнәк эшләргә чакырган шәхеснең, кешелекнең үсеш тенденциясен чагылдырган әдәби типның җитешмәве аерата ачыну тудыра.

3. Драмада сюжет — төп урынның берсен тота. Хәлбуки, бүгенге пьесаларны сюжет элементлары ноктасыннан сүтеп анализлый башласаң, аларның бик сыек булуын

күрәсең. Еш кына кульминацион ноктаны, ягъни драматик хәрәкәтнең иң югары урынын билгеләп булмый, алар ике, хәтта өчәү булып чыгалар. Бу исә әсәрдә сюжет сызыкларының берничә булып, аларның үзара бер ноктада кисешмәвеннән, бер төенгә бәйләнеп бетмәвеннән килеп чыга. Әсәр таркау, димәк, сәнгатьлелек ягыннан чатак була. Драматик хәрәкәт ягыннан озын, битараф, таркау пьесалар күбәйде.

4. Хәзерге пьесаларны М. Фәйзи, К. Тинчурин әсәрләре белән чагыштырып карасаң, аларның бик күпкә оттыруын күрәсең. Бүгенге пьесада ачык акцентлы жанлы тел сирәк кунак. Телнең байлыгы һәм төгәллеге исә драма өчен төп шартлардан берсе. Туган телгә, милли гореф-гадәтләргә игътибар кимү кебек, кимчелекләр театрыбызга шактый үтеп керде.

5. Язучыларның X съездыннан соң узган вакыт эчендә бүгенге драматургларның пьесалары тупланган 16 җыентык дөнья күргән, аерым классикларның томнары басылган. Мондый китапларның бөтен Союз буенча эшләп килә торган йөзләрчә халык театрлары һәм меңәрләгән үзешчән түгәрәкләр өчен саф һавадай кирәклеген истә тотып, нәшриятка бары тик рәхмәт кенә әйтәсе кала.

6. 50 елларда драматурглар К. Тинчурин, Ф. Бурнаш кебекләрнең мирасы кире кайтарылгач, татар театры яңарыш кичергән иде. Хәзер мондый мөмкинлекне без Г. Исхаки иҗаты кире кайтуда күрәбез. Бу хәл әдәбиятыбызның бүгенгесенә җитмәгән проблема һәм темаларны үстерү өчен дә өйрәнү мәктәбе булыр. Мәсәлән, милләтебез язмышы проблемасы бу талантлы әдип иҗатында буйдан-буйга бара. Ә хәзерге драматургия бу мәсьәләдә авызына су капкан, ул кечерәк мәсьәләләр белән теләбрәк шөгыльләнә. Бүрек селтәп кенә бүредән котылып булмый. Милләтебез язмышын, туган тел язмышын, аяныч хәлгә китергән сәбәпләргә хәзергә драматургиябез бүрек кенә селти.

## Газиз Кашапов

# ТЕШЕБЕЗ ҮТӘМЕ?

Күп еллар дәвамында кул-аяклары гына түгел, теле дә бәйләүле очерк һәм публицистика жанры тормышыбызда мөһим урын тота башлады. Алай гынамы, бу жанр хәтта заманның политик һәм идеологик тормышына турыдан-туры йогынты ясый алыр дәрәҗәгә күтәрелде. Бүген инде язучының үз намусына хилафлык кылмыйча матбугат, радио һәм телевидение аша халыкка җиткерә торган тугры сүзенә команда-административ җитәкчелекне алга сөрүчеләр, чыкылдап торган бюрократлар да колак салмыйча уздырып җибәрә алмый. Татар әдәбиятының сугышчан разведкасы — публицистика иҗтимагый мөнәсәбәтләр мохитына бәреп керде.

Беренче чиратта, билгеле ки, татар язучыларының, һәм һәрнәрсәгә риза булып тыныч кына өйләрендә ята белмәүчеләрнең һәммәсенең телләреннән элек тә төшмәгән олы проблема — күпне күргән татар халкының киләчәк язмышына турыдан-туры кагылышлы — милли мәсьәлә.

Милли мәсьәлә һәм аны хәл итү юлларын эзләү бүгенге көннең кадагы, иң авырткан җире. Әмма безнең республикада милли мәсьәләне гадел, үзара тигезлек, Ленин эшләп калдырган принциплардан чыгып хәл итәргә атлыгып торучы юк.

Әдипләр Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, аннары татар иҗтимагый үзәге әһәлләре алга сөргән нәрсәләр: Татарстанга союздаш республика статусы бирү буенча безнең Верховный Советыбыз, хөкүмәтебез һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты нәрсә дә булса эшли торгандырмы-юктырмы, безгә бу мәгълүм түгел...

Мин үзем, мәсәлән, Татарстанга, яки башка берәр республикага Союздаш статусы бирел кенә тигез хокуклылык булдырып булмый, моның өчен илдәге бөтен республикаларны бердәй итеп, бертигез дәрәҗәдәгеләрнең Совет социалистик республикалары итеп үзгәртүне гаделрәк булыр иде дип уйлыйм.

Шуңа күрә, хәзер инде төп төгәл нәтиҗә ясап әйтергә мөмкин: республиканы тоташ төзелеш мәйданына әверелдерү тамырдан ялгыш, чөнки ул башка халыкларның миграциясенә китерде. Туктаусыз үсә барган миграция Балтик буе халыкларына гына янамый. Безнең Татарстанда да ул инде — чынбарлыкның үзе. Чамасыз миграция утызынчы-илленче еллардагы бишьеллык төзелешләре, шахталары һәм кумәкләшү

чоры белән Сталин репрессияләре вакытындагы депортация китергән нәтиҗәләрне бирә. Ул чагында татар халкын күпләп читкә олактырдылар. Ә хәзер исә татар халкы катламын башка халыклар арасында сыегайтуны дәвам иттерәләр.

Нәтиҗәдә болай да бөтен илгә таралып яшәүче татар халкының өметләре баглангән, Ленинның милли политикасына карап эш иткәндә күз карасыдай сакланырга тиешле Татарстанда яшәүче татарлар саны милли азчылыкка әверелеп бара.

Төзелешләр турында әйткәнбез икән инде, республикабыз һәм татар халкы тәненә көнләп түгел, сәгате-минуты белән үрчи барган бу яман шешне читләтеп уза алмыйбыз. Чөнки бу яман шеш бер яктан туктаусыз миграция белән бәйле булса, икенче яктан тагын да куркынычрак нәрсә — экологик һәлакәт белән тыгыз бәйләнештәге мәсьәлә. Карагыз әнә Түбән Кама ягындагы нефть химиясенең соргылт аждаһасына. Карагыз әнә Казандагы химия заводларын һәм аннары, йөрәк шарифләрегез нык булса, — Менделеевск тарафларына. Ул яклардагы һаваны бер гасырдан артык дәвердә туктаусыз агулаучы иске химия заводына. Әнә селикагель цехы. Тыйнак кына цех дип атала ул. Чынлыкта исә Карпов исемендәге заводның элеккеге куәтләрен әйләндереп кенә каплый ул. Аның янәшәсендә генә, әллә ни тавыш күтәрмичә генә минераль ашламалар заводы төзеп куйдылар. Бу заводның исеме генә шундый гөнаһсыз — минераль ашламалар заводы — чынлыкта исә Тула өлкәсендәге бөтен дөнья әдәбият тарихының күз төбәп торган изге урыны — Ясная Поляна һәм аның тирәсендәге урман-су җирләрне харап иткән «Азот» берләшмәсенең кече туганы ул.

Нибары ике йөз-ике йөз илле чакрым җирдә әлеге дә баягы иң-иң куәтле ике АЭС — Татарстан һәм Башкортстан атом электр станцияләре төзелүне, аның тарафдарлары ничек кенә якларга тырышмасын, берничек тә аклап һәм яклап булмый. Бу төзелешләрне кичекмәстән туктатырга, түгелгән малны бүтән куркынычсыз юнәлешкә борып җибәрергә кирәк. Күптән түгел Алабуга-Чаллы ягында булган 6 баллы җир тетрәү моңа дәлил.

Язучыларны еш кына «идеология фронты сугышчылары» дип атый башлаганнар иде. Әгәр дә бу чынлап та шулай икән, ул чагында бит сугышчының кулында коралы булырга һәм ул төзек хәлдә торырга тиеш. Безнең мәгълүм ки, үзебезнең үзенчәлекле коралыбыз бар. Ул да булса — Тел. Туган тел. Ана теле!

Кызганычка каршы, ике съезд арасында безнең иң кадерле коралыбыз — татар теле илебезнең иксез-чиксез киңлекләренә сузылган фронтның барлык участокларында да һөҗүмгә күчеп бер карыш җир буе да алга китә алмады. Ул, хәтта, бөтен фронт буена сузылган траншеяларны саклап калуга да ирешмәде. Өстен торган көчләр кысрыклавына каршы тора алмыйча фронт сызыгын кыскартырга, «алдан әзерләнгән» позицияләргә чигенергә дучар ителде.

Республиканың совет, партия органнары һәм ничарадан бичара булып, күзләрен югарыдагылардан алырга куркып утыручы мәгариф әшлексезләре бу нәүбәттән элеккечә үк сүз боткасы куертуны эш күрсәтүдән өстенрәк күрәләр. Күпме чыгышлар булып, күпме сүз сөйләнүгә карамастан, татар телен укытуны тыючы, аның яңарышына аяк чалып утыручылар хәзерге көндә дә үзләренең олы-олы кабинетларында саусәламәт утыра бирәләр.

Күптән түгел генә «Правда» газетасы оештырган «СССР — күмәк йортыбыз» дигән түгәрәк өстәл тирәсендә сөйләшүчеләрнең берсе, украин язучысы В. Яворивский әйткәнчә, «Безнең илдә, мөгаен, озакламый дефицит әйберләргә булган чиратлар кыскарыр, кибет киштәләрендә, мөгаен, азык-төлек тә артыр. Ләкин шушы бәхетле көннәрнең берсендә без, мөгаен, котларыбыз очкан хәлдә, мәсәлән, ханты-манси эпохасының юкка чыгуын белербез. Яисә тагын да олырак җинаять — теге яки бу халыкның теле онытылып беткәнне ачыкларбыз. Ләкин бу тел проблемасын «Тук корсак» белән хәл итәрбез әле дип ята алмыйбыз. Ул вакытта инде соң булачак»...

ТАССРның халык мәгарифе министры иптәш Низамовның һәрбер докладында китерелгән саннарга ышансаң, барысы да бик яхшы. Чынлыкта исә тынычланыр өчен бер генә дәлил дә юк әлегә. Китерелгән фактлар министрлык отчетларында гына ул. Татар телен бүгенге кызганыч хәлгә җиткерүчеләр гап-гади күз буяу белән шөгыльләнәләр. «Үзгәртеп кору, яңарыш җиле узып китәр һәм барысы да элеккеге хәленә кайтыр» дип өметләнә алар. Мин үзем, әгәр дә мәгәр иптәш Низамов урынында утырып, татар халкына шундый корткычлыклар эшләгән булсам, кичекмәстән отставка сорар һәм үзем мактаган берәр «татар мәктәбе» исемен йөрткән мәктәпкә барып, татар теле укытырга керешер идем.

Татар язучылары-публицистлары ике съезд арасында күтәреп чыккан тагын бер проблема — ул татар авылларының бетеп баруы. Бу проблеманы мин шулай ук милли мәсьәләдән аерып карамас идем. Чөнки әлегә без, татар язучылары, димәк, татар әдәбияты да, бары тик авыллар хисабына гына тереклек кылабыз. Безнең публицистлар авыл проблемасын күтәрмәделәр түгел, күтәрергә тырышып карадылар... Әмма... без бит һаман да ул мәсьәләне Казандагы Сөембикә манарасының иң биек ноктасыннан

Арча, Әгерҗе, Актаныш, Яңа Чишмә, Аксубай, Әлки, Чүпрәле ягына караган килеш хәл итмәкче булабыз. Безгә үзебезнең «дөрес» фикеребезне радиодан, телевидениедән сөйләү, газетага язып чыгу кыйммәт. Калганын инде аның әйтелгән районнарда калып, Казан телевидениесе тапшыруларын карый алмыйча, Ижевск, Уфа, Ульяновск, Оренбург, Куйбышев студияләрендә әзерләнгән тәрбия җимешләрен йотып яшәргә тиешле кешеләр башкарырга тиеш.

Бу нәүбәттән «Социалистик Татарстан» газетасы татар язучылары һәм публицистларына гаять гыйбрәтле сабак бирергә тырышып карады. 1987 елның 23 сентябрь санында Ленин премиясе лауреаты язучы Иван Васильевның авылдагы үзгәртеп коруның әхлакый проблемалары турында фикер йөрткән «Үзеңнән әзлә» дигән уйлануларын бастырып чыгарды. Газета, мөгаен, безгә «язучының публицистик уйланулары менә шундый була, анда проблемалар бөтен зурлыгы, мөһимлеге белән куела һәм аны үзе дә Псков өлкәсе Великие Луки районының Борки авылында яшәп ятучы, димәк, язган һәр сүзенең дөреслегенә ышанган кеше генә яза ала», димәкче булгандыр. Әмма без бу сабактан гыйбрәт алмадык, үз тугызыбызны тугызлап яза бирдек...

Соңгы ике съезд арасында татар әдәбиятының очерк жанры үзе күп еллар элек кереп урнашкан ныгытмаларыннан күтәрелеп чыга алмады. Татар очерклары бүгенге көннең яңарышын тоймыйча, торгынлык чорында үзләштергән тормышы белән яшәп ята. Әдәбият теориясенең бөтен шартларына тәңгәл килә торган, катлаулы проблемаларның бөтен каршылыкларын ерып-җимереп барырдай әсәрләр — очерклар иҗат ителмәде. Кыскасы, татар әдәбиятының очерк жанры бүген торгынлык тутыгыннан арына алмыйча, тирән кризис эчендә бимазаланып ята.

«Казан утлары»ның очерклар бүлеге үз вазифасын канәгатьләнерлек үти алмый. Газеталарыбыз да очерк жанрын үстерергә салкын карый.

Татар әдәбиятының публицистика өлешендә элек-электән дә җир куенында яткан хәзинәләре ялтырап-ялтырап киткән чаклары була иде. Соңгы ике-өч ел эчендә ул хәзинәләр җир куенынннан өскә чыгарылдылар. Әмма алар әлегә безнең кулыбызга килеп кермичә, әледән-әле ялтырап, безнең күзләребезне чагылдырып кына алгалыйлар да, тагын Кабан күле төбенә төшеп киткән хәзинәләр савыты кебек, кулдан-күздән югалырга әзер торалар. Без үз проблемаларыбызны үзәк матбугатта күтәреп чыгып, нәтиҗәсенә ирешә алмадык.

Безнең соңгы еллардагы публицистик чыгышларыбыз әлегә аерым-аерым проблемаларның аерым-аерым бүрәнәләрен тәшкил итә. Аңлашыла ки, безгә аларны бергә туплап, киртләп-чутлап, бура итеп күтәрәсе һәм аның кыегын чыгарып, җиткереп куясе бар.

## Роберт Миңнуллин

# БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ НИ ХӘЛДӘ?

Сталинизм елларында, торгынлык чорында иң кимсетелгән, игътибардан иң читтә калган социаль катлам, мөгаен, балалар булгандыр. Без коточкыч заманалар кичердек. Үзегез уйлап карагыз. Сугышта һәлак булганнарның саны безгә яхшы мәгълүм. Сугыш ятим иткән балаларның саны ничә миллиондыр — аларны санап карауучы кеше булды микән? Сталинизм корбаннары 20 миллионга җитә, диләр. Алардан калган ятим балаларның саны ничә миллион булды икән? Ә балалар өчен төзелгән махсус лагерьлар, махсус йортлар? Гомер буйларына «халык дошманы баласы» дигән кара тамга?

Торгынлык елларының иң популяр лозунгларыннан берсе «Иң яхшысы — балаларга» иде. Без аны күп тапкырлар кабатладык — хәтта шуңа ышанып яшәдек. Янәсе, нинди бәхетле безнең балаларыбыз! «Бәхетле, кояшлы балачак!» «Балалар — тормыш чәчәкләре!» «Балалар — иң өстен сыйныф!» Ә бүген шушы бәхетле балаларыбызның Республика пионерлар сарае юк. Республика балалар китапханәсенең дә үз бинасы юк. Ул Казан буйлап сибелгән. Китаплары подвалларда су эчендә йөзеп йөри. Ул гына да түгел: без балаларыбыз өчен бер-беребезне уздыра-уздыра төрле подваллар эзлибез, табабыз, шул подваллар белән горурланабыз, рапортлар бирәбез.

Ләкин шуны да әйтергә кирәк. Республикада балаларга мөнәсәбәт акрынлап булса да әйбәт якка үзгәрә бара. Мәсәлән, республика балалар клиник больницасының 300 урынлы яңа корпусы төзелү озак елларга сузылу куркынычы бар иде. Совет балалар фондының Татарстан бүлеге бу хакта партиянең өлкә комитетына мөрәҗәгать итте, хәлнең аяныч булуын аңлатып бирде. Дөресен әйтим, безне аңладылар, әлеге мөһим объектны беренче секретарь үзе контрольгә алды. Яңа клиник больница балаларны вакытында кабул итәр диган өметебез бар. Казандагы югары кунакларга исәпләнгән ике кунакханә шулай ук балаларга бүләк ителде. Аларның берсендә инвалид балалар өчен санаторий урнашты. Зинин урамындагы икенче кунакханәдә хәзер — балалар поликлиникасы. Бүгенге көндә иске аэропортны балаларга бирү турында кайнар бәхәсләр бара. Анысы да уңай хәл ителер дип уйлыйбыз.

Кайбер саннар китерсәм, урынлы булыр. Республикадагы ятим һәм инвалид балалар тәрбияләнә торган 86 учреждениенең 47се зәгыйфь акыллы балалар өчен. Аларда 8790 бала яши. 16 яшькә кадәрге 878 бала церебраль паралич белән авырый. Аларның барысы да — гомерлек гариплеккә дучар балалар. 1568 бала йөрәк авыруы белән, 4282 бала тын юллары авырулары белән, 3633 бала бавыр авырулары белән, 1350 бала бөер авыруы белән, 4528 бала тире авырулары белән авырый, ел саен 100—120 баладан рак авыруы табылып тора. Бу саннарны тагы да дәвам итәргә булыр иде. Болары әле исәптә торганнары гына. Ә авылларда бер тапкыр да больницада булмаган, врачка күренмәгән балалар күпме?

Шушылар өстенә әхлаксызлык, рухи саңгыраулык, рухи сукырлык белән авыручы балаларны да өстәсәк? Әле тагын бер авыру бар. Анысы татар балаларына гына кагыла. Медицина термины беләнрәк әйтсәк, аны тел склерозы дияргә булыр иде. Аның диагнозын сез яхшы беләсез булыр: бала туган телен оныта. Шуның нәтиҗәсе буларак, акрынлап туган халкының культурасын, тарихын, әдәбиятын хәтереннән җуя башлый. Әти-әнисенә, туган җиренә. Туган иленә булган мөнәсәбәте үзгәрә. Гуманизм, патриотизм, фидакарьлек һәм әхлак сыйфатлары югала. Бу авыру белән күпме татар баласы авырыйдыр, әйтә алмыйм. Әмма алар күп, бик күп.

Бүгенге балалар әдәбиятында җиң сызганып талантлы язучылар, шагыйрьләр эшли. Өлкән әдипләребез, яшьләребез... Шигъриятебезнең инде аксакалы, соңгы вакытта Казандагы мәктәпләрдән, балалар бакчаларыннан кайтып кермәгән Шәүкәт Галиев, балалар әдәбиятының ветераны, ярдәмчел, гадел Ләбибә Ихсанова, Җан җанлы Шамил Рәкыйпов, сагындырып кына, ялындырып кына язучы, әмма бер язса, берәгәйле язучы Г. Сабитов, әкиятче Батулла, балалар поэзиясе солдаты Х. Халиков, «Яшь ленинчы» белән «Ялкын»да берсеннән-берсе матуррак әкиятләр бастырган Фәнис Яруллин, вакыт-вакыт үзенең шигырьләре белән сөендерүче Р. Фәйзуллин, үсмерләр прозасында үзен тапкан К. Кәримов, нәни китаплар да язучы дәү Мәхмүт Хәсәнов, табигать җене кагылган, хыялый А. Хәсәнов, балалар матбугаты ветераны, пионерия язучысы Р. Хафизова, шигъри әкиятләр авторы, яшь редактор Җ. Дәрзаман, балалар поэзиясенә уйламаган-нитмәгән җирдән килеп чыккан Н. Измайлова, балалар әдәбиятына лирик проза алып килгән Р. Бәшәр... Алар арасында холыклары белән бер-берсенә бик тә охшаган Адлер Тимергалин белән Гарәфи Хәсәнов та бар. Чиста күңелле «чиста» ике балалар язучысы. Аларның икесе дә Сталин терроры аша узган, Сталин төрмәләрен, сөргеннәрен татыган каләмдәшләребез. Язмыш аларны меңкат сынаган. Алар әле дә безнең белән янәшә, алар әле дә сәламәтлекләре мөмкинлек биргәнчә балалар әдәбиятында намус белән эшлиләр. Мөгаен, үзләре булып калу өчендер, Г. Хәсәнов бөтен иҗатын кешеләрдән ераккарак дөньяга — табигать дөньясына багышлады. А. Тимергалин да реаль тормышка караганда фантастик дөньяны якынрак күрде. Ул бүген безнең төп фантастыбыз. Әйбәт күңелле, ыгы-зыгылардан, тартыш-талашлардан өстен торган шушындый язучыларыбыз булганда балалар әдәбиятының йөзе һәрчак якты булачак.

Гомумән, иң авыр торгынлык елларында да безнең әдәбият балаларыбызга намус белән хезмәт итте. Г. Мөхәммәтшинның табигатьне саклауга, яклауга багышланган, экология проблемаларын күтәргән «Саумысез, аккошлар!» повесте, Ф. Шәфигуллинның авыл баласының рухи дөньясын ачып күрсәткән, гаделлек белән гаделсезлек көрәшен ачып биргән «Ак яллы аргамаклар» повесте, Ш. Галиевнең ул чакта әле бөтенләй сәер тоелган «Әни, дим, әчмә инде!», әт атучылар турындагы «Куркыныч хәбәр», туган телен онытканмалай турындагы «Магнитофон онытмый» кебек шигырьләре, Ә. Гаффарның әхлак проблемаларын күтәргән «Су астындагы чишмә» повесте... Боларны күрмәмешкә салышу гаделлек булмас иде.

Моннан унөч ел элек А. Гыйләҗев «Күзгә-күз» повестен язып зур кыюлык эшләгән иде. Катлаулы, четерекле темага язучылар сирәк булса да табыла тора. Мин монда иң элек Л. Ихсанованың «Милиционер малае» повестен, К. Кәримовның «Ана нәфрәте», Н. Акмаловның «Үз урамым» повестьларын, Батуллла белән Р. Мин-

галимнең Казан телевидениесеннән күрсәтелгән «Сандугач сары була» телевизион спектаклен күз алдында тотам. Әлбәттә, бу темага язу җиңел түгел. Андый әсәрләрне хәтта укуы да авыр. Шуңа күрә бөтен кешегә дә ошап та бетмәскә мөмкин. Ләкин балалар арасында барган катлаулы процессларны читтән генә күзәтеп тору безнең әдәбиятыбызны бизәмәс. Үсмерләр дөньясында җинаятьчелек күренешләре күбәйгән бер вакытта язучыларыбызның газета-журнал битләрендә публицистик язмалары бөтенләй диярлек басылмавын да берни белән дә аңлатып булмый. Бу, мөгаен, бүгенге балаларны белмәвебез, аларның күңелләрен аңламавыбыз, аларның мәнфәгатьләреннән ерак торуыбыз нәтиҗәседер.

Без менә ничә еллар инде мәкалә саен, ел йомгаклары саен, съезд саен мәктәп тормышыннан, пионер тормышыннан әсәрләр язылмый дип зарланыштык, борчылып сөйләдек. Монда, билгеле, пионер сборлары, тантаналы линейкалар, тимер-томыр җыючы пионерлар, тимурчылар, отличниклар, пионер активистлары белән гөр килеп торган повестьлар, хикәяләр күз алдында тотыла иде. Мин дә бүген шул ук сүзләрне кабатлыйм, ләкин шатланып, хәтта горурланып кабатлыйм. Әйе шул, соңгы елларда, чыннан да, пионер оешмасы турында, сүз тыңлаучан, тырыш, акыллы, итагатьле, әйбәт малайлар-кызлар турында проза әсәрләре бөтенләй диярлек язылмады. Газета-журналларыбыз төрле конкурслар да уздырып карады үз вакытында. Нәтиҗәсе барыбер булмады. Безнең язучылар тыштан ялтырып торган мәктәп, пионер тормышына алданмадылар. Ә бит күпме ясалма сюжетлы, ялган пафослы, көн кадагына суга торган бер көнлек әсәрләр язылган булыр иде. Болай да әллә ни мактанырлык булмаган балалар прозасы тагын да чүпләнер иде.

Бүгенге бала күңеле кискен борылышлар чорын кичерә. Идеаллар җимерелә. Ничә еллар табынып яшәгән кумирлар, геройлар күз алдында юкка чыга. Әйтик, Павлик Морозов кем ул? Укучылар, пионерлар да, укытучылар үзләре дә аптырашта хәзер. Матбугат битләрендә кайнар бәхәсләр бара.

Укучылар бездән яңа сүз, заман сүзе көтә. Балалар күңелендә хәзер мең төрле сорау. Мең сорауга мең җавап та булырга тиеш. Тик шунысы, өлкәннәрнең үз күңелләрендә дә шул ук мең сорау. Җавапларны бергәләп эзләргә туры килә. Публицистикада да, прозада да, сәхнә әсәрләрендә дә, шигърияттә дә. Әлегә, миңа калса, җавапларны бүгенге балалар поэзиясеннән эзләргә кирәк.

Шигырьне кимсетү соңгы вакытта модага кереп китте. Бу балалар поэзиясендә дә шулай. Әйтик, балалар әдәбияты турында сүз чыкса: «Бездә балалар шигыре бар ла ул, менә әйбәт проза, драматургия, тәнкыйть юк»,— дияргә яратабыз. Ләкин бит басымны төрлечә куярга мөмкин. Әйтик, менә болай: әйе, бездә балалар прозасы да, балалар тәнкыйте дә, драматургиясе дә бар. Әмма алар арасында балалар поэзиясе үзенең камиллеге, художество югарылыгы белән аерылып тора. Бу — аңлашыла да. Чөнки бүгенге поэзия артында Тукай, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Б. Рәхмәт кебек зур исемнәр тора. Шигърият балалар әдәбиятының һәрчак мактанычы булды. Шуңа күрә аны бер селтәнүдә генә юкка чыгару кыен булыр.

Безнең татар балалар поэзиясе ил сәхнәсенә чыккан, башка халыклар арасында йөз кызартмаган поэзия. Ул гына да түгел, илкүләм балалар поэзиясендә безнең үз йөзебез, үз биеклегебез бар. Тукай, Җәлил, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалим кебек шагыйрьләребезнең Мәскәү нәшриятларында чыккан китаплары шул хакта сөйли. Чөнки безнең шигъриятебезнең нигезендә сәламәт материал ята. Авыл материалы. Ә авыл ул — югары әхлак дигән сүз.

Шунысы да куанычлы, соңгы вакытта шагыйрьләребез бүгенге көннең иң катлаулы мәсьәләләрен дә шигырь юлларына күчерергә курыкмыйлар, балалар өчен чын мәгънәсендә яңарыш шигырьләре язалар. Ш. Галиевнең, З. Мансуровның, Г. Моратовның, Г. Садәнең соңгы бәйләмнәрен шундыйлар рәтенә кертер идем.

Балалар шигыре бүген бик тә кирәк. Туган телебезгә йөз белән борылганда. Балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр өчен, рус мәктәпләрендә укучылар өчен. Әйбәт шигырьләр кирәк, төрле-төрле шигырьләр кирәк. Татар теленә өйрәнгәндә бүгенге балага фәкать шигырь генә ярдәм итә ала. Бу — минем генә фикер түгел, укытучыларныкы да, тәрбиячеләрнеке дә. Балалар шигыренең файдалы эш коэффициенты соңгы вакытта бермә-бер артты. Шуңа күрә күпсенмик без балалар шигырен. Тәнкыйть мәкаләсе язганда да, газета-журналларда бастырганда да, китап итеп чыгарганда да!

Балалар китабы — кичә-бүген генә килеп туган проблема түгел. Без бу хакта съезд саен, ел йомгаклары саен сөйлибез. Ачынып, борчылып сөйлибез. Ләкин хәл озак еллар үзгәрешсез кала бирде. Балалар язучыларының сүзләрен ишетмәмешкә салыштылар. Китаплар төссез чыга килде. Нәшриятның балалар редакциясе массовый төстә уртакул әсәрләр чыгару белән мавыкты. «Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларына» дигән гриф белән зурлар өчен язылган сыек әсәрләр дөнья күрә торды.

Без күп чакта югарыдан ниндидер күрсәтмәләр көтәргә күнеккәнбез. Ә менә кайчакта аерым шәхесләр дә хәл итә ала торган проблемалар да була икән. Р. Мөхәммәдиевнең нәшриятка килүенә әле елдан артык кына. Ул үзенең күпсанлы чыгышларында, мәкаләләрендә балалар китабын күпләп, матурлап чыгарачакларын каткат әйтә килә. Безнең аңа ышанмаска хакыбыз юк. Хәл, чыннан да, әйбәт якка үзгәрә. Китап кибетләрендә төсле, зәвыклы бизәлгән, зур форматлы татар китаплары күренә башлады. Һәм гомергә күрелмәгән әйбер — китапларның тиражлары 100—150шәр мең данә. Монда Ринат Мөхәммәдиевнең үзенең дә талантлы балалар язучысы булуы сәбәпчедер, бәлки. Баксаң, балалар китапларын да башкалар төсле чыгарып була икән. Теләк кенә булсын! Әлбәттә, авырдыр! Әлбәттә, кыенлыклар күптер! Р. Мөхәммәдиев үзе дә бу хакта язып чыккан иде: «Ә менә сабыйлар өчен китап дип кайгыртучылар ни өчендер алай ук күп түгел. Балалар бакчасы һәм кече яшьтән үк үз телендә заманча төсле рәсемнәр белән зәвыклы бизәлгән китапларга ихтыяҗ канәгатьләндерелми торып, ата-ана һәм сабыйларны телсезлектә гаепләү коры сафсата булып кала — киң җәмәгатьчелекнең бу мәсьәләгә битарафлыгын мин берничек тә аңлый һәм аңлата алмыйм. Кем-кем, хәтта Язучылар союзыбызның махсус балалар өчен әдәбият секциясе тарафыннан да нәшрият хезмәткәрләре әлегәчә конкрет ярдәм күрә һәм яклау таба алганнары юк». Каты әйтелгән. Дөрес сүзгә җавап юк. Ни өчен дисәң, моңа кадәр балалар китабы бары тик балалар язучыларына гына, балалар әдәбияты секциясенә генә кирәк иде. Ләкин, иптәшләр, ялгыш фикер калмасын. Секция дә, балалар язучылары да нәшриятка ярдәм итәргә әзер. Ләкин ничек итеп? Ул хакта бергәләп уйлашырга кирәк. Киңәшен дә бирербез, язучылар, китаплар исемлеген дә тәкъдим итәрбез. Хәер, без болай да моңа кадәр Союзга караганда, нәшриятка күбрәк хезмәт күрсәтеп килдек. Секциянең төп эше нәшрият тәкъдим иткән кульязмалаларны тикшерүгә кайтып кала.

Болары, миңа калса, эшләп була торган, экономикага бәйләнмәгән әйберләр. Ә менә полиграфиянең артталыгын без генә хәл итә алмабыздыр. Бирелә нәшрият хезмәткәрләренә партия һәм совет органнарының да җитди ярдәме кирәк булачак. Ә полиграфкомбинатның бүгенге хәле нәшриятның таләпләренә дә, теләкләренә дә туры килми. Шулай булмаганда, М. Җәлилнең балалар китабы 1986 елдан бирле, Б. Рәхмәтнең шундый ук китабы 1987 елдан бирле полиграфкомбинат цехларында адашып йөрмәс иде. Ә инде М. Җәлилнең балалар шигырьләре тупланып, матур итеп бизәлгән бер генә татарча китабы да булмавы бик гаҗәп хәл. Югыйсә, «Малыш» нәшрияты аның шигырьләрен менә дигән басмада ике тапкыр бастырып чыгарды.

Балалар китабы турында без рәссамнар белән бер тапкыр да зурлап сөйләшкәнебез юк шикелле. Татарстан рәссамнары татар балалары алдында үзләрен бурычлы итеп сизәләр микән, белмим, әмма балалар китапларының төссезлегендә аларның да гаепләре зур. Шуңа күрә дә безнең ничә еллар инде балалар китапларына уздырылган абруйлы конкурсларда җиңеп чыгу түгел, аларда катнашканыбыз да юк. Шулай да бер өмет бар: нәшриятка талантлы рәссамыбыз Тавил Хаҗиәхмәтов килде. Җәл, Татарстан рәссамнары үзләренең съездларына безне — язучыларны чакырып тормадылар. Югыйсә, әйтәсе сүзләр, теләкләр, киңәшләр бар иде. Гомумән, безгә — иҗат Союзларына — балаларга багышлап берләштерелгән Пленум уздырырга вакыт җитте. Аерым гына без берни дә кыра алмабыз. Әнә шул аеры-чоеры яшәгәнгә-эшләгәнгә күрә дә безнең бүгенге көндә балаларыбыз өчен театрыбыз юк, нәниләр өчен журналыбыз юк, мультфильмнарыбыз юк һәм тагын бик күп әйберләребез юк. Хәер, «Союзмультфильм» күптән түгел «Шүрәле» дигән мультфильм төшерде төшерүен. Аны беренче татар мультфильмы дияргә дә мөмкиндер. Беренчедән, материалы татарныкы. Икенчедән, ул сүзсез мультфильм, бер генә тапкыр «Шүрәле» дигән сүз яңгырап китә. Әллә русча, әллә татарча әйтелә — аңлашылмый да кала. Нәниләр журналы да булачак диләр. Ә инде татар ТЮЗы турында безгә җитдирәк уйланырга кирәк. Чөнки ул укуга түгел, тыңлауга корылган. Татарча сөйләшә белүче татарларга гына түгел, татарча тыңлый белүче татарларга да кирәк ул. Эзләсәң акчасын да табарга буладыр. КамАЗ әнә балалар фильмы үзәге өчен 10 млн. сум акча тапты бит. Чыгарды да салды. Димәк, мөмкин. Сорый белергә генә, елый белергә генә кирәк.

Күптән түгел Академия театрында Т. Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» дигән балалар спектаклен карарга туры килде. Дөресен әйтим, балалар өчен андый әйбәт татарча спектакльне минем күптән күргәнем юк иде. Күтәрелгән заманча проблемалар, мәгънәле, үткен диалоглар. Бигрәк тә артистларның уены ошады. Аларның әлегә кадәр ачылмаган яңа мөмкинлекләрен күрдем мин ул спектакльдә. Татар ТЮЗының артистлары менә ничек уйнарга тиеш, татар ТЮЗында менә нинди спектакльләр уйналырга тиеш! Автор үзе дә нәкъ шул хакта уйлап утыргандыр, мөгаен. Аның да татар ТЮЗын күрәсе киләдер, татар ТЮЗы өчен язасы киләдер. Алай

үзенең дә теләге булгач — әйдәгез, без аңа. СССР халык депутаты буларак, наказ бирик. Язучылар исеменнән дә, Кукмара, Балтач, Саба сайлаучылары исеменнән дә. Татар ТЮЗын оештырып бирсен ул безнең балаларыбызга. Эшләсә ул гына эшли алачак бу зур эшне.

Без бүген яшь алмаш әзерләү турында да җитди сөйләшергә тиешбез. Безнең нинди резервыбыз бар? Тылыбыз ничек? Ныклымы — түгелме? Ә бит, Т. Миңнуллин әйткәнчә, түгәрәк кысыла бара, чикләр тарайганнан-тарая. Башкортстан белән Чувашиядән килгән Ләис Зөлкарнәев белән Ркаил Зәйдуллин соңгы могиканнар булмасмы? Ә килгәннәрен кул кушырып көтеп кенә утырсак, Татарстанның үзеннән дә килми башлаячаклар. Торгынлыкның иң чәчәк аткан чагында да Язучылар союзы яшьләр белән эшләүне үзенең иң төп эше итеп исәпли иде бит. И. Юзеев белән Ш. Галиев оештырган конференцияләр, семинарлар Союз тарихында матур бер сәхифә булып калачак. Шушы залда утыручы иптәшләрнең күбесе шул чорда әдәбиятка килгән. Алар С. Хәким, А. Гыйләҗев, Ә. Баян, Г. Ахунов, Р. Гатауллин кебек яшь алмаш тәрбияләү өчен энергияләрен дә, вакытларын да кызганмаган иптәшләрнең шифалы ярдәмнәрен тоеп үскән әдипләр. Тик ни гаҗәп, шушы изге эшне юкка чыгарырга тырышучылар табылды. Шунысы кызык, ул шикләнүчеләрнең күбесе яшьләр өчен кыл да кыймылдатмаган, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәгән кешеләр. Әллә шуларның сүзенә бирелеп, Язучылар союзы яшьләр белән эшләүне официаль рәвештә туктатты. Т. Миңнуллин үзе дә бу хакта йомшартып кына әйтеп китте. Хәтта ул гына да түгел, ВЛКСМ өлкә комитетының «Яшь ленинчы» каршындагы А. Алиш берләшмәсе җитәкчесе штатын да Союз үзенә тартып алды. Эшләүче генә булмады. Үзгәртеп кору чорында, татар халкының язмышы хәл ителгән бер вакытта, әдәбиятыбызның киләчәге турында аеруча борчылыр бер чакта яшь алмаш тәрбияләүгә төкереп карау, «талантларны мәктәпләрдән эзлисе юк, талант үз-үзенә юл яра ул» дигән принцип белән яшәү бүген кичереп булмаслык хәл. Безнең төп ориентирыбыз — мәктәпләр, дөресрәге, балалар бакчалары һәм мәктәпләр. Мәктәпләрдә булмаган, балалар белән сөйләшеп карамаган, андагы үзгәрешләрне читтән генә күзәтеп, матбугаттан гына укып барган язучыларны мин аңламыйм. Үзенә шәкерт әзерләмәгән язучыны да аңларга теләмим.

Әлбәттә, Союз аппараты эшләмәде дип кенә, яшьләр белән эшләү бөтенләй тукталмады. Мин монда яшь балалар язучыларының республика семинарын искә төшерер идем. Балалар әдәбияты секциясе уздырган әлеге семинар балалар әдәбиятында истә калырлык вакыйга булды. Күп кенә яшь язучылар Союз членлыгына тәкъдим ителде, яңа исемнәр ачылды. Ике съезд арасында чын язучылар булып өлгереп җиткән яшьләр шактый бездә. Менә аларның берничәсе:

Р. Корбанов — ике китап авторы. Өченчесе — нәшриятта. Беренче китабы ук укучыларның игътибарын җәлеп итте. «Иң күп укыла торган балалар китабы» дип табылды. Яшь балалар язучыларының Бөтенсоюз семинарында аның шигырьләре югары бәя алды.

Ләбиб Лерон — балалар әдәбиятында яратып, җиң сызганып эшли. Язганнары — шигырь, юмореска, фельетон, әкият, пародия. Язганнары — заманча, образлы. Күп яза, күп басыла, шуңа күрә күпне дә күтәргә була. Яшь балалар язучыларының Бөтенсоюз семинарында югары бәя алды.

Р. Низамова — нәниләр өчен язучы прозаик. Ике китап авторы. Өченчесе — әзер. Балалар психологиясен яхшы белә. Теле — матур, үзе — РСФСРның атказанган укытучысы. Әдәбият түгәрәге җитәкчесе. Аның соңгы китабы да китапханәләрдә иң укыла торган китапларның берсе икән.

Гайсә Гатауллин, Рәниф Шәрипов, Вакыйф Нуриев, Рафис Гыйззәтуллин, Зиннур Хөснияр, Рафаэль Газизов, Заһид Мәхмүтов һәм әле яңа гына авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган Илгизәр Гыйбадуллин... Балалар әдәбиятының киләчәге — алар кулында. Шушы яшьләр арасында тагын бер талантлы шагыйребез бар иде. Чын балалар шагыйре Афзал Нигъмәтуллин. Ике китабын чыгарып өлгерде. Өченчесен күрә алмады. Аның әле үзеннән соң да искиткеч шигырьләре, хикәяләре, повестьлары калды. Кызганыч, Союзга алып өлгерә алмадык. Игътибар җитмәде. Ә ул бик тә лаек иде.

Балалар әдәбияты бездә бары бик энтузиазмга гына корылган шул. Элек тә шулай булган, хәзер дә. Балалар өчен язу татар әдәбиятында ни өчендер мәртәбәгә исәпләнми. Хәтта Тукайның балалар өчен язуына да сәерсенеп караганнар бит замандашлары. Бу — тәнкыйтьнең мөнәсәбәтендә дә, китаплар чыгарганда да, Язучылар союзы җитәкчелегенең мөнәсәбәтендә дә ачык чагыла.

Аңлыйм, һәр язучының үз борчулары, үз мәшәкатьләре. Һәрберебезне иң элек үз жанрыбыз, үз китапларабыз, үз гонорарыбыз, үз томнарыбыз, әдәбияттагы үз урыныбыз, абруебыз кызыксындыра. Аннары инде, әгәр вакыт калса, энергия, теләк

калса, укучы, халык турында да кайгыртуыбыз мөмкин. Тик менә андыйларыбыз күп түгел шул. Шуңа да карамастан, съездда да, съездан соң да үз мәнфәгатьләребездән, көндәлек мәшәкатьләрдән өстенрәк булырбыз дип ышанам. Әдәбият, аның киләчәге, аның язмышы мәктәптән, балалардан, яшь буыннан башлана. Әгәр дә балалар язучылары гына түгел, гомумән, язучылар коллективы шушыны аңласа, киләчәгебезгә якты өметләр белән карарга мөмкин. Әгәр дә халкыбызның, димәк, әдәбиятыбызның да, гомерен озайтыйк дисәк, шушы хакыйкатьне онытмасак иде.

## Нурихан Фәттах

# ГАДЕЛЛЕК — НИГЕЗ БУЛСЫН!

Узган биш елның дүрт елы яңарыш чорына туры килсә дә, без уянып, күзне ачып, уйлана-борчыла башлаганчы шактый вакыт үтеп китте. Тәнкыйть өлкәсендәге җанлану 87 елда гына сизелә башлады. Чын уяну исә узган елда гына барлыкка килде. Дөрес, торгынлык елларында да тәнкыйть эше тукталып тормады. Тик аның эчтәлеге һәм юнәлеше генә башкачарак булды. Узган бишьеллыкта Нил Юзиев җитәкчелегендәге әдәбият галимнәре алты томлык «Татар әдәбияты тарихы» язуны дәвам иттерделәр. «Тарих»ның 2, 3, 4 нче китаплары узган бишьеллыкта дөнья күрде. Безнең галимнәр шулай ук татар әдәбиятының борынгы, урта гасыр һәм бүгенге чорларына караган күп кенә башка хезмәтләр бастырдылар. 1983 елда без халкыбызның горурлыгы булган Кол Гали юбилеен билгеләп үттек. Кол Гали һәм аның үлемсез «Кыйссаи Йосыф» дастанына багышланган яңадан-яңа хезмәтләр әле дә булса басыла тора.

Ике съезд арасындагы еллар олы юбилейларга аеруча бай булды. Без Ш. Мәрҗанигә 170, Гали Чокрыйга 160, Р. Фәхретдиневкә 130, Ш. Мөхәммәдевкә 120, Г. Тукайга, Ф. Әмирханга, Г. Ибраһимовка, К. Тинчуринга, М. Галәүгә, Җ. Вәлидигә, Ш. Әхмәдиевкә, шулай ук татар романына 100 ел тулу көннәрен билгеләп үттек. Боларның барысы да фәнни хезмәтләрдә, тәнкыйть мәкаләләрендә киң чагылыш тапты.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты каршында Флүн Мусин җитәкчелегендә Мирас комиссиясе төзелү академик тәнкыйтькә яңа рух өстәде, әдәбият галимнәренең эшчәнлегенә яңа юнәлеш ачты. Сталин терроры елларында нахакка рәнҗетелгән, «совет дошманы» дип тамгаланган һәм юкка чыгарылган әдәбиятчыларның исемнәрен аклау һәм аларның әсәрләрен яңадан халыкка кайтару өчен көрәш башланды. Бу уңайдан Гаяз Исхакый өчен барган тартышта аеруча тырышлык һәм принципиальлек күрсәткән өлкән буын вәкиле тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллин исемен хөрмәт белән телгә аласы килә.

Татар тәнкыйте, минемчә, беркайчан тулы мәгънәсендә ирекле һәм бәйсез була алмады. Ул, бер яктан, хаким идеологиягә һәм эш башындагы түрәләргә, икенче яктан әдәбиятны үз кулында тоткан аерым шәхесләргә һәм аерым төркемнәргә ялчы хезмәтен башкарды. Тәнкыйтьчеләр бары үз хуҗаларының гына исемнәрен мактау белән телгә алып, башкаларның исемнәрен дә, әсәрләрен дә телгә алмыйча, тәнкыйть мәкаләләре язарга өйрәнеп киттеләр. Шул рәвешчә, татар әдәбиятында исемнәрен, әсәрләрен курыкмыйча әйтеп була торган даһилар һәм читкә тибәрелгән, тәнкыйть тарафыннан танылмаган исемсезләр, хокуксызлар барлыкка килде. Моңа мин мисаллар китереп тормыйм. Ярым-йорты тәнкыйть мәкаләләренең авторлары да, хокуксыз язучылар кебек, үзләре дә билгесез булып калсалар яхшырак булыр дип уйлыйм.

Моннан берничә еллар элек «Казан утлары»нда хәзерге заман прозасы турында тәнкыйть сыман әйткәләшеп алу булган иде. Татарстан язучыларының әлеге XI съезды алдыннан шул ук «Казан утлары»нда «Заман һәм шигырь» дигән икенче әйткәләшү башланып китте. Әлеге бәхәс рәсми рәвештә журналның 1988 елгы беренче санынан башланса да, чынлыкта ул 1987 елда ук Мансур Вәлиевнең «Шигъри бушлык» дип аталган мәкаләсеннән соң кузгалды.

Бәхәскә катнашучы авторлар бүгенге татар шигыренең генә түгел, гомумән татар

әдәбиятының торышына, проблемаларына кагылышлы күп кенә мәсьәләләр кузгаталар, татар әдәбиятында торгынлык елларында барлыкка килгән кимчелекләрне ачып салалар һәм киләчәктә әдәбиятны үстерү өчен үзләренең тәкъдимнәрен дә әйтәләр. Арада яңача фикер йөртүче кыю һәм принципиаль авторлар булган кебек, искечә фикерләүләр, курку, алан-йолан карану һәм көчлеләр алдында ялагайлану омтылышларыннан котыла алмаган авторлар да очрый.

«Заман һәм шигырь» бәхәсендә татар әдәбиятчыларын һәм укучыларын борчыган барлык сорауларга җавап табылды, барлык мәсьәләләр хәл ителде дип әйтеп булмый. Бу бәхәсне киләчәктә булачак зур сөйләшүләрнең, чыннан да яңача һәм ачыктан-ачык сөйләшүләрнең башлангычы гына дип бәяләргә кирәк.

«Шигъри бушлык» мәкаләсендә М. Вәлиев тәнкыйть утын нигездә куркынычсызрак яшьләргә һәм кайбер шагыйрьләргә каршы юнәлтсә дә, бүгенге татар шигърияте турында шулай ук кыю гына фикерләр әйтә. Мансур Вәлиев бүгенге көндә безнең иң актив һәм тынгысыз тәнкыйтьчебез. Ул әлегә күп сөйли. Аңа кайчагында фикер тирәнлеге һәм ышандыру көче җитми. Аның «шигъри бушлык» сүзе күпмедер дәрәҗәдә арттырып, күпертеп әйтелгән шигъри сүз булды. М. Вәлиевнең әрнеп, ачынып әйтелгән менә шул утлы сүзе күпләрнең йокысын ачты һәм уйланырга, кулга каләм алырга мәҗбүр итте.

М. Шабаевның «Казан утлары»ндагы «Төшсез чикләвекләр», С. Хафизовның «Социалистик Татарстан»дагы «Үзгәрергә кирәк безгә, үзгәрергә» дип аталган мәкаләләре тәнкыйтьтәге кыюлык юнәлешендә тагын бер адым булды. Алар тәнкыйть тыелган кайбер исемнәргә карата берникди куркусыз үзләренең кире фикерләрен белдерәләр. Әдәбият тормышында гадәткә кергән кайбер ямьсез күренешләрне ачып салалар. «Мактаулар, тәнкыйтьләүләр...» дип аталган мәкаләсендә Г. Рәхимнең беркайчан тел-теш тидерелмәгән «обойма»дагы Р. Харис шигырьләрендәге «прозаизм» турында язып чыгуы да шигырь турындагы бәхәстә яңалык һәм кыюлык булды. Фәиз Зөлкарнәев исә «Сабыр төбе алтынмы?» мәкаләсендә кыюлык юнәлешендә тагын да зуррак адым ясады. Мәкалә авторы әлеге дә баягы «обойма»да, ягъни гел беренче урында аталып йөртелүчеләргә карата, һәркемне үз исеме белән атап, бер дә каушамыйча, үзенең фикерләрен әйтеп бирде.

Әхсән Баяновның «Юкәдәге чикләвекләр» мәкаләсе үзенең кискенлеге белән барлык мәкаләләрдән аерылып тора. Ә. Баянов язучылар арасында хөкем сөргән һәртөрле ямьсез күренешләрне, кода-кодагыйлыкны, карьеризмны, икейөзлелекне тәнкыйть утына ала. Бу уңайдан аның тәнкыйте М. Шабаев фикерләренә аваздаш булып яңгырый. Сибгат Хәким мәсьәләсенә килгәндә исә С. Хәким, Туфан кебек үк, татар халкының милли символы дәрәҗәсенә күтәрелде. Ләкин Ә. Баянов уйлаганча күндәмлеге, җайлылыгы белән генә түгел. С. Хәким кешесенә карата күндәм дә, җайлы да, кешесенә карата усал да була белде. Ни генә булмасын иң авыр, иң караңгы елларда С. Хәким халык шагыйре, халык символы булып калды. Бүген, шагыйрьнең вафатыннан соң берничә ел үтеп тә, кайберәүләр һаман аның данына көнләшә икән, бу инде тәнкыйтьләүченең түгел, шагыйрь С. Хәкимнең көче турында сөйли.

«Төшсез чикләвекләр» мәкаләсендә М. Шабаев уртакуллар, графоманнар, һәвәскәрләр турында каты-каты гына сүзләр әйтә. Аның бу сүзләре кайберәүләрнең авырткан җирләренә барып тигән. Р. Шәфиев «Казан утлары»нда, Рахмай Хисмәтуллин «Социалистик Татарстан»да бастырылган мәкаләләрендә М. Шабаев белән килешмәүләрен белдерәләр, мәкалә авторын яшьләргә карата хөрмәт күрсәтмәүдә гаепләргә тырышалар. «Татарстан яшьләре»ндә Марсель Галиев хәтта уртакуллар әдәбият өчен файдалы, дигән карашны алга сөрә. Ә. Баянов та әдәбиятта графоманнарның, һәвәскәрләрнең булуы табигый күренеш дип исәпли.

Уртакуллар, графоманнар, һәвәскәрләр һәм башкалар дигәндә тәнкыйтьчеләр башлыча олы әдәбиятка якын килергә куркыбрак йөргән читтәгеләрне, кыюсызларны, ләкин җае чыкса, китап чыгарудан һич тә баш тартмаган әдәбиятчыларны күз алдында тоталар. Барысы да дөрес: уртакуллар, һәвәскәрләр булган, бар һәм булачак. Хикмәт аларның булуында, булмавында түгел. Хикмәт безнең уртакуллыкка, һәвәскәрлеккә һәм кәсепчелеккә мөнәсәбәтебездә. Минем аңлавымча, бүгенге татар прозасының 80-90 проценты уртакул әсәрләрдән тора. Татар әдәбияты өчен, әйтик, Роберт Рәкыйповның, Риза Шәфиевнең яисә мәрхүм Рамазан Байтимеровның әрсезләнеп бер-сәрән китап бастыруы түгел, күпчелек язучының уртакулга, графоманга, һәвәскәргә һәм кәсепчегә әйләнүе куркыныч.

**Михаил Скороходов**

# РУС ЯЗУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫ

Татарстан республикасында рус телендә иҗат итүче утыз автор яши. Ике съезд арасында алар кырыктан артык китап чыгарды.

Сүзне проза әсәрләреннән башлап җибәрик. Геннадий Паушкинның «Онытырга ярамый» һәм «Тынлык минуты» исемле китаплары белән хәзер инде безнең арабыздан киткән Дмитрий Сычевның «Болар безнең җиребездә булды» дигән баш астында басылып чыккан сугыш хикәяләре, һичшиксез, югары бәя алырга лаеклылар. Бигрәк тә Паушкин повестьлары һәм хикәяләре үзләрендә кырыс сугыш хакыйкатен тулы чагылдыру белән аерылып торалар. Аларга чик буендагы беренче бәрелешләрдән алып, данлы җиңү көненнән соңгы сугышка кадәр бик күп эпизодлар сыйган.

Безнең нәшриятыбыз Тихон Журавлевның «Комбат» һәм «Рядовой Антипов» дип исемләнгән ике повестен да бик зур тираж белән бастырып дөрес эшләде. Чорыбыз классигы Михаил Шолохов тарафыннан югары бәя алган бу әдипнең иҗаты киләчәктә дә шундый «яшел юл» тапсын иде, укучыларга әзне суытмасын иде.

Иван Киндерның «Имтихан» дигән китабына кергән повесть белән хикәяләрнең дә тематикасы сугыш чорыннан алынган. Тик бирәдә сугыш чоры яшүсмерләрнең тылдагы хезмәт батырлыгы хакында сүз бара. Аларның бөтен көче, бар тырышлыгы җиңүгә багышланган. Әсәрләрдә тасвирланган мәхәббәт сызыгы да уңышлы килеп чыккан. Авторның хатын-кызга карашы да сокланырлык, матур, кешелекле. Бу елларда И. Киндерның «Тәгәрмәч» дигән балалар китабы да чыкты. Аңа кергән бөтен хикәяләрне дә уңышлы дип әйтеп булмый, ләкин байтагы мавыктыргыч итеп, юмор хисе кушып иҗат ителгән.

Ике съезд арасында Рөстәм Кутуй да нәтиҗәле эшләде. Аның өч проза китабы, ике шигъри җыентыгы басылып чыкты. Дәһшәтле елларга туры килгән балачак... Әтисенең үлем хәбәре... Бала күңелендәге тирән тетрәнү... Болар барысы да проза китапларында оста каләм белән тасвир ителгәннәр.

Ә Рөстәм Кутуйның шигырьләре, минемчә, юри катлауландырылганнар. Мин аларның күбесен аңламадым да. Ул үзенең төп талантын прозага сала да, калган вак-төяген шигырьгә тутыра дигән фикер туа. Әнә шуңа күрә аның проза әсәрләрендә җан һәм бәгырь сызлавы сизелеп тора, ә шигырьләрен йөрәк аша узган дип раславы кыен. Билгеле, ул шигырьне оста ясый, аны теләсә нишләтә ала. Әлбәттә, андый әсәрләр басылмасын дип тә әйтәсе килми. Бәлки, мондыйларга кызыгучы да табылыр, кем белә...

Диас Вәлиев тә ике китап бастырды: «Кискеч һәм таш» белән «Мәңгелек әйләнеш». Бу язучының, безнең һәрберебездә булган сыман уңышлы һәм уңышсыз әсәрләре бар. Ләкин алар һәрчак яңа һәм кабатланмаган. Аларда бүтән беркемдә дә булмаган үзгә каләм сизелеп тора.

Диас Вәлиевнең соңгы еллардагы иң зур уңышы — атаклы Әсгать Галимҗанов белән танышлыгы. Безнең Казаныбызда яшәүче гап-гади бер йөкченең үз хезмәте белән табылган дистә меңнәрчә акчаны ятимнәргә һәм бәлагә таручыларга бирүе хәзер инде бөтен илебезгә мәгълүм булды. Ә бит бу, нигездә, Д. Вәлиев аркасында. Язучы кешенең тормыштагы мондый каһарманга тап булуы бик сирәк очрак! «Узган унъеллыкларда без кеше турында тау-тау сүзләр сөйләдек,— дип яза автор.— Ләкин шунысы кызык: тормышның үзеннән Әсгать Галимҗанов дигән конкрет бер кеше килгәч, без аны танымадык, аны көн герое дип санамадык. Хәтта әле шикләндек тә: янәсе алдашадыр, хәйләлидер ул...»

Әйе, ничек кенә гаҗәп булмасын — безнең алда киләчәктән килгән кеше. Шуңа күрә күпләр аны танымау, аңламау гына түгел, ә аңа каршы ук төшә башладылар. Аңа каршы көрәш ачтылар. Эшләр кузгаттылар. Ләкин язучы Әсгать Галимҗановны шундук аңлый һәм аның турында язып та чыга. Д. Вәлиевнең бу каһарманга багышланган язмалары бик күп үзәк басмаларда дөнья күрде. Язучы халыкның, укучының күзен ачты.

Китапның «Эссе» бүлегенә туплап бирелгән уйланулар — иң кызыклысы. Анда чорыбыз, әдәбият һәм сәнгать, яшәү һәм үлем турында бик тә тирән фикерле язмалар бар. Болар Д. Вәлиев иҗатын тагын да тирәнәйтәләр.

Күптән түгел Татарстан китап нәшриятында Владимир Корчагинның да яңа китабы чыкты. Фәнни фантастик жанрдагы бу роман «Кешелек исеменнән» дип исемләнгән. Әсәрдә атом төш сугышын булдырмый калу өчен көрәш тә бар. Чит планетадан килгән гүзәл кыз белән җир кешесенең саф һәм югары мәхәббәте дә тасвирлана. Автор үз әсәрен тере, мавыктыргыч тел белән тасвирлап бара, алган максаты һәм идеясе белән чын күңелдән мавыгуы әллә каян сизелеп, күзгә бәрелеп тора. Роман тукымасына кирәк кадәр генә фантазия агымы да кушылып бара.

Узган ел Мәскәүдәге ДОСААФ нәшриятында Нонна Орешинаның «Күкләр биек...» исемле җыентыгы басылып чыкты. Биредә гражданлык, спорт һәм хәрби авиация очучыларына багышланган очерклар тупланган. Тагын шунысын да әйтеп узарга кирәк: Нонна Орешина үзе төрле тип самолетларда 800дән артык очышта катнашкан кеше. Шул исәптән, иң соңгы маркадагы, тавыштан да югары тизлек белән очучы самолетларда да, бомбардировщикларда да, ракета йөртүче самолетларда да, вертикаль күтәрелеп китүче самолетларда да очканы бар безнең Орешинаның!

Кыю һәм тәвәккәл кешеләр турында менә дигән очерклар китабы чыгарган автор! Бигрәк тә яшь укучыларны бу китап күккә дәшә.

Марсель Зарипов озак еллардан бирле инде авыл хуҗалыгы проблемалары белән шөгыльләнә. «Файдалы әйләнеш» — аның яңа китабы. Карабодай мәсьәләсе белән автор аеруча мавыгып шөгыльләнгән. Бу культурага кагылышлы материалларны дүрт ел буена җыйнаган. Илебезнең кайбер төбәкләрендә карабодай уңышы күтәрелеп килә икән — димәк монда безнең М. Зариповның да өлеше бар. Китапка кергән бүтән очерклар да мавыгып укыла. Аларның тырышып язылганы күренеп тора.

Александр Осипов дигән авторыбызның беренче китабы чыгу да ике съезд арасындагы күңелле яңалык булды. Аның геройлары — укучылар, яшь эшчеләр, пенсионерлар. Һәммәсенең үз холкы бар. Тасвирланулары да әйбәт кенә. Димәк безнең отрядка яңа көчләр килә тора.

Алла Гарзавинаның «Казанга, профессор Фукска...» һәм Геннадий Мухановның «Чистай сәхифәләре» дигән китаплары да безнең як тарихын кызыклы мәгълүматлар белән тулыландыралар.

Ике съезд арасында Ф. Галиев, Э. Мушинский, М. Вәлиева, Б. Сулимов һәм Л. Кожевниковларның да кызыклы яңа китаплары чыкты. Ике күмәк җыентык та дөнья күрде.

Ә шигъри җыентыклар саны егермегә якынлаша икән... Кызганыч, бездә русча язылган әсәрләрне анализлаучы бер генә тәнкыйтьче дә юк. Яңа ачылган яшьләр журналы «Идел» бәлки бу өлкәдә дә хәлне төзәтер?

Шулай да бөтен җыентыклар арасыннан Николай Беляевның «Лирика» китабы, шагыйрьнең илле яшьлегенә атап чыгарылган җыентыгы аерылып тора. Шигырьләре уйга, хискә бай. Тиз генә узып китә торган бер әсәр дә юк. Мондый китапны кат-кат укырга да була. Әнә шундый әсәрләр киләчәктә тагын да күбрәк тусын иде.

## Солтан Шәмси

# ЯШӘҮ ДАИРӘБЕЗНЕ КИҢӘЙТИК!

Озак еллар буе административ-командалык системасы басымы астында яшәгән татар халкы, башка халыклар кебек үк, бик нык ассимиляция кичерде. Бу процесс хәзер куркыныч төс алды. Татарларның байтак өлеше инде туган телен онытып өлгерде, үз культурасыннан бизү, йөз чөерү күренешләре дә тормышта бик зур урын алды. Ана теленнән аерылу, милли тамырлар булмау күпләрне рухи фәкыйрьлеккә китерде. Бу бигрәк тә яшьләр арасында киң таралды. Телгә кереп, яманаты бөтен илгә таралган «Казан феномены» дигән күренешнең нигезендә дә, минем уйлавымча, нәкъ менә рухи фәкыйрьлек белән кыргыйлык ята. Милли культура һәм туган телнең шифалы йогынтысында тәрбияләнгән кешегә, ниндидер өер-группаларга бер-

ләшеп, төрле вәхшилекләр кылып, урамнарда йөрүнең бөтенләй кирәге юк, дип уйлыйм. Бары тик үз халкыннан, милли культурадан, туган телдән аерылган кеше генә җил кайдан иссә шунда борыла торган флюгерны хәтерләтә, читтән килгән ялтыравык әйберләргә, культура дип тәкъдим ителгән суррогатка алдана. Андыйлар имансыз һәм мәсләксез бер бәндәгә әверелә.

Хәзер көн тәртибенә килеп баскан иң зур бурыч — туган телне саклау. Туган телне саклап калсак кына — милләтебез яшәр, саклый алмасак — эшче куллар булып кына калачакбыз. Бүгенге көндә безнең күпмилләтле дәүләтебез өчен тел һәм телләр мәсьәләсе үзәк мәсьәләгә әверелде, чөнки бер генә халыкның да, йотылып бетеп, юкка чыгасы килми.

Безнең халык өчен телне саклау мәсьәләсе аеруча җитди тора, чөнки Татарстан — индустрия бик нык үскән республика. Анда калалар һәм промышленность үзәкләре бик күп, алар татар халкы яшәгән төбәкләрне аерым утрауларга бүлгәләп бетереп, ассимиляция процессларын нык тизләтәләр. Шуның өстенә мәктәпләрдә тоташтан русчага күчү бара. Болар хәлне тагын да авырайта. Бу шартларда телебезне һәм милли йөзебезне саклап калу өчен безгә җиң сызганып телнең яшәү сферасын киңәйтә башларга вакыт. Татар теле тулы хокуклы тел сыйфатында тормышның бөтен өлкәләрендә дә файдаланырга тиеш. Татарстан территориясендә ул дәүләт теленә әверелергә тиеш. Шул вакытта гына аңа ихтыяҗ артачак. Шундый шартларда гына күпмилләтле дәүләттә реаль икетеллелек тәэмин ителәчәк.

Әгәр дә без туган телне саклап калу өчен аның яшәү сферасын киңәйтү бурычын куябыз икән, татарчага тәрҗемә бу зур эшнең мөһим бер тармагы булып кала. Үз телебезгә әдәби әсәрләр тәрҗемә итүгә нәкъ менә шул күзлектән карарга кирәк.

Шунысын да әйтергә кирәк: мөмкинлекләре чикләнгән автономияле республика шартларында яшәп, һәм нәшриятыбыз берәү генә булып торып та, ягъни шактый авыр шартларда да, без билгеле бер югарылыкта торган татарчага тәрҗемә итү мәктәбе булдыруга ирештек. Бу мәктәпнең вәкилләре барыбызга да таныш — алар К. Миңлебаев, Р. Даутов, Ф. Гайнанова, Ф. Миңнуллин, Т. Нурмөхәммәтов, Я. Халитов, Л. Хәмидуллин, С. Ибраһимова, В. Зыятдинов. Тәрҗемәчеләрнең шушы буыны әдәбиятта шактый зур эшләр башкарды һәм башкара килә. Алар артыннан ышанычлы әдәби алмаш үсеп чыкты — алар Н. Вәлитова, М. Харисов, Ф. Зыятдинова, Н. Вәлиуллина, Л. Нәҗмиева һ. б. Тәрҗемә секциясе җитәкчесе К. Миңлебаев тырышлыгы белән бу эшкә студентлар да тартыла башлады. Кыскасы, эшләргә кеше бар, шартлар гына кирәк.

Шушы чыгышны әзерләгәндә миңа соңгы 35 ел эчендә, ягъни 1954 елдан безнең көнгәчә дөнья күргән тәрҗемә китапларын барлап чыгарга туры килде. Сәбәбе гади — тәрҗемәнең элек нинди хәлдә булуын ачыклыйсым килде. Кая барабыз? Гомуми тенденция нидән гыйбарәт? Нишләргә кирәк? Шундыйрак сораулар борчый иде мине.

Инде фактларга мөрәҗәгать итик.

1954 елны татар теленә 74 әдәби китап тәрҗемә ителгән. Чагыштырып карау өчен шунысын да әйтергә кирәк: 1989 елда безнең нәшриятта татар телендә 8 тәрҗемә әсәре басылып чыгачак! 74 һәм 8! Күрәсез, аерма бүгенге көн файдасына түгел.

Мәктәп еллары искә төшә... Без ул чакта татар язучыларының китаплары белән бергәттән тәрҗемә әсәрләрне дә бик күп укый идек. Хәтта, әйтер идем, без тәрҗемәләр диңгезендә йөзә идек! Дөрес, ул китапларның тәрҗемәләр икәнен уйлау юк иде. Барысын да үз әдәбиятыбыз дип кабул итәбез, чөнки барысы да татарча. Ләкин ул заманда татар әдәбияты тәрҗемәләр хисабына яшәгән икән дигән фикер калмаска тиеш. 1954 елны 74 тәрҗемә әсәренә өстәп тагын 61 татар язучысының әсәре дә дөнья күргән.

Без, язучылар, еш кына тәрҗемәчеләрнең нәшрият планына кергән китапларын күреп, ризасызлык белдерәбез, безнең өлешкә керәләр, янәсе. Минемчә, иптәшләр, безнең тәрҗемәчеләрне гаепләргә хакыбыз юк — алар да бит халыкка хезмәт итә. Без бу очракта әдәбиятыбыз яшәгән авыр шартларны гаепләргә тиешбез.

Әйдәгез әле, уйлап карыйк. Хәзерге көндә бездә бөтен политик һәм экономик тормыш бары тик рус телендә генә бара. Эш кәгазьләре йөртү, суд эшләре, укуукыту да шулай ук рус телендә алып барыла. Шуңа үз телебездә фәннең булмавын да өстик. Болар ни турында сөйли? Болар телебезнең бары әдәбият өлкәсендә генә яшәвен сөйли. Татар теле күптән инде санап үтелгән өлкәләр хисабына үсми, аның сүзлек фонды артмый. Без, ана телендә язучылар, күптән инде тормышның төрле өлкәләрендә барлыкка килгән терминнарның татар телендә булмавының кыенлыкларын кичерәбез. Өстәвенә милли мәктәбебез дә тирән кризис кичерә. Татарстандагы укучыларның 12 проценты гына татарча белем алуы шул хакта сөйли.

Без милли әдәбиятыбызны үстерү белән берррәттән, дөнья культурасы тудырган хәзинәләрне дә мөмкин кадәр күбрәк үзләштерергә тиешбез. Үз телеңә тәрҗемә итү юлы белән үзләштерергә! Шул культураны үз телебездә халыкка тәкъдим итәргә.

Әгәр дә без зур әдәбиятлардагы хәлгә күз салсак, анда тәрҗеменең гел игътибар үзәгендә булуын, гел хуплануын күрәбез. Сыйфатлы тәрҗемәләрнең үз әдәбиятыны үстерүдә ярдәм итүен, бу эштә бер этәргеч роле үтәвен анда яхшы аңлыйлардыр, күрәсең. Без исә бер елга 2-3 рус авторын 1-2 чит ил язучысын үз телебезгә тәрҗемә итәбез. СССР халыклары телләреннән тәрҗемә итү исә моннан да авыр хәлдә. Без хәтта тугандаш төрки халыклар әдәбиятлары белән дә элемтә тотмыйбыз диярлек, тәрҗемәләрнең аз булуы шул хакта сөйли. Бу исә әдәбиятыбызның изоляциядә яшәвен күрсәтә. Без үз казаныбызда кайныйбыз һәм бу хәл офыкларның тараюына китерә.

Ни сәбәпле андый изоляциядә калдык соң без? Дөресен әйтергә кирәк: торгынлык еллары дип йөртелгән заманда безнең мондый хәлдә яшәвебез кайберәүләр өчен хәтта файдалы да иде. Ул елларда халыклар һәм культураларның төрле рангларга бүленеп йөртелүе беркем өчен дә сер түгел бит.

Әйтик, бар союздаш республикалар. Әлбәттә, аларның мөмкинлекләре зуррак. Табигый, союздашлар шундый республикалар белән генә аралаша. Шул ук вакытта киселгән бюджетлы автономияләр әдәбиятлары да яши. Һәм аларны һич тә союздашлар белән янәшә куеп булмый.

Әдәби осталык буенча безнең хәлләр начар тора дип әйтеп булмый. Өлкән буын тәрҗемәчеләребезнең уңышлары барыбызга да билгеле, яшьләр арасында да өметле алмаш үсеп килә. Шуңа да карамастан, борчылырга сәбәпләр бар. Эш шунда ки, әдәби алмашның саны бик чикле. Өстәвенә өлкән буын тәрҗемәчеләребез пенсиягә китә башлады яки китәргә җыена. Авыр тәрҗемә эшен алар озак тартып бара алмаячак. Шул ук вакытта тәрҗемәләрнең елдан-ел кысыла бару тенденциясе сакланган очракта, яшьләр дә җиң сызганып эшли алмаячак. Димәк, аларның сафы кешеләр хисабына үсмәячәк. Шулай итеп, киләчәктә хәлләрнең бөтенләй мөшкелләнеп китүе ихтимал.

Мондый авыр хәлдән чыгуның бер генә юлы бар, ул да булса — яңа нәшрият ачу. Союздаш республикалардагы кебек үк! Татарстан ил табынына зур өлеш кертә. Шуңа күрә хәзер социаль гаделлек урнашырга тиеш. Бары тик яңа нәшрият ачу гына безнең әдәбиятка үсү өчен нормаль шартлар булдыра алачак. Хәзерге көндә исә без, алга барасы урында, артка таба чигенә башладык.

Инде ике съезд арасында дөнья күргән тәрҗемә китапларына тукталыйк. Барысыннан да элек, иң актив эшләүче тәрҗемәчеләрнең дә ике китап кына бастырып чыгара алулары күзгә ташлана. Кайберәүләр хәтта бер китап белән чикләнгән. Ни сәбәпле? Сәбәп шул ук: мөмкинлекләр юк. Әгәр дә шушы вакыт эчендә язучыларыбыз әсәрләрен кысмыйча гына тәрҗемәләр биш тапкыр күбрәк басылып чыкса, әдәбиятыбыз оттырыр идеме-ни?

Тәрҗемә китаплардан иң күзгә ташланганы Г. Маркесның К. Миңлебаев тәрҗемәсендә дөнья күргән «Ялгызлык» романы. Ниһаять безнең әдәбиятта да исәнсау Нобель премиясе лауреатының романы тәрҗемә ителде!

Ф. Гайнанова тәрҗемәләре аерым игътибарга лаек. Ул шушы вакыт эчендә Ж. Вернның «Серле утрау»ын, А. Иванов повестьларын тәрҗемә итте. Ф. Гайнанова — әдәби тәрҗемә өлкәсендә осталыкның югары баскычында тора. Аның җөмләсе шундый табигый укыла ки, хәтта тәрҗемә әсәре укыганыңны онытылып та җибәрәсең.

Т. Нурмөхәммәтов белән В. Астафьев арасында урнашкан иҗади дуслык әдәбиятыбызга бай җимеш бирде. «Патша балык»— язучының татарча басылып чыккан өченче зур әсәре һәм аларның барысын да Т. Нурмөхәммәтов тәрҗемә итте. Аның тәрҗемәсендәге роман русча варианты кебек табигый һәм җитди яңгырый.

Ф. Миңнуллин укучыларга барыннан да элек җитди һәм принципиаль тәнкыйтьче буларак билгеле. Соңгы елларда ул үзен сәләтле тәрҗемәче буларак да танытты. Д. Лондонның «Мартин Иден» романы, Г. Уэллсның «Күренмәс кеше» әсәре аның тәрҗемәсендә дөнья күрде. Ике съезд арасында ул Г. Уэллсның тагын бер романын — «Галәмнәр сугышы»н дөньяга чыгарды. Фантастик жанрның безнең әдәбиятта ярлы хәлендә генә яшәвен истә тотсак, бу китапның үсмерләр өчен нинди зур бүләк булуын аңлавы кыен түгел.

Соңгы вакытта бездә хәрби темага багышланган әсәрләр дә тәрҗемә ителде. Бу җәһәттән Ю. Бондаревның Я. Халитов эшләгән «Кайнар кар» романын, В. Быковның Л. Хәмидуллин тәрҗемәсендәге «Һәйкәл» һәм «Таң атканчы яшисе бар» повестьларын күрсәтергә мөмкин.

Соңгы елларда әдәби тәрҗемә өлкәсенә сәләтле яшь кадрлар килде. Бу уңайдан Н. Вәлитованың актив иҗат итүен күрсәтеп үтәргә кирәк. Аның тәрҗемәсендә В. Рас-

путинның «Онытма гомергә», Н. Думбадзеның «Мәңгелек канун» әсәрләре инде укучылар кулына барып та ирешә. Авторларның сайланышы ук тәрҗемәчегә югары зәвык хас булуы турында сөйли.

Тәрҗемәчеләрнең хәле турында да бер-ике сүз әйтми булдыра алмыйм. Кызганыч, бездә тәрҗемәче язмышы да бердәнбер нәшрият мөмкинлегеннән һәм башлыкларның аңа карата мөнәсәбәтеннән тора. Кайвакытта тәрҗемә ителгән әсәрләр еллар буе нәшрият планына керә алмый... Безнең тәрҗемәчеләр әнә шундый шартларда да туктаусыз эшләргә, иҗат итәргә, ирешкән биеклекне сакларга тырышалар.

Әдәбиятны үстерү, яңа мөмкинлекләр булдыру өчен безгә яңа нәшрият кирәк. Һәм ул яңа нәшриятта тәрҗемәләр белән махсус шөгыльләнүче аерым редакция булдыру әдәбиятка зур файда китерер иде.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

**Язучылар союзы идарәсе председателенең докладын һәм әдәбиятның аерым жанрлары буенча өстәмә докладлар тыңлап тикшергәннән соң, Татарстан язучыларының XI съезды КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Язучылар союзы идарәсенең отчет чорындагы эшчәнлеген хупларга. Язучылар союзы идарәсенең эшен канәгатьләнерлек дип табарга.

2. Татарстан Язучылар союзының яңа идарәсенә, шулай ук Әлмәт һәм Чаллы язучылар оешмаларына төп игътибарны: әдәбият-сәнгатьнең илдәге социаль-әхлакый үсеш һәм җәмгыятьне әхлакый сәламәтләндерү өчен җаваплылыгы турында КПССның XXVII съезды һәм XIX Бөтенсоюз партия конференциясе карарларында әйтелгән күрсәтмәләрне тормышка ашыруга юнәлдерергә. Язучылар союзы идарәсенә съездда әйтелгән тәнкыйть фикерләрен һәм тәкъдимнәрне тормышка ашыру буенча эш планы төзергә. Татар теленең һәм әдәбиятының уңышлы үсеше өчен кирәкле иҗади атмосфера тудырырга.

3. Иҗат яшьләре белән эшләүгә аеруча игътибар итәргә, әдәби түгәрәкләргә һәм берләшмәләргә, сәләтле башлап язучыларга ярдәм күрсәтүне көчәйтергә.

4. Татарстанга союздаш республика статусы бирү һәм татар телен республикада дәүләт теле итеп игълан итү турында җәмәгать оешмалары керткән тәкъдимне Татарстан язучыларының XI съезды тулысынча яклый.

5. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, уку йортларында татарча тәрбия һәм белем бирүче группалар, класслар ачуда эшлекле ярдәм күрсәтүне үтенеп съезд партия, совет оешмаларына мөрәҗәгать итә.

6. Партиянең XIX Бөтенсоюз конференциясе карарлары яктылыгында һәм татар халкының социаль-экономик, культура ихтыяҗларын канәгатьләндерү йөзеннән Татарстан язучыларының XI съезды СССР Госкомиздаты һәм республикабызның директив органнары алдында түбәндәге мәсьәләләрне куярга кирәк дип саный:

а) Татарстан Язучылар союзының «Язучы» нәшриятын ачу;

б) республикада атналык әдәби газета булдыру;

в) мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен («Колобок» тибында) татарча рәсемле, төсле яңа журнал чыгару.

7. Республиканың югары һәм махсус урта уку йортларында укырга керү имтиханнарын татарча тапшыру мөмкинлеген гарантияләргә. Авыл хуҗалыгы, ветеринария һәм педагогия институтларында татарча укытыла торган параллель группалар булдыруга ирешүгә.

8. Съезд татар мәктәпләрендә чит тел сыйфатында гарәп телен укытуны максатка ярашлы дип саный. Татарча хәрефләр куелган язу машинкалары чыгаруны сорап, съезд тиешле оешмаларга мөрәҗәгать итүне кирәк таба.

9. Татарстан Язучылар союзы каршында китап кибете оештырырга. Подписка буенча таратыла торган китапларны булдыруда язучыларга ярдәм итәргә.

10. Съезд Татарстанда яшь тамашачылар театры булдыруны һәм нәфис фильмнар төшерүче студия ачуны зарур дип саный.

11. Хәзерге татар әдәбиятын һәм әдәби мирасны пропагандалау буенча «Казан утлары» журналының нәтиҗәле эшен билгеләп үтәргә.

12. СССР Фәннәр академиясенең Казанда ачылачак фәнни үзәге каршында әдәбиятсангать институты булдыруны максатка ярашлы дип санарга.

13. Яңа идарә составына Язучылар союзы нигезендә Татар язучыларының Бөтенсоюз ассоциациясен оештыру мәсьәләсен карарга.

14. Татарстан Язучылар союзына тугандаш әдәбиятлар белән бәйләнеш буенча секретарь штаты бирүне сорап РСФСР Язучылар союзы идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

15. СССР Язучылар союзы идарәсе алдына РСФСР халыклары әдәбияты буенча Совет төзү мәсьәләсен куярга.

16. Сталин репрессияләре корбаны булган татар язучыларының тулы исемлеген төзергә. Тикшерү материаллары буенча язучыларның Тукай исемендәге клубында мемориаль комплекс оештырырга.

17. Татар телендәге Бөтенсоюз газетасын яңадан торгызуны зарур дип санарга. Директив органнардан һәм СССР телевидение, радио тапшырулар дәүләт комитетыннан татарча тапшыруларның вакытын һәм станцияләрнең куәтен арттыруны сорарга.

18. Ике елдан соң язучыларның гомуми җыелышында идарә председателенең һәм «Казан утлары» журналы баш редакторының XI съезд карарларын үтәү буенча отчетларын тыңларга, аларга ышаныч белдерү-белдермәү мәсьәләсен карарга.

19. Яңа сайланган идарәдә һәр әгъзаның конкрет бурычын билгеләргә, тапшырылган эш өчен аларның шәхсән җаваплылыгына һәм хисап биреп баруларына ирешергә.

20. Республиканың төп халкы телен — татар телен белүне идеология эше белән бәйләнгән һәркем өчен тормыш ихтыяҗы тудырган мәҗбүрият дип санарга.

21. Соңгы елларда татар телен куллану даирәсе борчу тудырырлык дәрәҗәдә тараюны искә алып һәм, шул ук вакытта язучыларның профессиональ союзына үзе татар булып та башка телдә, бигрәк тә рус телендә язучы авторларның һаман күбрәк килә баруын истә тотып, Татарстан язучыларының XI съезды түбәндәгене белдерүне кирәк саный: әдәбиятның миллилеген билгеләүче төп критерий булып, теге яки бу әсәр язылган әдәби тел санала.

22. Съезд яңа сайланган идарәгә Татарстан язучыларының XI съезды материалларын аерым китап итеп бастырып чыгаруны йөкли.

Рафаил Төхфәтуллин

# ДӨРЕСЛЕК КАЯН БАШЛАНА?

Узган ел җәй Казан телевидениесеннән язучы Фәүзия Бәйрәмова болай дип белдергән иде: «Без моңарчы ялганны язганбыз. Укучыны ялган белән алдап килгәнбез». Бу сүзләрне үз колакларыма ышанмыйча, шаккатып тыңладым. Нәрсә бу? Әдәбиятыбызның җитмеш елдан артык бай мирасына нигилистларча кул селтәүме? Әллә яшьлек кайнарлыгы гынамы? Шунда ук Фәүзия сеңлемнең үзенең үк «Болын» повестен хәтерләдем. Табигать һәм рухи экология турында йөрәк каны белән язылган бу әсәр дә, димәк, ялган микәнни? Озак та үтмәде, шул ук авторның «Социалистик Татарстан» газетасында «Кыңгырау» повестеннан өзек басылып чыкты. Биредә сүз утызынчы еллардагы коточкыч репрессия турында бара. Ах, мин әйтәм, Фәүзия сеңлемчә, дөреслекне язу, ялганламау әнә ничек була икән! Автор әле дөньяга да килмәгән чорның дәһшәтле вакыйгаларын язса, бу — дөрес, ә үзе күргән-кичергәннәр чагылган «Болын» повесте — ялган. Шуннан соң «Социалистик Татарстан»да бер-бер артлы Ә. Гаффарның «Олы юлның тузаны» әсәреннән өзек, аннары Н. Гыйматдинованың «Манара» хикәясе басылып чыкты. Боларда да сүз шул ук дәһшәтле утызынчы еллар турында, авторлар үзләре әле дөньяга да килмәгән чордагы вакыйгалар сурәтләнә. Бу хәлгә мин сагаеп калдым. Нәрсә бу? Әнә шулай илебез тормышындагы иң фаҗигале еллар турында язсаң гына дөреслекне язу була, дигән караш әллә безнең яшь буын язучылары өчен уртакмы? Мин, әлбәттә, яшьләр үзләре күрмәгән-кичермәгән утызынчы еллар турында язмасыннар дигән караштан ерак торам. Социализм идеяләрен, гуманистик гомумкешелек принципларын варварларча изеп-сытып үткән ул еллар фаҗигасе шул буын кешеләре тормышында гына түгел, билгеле булганча, килер буын кешеләре тормышында да төзәлмәс җәрәхәт булып калды. Бу яра-җәрәхәт әле тиз генә төзәлмәс тә. Димәк, ул еллар фаҗигасе һәр буын язучылары иҗатында теге-бу дәрәҗәдә чагыла икән — бу бик табигый.

Мине борчыганы менә нәрсәдә.

Чын иҗат олы хакыйкатьне үз йөрәгең аша кичереп язудан гыйбарәт. Моның беренче шарты — язган чорыңның чын дөрес атмосферасын тирәнтен тою. Бу тоем, үз чиратында, әдәби детальләрнең тормышчан дәрес булуында чагыла.

Ф. Бәйрәмованың «Кыңгырау» повесте, Ә. Гаффарның «Олы юлның тузаны» миңа әле аерым өзекләре буенча гына таныш. Өзекләр буенча әсәр турында тулаем фикер йөртү дуамаллык кына булыр. Ә менә Н. Гыйматдинованың «Манара» хикәясе укучыга тулы килеш таныш. Хикәядә чорның атмосферасы һәм детальләр дөреслеге ни дәрәҗәдә соң? Монысы турында инде тулырак туктала алам.

Алдан ук шуны әйтим, Н. Гыйматдинованың җитмешенче еллар урталарында беренче хикәяләре күренү белән үк, мин аның иҗатын зур кызыксыну, олы өмет һәм соклану белән күзәтеп барам. Әдәбиятка үз сүзең, үз тавышың белән килү — бу инде иң мөһиме. Әйтергә кирәк, иҗади бәхет һәм талантның иң беренче билгесе.

«Манара» хикәясе исә Нәбирәнең һич тә үз сүзе, үз тавышы түгел. Хикәядә сүз, әйткәнемчә, утызынчы еллар урталарында бара. «Дин» сүзе «контр» сүзе белән бер дәрәҗәдә йөргән еллар бу. Картларның бисмилла сүзләрен дә кычкырып, хәтта пышылдап әйтү түгел, ә эчләреннән генә кабатлый торган еллары. Менә шундый чорда авыл советы председателе Заһидулла мәчет манарасын ремонтлатып, аңа яңа ай куйдырып йөри. Заһидулланы колхоз председателе Нурулла әлеге белән «алып китәләр». Бу — әлеге еллар атмосферасына бөтенләй каршы килә торган ситуация. Мәчет манараларын массовый кисеп ыргыткан елларда, Заһидулланың манараны ремонтлап, яңа ай куйдырып йөрүе-

на ышануы кыен. Аннары — моңа инде һичкемнең элэгэ-доносы кирэкми, шунда ук гаепланэсе ачык.

Инде вакыйганың практик ягын алыйк. Мэчет манарасындагы айны алай һич тэ жиңел алып төшеп булмый. Һич мөмкин түгел бу. Без, ул еллар малайлары, манараның төзелешен, клубка әйләндерелгән манаралы мәчетләргә менеп тә, инде төшерелеп җирдә яткан манаралар буенча да бик яхшы беләбез. Манара эченнән мәэзин азан әйтә торган тәрәзәгә кадәр генә баскыч ясалган. Аннан ары манара очына шома багана буйлап кына менәргә мөмкин. Менеп җитә алсаң да әле бик нык тышчага, зур түгәрәк гөмбәзләргә килеп төртеләсең. Ә хикәядә Нурулла, манара очына эчке баскычтан менеп, айны җиңел генә алып төшә. Әйтерсең, мәчет ае тәти бер елка уенчыгы гына! Потлап авырлыктагы айны җиңел генә ихатасына алып кайтып, яшереп тә куя. Картаймыш көнендә исә шул потлы айны күтәреп, янә мәчет манарасына менмәкче булып маташа. Нәбирә сеңлем, белмәгәнлектән, хикәясен әнә никадәр ясалма һәм мөмкин дә булмаган ситуациягә кора.

Менә ни өчен яшь талантларның үзләре белмәгән-кичермәгән вакыйгалар турында язарга ташланулары мине күпмедер хафага сала.

Бу буын язучыларның балалык һәм яшьлек еллары, әгәр тирәнтен уйлап баксаң, репрессиянең бүтән төр ысулларына гына алыштырылган тынчу торгынлык елларына туры килә. Әле тарих тузаны капларга өлгермәгән шушы елларның тетрәндергеч вакыйгалары турында, тирәнтен уйланып, шулар турында язасы урынга, нигә яшь талантларны бабаларыбыз тормышы күбрәк кызыксындыра соң әле? Бу сорауга минем хәзергә җавап таба алганым юк.

Дөрес, торгынлык елларының табигать һәм рух экологиясенә китергән фаҗигалетынчу вакыйгалары турында да әсәрләр күренә башлады. Шундыйлардан мин, беренче чиратта, М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повестен атар идем. Повесть, нәкъ Мәһдиевчә, йөгерек-шаян тел, ихлас ачынулы аһәңдә язылган. Әсәргә Лермонтовның: «Кешеләргә татлы ризыкларны җитәрлек ашаттык; моңардан аларның ашказаны бозылды, ачы дарулар, яндыра торган хакыйкатьләр кирәк»,— диган сүзләре эпиграф итеп алынган. Әсәрдән мондый «яндыра торган хакыйкать» күренешләрен шактый укыйбыз. Ләкин «ачы хакыйкать» дип, автор үткәндәге ялгышларыбызны тәнкыйтьләү дәртенә артыграк та биреләп китә һәм хәтта ялганга кадәр барып җитә. Бер мисал. «Без балачакта укыган китаплар: «Куян үстерү — илебез экономикасының төп нигезе»,— ди автор. Белмим, кайчан, кайдан алып укыды икән Мөхәммәт мондый китапны? «Куян үстерү — илебез экономикасының төп нигезе». Ягъни, куян асрамасак — беттек, харап булдык, нигезебез җимерелә! Нәрсә-нәрсә, шушы кадәр үк ахмаклыкка барып җитмәдек лә, җәмагать. Нефть — ил экономикасының нигезе дип, «кара алтын» чыгаруга бөтен көчебезне туплап, иң уңдырышлы басуларыбызны харап итеп бетердек тә, нефть бәрабәренә чит илдән икмәк сатып алып ашау хәленә барып җиттек, ләкин алай куян койрыгына ябышканыбыз булмады лабаса! Яки менә азык-төлек программасын үтәүдә шәһәр халкының ярдәмен Мөхәммәт менә мондый, шулай ук шарж-карикатура сурәтендә чагылдыра. Имеш, шәһәр кызлары «скверга чыгып, лезвие, пәке, кайчы белән чирәм кыркып йөрделәр». Ачы сатирик әсәр өчен менә дигән сюжет! Лезвие белән әзерләнгән шушы ике-өч бөртек үлән өчен кызның ничә бармагын кисүе, аңа күпме больничный-пособие түләнүе, бармаксыз кыздан күпме «асыл» егетнең йөз чөерүе һ. б. һ. б. турында фараз кылырга була. Ләкин бит «Бәхилләшү» моңсу повесть дип аталган. Шуңа күрә дә моңсу-лирик повестьта мондый сатира, шарж-карикатура күренешләренең катнашып китүе һич тә «ачы хакыйкать» булып түгел, ә теш ыржайтулы ялган булып яңгырый.

Хәзерге яңарыш чорының ачыктан-ачык сөйләшү һәм чын демократия шартлары әдәби иҗатта гаять киң мөмкинлекләр ачты. «Бәхилләшү» повестен, бу мөмкинлекләр ачылгач М. Мәһдиевнең иҗат потенциалы никадәр ургып-ургып ташый башлавына сокланып укыйсың. Ләкин бу ташкынның һичнинди чик-чаманы белми башлавы сагайта да. Чын демократиянең гадел законнары булган кебек, әдәбиятның да гасырлар буена килгән үз кануннары бар лабаса!

Минем карашымча, кыю иҗади эзләнүләр һәрьяклап яклауга лаек, ләкин бу эзләнүләрдә аз гына да ялган катнашмасын! Тормыш дөреслеге — детальләр дөреслегеннән башлана. Бу хакыйкать чын художникның канына сеңсен иде!

**Фатих Ибраһимов**

# ӘЛЕ ДӘ КҮҢЕЛ ТҮРЕНДӘ

Ул еллар бездән ераклашкан саен, хатирәләр күңелгә якынлаша гына бара. Кешенең яшьлектән аерыласы килмәү галәмәтедер инде, күрәсең. Мин бу очракта рабфак елларын күздә тотам. Безнең чор рабфаклары эшче-крестьян яшьләренә урта белем бирде. Аларга дүрт еллык белемле кешеләр кабул ителә. Башта рабфак студентлары арасында производстводан килгән 30-35 яшьлек эшчеләрне дә очратып була торган иде. Беренче елларда уку срогы дүрт ел булды, соңга таба өч елга калдырылды. Егерменче елларның урталарында һәр югары уку йортында диярлек рабфак була торган иде. Алар шул рәвешле эшче-крестьян яшьләреннән үзләренә булачак студентлар әзерләде.

Утызынчы еллар урталарында миңа Казан педагогия институты рабфагында укып, урта белем алырга насыйп булды. Педрабфак башта, Муса Җәлил һәм Сибгат Хәким укыган елларда, хәзерге СССР Фәннәр Академиясе филиалы бинасына урнашкан була. Соңрак аны педагогия институтының Л. Толстой урамындагы кечерәк бинасына күчерделәр. Аннары педрабфак Чистай шәһәренә җибәрелә һәм Бөек Ватан сугышы чорында бөтенләй ябыла. Бу — барлык рабфаклар өчен дә уртак язмыш иде.

Менә без — педрабфакта. Арабызда яшьрәкләр дә, шактый олы ир-егетләр һәм хатын-кызлар да бар. Безне Горький һәм Галактионов урамнары чатында, «Кекин йорты»ндагы тулай торакка урнаштырдылар. Беренче катта — ашханә. Анда әчеп беткән тозлы кәбестәдән аш пешерәләр. Укырга да, ашарга да пединститут студентлары белән бергә йөрибез. Институтның күп кенә педагоглары рабфакта да укыта.

Без, рабфак студентлары, көтмәгәндә, гаҗәп кызыклы һәм өметле биографияле шәхесләр арасына килеп кердек. Иртә белән торып коридорга чыксаң, иңенә бишмәтен салган Сибгат Хәкимнең нәрсәдер уйланып йөрүен күрәсең. Аның иреннәре кыймылдый. Ул беркемгә дә игътибар итми. Әнә шулай яңа шигырен «чарлавы» икән...

Җәһәт-җәһәт атлап, кулларын болгый-болгый Шәйхи Маннур үтеп китә. Ашыкмый гына Идрис Туктар белән Хәсән Шабановның гәпләшеп барганнары күренә, Хәсән Хәйри белән Хабра Рахман уза. Урамда, тарантаска утырып, Мөхәммәт Гайнуллин каршыга килә. Ул институт эшләре белән каядыр ашыга, күрәсең. Кемнәр генә очрамый институтка бару юлында! Галимҗан Нигъмәти дә, Гомәр Толымбай да. Инде шактый танылып өлгергән башка шәхесләр дә...

Рабфак пединститутның шифалы йогынтысын тоеп яшәде. Тарих фәненнән Һади Такташның энесе, бик җитди кыяфәтле Габит Такташ укыта. География дәресләрен гаять ягымлы, йөзеннән елмаюы китми торган, язучы Мөхәммәт Гали алып бара. Татар теле һәм әдәбияты галиме Габделхәй ага Хисмәтуллин безне әдәбият дөньясына алып керә. Аның башы туктаусыз әкрен генә селкенеп тора иде. Бу авыру беренче бөтендөнья сугышында алган контузиядән калган, диләр. Заһидә ханым Тинчурина безне рус теленә өйрәтә. Ул гаҗәп хәрәкәтчән. Соравына җавап бирә алмыйрак торсаң, ул сузаеп кала, туфляларының үкчәсе тагын да күтәрелә төшә сыман. Җавабың матур булса, елмаеп куя, ялгыш булса, кәефсезләнә.

Заһидә апа безгә бөек рус телен үзләштерергә ярдәм итте. Пушкин, Толстой, Горький турында да без аңардан белдек. Татар яшьләрен русча сөйләшергә өйрәтүдә ул көчен дә, вакытын да, сәләтен дә кызганмады.

Мондый шартларда безнең начар укырга, ялкауланырга хакыбыз юк иде. Дәресләрнең күплегенә карап тормадык. Сибгат Хәким һәм Габделхәй Хисмәтуллин булышлыгы белән әдәбият сөючеләр түгәрәге оештырып җибәрдек. Безнең арада Шәраф Мөдәррис аерылып тора. Ул күп тә яза, әйбәт тә яза, аның шигырьләре

мавыктыргыч сюжетлы да була, рифмалары да килешле. Озакламый аның шигырьләре республика матбугатында да күренә башлады. Шәриф Весновский дигән иптәшебезгә сатирик темалар җиңел бирелә иде. Аның шигырьләрен «Чаян» журналына бик теләп кабул итәләр. Гали Галиев дигән егетебез дә өметле күренә. Түгәрәккә финанс-экономика институты студенты Галимҗан Латыйп та йөри иде.

Сибгат Хәким бик ярдәмчел, ул безнең әдәбият түгәрәгенә шефлык итә: түгәрәк утырышларында катнаша, башлап язучыларга, әсәрләре тикшерелгән иптәшләргә эшлекле киңәшләр бирә. Түгәрәк утырышларында тема сайлау, сюжет төзү, рифма табу турында бәхәсләшүләр шактый вакытны ала иде. Әдәбият теориясе турында лекцияләр укырга галимнәрне дә чакыргаладык. Тикшерелгән әсәрләрне газета-журнал һәм китап нәшриятына тәкъдим дә итәбез. Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Яшь көчләр» исемле җыентыкны әзерләшүдә безнең түгәрәк членнары якыннан катнашты һәм бу безгә зур шатлык китерде.

Бер утырышта кульъязма әдәби журнал чыгару кирәклеге турында киңәштек. Аңа «Яшь көч» исеме бирдек. Түгәрәкнең җитәкчесе буларак, редактор итеп, мин билгеләндем. Ул айга бер тапкыр чыгып килде. Аның тышлыгына рәсем ясала, язмалар машинкада бастырыла. Рәсемне исә ул чактагы «Кызыл яшьләр» газетасының художнигы Ш. Зәбих ясап бирә, редакциянең әдәби хезмәткәрләре Гали Хуҗи белән Нәби Дәүли «Яшь көч»тә урнаштырыла торган язмаларны редакцияләүдә ярдәм итәләр иде.

Түгәрәк членнары төрле жанрларда язганлыктан, журналның эчтәлеге шактый кызыклы була, аның һәр саны көтеп алына. Шунысы яхшы, рабфак дирекциясе хуплап кына калмый, чыгымнарны да үз өстенә ала, журналда актив катнашучыларны бүләкли дә иде.

Түгәрәк членнары иҗат иткән кайбер кульъязмаларны Язучылар союзы идарәсе аша күренекле язучыларга рецензиягә дә бирә идек. Әйтик, минем «Югалган эзләр» исемле кульъязмамны укыгач, Ибраһим Газиның: «Каләме өметле күренә. Алга таба дәвам иттерсен иде!» дигән фикере хәтеремдә калган.

Түгәрәк барлык студентларны әдәби хезмәткә тарту юнәлешендә дә даими эш алып барды. Татар язучылары белән очрашулар, китап укучылар конференцияләре һәм әдәби кичәләр уздыру түгәрәкнең гадәтенә керде. Ул елларда Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты» әсәре әдәбият сөючеләрнең, бигрәк тә яшьләрнең күңелен яулап алды. Рабфакта үткәрелгән конференциядә бөтен коллектив диярлек катнашты.

Татар академия театры спектакльләренә күмәкләшеп йөрүләр оештырыла иде. Рабфакның профкомы театрга ел саен ике даими билет сатып ала — студентлар шул билетлардан да бик теләп файдаланалар. Әдәбият түгәрәге Татарстан Язучылар союзы белән якын элемтәдә торды. Кави Нәҗми безне хуплый, яшьләр иҗатына җитди игътибар бирә. Ул елларда Г. Тукай исемендәге клуб сәхнәсе артындагы бүлмәдә утырышта катнашучы язучылар өчен чәй хәзерләнә. Кави Нәҗми безгә ымлап: «Сәхнә артына кереп чыгарга онытмагыз, егетләр!» — дип күз кысып куя торган иде. Кая инде оныту! Безгә, студентларга, анысы бигрәк тә кирәк!

Кави Нәҗминең әдәбиятыбыз торышы турындагы кайбер фикерләре дә истә калган. Ул, мәсәлән, кайчак: «Минем өч-дүрт ел язган әсәремне укучы бер атнада укып чыга. Язучыларыбыз азрак шул безнең»,— дип зарланып куя торган иде.

Рабфакта уздырыла торган очрашуларга Кави Нәҗми, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин кебек танылган әдипләр дә килә. Ул көнне язучыны барып алу, соңыннан илтеп кую бездәй егетләр вазифасына керә иде. Чиратта — Хәсән Туфан. Миңа аның Старый урамындагы фатирында булырга туры килде. Очрашу көнендә аны алырга барсак, ул... өйдә юк иде. Алдан ук үзе чыгып киткән икән.

Кәрим ага Тинчурин белән очрашуны аның тормыш иптәше, укытучыбыз Заһидә апа ярдәмендә оештырдык. Заһидә апа, җае туры килгәндә, драматург турында сөйли иде. Шунлыктан танылган драматургның иҗади портретын без азмы-күпме күз алдыбызга китерә идек инде. 1921 елда Кәрим Тинчурин җитәкчелегендә бер төркем татар артистлары Урта Азиягә юл тотканнар. Идел буенда — ачлык. Күпләр, икмәк эзләп, Ташкентка омтыла. Юл озын, мәшәкатьле. Вакытны ничек уздырырга? Менә шул чакта мәҗлеснең уртасында Кәрим Тинчурин була. Заһидә апаның тасвирлавына карaганда, Кәрим ага үзенең юлдашларына бертуктаусыз диярлек әкият сөйләп барган. Халык әкиятләрен генә түгел, үз әкиятләрен дә! Атна-ун көн буена. Драматург уйлап чыгарган әкиятләрнең күплегенә, мавыктыргычлыгына һәм әкиятченең хәтеренә иң якын иптәшләре дә хәйран калган! Кызганычка каршы, Кәрим Тинчуринның әкиятләре беркайда да күренми. Димәк, автор аларны тәртипкә китереп, язып-теркәп куярга өлгерә алмый калган.

Татар әдипләре белән очрашулар бездә эшлекле шартларда уза иде. Әйтик, дра-

матургны чакыру алдыннан театрда бара торган әсәрләрен карыйбыз. Башкалары килгәндә дә иҗатларын өйрәнәбез. Мәгълүматларыбызны гомумиләштерергә әдәбият укытучыбыз Габделхәй ага Хисмәтуллин булыша. Ул елларда, Шәриф Камалның «Томан артында» дигән әсәре кебек үк, Кәрим Тинчуринның «Алар өчәү иде» драмасы да зур уңыш белән бара иде. Кыскасы, Кәрим ага Тинчурин белән очрашуны без аеруча әзерләнеп һәм зур кызыксыну белән көтеп алдык. Менә безнең каршыбызга уртачадан биегрәк буйлы, тыгыз гәүдәле, киң маңгайлы, куе кара чәчле, ачык йөзле кунагыбыз килеп басты. Ул үзенең самимилеге, һәр сүзенә тирән мәгънә салып сөйли белүе, үтә тыйнак, киң күңелле булуы, барыннан да бигрәк, бездәй студентларны үз итүе белән күңелләрне тиз җәлеп итте. гади, бик гади кеше иде танылган драматургыбыз Кәрим ага Тинчурин!

Очрашу озакка сузылды. Студентлар бик күп сораулар бирде, үзләре дә чыгып-чыгып сөйләде. Тема сайлау, кульминациягә ничек бару, образлар тудыру, чынбарлык һәм автор фантазиясе турындагы сорауларга драматург көлдерә-көлдерә җаваплар кайтарды, әсәрләренең язылу тарихларын бәйнә-бәйнә сөйләде.

— Теге яки бу образым, аеруча баш геройларым күз алдыма килеп басмый торып, кулыма каләм алмыйм,— диде Кәрим ага.— Мин аларның чәчләрен, йөз-кыяфәтләрен, кием-салымнарын гына түгел, хәтта тырнак астындагы ак тапларын да алдан ук күреп торам...

Булат, Мәйсәрә, Ишан кебек, бер күрүдә күңелгә кереп кала торган образлар тудырган драматургның җавабы әнә шундый булды.

Безнең түгәрәк членнарына нәкъ менә әдәбият әһелләре Сибгат Хәким, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази җанлы үрнәк булдылар. Болар арасында Кәрим ага Тинчуринның роле аеруча зур. Без аларга охшатырга тырышып иҗат иттек, әзләндек, табышларыбызга шатландык, алар кебек булырга омтылдык.

Дөрес, барыбыз да әдәбиятчылар булып китә алмадык. Моңа, бәлки, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы да камачаулагандыр. Шулай да без бүген түгәрәкнең актив члены Шәрәф Мөдәррис иҗаты белән горурланабыз. Гали Галиев дигән иптәшебез бер генә җыентык чыгарып калды. Ул сугышта һәлак булды. Сәләх Хафизов дигән иптәшебез оста тәрҗемәче булып җитеште, хәтта В. И. Ленин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүдә катнашты. Мин дистә еллар буена «Чаян» һәм «Совет мәктәбе» журналларының баш редакторы хезмәтен үтәдем.

Һади Такташча әйткәндә, «шушы шаярулар», классик әдипләребез белән очрашулар, укучылар конференцияләре, әдәби кичәләр — һәммәсе рабфак студентлары өчен һич тә эзсез калмады. Күңелләребездә туган әдәбиятыбызга мәхәббәт тәрбияләнде, аның халыкчанлыгына ышаныч артты. Педрабфакның ничәмә-ничә студенты татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып җитеште, алар яшь буынны ялкынлы патриотлар итеп тәрбияләүдә актив катнаштылар.

# ЯЛКЫНЛЫ ЕЛ АВАЗЫ

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңеп яшь Совет республикасы барлыкка килгәч тә, халыкара империализм бу республиканы бетерү, Россиядә капитализмны яңадан тергезү, территориясен аерым илләр арасында хәрәкәт зоналарына бүлеп, аның бәйсезлеген юкка чыгару өчен коралды интервенция оештыру чараларына керешә. Бу — мөстәкыйль дәүләткә каршы оятсыз рәвештә, игълан итмичә сугыш башлау иде.

1918 елның 18 февралендә Германия, Австро-Венгрия, Төркия гаскәрләре, вакытлы солых шартларын бозып, Фин култыгыннан Дунай тамагына кадәр фронтта һөҗүмгә күчтеләр. 3 мартта Брест-Литовскида солых договорына кул куелса да, бу гаскәрләр үзләренең һөҗүмнәрен туктатмадылар, аз гына вакыт эчендә Балтик буен, Белоруссиянең, Украинаның зур өлешен, Закавказьены басып алдылар. Шул ук елның яз, җәй айларында АКШ, Англия, Франция, Италия гаскәрләре Мурманск, Архангельск шәһәрләренә керделәр, японнар белән берлектә Ерак Көнчыгышта үз тәртипләрен урнаштырдылар. Урта Азиядә, Бакуда инглизләр хуҗа була башладылар.

1918 елның 2 маенда Антантаның верховный советы аерым чех-словак корпусын Советлар Төньягында һәм Себердә интервенция көчләренең авангарды итеп кулланырга карар бирде. Империалистик сугышта Россиягә әсир төшкән Австро-Венгрия армиясе солдатларыннан Вакытлы хөкүмәт тарафыннан төзелгән бу корпус Брест солыхы шартлары буенча Франция армиясенең өлеше итеп танылган иде. Халык комиссарлары Советы карары нигезендә Франциягә кайтару өчен 60 эшелонда Ерак Көнчыгышка җибәрелгән бу корпус Пензадан Владивостокка кадәр арада хәрәкәтен туктатып, Советлар властена каршы коралды фетнә күтәрә. Пенза тирәсендә тупланган 5 меңгә якын фетнәче Урта Идел буе шәһәр-авылларына куркыныч сала. 30 майда Пенза, 8 июньдә Самара алар кулына төшә. Биредә интервентлар штыклары ярдәмендә нигездә уң эсерлардан төзелгән Учредительное собрание членнары комитеты (Комуч) үзен «Россиядә иң югары власть органы» дип игълан итә. Комуч, Самарада Советлар властен бетереп, Октябрь революциясенә кадәр булган шәһәр думасын, земство идарәсен аякка бастыра, завод-фабрикаларны элекке хуҗаларына кайтара, үзенең властен ныгыту һәм Советлар властена каршы көрәшне киңрәк җәелдерү өчен ирекледәрдән һәм мобилизация юлы белән «халык армиясе» төзи башлый.

Интервенция, гражданнар сугышы яшь Совет республикасы өчен иң авыр шартларда башлана. Иске армия таратылган, ирекледәрдән генә төзелеп килүче Кызыл Армия илне урап алган дошман боҗрасына каршы торырлык түгел, һәм ул боҗра кысылганнан-кысыла бара. Илдә ачлык хөкем сөрә.

Интервентларның эчке контрреволюция белән бергә башлаган походы Советлар властенең яшәвенә зур куркыныч тудыра. В. И. Ленин җитәкчелегендәге Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте дошманны тар-мар итү, Бөек Октябрь казанышларын саклап калу өчен бөтен көчне тупладылар, гадәттән тыш чаралар күрделәр. Кызыл Армияне мобилизация юлы белән тулыландыруга күчү, интервентларга һәм акгвардиячеләргә каршы көрәшүче совет гаскәрләренә җитәкчелекне үзәкләштерү өчен Көнчыгыш фронт оештыру һәм бу фронтны мөмкин кадәр көчәйтү, урыннарда хәрби частьлар оештыруны тизләтү һәм башкалар — шундый чаралардан.

Кызыл Армия частьлары оештыру Казанда да киң колач ала. 1918 елның язында ук биредә пехота, артиллерия, хәрби флотилия частьлары, шулар исәбеннән 1 нче мөселман социалистик полкы төзелеп, ак чехлар фетнәсе башлангач, алар үзләреннән сугышчылар, корал биреп, алардан шактый көчле дүрт кушма отряд оештырылып фронтка озатылалар.

20 июньдә Көнчыгыш фронтның Революцион хәрби советы һәм штабы Казанда хәзерге Бауман урамындагы «Казан» кунакханәсе бинасында урнашалар.

Ак чехларга һәм акгвардиячеләргә каршы кискен көрәш барган көннәрдә Мил-

ләтләр эшләре буенча халык комиссариаты председателе һәм бу комиссариат янында оештырылган Үзәк мөселман хәрби коллегиясе председателе Мулланур Вахитов татар, башкорт һәм башка төрки халыкларны бу изге көрәшкә туплауга күп көч куя. «Известия ВЦИК» газетасында 13 июньдә, Казанда чыга торган «Знамя революции», газетасында 16 июньдә басылып чыккан «Барлык мөселман комиссариатларына» мөрәҗәгатендә М. Вахитов мөселман пролетариатын Советлар республикасы кичерә торган куркыныч моментта аны саклар өчен көрәшкә бердәм күтәрелергә өндәде.

15 июньдә «Правда» газетасында, 19 июньдә «Чулпан» газетасында Халык Комиссарлары Советының Хәрби эшләр буенча халык комиссариатының һәм Үзәк мөселман комиссариатының «Барлык мөселман хезмәт ияләренә» мөрәҗәгате басылып чыга. Проектын М. Вахитов язган бу гаять әһәмиятле һәм мөһим хөкүмәт документында түбәндәге сүзләр дә бар:

«Үзен җиңдерми торган баһадир революционный мөселман гаскәрләре Россиянең төрле урыннарыннан ялкынлы ташкыннар булып эшче вә ярлы крестьяннарның хакимиятен сакларга агылсыннар.

Яңа бөек тәкъдирләргә таба күзен ачкан мөселман пролетариаты революция тарихының хәятендә мактаулы, баһадирлыклы сәхифәләр ачар дип без бик нык ышанабыз».

Мәскәүдә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе тарафыннан оештырылган 1 нче татар-башкорт пехота батальоны 15 июньдә Казанга килә. Бу батальон киткәннән соң Мәскәүдә 2 нче мөселман социалистик батальоны төзелә башлый.

18 июльдә Үзәк мөселман комиссариатының баш коллегиясе утырышында М. Вахитов Идел буенда ак чехлар һәм акгвардиячеләр белән барган кискен сугышның алгы сафларында булу кирәклеген, шуның өчен дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясен Казанга күчерүнең зарурлыгын күрсәтә. Баш коллегия М. Вахитов тәкъдимен кабул итә.

23 июльдә Халык Комиссарлары Советы утырышында М. Вахитов азык-төлек буенча гадәттән тыш комиссар итеп билгеләнә. 25 июльдә В. И. Ленин имзасы белән бирелгән мандатта М. Вахитовка Казан губернасы районнарында ашлык һәм башка азык йөкләрен әзерләү һәм озату буенча зур вәкаләтләр бирелүе әйтелә. 1 августта В. И. Ленин кул куйган таныклыкта М. Вахитовның Халык Комиссарлары Советы тарафыннан мөселманнар яши торган урыннарга (Идел буена, Уфа, Оренбург һәм башка губерналарга) җибәрелүе язылган.

Укучыларга тәкъдим ителә торган документ М. Вахитов һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең башка членнарының ак чехлар керер алдыннан Казандагы эшчәнлеге, коллегиянең Көнчыгыш фронт командующие И. И. Вацетис белән мөнәсәбәте, дошман кулында калган шәһәрдәге хәлләр, М. Вахитовның әсирлеккә эләгүе һәм һәлак булуы турында кайбер яңа мәгълүматлар бирә. Аның авторы — М. Вахитовның якын туганы (этисенең энесе) һәм көрәштәше Нәбиулла Гәрәй улы Вахитов (1886-1974).

Бу документ Мәскәүдә Совет Армиясенең Үзәк дәүләт архивындагы Хәрби эшләр буенча халык комиссариаты фондында шушы юлларның авторы тарафыннан табылган иде. Матбугатта беренче мәртәбә чыга.

Доклад 1918 елның 10 сентябрендә язылган. Нәкъ шушы көнне Кызыл Армия гаскәрләре Казанны дошманнан азат итәләр.

Илдус **ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН**,
тарих фәннәре кандидаты

**Хәрби эшләр буенча халык комиссары урынбасары Э. М. Склянскийга Казанның интервентлар һәм акгвардиячеләр тарафыннан алынуы һәм коллегия председателе М. М. Вахитовның әсирлеккә төшүе турында[1]**

**Үзәк мөселман хәрби коллегиясе члены Н. Г. Вахитовның доклады Күчермәсе — Комиссариатның оператив бүлек начальнигы С. А. Араловка.**

**10 сентябрь 1918 ел.**

Шушы елның 2 августында председатель Мулланур Вахитов, членнары Маликов[2] һәм Нәбиулла Вахитов иптәшләр, хәрби җитәкче Ловчицкий иптәш составында Үзәк мөселман хәрби коллегиясе 2 нче социалистик мөселман батальоны кызылармиячеләре отряды, Коллегия хезмәткәрләре һәм «Кызыл Армия»[3] газетасы сотрудниклары белән Казанга китте.

4 августта Казанга килеп җиттек. 5 августта 1 нче мөселман социалистик полкы командиры иптәш Алимов[4] һәм Татар-башкорт батальоны командиры иптәш Гобәйдуллин[5] катнашындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясе киңәшмәсендә Татар-башкорт батальонын полкка әйләндерү эшенә кичекмәстән тотынырга карар чыгарылды. Киңәшмәдә катнашучылар бәйләнеш урнаштыру һәм хәбәрләшү өчен Көнчыгыш фронт штабына юнәлделәр. Фронт командующие иптәш Вацетис[6] белән сөйләшүләрдән соң аның мөселман пролетариатын фронтка, мөселман буржуазиясен тыл эшләренә мобилизацияләргә ризалыгы алынды.

Көнчыгыш фронт командующие иптәш Вацетис белән сөйләшүләрдә якындагы киләчәктә Казанга дошман кулына төшү куркынычы янамавы билгеле булды.

5 августта Тәтештән пароход белән килгән Үзәк мөселман комиссариаты баш коллегиясе члены иптәш Казаков[7] Тәтешнең һәм Богородск (хәзерге Кама Тамагы — И. Г.) авылының чехословаклар тарафыннан алынуы, үзенең Казанга Трофимовский отряды[8] белән килүе, Казанга килүче пароходларның дошман пароходларыннан эзәрлекләнүе турында сөйләде.

5 августта кич дошман пароходлары Казан пристанена[9] якынлашып, аңа ата башладылар. Бу һөҗүм кире кайтарылды. Татар-башкорт батальонының политик комиссары һәм командиры Гобәйдуллинның донесениесе буенча батальонның пристаньне саклаучы бер отряды дошман һөҗүмен кире кайтаруга актив катнашкан.

6 августта ашыгыч чакырылган җыелышта полклар каршында вербовка комитетлары төзү, мөселман офицерларын мобилизацияләп, аларны конструкторлар итеп билгеләү турында кичектермичә приказ чыгару; мөселман ярлыларын Кызыл Армия сафына чакыру өчен күпләп агитаторлар тарату; ашыгыч рәвештә өндәмәләр чыгару; Казанны ныгыту өчен гадәттән тыш чаралар күрү турында карар кабул ителде. Өндәмәләр һәм боерыклар чыгару иптәш Габидуллинга[10] (Түбән губернасы мөселман комиссариаты председателе) йөкләтелде. Мине вербовка оештыру буенча ике сметаны раслату һәм хәбәрләшү өчен Көнчыгыш фронт штабына җибәрделәр. Иптәш Вацетис сметаларны раслый һәм акча бирдерә. Фронттагы хәл турында минем сорауга иптәш Вацетис Казанга бернинди дә куркыныч янамый, Казаннан 25-30 чакрым ераклыктагы утрауга (исемен хәтерләмим) дошман зур булмаган десант төшергән, без ул «кыюларны» акылга утырту өчен бер отряд җибәрдек, диде. Кичке алтынчыларда мин штабтан чыгып, безнең коллегия урнашкан комиссариатка[11] юнәлдем. Комиссариатка килгәч, мин безнең бухгалтер иптәш Ивановны гына очраттым. Безнең коллегия кайда, дип соравыма ул иптәш Каспранский (Мөселман коммунистлары комитеты председателе) килгән иде, чехословакларның шәһәргә кереп Суконная бистәсен һәм Крестовниковлар заводын (хәзер М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинаты.— И. Г.) алуларын әйтте, диде. Иптәш Иванов коллегия членнарының бу хәбәрне ишеткәч таралуларын, миңа «үзбилгеләнергә» кушып калдыруларын җиткерде. Хәрби җитәкче иптәш Ловчицкийдан башкаларның квартиралары булмаганлыктан, мин аның квартирасына юнәлдем. Бу вакытта урамнарда сугыш бара иде. Иптәш Ловчицкий квартирасына килгәч мин коллегия председателе Мулланур Вахитовның 3 нче Тау урамына әтисе квартирасына (хәзер Калинин урамы, 67 йорт, 4 квартира.— И. Г.) киткәнлеген белдем. Миндә үзем белән югарыда әйтелгән смета буенча Көнчыгыш фронт штабыннан алынган 84000 сум акча бар иде, 21 сәгатьтә, иптәш Ловчицкий янында вакытта Воскресенская урамы (хәзерге Ленин урамы.— И. Г.) ягыннан музыка тавышы ишеттем. Хәрби тәҗрибәм буенча дошманның гадәттә төнлә шәһәргә кермәвен белгәнлектән, безнең гаскәрләр дошман һөҗүмен кире кагып, музыка белән кайтып киләләр дип уйладык. Иртән-иртүк мин акчаны алдым да, квартирмейстер иптәш Полторжицкий белән бергә 3 нче Тау урамына коллегия председателе янына киттек. Поплар Тавы (хәзерге Тельман.— И. Г.) урамында кы армиячегә ошаган бер солдатны күрдек тә, аннан мөселман комиссариатына барып җитәргә буламы, дип сорадык. Ул белмим, мин бүген төнлә генә килдем, дип рус телен ватып-җимереп, җавап бирде. Без аны латыш укчысыдыр, дип уйладык. Почта барып җиткәч, фуражкасында акгвардияче значогы булган часовой солдатны күрдек. Акгвардиячене күрүгә без кирегә борылган идек, безнең маневрны күргән часовой «Туктагыз, монда килегез», дип кычкырды. Без аңа якынлаштык. «Нәрсә алып барасың», дип сорады. «Мин банк кассиры, банкка акча алып барам», дидем. «Андый акча белән урамда йөри торган вакыт түгел»,— дип ул шелтәләде, мине кире борып җибәреп бик гаҗәпләндерде.

Бу вакыт урамнарда патрульләр күренә башлады. Зур акча белән артык баруның куркынычлыгын аңлап (һичшиксез мине кулга алырлар иде), йортлары яныннан узганда танышларыма кереп, акчаны, саклауларын үтенеп, аларда калдырып чыктым, кичен кереп алырмын, дип уйладым.

Акчаны калдырып, шәһәрнең капма-каршы ягына, 3 нче Тау урамына киттем, шунда председательне очратырмын, дип исәпләдем.

Бу вакытта урамнарда атулар, комиссарларга, кызылармиячеләргә һәм совет работникларына урам судлары бара иде. Әтисенең квартирасында председательне (М. Вахитовны.— И. Г.) туры китереп, без аның белән бергә чыгып киттек, чөнки чехословакларның безне эзләп монда килүләре бик ихтимал иде.

Урамга чыккач, без икебез ике якка юнәлдек. Беркадәр вакыттан соң (2—3 сәгатьләр үткәч) мин иптәш М. Вахитов белән Кабан күленнән ерак түгел Болак буенда очраштым. Бирелән ул миңа таныш булмаган Зәйнетдин исемле бер татар белән көймәдә Кабан күле буйлап китте»[12].

Яшеренер урын эзләп озак азаплангач, иптәш С. Саинов мине Апанаевлар кунак йорты (хәзер Париж Коммунасы урамы, 12 йорт — И. Г.) ишегалдындагы кер киптерә торган сарайга урнаштырды. Биредә мин ашамыйча-эчмичә өч тәүлек утырдым. Дүртенче тәүлек киткәч, хатын-кызларның кер эләргә килүләреннән файдаланып, аларга сиздермичә генә чыктым да, трамвайга утырып Бишбалта бистәсенә, туганым И. Казаков (Үзәк мөселман комиссариаты председателе урынбасары) квартирасына киттем. Анда аның гаиләсе һәм М. Вахитовның әнисе яшиләр иде.

Алар миңа бик көенечле хәбәр — иптәш М. Вахитовның кулга алынуын һәм 1 нче губерна төрмәсенә ябылуын әйттеләр, шулай ук иптәш Вахитовның атылу мөмкинлегенә каршы мөселман эшчеләренең протест белдерүләре турында да сөйләделәр. Бу безне бераз тынычландырды, ләкин буржуазия бөтен «Вахитовлар нәселен» бетерүне катгый рәвештә таләп итә икән, дигән сүзләр киң таралып бара иде.

16 августка кадәр төрмәдән бернинди дә хәбәр килмәде. Шул көнне иптәш М. Вахитов С. Саиновка хат җибәреп, аннан әтисенә һәм әнисенә ашамлык алып очрашырга килергә әйтүен сораган. Иптәш Вахитовның әнисе шунда ук комендант янына китеп төрмәдә улы белән ике очрашуга пропуск алган.

Беренче очрашу 21 августка[13] билгеләнгән иде. Ашамлыкны төрмә идарәсе аркылы һәр көн бирергә мөмкин икән. 21 августка кадәр төрмә идарәсенә ашамлык биреп килендә, аны алганга расписканы бу докладка өстәмә итеп бирәм[14]. 21 августта рөхсәт ителгән очрашуга килгәч, әнисенә иптәш М. Вахитовны төнлә каядыр алып киттеләр, кая, ни өчен икәнлеге билгесез, диделәр. Аның атылганлыгы турында шәһәрдә сүзләр йөрсә дә, әтисе белән әнисенең белешүенә икеле-микеле генә җавап биргәннәр.

24 августка кадәр мин Бишбалта бистәсендә яшерен рәвештә тордым. Ниһаять иптәш Бари Миндубаев (кем икәнлеге билгесез — И. Г.) аркылы 3000 сумга паспорт таптым. Аның өчен үземдә булган бөтен әйберне (сәгатьне, балдакны, өске киемне) сатарга туры килде. Иске, алама кием табып киеп, сатып алган паспорт буенча Самарага (хәзерге Куйбышев — И. Г.) пропуск алып, 25 августта иптәш Бари Миндубаев белән пароходка утырып киттек.

Самарада Хвалынскига бару өчен пропуск алдык. Без барып җитәр алдыннан Хвалынск безнең гаскәрләр тарафыннан утка тотылган, шәһәрдә янгын чыккан, паника күтәрелгән, шәһәрдән качу башланган, акгвардиячеләрнең 18 яшьтән 35 яшькә кадәр ир-егетләрне хәрби хезмәткә чакыру турындагы приказына буйсынып, бераү дә регистрациягә килмәгән. Шул ыгы-зыгыдан файдаланып без, бернинди дә рөхсәт сорап тормыйча, Вязовая авылына киттек. Вязоваядан Кулатка станциясенә, Кулаткадан уравыч юл белән, фронт сызыгын читтә калдырып, Вольскига бару өчен Поселки авылына юнәлдек. Кешеләрдән сорашканнан соң Поселкида акгвардиячеләрнең кичә булганлыгы беленде. Биредә төн уздыргач, иртән ниндидер гаскәрнең авылга керүе күренде. Безнең шатлыкка каршы, ул Вольск партизан отряды булып чыкты. Биредә без үзебезнең кызылармияче иптәшләр тарафыннан кулга алындык. Безне гади татар сәүдәгәрләре дип белеп азат иттеләр, Вольскига кадәр пропуск бирделәр. Аннан Саратовка кадәр без ялган паспортлар белән бардык. Саратовта мөселман комиссариатыннан таныклык һәм пропуск алып Мәскәүгә киттек. Мәскәүгә 7 сентябрьдә килеп җиттек.

Коллегиянең башка членнарының язмышы билгеле түгел[15].

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе члены
Н. Вахитов

Искәрмәләр:

[1] Совет Армиясенең Үзәк дәүләт архивы, 1 фонд, 2 тасвирлама, 150 эш, 2—4 бб.

[2] Һади Кәрим улы Маликов (1897—1974) турында кара: Көрәштәшләр: (Мулланур Вахитов һәм аның көрәштәшләре турында истәлекләр һәм мәкаләләр.) Казан, 1972, 146—154 бб.

[3] Докладта ялгыш «Кызыл байрак» дип язылган.

[4] Нурмөхәммәт Нигман улы Алимов (1892—1964) турында кара: Илялов Р. Батыр уходит в легенду. Казань, 1984.

[5] Мөхәммәтсафа Бакый улы Гобәйдуллин (Корбанаев) (1885—1959) турында кара: Халык бәхете өчен көрәшүчеләр. Казан, 1970, 269—272 бб.

[6] Иоаким Иоакимович Вацетис (1873—1938) Көнчыгыш фронтының командующие итеп РСФСР Халык Комиссарлары Советы 1918 ел 12 июль карары нигезендә билгеләнә. Аның турында кара: Голубев А. В. Первый Советский Главком И. И. Вацетис.— Военно-исторический журнал; 1972, 2 сан, 72—83 бб.

[7] Исхак Мостафа улы Казаков (1876—1939) турында кара: Халык бәхете өчен көрәшүчеләр: Икенче китап. Казан, 1985, 171—174 бб.

[8] Сембер ягыннан килүче дошман походларын тоткарлау өчен И. И. Вацетис Кама тамагына хәрби пароходларда отряд җибәрә. Ләкин дошман ягыннан ату тавышлары ишетелү белән отряд начальнигы Трофимовский чигенергә приказ бирә, үзе «Миссури» пароходында Чабаксарга кача, Казанга һөҗүм итәр өчен дошманга су юлын ача. Соңыннан Трофимовский кулга алына һәм суд карары буенча атыла. Кара: Литвин А. Л., Мухарямов М. К. Решающий рубеж. Казань, 1978, 59 б.

[9] Казан пристане ул вакытта Ерак Устьеда иде. Куйбышев сусаклагычы барлыкка килгәч, бу урын су астында калды.

[10] Хаҗи Заһидулла улы Габидуллин (1896—1940) турында кара: Халык бәхете өчен көрәшүчеләр: Икенче китап. Казан, 1985, 54—60 бб.

[11] Сүз Казан губернасы мөселман комиссарияты турында бара. Ул Лобачевский урамындагы Стахеев йортында (хәзер 9 нчы йорт) урнашкан була.

[12] М. Вахитовның туганнан туган энесе Солтан Саинов 1955 елда язган истәлекләрендә көймәгә өчәүләп утырып Борисково авылы ягына китүләре турында күрсәтә. Кара: Мулланур Вахитов: Жизнь и деятельность пламенного революционера-ленинца. Казань, 1985, 104 б.

[13] М. Вахитов 19 август таңында Кремль стенасы янында атыла.

[14] Расписка юк.

[15] Үзәк мөселман хәрби коллегиясе члены һ. К. Маликов Казанда үзенең танышларында яшеренеп кала (кара: Нафигов Р. И. Мулланур Вахитов: (Историко-биографический очерк). Изд. 2-е. Казань, 1975, 202 б.). Коллегиянең гаскәр оештыру бүлеге мөдире М. Г. Конов Арчага барып чыга, татар авылларында йөреп, ирекледәрдән отряд оештыра һәм 2 нче армиянең В. М. Азин җитәкчелегендәге Уң группасы составында үз отряды белән Казанны азат итүдә катнаша (Кара: Көрәштәшләр: (Мулланур Вахитов һәм аның көрәштәшләре турында истәлекләр һәм мәкаләләр). Казан, 1972, 197 б.). Коллегиянең хәрби җитәкчесе С. Ловчицкий Советлар властена хыянәт итеп, ак чехлар ягына чыга.



*Татар халык*
*музыка уен кораллары*

# БЫРГЫ


Быргы — тынлы уен коралы. Төзелеше буенча ул бик гади. Килеп чыгышы буенча да иң борынгы уен коралларының берсе. Борынгы быргылар ике өлештән торган: тавыш сыбызгысы һәм тавыш көчәйткеч.

Быргы көнкүрештә төрле максатларда кулланылган: ау өчен — аучы быргысы, сугыш максатлары өчен — сугыш быргысы, көтүче быргысы һәм башкалар. Соңга табарак быргы музыка уен коралы буларак камилләштерелгән.


Татарлар арасында быргының берничә төре бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Аучы быргысы Татарстанның Балтач, Мари АССРның татарлар яши торган Мари-Төрек, Бәрәңге районы авылларында, ә көтүче быргысында уйнаучылар Минзәлә, Әгерҗе һәм башка районнарда очрый.

Аучы быргысы — исеменнән үк күренеп торганча, ау максатлары өчен кулланылган. Халык авыз иҗаты әсәрләреннән күренгәнчә, поши, болан, бүре кебек киек җәнлекләргә ялган аваз биру, төрле кошлар булып сайрау аучылар өчен бик әһәмиятле булган. Ауның уңышлы яки уңышсыз бетүе уен коралының сыйфатына, уйнаучының башкару осталыгына бәйле. Шуңа күрә дә быргыны аучы һәр сезон саен яңартып, камилләштереп торган. Аучылар быргы ярдәмендә бер-берсенә төрле хәбәрләр биргәннәр, аны җәнлекләрне куркыту өчен дә файдаланганнар. Аучы быргысы ясауның берничә ысулы билгеле: апрель, май айларында агач суты ага башлагач, каен агачының шома, ботаксыз урыныннан 50-70 мм киңлектә һәм метр чамасы озынлыктагы спираль формасында каен тузы телеп алына. Аның ике ягын да яхшылап чистарталар, әзер тасманы агачтан юнып ясалган конуссыман калыпка тыгыз итеп чорныйлар. Калыпның бөгелгән зур мөгез формасында ясалганнары да очрый. Каен тузының өске ак ягы быргының эчендә калырга тиеш.

Түбәндә аучы быргысының рәсеме бирелә.



Быргының нәзек башына сыбызгы өлешен ясап киертеп куялар. Аны ясау өчен шундый ук каен тузы алына. Аны тагын да юкартып 40 мм киңлектә, 30 мм биеклектә кисеп алалар. Түбәндәге рәсемдә күрсәтелгәнчә, урталай бөклиләр һәм өске ягын түгәрәкләп кисеп алалар.



Аучы быргысы төрле зурлыкта ясалган: озынлыгы 150 мм дан 500 мм га кадәр. Сыбызгы өлеше беркетелә торган нәзек башының диаметры 15 мм-20 мм, ә икенче юан башының диаметры 40-100 мм га кадәр булган.

Башкарыла торган сигналга карап, аучы быргысының ике-өч тишеме булган. Тавышы билгеле бер тональностька — тавыш югарылыгына көйләнелмәгән.

Сыбызгы өлешен кош каурыен яки кипкән камышны кыеклап кисү юлы белән дә ясарга мөмкин. Соңгы вакытта аучы быргысы бөтенләй дип әйтерлек кулланудан төшеп калган. Аны хәзерге көндә фольклор ансамбльләре составында кулланырга була. Тавыш үзенчәлеген бетермичә, уйнау мөмкинлекләрен арттыру өстендә күп эшләргә кирәк әле. Аучы быргысы үзенең үзенчәлекле, көчле тавышы белән музыка сөючеләргә шатлык өстәп, культура сарайларында, бәйрәмнәрдә еш яңгырар дип ышанасы килә.

Кояшлы, тыныч авыл иртәсе. Һәр йортта диярлек яшь киленнәр, кызлар сыер саварга әзерләнә. Шулвакыт авылның бер башыннан көчле, ачык тавышлы көтүче быргысы хәбәр сала. Хуҗабикәләр, мал-туарлар әлеге хәбәрне инде күптән көтә. Шулай итеп, иртәнге кояш белән хуҗалык көтүе юлга хәзерләнә.

Бу күренеш революциягә кадәр авылларда һәр көнне диярлек кабатланып торган.


Әйе, авылның йөзе үзгәрә. Тормыш алга бара. Күп кенә гореф-гадәтләр, көнкүреш кораллары акрынлап көндәлек кулланудан төшеп кала, онытыла.

Ләкин без аларны булдыра алган кадәр сакларга, онытылганнарны яңадан тормышыбызга кайтарырга тиешбез.


**Көтүче быргысы** ике өлештән тора: сыбызгы һәм мөгез өлеше.


Сыбызгы өлешен элеккеге осталар берничә ысул белән ясаганнар.

БЕРЕНЧЕ ЫСУЛ. Җептән бушаган кәтүкне нәкъ урталай кисеп һәм киселгән башын аз гына очлап мөгезгә тыгыз итеп кидерәләр. Ә киң түгәрәк башын ике яктан тигез итеп телергә кирәк. Аңа каен тузыннан яки үлән кыягыннан, ә соңгы елларда резина материаллардан 4-5 мм киңлектә яры тарттырып бәйлиләр.



ИКЕНЧЕ ЫСУЛ. 60-80 мм озынлыкта, эчке диаметры 5-7 мм лы кош каурые яки камыш сабагы кисеп алына. Ябык башыннан 40-50 мм озынлыкта тел ясала. Уйнаганда тел өлешен тулысынча авызга кабып бетерергә кирәк. Чөнки өргәндә тел иркен тибрәлеп торырга тиеш. Каурыйның яки камышның ачык башын тыгыз итеп мөгезгә киертеп куялар. Мөгез өлешен ясау өчен сыер мөгезе алына. Аны яхшылап чистарталар һәм нәзек, очлы башыннан эчке тишеме чыкканчыга кадәр кисеп кыскарталар. Сыбызгы өлешен киертеп кую өчен кирәкле зурлыктагы оя әзерлиләр.





Соңгы елларда көтүче быргысы күпмедер дәрәҗәдә камилләштерелде. Мәсәлән, мөгезгә сорнай мөштеген кигезеп куйсаң, быргының тавышы бермә-бер көчлерәк, чистарак яңгырый, билгеле бер тональностька көйләргә җиңелрәк һәм тавышының яңгырау үзенчәлеге дә элеккечә кала.

Көтүче быргысында тишемнәр булмый, тавыш югарылыгы бер генә төрле. 'іе. вышның тембрын мөгезенең эченә уң кулның урта һәм имән бармакларын тыгь көйлиләр. Мондый быргыда ритмик бизәкләүләр яхшы башкарыла.

Быргыны билгеле бер тавыш югарылыгына көйләү өчен башта сыбызгы өлеш аерым гына көйлиләр. Ул безгә кирәкле тавыш югарылыгыннан аз гына югарыр булырга тиеш.

Аннан соң мөгезгә сыбызгыны киертеп көйлиләр. Әгәр тавыш әз генә түбән бу са, мөгезнең нәзек очыннан кисеп кыскартырга, йә киң башын бизәкләп кыеп алы га мөмкин, яисә мөгезнең янына тишем тишәргә була.

ӨЧЕНЧЕ ЫСУЛ. Бу төр быргыларның көчәйткеч өлеше мөгездән ясалмый. Эле рәк аларны аучы быргысы кебек каен тузыннан яки юкә кайрысыннан төреп ясаган булсалар, соңгы вакытларда 4-6 мм лы калайдан ясыйлар. Нәзек башының эчк диаметры 10-12 мм, ә киң башының диаметры 90-110 мм. Озынлыгы 500-600 мм. Сыбызгы өлешен ясау өчен җептән бушаган кәтүк алына. Бер башының киң өлеше кисе алына һәм азрак очлап быргыга тыгыз итеп киертеп куела. Ә икенче башындагы түгәрәк өлеше шул килеш кала. Ләкин, эчке тишеменең диаметрын 5-6 мм тирәнлектә аз гына киңәйтергә кирәк. Сыбызгы урынына хәзерге быргы (горн) мөштеген файдаланырга мөмкин.

Бу төр быргының тавыш югарылыгын билгеле бер тональностька көйләү өчен башта төп тональностьны табарга кирәк. Ул быргының озынлыгына һәм диаметрына бәйле. Аннан соң инде тишемнәрне тишәләр. Тавышы кискен — көчле, үзенчәлекле. Яңгырау көче ике фортега кадәр.

Безгә билгеле булган тынлы музыка уен кораллары да шушы ысуллардан чыгып камилләшкәннәр. Мәсәлән, торба, кларнет-саксафон, гобой һәм алар семьялыгына кергән башка уен кораллары. Ләкин, һәр халыкның гасырлар буе формалашкан үзенә генә хас моңы, үз тембры, үз бизәкләүләре бар. Аларны хәзерге камил уен кораллары гына алмаштыра алмый.


Ринат ГЫЙЛӘҖЕВ,

Татарстан АССР Культура министрлыгы
фәнни-методик үзәк директоры.

# ӨЧЕНЧЕ ДӘРЕС

*Нигә икән безнең Рөстәм*
*Сөйләшергә өйрәнми?*
*Әллә инде безнең белән*
*Дус булырга теләми.*

*Сөйләшик әйдә, Рөстәм,*
*Син бит инде зур үскән.*
*Синең кебек Гөлкәй әнә*
*Сөйләшә инде күптән.*

Әминә Бикчәнтәева

Баланы телгә өйрәткәндә иң беренче чиратта аның сүзлек маясын даими арттыру, билгеле күләмдә сүзләр байлыгын булдыру өстендә эшләргә кирәк. Бала белән һәр шөгыльләнүдә (һәр дәрестә) кимендә 4-5 сүз өйрәтү күздә тотылырга тиеш. Шул ук вакытта алдагы дәрестә өйрәнгән сүзләрне дә һәрвакыт кабатлап торырга, аларны баланың сөйләменә кертә барырга кирәк. Сүзләр яхшырак истә калсын өчен, алда әйтелгәнчә, исеме аталган предметларның үзләре яки аларның рәсемнәре күрсәтелә, сүз кат-кат әйтелә. Русча тәрҗемәсен дә китерергә мөмкин. Бала теге яки бу сүзне, аның төгәл мәгънәсен аңлап үзләштереп калсын өчен, түбәндәгечә тел күнекмәләре үткәрергә мөмкин.

— Бу нәрсә?
— Бу — алма.
— Бу алмамы?
— Әйе, бу — алма.
— Бу алмамы? (Помидор күрсәтелә).
— Юк, бу алма түгел, бу — помидор.

Шулай ук сүзләрне әкренләп сөйләмдә куллана башларга, ягъни гади генә булса да җөмләләр төзергә кирәк. Мәсәлән: Бу — алма. Ул бик тәмле. Бу — туп. Ул түгәрәк (тәгәрәтеп күрсәтелә).

**Авазларның дөрес әйтелеше.** Узган дәресләрдә без **а о ө ү** (өстәл, үрдәк) сузык авазларының һәм **к** (қ) **г** (ғ) тартыкларының дөрес әйтелеше турында сүз алып барган идек. Бу авазларны баланың ничек әйтүенә һәрчак игътибар итәргә кирәк. Бу дәрестә **е** (э) сузык авазының һәм **ж, ч** тартыкларының ничек әйтелешен махсус өйрәнербез. Без русча да, татарча да бер үк хәрефләрдән файдаланабыз. Ләкин һәр телнең авазлары, аларның сыйфаты үзенчәлекле. Мәсәлән, түбәндәге сүзләрдә бер үк **е** хәрефенең әйтелешенә игътибар итегез.

| *русча* | *татарча* |
|---|---|
| теремок | тере (шаян) малай |
| телефон | татар теле |

Татарча е бик кыска, авызны киң ачмыйча әйтелә, мәсәлән, рус телендәге тише, хуже сүзләрендәге кебек. Ә русча е авызны киңрәк ачып, озынрак әйтелә.

Татар әдәби телендәге **ч** авазы да русча **ч** дан шактый нык аерыла. Русча бу аваз шактый көч куеп, шартлап әйтелә (аффрикат), ә татарча бик йомшак, өрелеп кенә әйтелә — чана, чаба, кача.

**Җ** авазы да шундый ук йомшак, авызны йомар-йоммас әйтелә торган аваз:

Җырлый-җырлый Нәҗия
Урманда җиләк җыя.
Сызганган ул җиңнәрен,
Үзә кура җиләген.
Кайсыларын Нәҗия
Авызына да җыя,
Җыя-җыя-җыя да
«Ау-у»,— дип кычкырып куя.

Бари Рәхмәт

Бу дәресебезне дә без уенчыклар янында үткәрәбез. Түбәндәге сүзләрне һәм сүзтезмәләрне отып калырга тырышыйк. **Туган көн, котлыйм, бүләк, мә ал, зинһар өчен, рәхим ит.**

Башта уенчыкларның исемнәрен хәтергә төшерәбез, сөйләшеп алабыз. Бу — шар. Бу шар кызыл. Бу — туп. Туп яшел һ. б. Бер һәм берничә предмет сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтелә, аларның исеме берлек һәм күплек санда әйтелә.

| | |
|---|---|
| Бу — курчак | Болар — курчаклар |
| Бу — машина | Болар — машиналар. |

(туп — туплар, шакмак — шакмаклар һ. б.)

«Туган көнгә бүләкләр» дигән уен үткәрәбез.

Айсылуның (курчак күздә тотыла) бүген туган көне. Әйдә, без аңа бүләкләр китерик. Мин — сатучы. Килегез, кибет ачык, мин уенчыклар сатам.

— Сиңа ни кирәк?
— Миңа курчак бирегез әле, зинһар.
— Мә, ал, рәхим ит.
— Рәхмәт, сау булыгыз. (Шулай дәвам ителә).

Айсылуны котларга киләбез.

— Исәнме (исәнмесез), Айсылу!
— Исәнмесез!
— Мин сине туган көнең белән котлыйм. Мә сиңа курчак, ал.
— Рәхмәт, рәхим итегез, утырыгыз.

Куян килә.

— Исәнме, Айсылу! Мин дә сине туган көнең белән котлыйм. Мә сиңа туп, ал. (Уенны шулай дәвам итәргә мөмкин).

Ә хәзер Айсылуны җыр белән котлыйбыз.

Айсылуның туган көненә
Без пешердек ак калач.
Менә шу-ундый зурлыкта,
Менә шу-ундый киңлектә,
Менә шундый ул биек,
Менә шундый тәбәнәк.
Ак калач, ак калач,
Теләгәнең алып кач!

Шигырьләрне укыгыз, әчтәлеген балаларга сөйләп бирегез. **е (э), җ, ч** авазларының дөрес әйтелешенә игътибар итегез.

## Энесенә ул апа

Мөнир Мазунов шигыре

Җырлый-җырлый кыз бала
Энекәшен йоклата.
Биштә генә булса да,
Энесенә ул — апа.

Әлли-бәлли, бәй итә,
Энем йокыга китә.
Әни мәми пешерә,
Әткәйне эштән көтә.

Кошлар кунган тирәккә,
Аларны җил тибрәтә.
Тышта җилләр искәндә,
Бәби йоклый мендәрдә.

Түбәндәге шигырьдә **ч** авазының дөрес әйтелешенә игътибар итегез.

## ЧЕБИЛӘР

Мәхмүт Хөсәен шигыре

Өй алдында чебиләр
«Чип-чип-чип»,— дип йөриләр.
Кечкенә канатлары,
Муеннары сап-сары.
Күпереп тора йоннары,
Ул аларның туннары.
Чеби-чеби-чебиләр
«чип-чип-чип»,— дип йөриләр.
Тары бирмәсәң, диләр,
Чирәм йолкабыз, диләр,
Черки тотабыз, диләр,
Чебен йотабыз, диләр.
Җәй айлары үтәрләр,
Чебиләр дәү үсәрләр,
Шатланырлар, биерләр,
«Без — тавык! — дип йөрерләр.

**Фәһимә ХИСАМОВА,**
филология фәннәре кандидаты,
**Рәшидә БОРҺАНОВА,**
методист.

Газизә Сәмитова

# قلم

عزیزه سمیتووا

قارا ساویتتا تورا
کمش باشلی جیز قلم .
قلمنڭ حزمتی ایله
آغاردی بتون عالم .

ای قلمم ، قلمم !
سڭا اولسن سلامم .
سنڭ قلغان حزمتیگه
یوقتر هیچبر کلامم .

کاغز اوستن قارالتتڭ .
دنیا یوزن آغارتتڭ .
نیچه میلیون نسخه‌لرنی
جیر یوزونه تاراتتڭ .

دیگگز کیچرگه ن- قلم ،
جهان گیزدرگه ن- قلم ،
یارنی ایشوپ ، تاونی تیشوب ،
تاشنی واتترغان- قلم .

توپنی آتترغان-قلم ،
شهر واتترغان-قلم ،
داوچغارسا ، صلح قیلا ،-
شول قلمگه یوز سلام !

عبرت اوچون یازلدی کوب کشیگه
سلام دیدم قلمنڭ بو اشینه .
قلم اوگره ن ، قلم ایزگیگه تارتر ،
قلم بلگه ن کشینڭ بختی آرتر .

## Каләм
(КЫСКАРТЫП АЛЫНДЫ)

Кара савытта тора
Көмеш башлы жиз каләм.
Каләмнең хезмәте илә
Агарды бөтен галәм.
Әй каләмем, каләмем!
Сәңа улсын сәламем.
Синең кылган хезмәтеңә
Юктыр һичбер кәламем.
Кәгазь өстен каралттың.
Дөнья йөзен агарттың.
Ничә миллион нөсхәләрне
Жир йөзенә тараттың.
Дингез кичергән — каләм,
Җиһан гиздергән — каләм.
Ярны ишеп, тауны тишеп,
Ташны ваттырган — каләм.
Тупны аттырган — каләм,
Шәһәр ваттырган — каләм,
Дау чыгарса, солых кыла,—
Шул каләмгә йөз сәлам!

* * *

Гыйбрәт өчен язылды күп кешегә,
Сәлам дидем каләмнең шул эшенә.
Каләм үгрән, каләм изгегә тартыр,
Каләм белгән кешенең бәхете артыр.

*Журнал өчен текстны Җәүдәт МИҢНУЛЛИН
һәм Раиф МӘРДАНОВ әзерләде.*

## Шамил Рәкыйповка — 60 яшь



Шамил Җиһанша улы Рәкыйпов 1929 елда Татарстан АССРның Чүпрәле районы Яңа Чокалы авылында туган.

Аның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре — очерк һәм хикәяләре, нәсер һәм кече формадагы сәхнә әсәрләре матбугатта 1956 елдан күренә башлый. Ш. Рәкыйпов язучы буларак укучыларга үзенең художестволы документаль проза әсәрләре белән киң билгеле. Бу юнәлештә ул алтмышынчы елларда эшли башлый. Авторның әсәрләрен үзәк бер тема берләштерә. Ул тема — Бөек Ватан сугышы һәм аның үлемсез каһарманнары. 1967 елда язылган «Чәчәкләр сөйли белә»— Барый Шәвәлиевкә, 1968 елда язылган «Кайдан син, Жан» — Иван Кабушкинга, 1969 елдагы «Таңнар һаман матурмы?» — Гыйлфан Батыршинга, 1972 елда язылган «Кызлар-йолдызлар» һәм 1975 елда язылган «Кипарислар җыры» Мәгубә Сыртланова һәм аның сугышчан дусларына багышланган. Соңгы елларда ул халкыбызның кыю улы генерал Гордов турында кызыклы әсәр иҗат итте.

Ул — РСФСРның атказанган культура работнигы.

Каләмдәшебезне юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз! Аңа ныклы сәламәтлек һәм яңадан-яңа уңышлар телибез!

## *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



### Нияз Акмалов

Нияз Рәшит улы Акмалов 1954 елда Сарман районының Катыш-Каран авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә югары белем ала. Район газетасында, соңрак «Яшь ленинчы» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли.

Ул — «Учак» исемле шигырьләр җыентыгы һәм «Үз урамым» дип аталган проза китабы авторы.

Бүгенге көндә «Казан утлары» журналы редакциясендә проза бүлеге редакторы булып эшли.

## Әсрар Галиев



Әсрар Әбрар улы Галиев 1938 елның 16 октябрендә Әлки районының Биктимер авылында туган. Бик яшьтән колхозда эшли. Совет армиясе сафларында хезмәт итә. Аннан соң, шахта якларына китеп, шахтерлар арасында эшли; Лениногорск якларына кайтып нефтьчеләр тормышын өйрәнә. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген читтән торып тәмамлый, журналистлык эшен башкара, әдәби әсәрләр яза.

Татарстан китап нәшриятында аның «Төнге җыр» һәм «Асыл кошым минем...» исемле китаплары басылып чыкты.

Әсрар Галиев бүгенге көндә Лениногорскида яшәп иҗат итә.

## Газинур Моратов



Газинур Васик улы Моратов 1959 елда Кукмара районы Зур Сәрдек авылында туа. Урта мәктәп тәмамлагач, 1976—1981 елларда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, югары белем ала. Аннан соң «Татарстан яшьләре» газетасы һәм «Ялкын» журналы редакцияләрендә эшли. Бүгенге көндә ул — «Идел» журналының бүлек редакторы.

1985 нче елда «Җир хәтере» исемле беренче китабы дөнья күрә. Аннары шагыйрьнең 1988 елда «Мин дөньяны тыңлыйм», 1989 елда балалар өчен «Тәмле тел» исемле китаплары басылып чыкты.

1989 елда Г. Моратов СССР Язучылар союзына кабул ителде.

## Миргалим Харисов



Миргалим Харис улы Харисов 1939 елның 16 мартында Актаныш районының Чат авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң Минзәлә педогогия училищесында укый. 1956—1961 елларда Мәскәүдә М. Щепкин исемендәге театр училищесында югары белем ала. Бүгенге көндә «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Миргалим Харисов — балалар өчен язылган «Тәскирә», «Сабыйлар хакына», «Кызыл планетага сәяхәт», «Ватан нидән башлана?» дигән җыентыклар авторы. Соңгы елларда ул әдәби тәрҗемә белән актив шөгыльләнә. Н. Думбадзеның «Мин кояшны күрәм», Г. Шәрипованың «Гафурлар гаиләсе», Л. Гумилевскийның «Зинин» дигән әсәрләрен һәм башка китапларны татар теленә тәрҗемә итте.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

21 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзының ачык партия җыелышы булып узды. Быел татар һәм рус телләрендә чыга башлаган яшьләр журналы «Идел» турында сөйләшүгә багышланган бу җыелышта тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин һәм язучы Солтан Шәмси доклад белән чыктылар. Алар, яңа журнал алдында торган олы мәсьәләләр, максатларга тукталып, үзләренең җитди фикерләрен әйттеләр. Фикер алышуда әдипләр С. Баттал, Г. Бәширов, М. Садри, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Р. Мөхәммәдиев, «Идел» журналының баш редакторы Римзил Вәлиев, Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Г. Зәйнашева, С. Маннапов, Н. Беляев, Ә. Гадел, Н. Акмалов һ. б. катнашты.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

28 сентябрьдә Чаллы язучылар оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Р. Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Ул Кама төбәге әдипләрен республикабыздагы әдәбият-сәнгать яңалыклары белән таныштырды.

Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре итеп сайлау өчен, Түбән Камада яшәүче шагыйрь һәм прозаик Рахмай Хисмәтуллин белән балалар язучысы Рәшит Бәшәр күрсәтелде. Ачык тавыш бирү нәтиҗәсендә, Чаллы язучылар оешмасының яңа җитәкчесе итеп Р. Хисмәтуллин сайланды.

Чаллы язучылар оешмасының отчет-сайлау җыелышында Татарстан Министрлар Советының бүлек мөдире Т. Минһаҗев, партиянең шәһәр комитеты секретаре З. Шаймөхәмматова, халык депутатларының Чаллы шәһәр Советы культура бүлеге мөдире И. Тарханов катнашты. Анда шулай ук КПССның Чаллы шәһәр комитеты секретаре М. Гатин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШЛӘР

27—29 сентябрьдә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының икенче уку корпусында «Милли телләрнең һәм әдәбиятларның үзара бәйләнеше законнарлыгы» циклы буенча конференция узды. Аны кереш сүз белән КДУ проректоры профессор М. Г. Госманов ачты.

Казан галимнәреннән тыш анда Мәскәү, Ленинград, Саратов, Уфа шәһәрләреннән килгән кунаклар да катнашты. Чыгыш ясаучылар арасында Азербайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Украина союздаш республикаларыннан килгән иптәшләр дә бар иде. Конференциядә катнашучылар 5 секциягә бүленеп эшләделәр. Секцияләрдә үзара аралашу, телләрнең бер-берсенә тәэсире, СССР халыкларының төрле телләреннән тәрҗемә итү, милли әдәбиятларның үзара йогынтысы турында җитди сөйләшү барды.

## КИНЕМАТОГРАФИСТЛАР ҖЫЕЛЫШЫНДА

Октябрь башында Татарстан Кинематографистлар союзының чираттагы җыелышына, кинохроника студиясендә эшләүчеләрдән тыш, Казан телевидениесе хезмәткәрләре, төрле иҗат союзлары, культура учреждениеләре вәкилләре дә чакырылган иде. Анда сүз Казанда нәфис фильмнар эшләүче киностудия ачу кирәклеге турында барды. Җыелыш бу мәсьәлә буенча КПССның Татарстан өлкә комитетына, Татарстан Верховный Советы Президиумына һәм Министрлар Советына хат белән мөрәҗәгать итү турында карар кабул итте.

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ БУЛАЧАК

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, Татарстан нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре буенча дәүләт комитетының 1989—2000 елларда күптомлы Татар Совет Энциклопедиясе (татар һәм рус телләрендә) әзерләү һәм бастырып чыгару турындагы тәкъдимнәре Татарстан Министрлар Советы утырышында хуплау тапты. Бу уңайдан Татар Совет энциклопедиясенең фәнни-оештыру советы расланды һәм аңа әлеге энциклопедияне төзү һәм бастыру белән бәйле бөтен фәнни-оештыру эше тапшырылды. Энциклопедияне төзүгә бәйле практик эшләр Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында тупланачак. Энциклопедияне төзүдә, килешү буенча, республикабызның фән учреждениеләре һәм вузлар галимнәре, журналистлар, язучылар, культура эшлеклеләре, укытучылар, крайны өйрәнүчеләр, музей хезмәткәрләре һәм киң җәмәгатьчелек катнаша ала.

Моннан тыш, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында Татар Совет Энциклопедиясе фәнни үзәгенең махсус счеты ачылачак. Теләгән кешеләр, шул исәптән чит ил гражданнары да, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр бу счетка акча күчерә алачаклар. Ә Татарстан министрлыклары һәм ведомстволары, шулай ук производство берләшмәләре, предприятиеләр, учреждениеләр, иҗат союзлары, колхоз һәм совхозлар эн-

циклопедиянең фәнни үзәгенә күренекле шәхесләр, хезмәт алдынгылары, производство объектлары һәм алар чыгара торган продукция турында мәгълүматлар туплауда ярдәм итәргә тиешләр.

Татар Совет Энциклопедиясе томнарын бастыра башлау 1993 елга планлаштырыла.

## ГАЛИМНӘРЕБЕЗ ТӨРКИЯДӘ

Истанбулның Мәрмәрә университеты каршындагы фәнни тикшеренүләр үзәге чакыруы буенча РСФСРның һәм Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, философия фәннәре докторы профессор Я. Г. Абдуллин һәм СССР Язучылар союзы члены, Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Ә. Г. Кәримуллин Төркиядә булып кайттылар. Алар анда Төркиянең социаль һәм экономик тарихына багышланган V халыкара фәнни конгресс эшендә катнаштылар. Я. Абдуллин «Тәнзыймат һәм татар мәгърифәтчелек хәрәкәте: типологик аспект», Ә. Кәримуллин «О. С. Лебедева (Гөлнар ханым) Төркиядә һәм аның мәгърифәтчелек эшчәнлеге» дигән темаларга доклад ясадылар.

Галимнәр Истанбул университеты каршындагы Төркият институтында булдылар һәм Казан университеты профессоры Н. Ф. Катановның анда саклана торган фонды белән таныштылар, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез белән очраштылар һәм чит илләрдә көн күрүче татарлар турында мәгълүмат туплладылар.

## ЭНЦИКЛОПЕДИЯДӘ — ХАЛКЫБЫЗ ТУРЫНДА

Мәскәүнең «Совет энциклопедиясе» нәшрияты күптән түгел «Дөнья халыклары» дигән тарихи этнографик белешмә чыгарды.

Китапта татар халкы турындагы материалларга да киң урын бирелә. Мәгълүм булганча, татарлар Идел буенда гына түгел, ә илебезнең бик күп өлкәләрендә һәм чит илләрдә дә яши. Китапта татар халкының килеп чыгышы, аларның төп шөгыле, һөнәрләре, милли киемнәре, фольклоры һәм башка яклары яктыртыла. Төсле фоторәсемнәр, бай иллюстрация китапны тагын да кызыклырак, күркәмрәк итә.

## ОЕШМА РАСЛАНДЫ

Күптән түгел Пермь шәһәрендә Муллануp Вахитов исемендәге татар-башкорт җәмгать оешмасының беренче өлкә конференциясе булып узды. Анда шәһәрдән һәм татарлар яши торган районнардан 130 делегат катнашты. Оешма рәисе урынбасары докладыннан соң фикер алышуда дистәләрчә делегат чыгыш ясады. Программа, устав һәм резолюция кабул ителгәч, 23 кешедән торган совет сайланды.

Оешманың председателе итеп педагогия институтының соңгы курсы студенты, мәгариф хезмәткәрләре съезды делегаты Рафаил Хәплехәмитов, аның урынбасарлары итеп Мәсгут Иткинин һәм Исрафил Адутов сайланды.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» КӨННӘРЕ

6 сентябрьдә Әлмәтнең яңа ачылган татар дәүләт драма театры бинасында «Казан утлары» көне үткәрелде. Әлмәт шагыйрьләре Гамил Афзал, Клара Булатова, Нур Әхмәдиев, Казан әдипләреннән Мөсәгыйт Хәбибуллин, Марсель Галиев һәм «Казан утлары»ның баш редактор урынбасары Рашат Низамиев журнал укучылары белән очраштылар, аларны татар әдәбияты һәм сәнгате яңалыклары, үз әсәрләре белән таныштырдылар.

7 сентябрьдә шундый ук очрашу Сарман район культура йортында да үткәрелде.

## ТУКАЙ БУЛГАН ҖИРЛӘРДӘ

Хәзерге Ульяновск өлкәсенең Барыш районында татарлар шактый күп яши. Бу төбәк Ш. Усманов, С. Гафуров, Б. Белоусов, Ф. Бурнаш кебек шәхесләрнең исемнәре белән дә бәйле. Алар монда революцион эш белән шөгыльләнгәннәр, әдәби әсәрләрен язганнар. Революциягә кадәр бирелә атаклы Акчуриннарның фабрикалары эшләгән. Бу якларда татар халкының бөек улы Г. Тукай кунакта булган.

7—10 сентябрьдә биредә шагыйрьләр Радиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин яшь шагыйрә Флера Низамова булып китте. Әдипләр байтак кына авылларда булып, чыгышлар ясадылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры артистлары **Венера Ганиевага** һәм **Айдар Фәйзрахмановка**, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 6 июль Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге өчен СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел белеме лабораториясе мөдире, филология фәннәре докторы профессор **Фуат Әшрәф улы Ганиевкә**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 6 июнь Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры концертмейстеры **Людмила Әхмедовага**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 9 июнь Указы нигезендә, **«Татарстан АССРның халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 9 июнь Указы нигезендә, түбәндәге иптәшләргә «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде:

**Равил Идрисовка** — М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры артисты;

**Хәнәви Шәйдуллинга** — Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчысы.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре һәм күп еллар буена нәтиҗәле эшләгәне өчен, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 28 август Указы нигезендә, «Казан утлары» журналы редакциясенең бүлек редакторы, язучы Кояш Тимбиковага «РСФСРның атказанган культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы — Татарстан китап нәшриятының баш редакторы Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов), Татарстан АССР Верховный Советы Указы белән, «Татарстанның атказанган культура хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен, «Казан утлары» журналы редакциясенең тәнкыйть бүлеге редакторы Мансур Вәлиевкә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 6 июль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Республикабыздагы зур бер төзелешнең барышын һәм аның проблемаларын тулырак яктырту нияте белән, безнең журнал 1983 елда Татарстан атом электр станциясен төзүче оешмалар белән иҗади хезмәттәшлек килешүе төзегән иде. Әлеге хезмәттәшлек «Әдәби пост — АЭС» рубрикасында даими яктыртыла килде. Кама Аланында ел саен шигъри митинглар үткәрелде, әдипләрнең байтагы АЭСка иҗади командировкага җибәрелде. Бу иҗади элемтә дистәләрчә язучыларга төзүчеләр тормышын якыннанрак аңларга, экономика һәм экология мәсьәләләрен ныклабрак өйрәнергә ярдәм итте.

Килешүгә кул куйганда редакция, төзелеш җитәкчеләре белән аңгәмәләшеп, АЭСка бәйле күп кенә җитди мәсьәләләрне кузгаткан иде. Еллар үтә торгач, аларның кайберләре кискен проблемага әйләнде. Әйтик, атом электр станциясенең тирә-юньдәге табигатькә тәэсире мәсьәләсе бүгенге көнгә кадәр чишелмәгән килеш кала бирә. Проектта каралганча, Татарстан АЭСы инде 1989 елда илгә электр энергиясе бирә башларга тиеш иде. Ләкин ашыгып, кайнарланып башланган бу эш озын юлга кереп китте. Төзелешнең хәвефсезлеге киң катлам җәмәгатьчелек, шул исәптән әдипләребез һәм укучыларыбыз тарафыннан да шик астына куелды.

Менә шуларны истә тоткан хәлдә, редакция Татарстан АЭСы белән ике арадагы хезмәттәшлек килешүе үзенең көчен югалтты дип саный һәм аны туктатуны кирәк таба.

Республикабызның экологик хәле исә журнал битләрендә алга таба да яктыртылачак.



*Съезд залында. Алдагы рәттә Н. Фәттах, Ф. Миңнуллин, В. Нуруллин.*



*Р. Харис, Г. Ахунов, Р. Мөхәммәдиев.*



*Р. Әхмәтҗанов, З. Мансуров, Р. Фәйзуллин.*



*В. Ганиев һәм Г. Паушкин*



*Ә. Гаффар һәм М. Мәһдиев*



*Съезд залында. А. Әхмәдуллин, А. Гыйләҗев, Ф. Мусин, Ә. Баян.*



*Алдагы рәттә К. Латыйп, Р. Гатауллин, Р. Хәмид.*

**Н. СЕДОВ** фоторепортажы.

# ТУКЫЛГАН РӘСЕМ

Сәнгатьнең бу төре Татарстан җирлегендә чагыштырмача яшь тармаклардан санала. Ул алтмышынчы еллар башында барлыкка килә, төссез һәм бертөрле архитектура корылмаларына нинди дә булса үзенчәлек, аерым бер төсмер бирү җәһәтеннән туа. Чирек гасыр дәвамында бу сәнгать алымы үзенә хас үзгәрешләр дә кичерә, гади геометрик өлгеләрдән башланган сурәтләр әкеренләп табигать күренешләре, милли бизәкләр белән байый бара.

Тукылган рәсем жанрын тудыручыларның берсе — рәссам М. С. Килдебәкова. Ул үз фикердәшләре, үзе кебек үк омтылучан кешеләр — Г. Маликова, А. Егоров белән бергә алтмышынчы еллар азагында Татарстан художество фонды каршында махсус остаханә оештыра. Әлеге остаханәдә тукылган рәсемнәр Казанның күп кенә җәмәгать биналарын — Көнкүреш йортын, «Универсам» ресторанын, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрын һәм башка биналарны бизәүдә файдаланылды. Рәссамнарның һәркайсы үз алымы белән эш итә, үзенчәлеккә омтыла.

Милли традицияләрне чагылдыруда барыннан да бигрәк М. Килдебәкованың уңышлы эшләвен әйтергә кирәк. Ул Әлки, Алексеевск районнарының иң ерак авылларында яшәүче өлкән яшьтәге осталарны — келәм туку серләрен саклап калучы апаларны эзләп тапкан, алардан агач станнарның эш рәтен, келәм, җәймә туку ысулларын, бизәк һәм сурәт өлгеләрен җентекләп өйрәнгән. Үзенең беренче зур хезмәте — «Сабан туе» дигән әсәрендә рәссам әнә шул авыл осталарыннан алган бизәкләрне уңышлы файдаланган. Көмешсу төстәге тукымада татар халкының шушы гүзәл бәйрәменнән сайлап алынган күренешләр — көрәшчеләр, йөгерешчеләр, биюче кызлар сурәте иң килешле төсмерләр аша чагылдырылган.

Милли бизәкләрне, табигать төсмерләрен рәссам үзенең «Күбәләкләр» (тышлыктагы рәсемдә), «Яз», «Торналар» исемле әсәрләрендә дә сизгер куллана. Аларда автор дөньяви чынбарлыкка якынаерга, фәлсәфи уйлануларны иң садә төсмерләр аша гәүдәләндерергә омтыла.

Сиксәненче елларда инде рәссам үзенең иҗади өлгергәнлек чорына керә. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасын бизәгән тукылган рәсемнәр рәссамның еллар дәвамында эзләнеп иҗат иткән әсәрләре. Аларның сызымнарын автор үзенең ире, милли сәнгатьнең бай төсмерләрен аеруча сизгер тоючы кешеләрнең берсе Р. Килдебәков белән бергәләп эшли. Аның һәр әсәре халык тормышының, халык язмышының иң табигый һәм иң нечкә күренешләрен чагылдыра.

**В. ЦОЙ**
Татарстан сынлы сәнгать музее хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** XIX йөздә Казан шәһәре күренешләре. Болак. Шул чор открыткасыннан **Ю. ФИЛИМОНОВ** фоторепродукциясе.

# ЯҢА КОНКУРС

Татар иҗтимагый үзәге милли (татар) укыту-тәрбия учреждениеләрендә укыту һәм тәрбиянең иң яхшы концепциясенә конкурс игълан итә.

Конкурс педагогларның иҗади фикерләвен активлаштыру һәм милли (татар) гомуми белем мәктәпләрендә, шулай ук мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә, ПТУларда һәм югары мәктәптә белем һәм тәрбия бирүнең яңа концепциясен булдыру максатында игълан ителә.

Концепция түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. Ачык максатны.
2. Белем һәм тәрбия бирүнең торышына тәнкыйди анализны.
3. Укыту-тәрбия процессының структурасын, эчтәлеген, форма һәм методларын ачуны.

Яңа концепциянең кайда сынап каралганлыгы да күрсәтелсә иде.

Конкурста җиңүчеләргә:
Беренче премия — 500 сум
Икенче премия (2) — 300 сум
Өченче премия (3) — 100 әр сум.
Хезмәтнең күләме чикләнми.

Жюри составына күренекле укытучы-педагоглар, иҗтимагый фән белгечләре, Татар иҗтимагый үзәге вәкилләре кертелә.


Иң яхшы хезмәтләр басылып чыгачак. Конкурска тәкъдим ителә торган кульязмалар машинкада ике интервал белән 2 данәдә бастырылырга тиеш. Алар 1990 елның апреленә чаклы кабул ителә.

**Адрес: 420111, Казан шәһәре, К. Маркс урамы, 36 йорт, 45 нче бүлмә. Татар иҗтимагый үзәге.**

**Телефон: 39-05-79. Конвертка «Конкурска» дип күрсәтергә.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)